ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

2.2000





КАЮМ НАСЫЙРИ

1825—1902

Казан утлары
Qazan utları

2000

2

(928)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Гариф Ахунов,**
**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## *Бу санда*


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

ЗӨЛФӘТ. Бездән калыр—шигъри сүз генә... *Шигырьләр* ..... 5
Вахит ИМАМОВ. Утлы дала. *Роман* ..... 10
Илдар ЮЗЕЕВ. Заман хисләренә кагылам да. *Шигырьләр* ..... 100
Гариф АХУНОВ. Күз нурым. *Хастаханә көндәлеге* ..... 104

**РАШАТ НИЗАМИЕВКА 50 ЯШЬ**

Рашат НИЗАМИЕВ. Ачам еллар дәфтәрен. *Шигырьләр (М. Шабаев кереш сүзе белән)* ..... 118

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Соңгы өмет. *Хикәя (М. Вәлиев кереш сүзе белән)* ..... 128

**РИМ ИДИЯТУЛЛИНГА 60 ЯШЬ**

Рәдиф ГАТАШ. «Тормыш—хуш исле бер чәчкә...» ..... 134

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Юныс САФИУЛЛИН. Сәхнә әсәрләребез нинди? ..... 138

**МИЛЛӘТТӘШЛӘРЕБЕЗ ЧИТ ИЛЛӘРДӘ**

Рабит БАТУЛЛА. Дәүләтле Надир Дәүләт ..... 145
Надир ДӘҮЛӘТ. Шагыйрь Шаһвәли Келәүли иҗаты ..... 147

**СӘНГАТЬ**

Дамир ГАРИФУЛЛИН. Илһам шәҗәрәсе ..... 154

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Миргазиян ЮНЫС. Бәхетле мескенлек *(Рецензияләр конкурсына.)* ..... 167

**SӘĞIT RӘMİEFNEŅ TUUINA 120 YIL**

Sәğıt RӘMİEF. Taŋ waqıtı. *Şigerlәr* ..... 173

**KİTAP KÜZӘTÜ**

Ənwər ŞƏRİPOF. İgelekle xezmət ..... 175
Мөселман календаре ..... 178
«Казан утлары» архивыннан ..... 179
Укучы сүзе ..... 181
Безнең календарь ..... 183
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 190
Тышлыктагы сурәтләр ..... 192

# В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: В. ИМАМОВ. Продолжение романа «Огненная степь»; Г. АХУНОВ. «Свет очей моих» *(из больничного дневника)*; стихи ЗУЛЬФАТА, И. ЮЗЕЕВА.
«К 50 - летию Р. Низамиева»: стихи юбиляра *(с предисловием М. Шабаева)*.
«Новые имена»: рассказ А. АХМЕТГАЛИЕВОЙ «Последняя надежда» *(с предисловием М. Валиева)*.
«Современник»: статья Р. ГАТАША к 60 - летию поэта Р. Идиятуллина.
«Литературная критика»: статья Ю. Сафиуллина о современной драматургии.
«Татары за рубежом»: статья Н. ДАВЛЕТА «Творчество поэта Шахвали Келаули *(с предисловием Р. Батуллы)*.
«Искусство»: статья Д. ГАРИФУЛЛИНА «Родословная Ильхама» посвящена известному татарскому певцу И. Шакирову.
«Литературная критика»: М. ЮНУС рецензирует короткий роман А. Халима «Татарское время».
«К 120 - летию С. Рамиева»: стихи юбиляра на латинской графике.
«Книжное обозрение»: А. ШАРИПОВ рецензирует книгу Р. Исламова «Золотая Орда и Мамлюкский Египет». (на латинской графике).
Мусульманский календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: фоторепродукция с картины В. Федорова «Г. Камал»; писатель Галимзян Гильманов.

# IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": V. IMAMOV'S novel «Fiery steppe»; verses of ZULFAT, I. USEEV.
"Commemorating the 50th anniversary of Nizamiev": jubileer's verses (with M. Shabaev's preface).
"New names": A. AKHETGALIEVA'S story «The last hope» (with M.Valiev's preface).
"Contemporary": R. GATASH'S article devoted to 60th anniversary of poet R. Idiatullin.
"Literary criticism": U. SAFIULLIN'S articl about modern dramatics.
"Tatars abroad": N. DAVLET'S article «The creative works of poet Shahvaly Kelauly» (with R. Batulla's prefase).
"Art": D. GARIFULLIN'S article «The family tree of Ilham» devoted to famous tatar singer I. Shakirov.
"Literary criticism": M. UNUS'S review of A. Khalim's novel «Tatar's time».
"Commemorating the 120 th anniversary of S. Ramiev": jubileer's verses in latin graphic.
"Book review": A. SHARIPOV'S review of R. Islamov's book «The Gold Arda and the Mamluk Egypt».
The Moslem calendar.
The diary of social and cultural life.
In our covers: the photoreproduction from V. Fedorov's picture «G. Camal»; the writen G. Gilmanov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 21.01.2000 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108¹/₁₆.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8653 Заказ Э-21
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2000 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Зөлфәт

### БЕЗДӘН КАЛЫР—ШИГЪРИ СҮЗ ГЕНӘ...

### Язмыш

Язмыш белән, юк, көрәшмә икән,
Без сөйләдек,
язмыш—дәшмәде.
Хәер, үзе бәхет түгелмени
Җан тулы моң килеш яшәве?

Язмыш белән тарткалашма инде!—
Килә гомер... килә көзенә;
Кемдер
җимерелгән ил калдырыр,
Бездән калыр—
Шигъри сүз генә...

### Эчем яна—тышым яна...

*Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан ядкаре*

Шагыйрьләрчә моңсу да бу табын,
Шагыйрьләрчә шаулы, дуамал,
Өермәле буран дулый тышта—
Тынасы юк, тынмый, тынмаган...

Авызлыксыз һәм тыйгысыз җаннар!
Шагыйрь безне тыеп туктата:
—Мәҗлес мондый булмый, багырләрем!
Җырсыз утырасыз төн ката!

...Богемалы безнең мәгарәне
Тутырып ул үзе җыр суза—
Җыры да бит аның үзе сыман
Шук та, сагышлы да, моңсу да:

—Ак үрдәккә, күк үрдәккә
Җимнәр салдым түмгәккә...
Эчем яна, тышым яна—
Ут кабынмый күлмәккә! Уф!..

Җыр әйтә дә безгә карап тына:
—Сезгә җыр җырлаган мин—дурак!
Беләсезме, нигә шагыйрь булып
Йөрибез бу җирдә каңгырап?

Бүтән юньле эшкә ярамыйбыз!
Тел бар—карга алып китмәскә...
Йә, далада яшәмисез! Тутыр!
Дөнья вагы җирдә бетмәс лә!

Җырлатыгыз юмарт чакта!
Хәер,
Җыр үтәрлек түгел инде сез...
Әмма... тагын болай җырлашулар
Насыйп булыр микән—билгесез...

Ник чүмәштең анда мәрткә китеп?
Касәләрне тутыр, яшь иптәш!
Менә җырның сезгә яраклысы—
Башкасына сезнең баш җитмәс!

—Һәй! Базарда Маручкылар
Саталар саручкылар,
Маручкылар белән йөрсәң
Тиз бетә палучкылар!

—Рәшит абый, үзең сөйлә әле
Баштан узган гыйшык-мыйшыкны!
Син күпләрне кыйшык иткән, диләр,
Һәм төзәткән, диләр, кыйшыкны...

—Син, яшь иптәш, багрем, күпне белмә!
Әйе, кызлар миңа күз атты—
Гомеремә кызлар озатмадым,
Кызлар үзләре гел озатты!

Элек заман кемдер җыр чыгарган—
Әллә мишәр, әллә керәшен—
Кызлар гыйшыгыннан минем сыман
Интеккәндер инде, күрәсең...

Чибәрләрдән туеп елагандыр
Калмаганга күрә һич чара.
Үземнеке итеп җырлыйм шуны...
Өзелепләр әйткән бичара:

—Базарларга чыгып ике ат алдым,
Икесен дә йөз дә унарга;
Урамнарга чыгар хальләрем юк—
Кызлар чакыра мине кунарга!..

... Табындашлар тәгәрәшеп көлә,
Рәшит сүккән булып кылана:
—Сезме аңлар чибәр егет хәлен?!
Җыен котсыз! Җыен дивана!

Анә—көзге! Карагыз бер! Сезне
Агартканчы кирәк юарга!

Кыз-кыркынның иң беткәне хәтта
Кертмәс куенына кунарга!

Сез җавапсыз мәхәббәттән шигырь
Язар өчен генә яраклы!
Шигырь сөйлик! Шигырь сәгате бу!
Әнә, буран тынды... таң атты...

...Табындашлар таңда шигырь сөйли,
Дөньяларда ал таң яктысы,
Дөньядагы ал таң яктысының
Яртысы ла шигырь яктысы...

Таңга уралыплар искә төшә,
Сөйли, җырлый, елый, шаярта...
Моңсуланып кына кояш бата,
Сагындырып алсу таң ата...

И туганкай! Синең йомгак та бит
Ахырына кадәр сүтелде—
Киләбез дә китеп югалабыз
Өермәле буран шикелле...

Безне—сәер яшәп киткәннәрне—
Искә алмас, бәлки, беркем дә,—
Җырлаган җыр, тере шигырь калыр
Дөньядагы җилләр иркендә...

## И дөнья!..

—И дөньялар!..—диеп ил картлары
Әйттеләр дә, тынып калдылар—
Кар-бураннар котырынды җирдә,
Килде—китте бозлы яңгырлар...

Ел артыннан еллар килә торыр,
Көн артыннан судай көн агар.
—И дөньялар!..—дияр ил картлары,—
Нишләде бу матур дөньялар?

... Кояш бата...
Койма буендагы
Утыргычта—картлар...
Сүз бара...
Тарихларны айкап чыга алар,
Керә—без кермәслек елларга...

Сөйлиләр дә тукталалар алар
Сере бикле дөнья алдында...
Аксакалның нәтиҗәсе гади,
Үтерерлек гади:
—И дөнья!..

...Үзебез дә инде баргач, анда—
Тегендә,
Нәкъ Үзе янында
Уфтанмабыз, дисең мәллә, туган,
Шул ук бер сүз белән:
—И дөнья!..

## Яшенле төн

Нилəр булды икəн сиңа тагын?—
Яшенле төн сыман шомлы чагым...

Күкрәгемдә тора күкләр күкрәп,
Йөрәктә шау ялкын дулый дөрләп.

Ни китерде сиңа яңа таңың?
Нилəр булды икəн сиңа тагын?

Дәваламый гына Вакыт-табиб,
Онытырга күптән вакыт та бит!—

Ләкин әрнү һаман килә тора
Суык елларны да ера-ера...

## Иярде дә китте

Актарды җил каен ябалдашын!
Яшел шавы шушы каенның
Иярде дә китте таң җиленә—
Җил зәхмәте аңа кагылды.

Һәм туй итте дөнья киңлегендә
Каен шавы белән таң җиле—
Шул зәхмәтле туйның гайрәтеннән
Шау өермә купты, билгеле...

Бу өермә, Тәңре үзе кушкач,
Әверелде кинәт адәмгә.
Ак кәгазьгә иелде ул адәм
Һәм үрелде кулы каләмгә...

Каләменнән төшкән хәрефләргә
Сыйды аһлы һәм шат гомерләр!..
...Әнә шулай пәйда була тора
Сәер затлар—әһле шагыйрьләр...

## Яулар идем...

Яугизәр ир итсә әгәр Ходам
Мине—сөеп шашкан юләрен,
Сиңа илләр бүләк итәр идем,
Ниндиләрен генә илләрнең!

Былбылларның иң моңлысы сайрар
Илне яулар идем мин сиңа,
Таңы синең карашыңа лаек
Илне сайлар идем мин сиңа...

Мин чикләрен ачкан гүзәл илдә
Булыр иде моңга моң тоташ,
Гөл дулкынын кузгаткан наз җилләр
Булыр иде сиңа сулышташ.

Күге кояшлы ил яулар идем
Яугир көче булса кулымда—
Һаваларда калган кош эзләрен
Укыр идек икәү тын гына...

Яулап бирер идем горур илне,
Ул ил—
мәгърур таулы ил булса,
Кыялардан төшкән шарламалар
Толымнарга синең тиң булса!

Күлләр илен яулар идем сиңа...
Шундый күлләр анда табылса—
Күзләреңдә синең чагылгандай
Серләр сере анда чагылса...

Яулар идем илләрне мин сиңа
Яугир булсам, шагыйрь, булсам да...
Ләкин
һәр тередән куәтлерәк
Бөек Куәт бар шул
Җиһанда.

Һәм шул куәт барлык терeләрне
Мәхәббәтле итеп яраткан—
Синдә булган барлык яктылыкны
Сөйдергеч нур итеп тараткан.

Үзебезне сөю яуласын дип
Дога кылам синең алдыңда...
Сине хәтерләткән өчен генә
Ямьле микән әллә бу дөнья?

Дөнья үзе сине хәтерләтә!
...Һәрбер мәлем синле көннәрдә
Шундыйлары уйның килә һаман
Миңа—сөеп шашкан юләргә...

## Тар...

Кылыч белән яулаганнар әйткән:
—Иштем ишәсен—
Һәр кыйтганың
Чикләренең чикләренә чыгып,
Шушы яу арып бит туктады...

Яулап алдым бөек дөньяны мин,
Тик ул дөнья
һаман тар калды.
...Усал илләрне мин буйсындырдым.
Миңа буйсынмаган
яр калды.

## Чәчмә әсәрләр

**Вахит Имамов**

# УТЛЫ ДАЛА

ТАРИХИ РОМАН

### Җиденче бәйләм

1

Әтисенең вафаты турындагы хәбәрне Андрей кенәз бер ай вакыт чамасы үткәннән соң гына алды. Байгөл бу көннәрдә өченче бала көтеп тулгаклый, Андрей исә кабат аның малай табуына өметләнә иде. Кара кием киеп килгән чапкынны ул кече йортка чакырып каршылады, үзен булдыра алган кадәр тыныч, кырыс тотты.

—Бердән, мин акыл җуеп елый торган яшьтә түгел инде. Икенчедән, бу илдә кайгы дигән зәхмәтнең һәр кеше белән янәшә йөрүен дә күптән беләм. Шуңа күрә әйтер хәбәреңне бизәп маташма. Нәрсә булган, кайчан, ничек?—һәммәсен дә миңа яшермичә сөйлә.

Юлчыны кенәзнең сүзләреннән бигрәк каш астыннан бораулап текәлгән салкын, өшәндергеч карашы сискәндерде. «Кыю, тәвәккәл кенәз, дип сокланалар. Әйе, бу кеше, чыннан да, курку, икеләнү хисен белми бугай. Корыч кешедер бу, валлаһи, корычтыр. Шулай булмаса, бер ялгызы көе әтисенә, туганнарына каршы чыгарга җөрьәт итәр идемени?»

—Юрий кенәз вафат.

Язмыш тарафыннан шактый иләнгән Андрейның йөзендә бер төге дә селкенмәде. Чапкын, авыр сулаганнан соң гына, өстәп куйды.

—Дөрес булса, агулап үтергәннәр.

Андрей түр почмакта торган иконага карап чукынып куйды, уртын кысты. Алдагы сүзләре теш арасыннан чыккан шикелле ысылдап ишетелде.

—Бәйнә-бәйнә сөйлә.

—Юрий кенәз Петрила бояр йортына кунакка барган булган. Ахырда Андрей углы исеменнән кунак килде дип, ниндидер Козьманы залга чыгарганнар.

Андрей күзләрендә очкын пәйда булды, әмма эндәшмәде.

—Шул Козьма синең исемеңнән Юрий кенәзгә башта җилән бүләк иткән. Аннары үзе белән алып кергән шәрабны салып биргән. Шуны эчүгә, Юрий кенәз идәнгә егылган, ди.

—Козьма дигән кешене тотканнармы?

—Бик яман кыйнаганнан соң, боярлар аны Ләһ капкасы янындагы чокырга чыгарып ташлаганнар. Инде аягын сузды, дип исәпләгән булганнар. Ә икенче таңда чокырга чыксалар, Козьмадан җилләр искән. Һәр

---

Дәвамы. Башы 1 санда.

тарафка да унбиш-егермешәр жайдак куып карадылар, әмма эзен-мазар күрүче табылмады.

Андрей уйга чумды. «Козьма, Козьма! Минем эшемә ярдәм итмәкче булып юлга чыккан идең. Мин сиңа бернинди җилән дә, шәраб та бирмәдем бит. Кайсы кабих корган тозакка эләктең икән? Исән-имин котыла алдыңмы син? Хәзер кайда? Вакыйгаларның асылын, әтиемне үтерүчененең исемен миңа кайтарып җиткерә алырсыңмы? Гомумән, кайтарсыңмы?»

Андрей, уйларыннан арынып, янә юлчыга текәлде.

—Олуг кенәзне кайда җирләделәр? Әтисе—Бөек Мономах белән янәшәдәме?

Чапкын беравык дәшми торды. Йөзе каралып чыкты, авыр сулап куйды.

—Киевтагы бөтен бәла, бөтен мәхшәр әтиең үлгәч башланды, Андрей кенәз. Әтиеңнең вафаты турындагы хәбәр таралуга ук, котырынган Киев халкы олуг кенәз сараена ябырылды һәм андагы бөтен байлыкны саранча шикелле тоташ талап чыкты. Аннан соң талау кенәзнең Днепр елгасы артындагы җәйге йортына, синең энең Василийның сараена күчте. Мәгәр котырынган Киев холопларының нәфесе алай гына да басылмады. Алар инде Суздаль боярларының Киевтагы барча биләмә-сарайларына бәреп керде. Кулына корал тотып байлыгын сакларга җыенган дистәләгән суздальлене изеп ташладылар, ә мал-мөлкәтләрен энәсеннән-җебенә кадәр талап чыктылар.

—Ох, хәшәрәтләр! Ох, кабихлар!—дип авыр ыңгырашып, Андрей чигәләренә ябышты. Утырган җирендә уңлы-суллы килеп селкенгәләп алды. Ә чапкын аның саен күңелсезрәк хәбәрләр өсти торды.

—Киев халкы Юрий кенәзне әтисе Владимир Мономах белән янәшәдә, София соборы янына күмүдән баш тартты. Ул котырган этләрнең бер төркеме хәтта Юрий кенәз җеназасын җиргә салып та таптамакчы булган. Шуннан соң инде яшереп диярлек алып чыкканнар да, Юрий кенәзне шәһәрдән бөтенләй читтә, Спас монастыре эчендә җирләгәннәр.

—Хурлык, оят! Ах, ул хәшәрәтләрне!

Андрей шул рәвешчә туарылып шактый озак сүгенде, ярсуына чыдый алмыйча әрле-бирле йөренде. Чапкын аны тын гына күзәтте, бер сүз дә эндәшмәде. Инде шактый вакыт үткәннән соң гына, усал итеп төйнәлгән куш йодрыгын Киев тарафына юнәлтеп, Андрей кенәз соңгы сүзен әйтте:

—Мин әлеге мәсхәрәне мәңге онытмамын. Әмма сезнең дә канлы яшь коеп еласы көннәрегез алда әле, Ходай каргаган Киев кабихлары!

## 2

Берәр атнадан соң нарасыйны күрергә дип Андрей кергән чакта Байгөл әле түшәктән дә кузгалмаган иде. Хәле бик чамалы гына булса да, сабыен күкрәгенә кысып, әти кешене усал караш белән каршылады.

—Ике малаемны миннән тартып алдың. Алар кара җилән кигән мәкерле монахлар коткысында үсә. Дөньяга үзләрен яраткан газиз аналарын берсенең дә килеп күргәне юк. Йөрәк парәләремне аерып алып, син шулай мине җансыз-бәгырьсез калдырдың. Ә хәзер ас, кис мине, монастырьга биклә, әмма бу баламны һичкемгә бирмим. Бер улыма гына булса да туган әнкәсенең телен белеп үссә дә ярый. Мин аны әнә шулай, ике телле, тигез канатлы итеп үстерергә телим. Комачаулама миңа!

Байгөл ярсыган, күзләреннән яшь бөртекләре бәреп чыккан иде. Болай да сырхаулап яткан ананың бу халәте Андрейга бик кызганыч булып тоелды. Ул сәке янына килеп тезләнде, борынын Байгөлнең муенына төртте, сыңар кулы белән хатынын кочкан кебек итте. Соңгы көннәрдә

анын үзенә дә бик ямансу, авыр, аңа да хәзер күнел юатырдай терәк кирәк иде.

—Сине беркем дә рәнжетергә җыенмый, Байгөл, юкка хафаланма. Тизрәк савык, баланы үзең белгәнчә тәрбияләп үстер. Мәгәр ана дошманнар агулап үтергән атам атын куйыйк, анысына, зинһар, каршы килмә. Монысы минем әткәм рухы алдындагы бурычым.

Байгөл ризалык белдереп керфек какты. Ир белән хатын бәхетле елмаеп, яңакларын яңакка терәделәр. Андрей сарайга да ирен читләрендәге елмаю, бәхет чаткыларын яшерә алмыйча чыкты.

Ләкин ул арада Боголюбовога Суздаль каласыннан да чапкын килеп җиткән икән инде. Киев каласыннан Суздальга Андрейнын үги әнкәсе, шул анадан туган дүрт энекәше кайтып төшкән. Хәзер һәммәсе дә аны үз яннарына, олы кинәшкә дип чакыралар. Алар тарафыннан ниләр ишетәсен аермачык белеп торса да, Андрей юлга җыенырга мәҗбүр булды. Әмма юлда ул бертөрле дә ашыгу күрсәтмәде. Берничә атна буена Владимир каласында тукталып торды, мәрхүм әтисе истәлегенә, анын исемен кушып, чиркәү нигезләтте.

Ул Суздальга таба янә кузгалганда табигатькә август ае кергән иде инде. Андрейны туган шәһәр халкы кала читенә үк чыгып каршылады. Руханиларнын кулларында алтын хоругвилар, боярларда ипи һәм тоз күргәч, Андрейнын баш түбәсе җиде кат күккә тигән кебек булды. Башка шәһәрләрдә мондый олылау һәм хөрмәт фәкать мәмләкәтнен олуг кенәзен каршылаган чакта гына күрсәтелә. Ә яңа, зур кенәзлек төзеп килгән мәлдә үзен халыкнын илбашыдай бөек күрүе Андрей өчен, әлбәттә, зур мәртәбә иде.

Тик кенәз сараенда үзенекеләр белән тәүге сөйләшү үк Андрейнын кәефен су югандай кырып төшерде. Билгеле ки, беренче булып аңа үги анасы—грек хатыны Гайда ябырылды.

—Безнең өебездә генә түгел, бөтен нәселебездә кайгы-хәсрәт. Без матәм эчендә йөрибез, ә син гомер ирешмәгән әллә нинди җинүләреңне тантана итәсең. Чит дәүләтне буйсындырып кайткан сәргаскәрмени?! Аны бөтен шәһәр басу уртасына чыгып каршы ала. Император, валлаһи, император!

Тол калган кенәзбикә әрле-бирле килеп тузына иде. Андрей кыяфәтендә һични үзгәртмичә залны күзәтеп чыкты. Әнә, алар—Андрейнын бер ата, ике анадан туган кардәшләре—элеккеге кенәз кәнәфие урынына озын эскәмия куеп тезелешеп утырганнар. Яшүсмерләр булып килүче Мстислав һәм Василий, әле урамда йөгереп шар сугарлык, тугыз-ун яшьтәге Михаил. Шулар янәшәсендә үк туктаусыз рәвештә аякларын селкеп утыручы ике яшьлек сабый—Всеволод. Әле тагын мич буена Андрейнын абыйсы Ростислав вафат булганнан соң ятим калган Мстислав белән Ярополк атлы туганнан-туган энекәшләре дә урындыклар өстенә менеп кунаклаган. Андрей кул астында шәһәрләр җитәрлек: Владимир, Суздаль, Мәскәү, Муром, Рязань, Волок-Ламск, Ростов, Коломна, Клязьма... Сүз дә юк, ирек куйсаң, боларнын һәркайсы үзенә аерым-аерым шәһәр даулаячак. Ләкин болар кубызына бии башласаң, Андрей хыялланган бөек кенәзлек—яна дәүләт нигезе төзеләчәкмени?!

Үги кенәзбикә Андрей каршында кинәт туктап калды.

—Ә синең тантана итүең, бәлки, урынлыдыр? Юрий кенәзне син юллаган холоп агулаган, дип сөйләгәннәрендә, бәлки, нигез бардыр? Бәлки, син хәзер шул җинүне тантана итәсеңдер? Йә, нигә эндәшмисең?

Андрей уртларын шыгырдатты, күзләрен кыса төште. Куе керфекләрен сындырып чыккан усал карашы белән үги әнкәсенә озак текәлеп торды. Гайдага кырык биш-илле яшьләрдән дә артык түгел, чәчләре чем кара, яңаклар җыерчыксыз, иреннәре сусыл, гәүдәсе төз, тулы. Читтән карасаң, мөгаен, ул бик матурдыр. Әмма бу минутта тол кенәзбикә Андрейга барча явызлык-усаллыкны үзенә туплаган кара елан булып күренде. Үч-ярсуын тыеп, ул берничә генә сүз сытып чыгара алды:

—Мин үз кенәзлегемдә үземне кимсетүгә ирек куя алмыйм. Телен тыя, буйсына белмәгәннәргә фәкать киту юлын гына күрсәтәсем кала.

—Оһ, кансыз, бәгырьсез! Без котырынган Киев холопларыннан күч-хәл белән качып, монда сыену эзләп кайттык. Инде ата-баба утары да минем ятим балаларыма төс түгел, ә бертуган абыйлары өчен алар бөтенләй чит-ят икән!—дип, саллы гына чәрелдәп кычкырды да, тол кенәзбикә сузып-сузып еларга тотынды. Бераздан ана эскәмиядә аякларын селкеп утыручы нәни Всеволод та кушылды.

Елау тавышлары беркадәр басыла төшкәч, беренче булып тынлыкны яшь кенәзләр арасында иң өлкәне саналган Василий бозды:

—Әткәй урынына, Киев тәхетенә Чернигов кенәзе, аның кан дошманы Изяслав Давидович менгәнен ишеттеңме, абый?

—Әйе, күптән ишеттем инде.

Бу юлы да Андрей йөзендә бер төк тә селкенмәде. Киевтагы хәлләр турында ул, чыннан да, хәбәрдар иде инде. Яшүсмер Василий шактый сәерсенеп дәвам итте:

—Ә бит ул тәхеткә син утырырга тиеш идең. Мономах оныгы буларак та, әткәйнең иң өлкән һәм иң шанлы улы буларак та нәкъ менә син олуг кенәз урынын яуларга тиеш идең, Андрей кенәз.

—Мин боларның һәммәсен дә беләм,—дип, Андрей уң кулын югары күтәрде, әңгәмәнең йөгәнен үз кулына алды. Һәммәсе тын калдылар.—Минем ул Ходай каргаган Киев тәхете тирәсендәге очсыз-кырыйсыз һәм мәгънәсез сугышларда йөреп, кан коярга һичбер исәбем юк. Һәм, гомумән, Киев тәхетенең мина кирәге юк. Минем хәзер рус җирендә иң эре, иң куәтле саналган үз кенәзлегем, шулай булгач үз тәхетем дә бар. Ул Владимирда. Мин шуннан торып бөтен калаларны үз канатым астына җыячакмын. Һәм ант итеп әйтәм: иртәме-соңмы, Киев каласы да мин төзегән яңа дәүләтнең гади биләмәсе генә булып калачак. Антымны янә бер кабатлыйм: мин Киев каласын да җиргә тезләндерәчәкмен!

Яшь кенәзләр тын да алмыйча Андрейга текәлеп утырды. Ул арада тол кенәзбикә Гайда телгә килде:

—Ә минем ятим балаларыма гомер буена да аерым биләмәгә ия булу бәхете тәтемәсмени?

Андрей һич югалып калмыйча җавап бирде:

—Ә син беләсеңме соң, анакай, мин утыз җиде яшемә кадәр аерым кенәзлек түгел, хәтта җимерек бер шәһәргә дә хуҗа була алмадым. Мона үкенмим дә. Чөнки хәзер минем кул астымда егермедән артык кала, йөзәрләгән вак-вак авыл бар.

—Синеке күп, син бай. Ә менә без? Без, ятимнәр, кайда туеныйрбыз?

Тол Гайданың янә еламсырап дәшкән тавышы Андрейны уйланырга мәҗбүр итте. Ул беркадәр вакыт бармакларын тез өстендә сикертеп утырды да, бәхәс-дәгъваларга урын калдырмаслык итеп, өзеп салды:

—Туклану өчен мин сезне шушы шәһәрдә калдырам. Әнә, егетләрнең өлкәне, Василий, кенәзегез булыр. Мәгәр аның кемгәдер каршы сугыш башларга да, гаскәр тупларга да, каланы башка берәүгә бүләк яки әманәт итәргә дә—һичбер хокукы юк. Василий тулысы белән мина буйсыначак. Барча эшне тик мин хәл итәм. Ә яшь кенәз зур эшләргә өйрәнә торсын өчен мин аңа ярдәмгә әле тагын үземнең воеводам Борис Жидиславичны да калдырып китәм. Кыргый кыпчак баласы, дип, аңа карата илтифатсызлык яки дорфалык күрсәтмәгез. Чукынган кыпчак булса да, ул урысның аумакай һәм куркак егерме-утыз кенәзен берүзе алыштыра. Аннары... аннары мин үзем дә кыпчак баласы бит, шуны да онытмагыз.

—Кенәзлек буламыни бу? Коллык, хурлык бит бу!—дип тол кенәзбикә тагын яшь аралаш сукрана башлаган иде, Андрей кенәз инде сикереп урыныннан купты. Ул шапылдатып ишек япкан чакта тәрәзә пыялалары гына зеңгелдәшеп калды...

Андрей икенче көнне инде Владимирга кайтырга җыена башлаган иде, көтелмәгән хәбәр аны юлга кузгалуын туктатырга мәҗбүр итте.

—Суздальга таба энекәшен Борис кайтып килә. Аны Святополк оныгы Юрий Ярославич Туров каласыннан куып чыгарган.

«Киевта кенәз алышынды. Димәк, ул мәхшәр дигәннәре янә бөтен биләмәләр буенча таралачак инде». Андрей шул рәвешчә уйлап алды да, яраннарын да дәшеп тормастан Киев юлына ашыкты. Рус кенәзләре арасындагы очсыз-кырыйсыз суеш-талаш өчен ачынудан эчендә чүл бүреләре улагандай итте. Нахакка рәнҗетелгән энесен кызгана башлады, атын куалады. Борис белән алар бер ана балалары, Андрей рәнҗетелгән энекәшенә ихтирам күрсәтмичә булдыра алмый иде.

Юлда буаз сыер сыман бик акрын гына кыймылдап килгән олауларны күргә үк Андрейның күңеленә кайнап торган су шикелле хәтәр шом йөгерде. Бәла-каза ялгыз йөрми, диләр, нәрсә, әллә инде «Озын кул» нәселендә яна хәвеф-хафа көтеләме?

Андрей якынайгач та, олаулар туктап калды. Сакчылар сүзсез генә, ияк кагып, өсте киез белән ябулы киң арбага ишарәләде. Чабуыннан сабырсызлык тарта башлаган Андрей шундук ияреннән сикереп төште, атлый-йөгерә диярлек киң арба янына килеп житте.

Борис мул итеп түшәлгән печән өстендә ята, бар гәүдәсе жылы юрган белән уратылган иде. Чыбылдыкны күтәреп арба өстенә менгән Андрейны ул елмайгандай итеп каршылады.

—Ә мин сине аяк атлауларыңнан ук таныдым, абый. Син һаман элеккечә. Җиргә каты басып, һич тә курку-икеләнү белми йөрисен.

—Исәнме, энекәш!—дип Андрей әүвәл, иелеп, Борисның куе сакалыннан үбеп алды. Йөзендәге хәвеф төсмерен яшерә алмый иде, шуна күрә турыдан ярып сорады:

—Сиңа нәрсә булды? Авырыйсыңмы әллә?

—Минем хәлләр хөрти бугай, абый,—диде дә, башка бер сүз әйтеп тормастан, Борис өстендәге юрганын кайтарып ташлады. Аның күкрәге шактый калын итеп ак батис чүпрәк белән уралган, әмма шулхәтле чүпрәк аша кып-кызыл кан саркып чыккан иде. Арба эченә күңел болгаткыч, зәһәр ис таралса да, Андрей йөзен чытмады, ашыгып сорау бирде:

—Кайда яраландың? Кайсы кабих жанның этлеге бу?

Борисның йөзен кара күләгә каплагандай булды.

—Мине Туровтан Ярослав көчеге Юрий-убыр куып чыгарганын әйткәннәрдер бит инде. Гомер буе Мономах нәселе хужа булып торган каланы якламакчы идем, куәт житмәде. Камыш сыман ялгыз утырсаң, дошман сине бик тиз сындыра икән бит ул. Юрий-убыр да мине, менә, ялгыз камыштай бөкте. Шулай булгач, тәнгә яраны да ул ясады. Ә инде күңелдәге турында сораша калсаң, аңа жавапны белмим. Әткәйдән соң Киев тәхетен эләктергән Изяславны илгә хужа була белмәүдә гаепләргәме? Әллә... «Озын кул» балаларының берәм-берәм үз биләмәләреннән колак кагуында өлкән абыйлары гаеплеме?

Сүзеннән тукталды да, Борис очкынлы, хәтта ачулы караш белән Андрейга текәлде. Абый кеше авыр сулап куйды, әмма эндәшмәде. Борисның түземлеге төкәнде:

—Йә, нигә жавап бирмисең? Нишләп акланмыйсың?

Андрей энекәшенә карамыйча гына телгә килде:

—Эх! Без бер ана балалары бит, югыйсә. Ә барыбер аңламыйсың.

—Ни аңларга тиеш икән соң мин, Алла колы?! Синең үзәкләштерелгән дәүләт төзү турындагы буп-буш хыялыңнымы?—Борисның тавышы тау чишмәсен хәтерләтеп ярсулана башлады.—»Яңача хакимлек итү, яңа дәүләт». Валлаһи, әкият бит бу! Ул үзара сугышудан мәңге туктый белмәс рус кенәзләрен бер түбә астына туплап буламыни? Үзең күрәсең бит: әтине үтерделәр, инде дошманнар безне берәм-берәм чүпли башладылар. Әүвәл синең биләмәңә үги әнкәй үз балалары белән кайтып егылды. Инде, менә, мине кудылар. Иртәгә, бәлки, Глеб белән Святослав туганнарың да урамга куылып, мал-мөлкәтсез калыр. Ә син ни көтәсең? Үз энеләреңне нигә якламыйсың? Шулкадәр үк жансыз-бәгырьсез

бәндәмени соң син, абзый кеше?!

Андрейның күз карашы монсуланды, ул бераз вакыт дәшми торды. Борис энекәше—яман хаста, ана авыр бәрелү гөнаһ гамәл иде.

—Сез һәммәгез мине Киевны дауларга, Изяславка каршы яу чыгарга әйдиклисез инде,—дип, ниһаять, ул бик төшенке тавыш белән сүз башлады.—Әмма мин аскан казандагы ризыкның тиешенчә пешеп чыкмаганын һичберегез анларга теләмисез. Ә пешмәгән ризык костыра бит ул, энекәш. Мәгәр сәгать сугар, Аллаһы Тәгалә ярдәме белән бөек сәгать сугар һәм шулчакта мин бөтен рус кенәзләрен тез астыма салып сытармын!

Андрей читкә төбәлгән, күзләрендә шайтан уты яна, ул сүзләрен Борис өчен түгел, бәлки, әйтерсең лә, үзен-үзе ышандырырга дип тезә иде.

—Мин сезнең күңелегездәге рәнжешне дә, миңа булган ачуыгызны да тоям. Дошманнарның минем яуга чыгуымны, көчсезләнгәнемне көткәнен дә беләм. Энеләрем, сез түзегез. Олы максат, бердәм дәүләт хакына түзегез берүк. Андый бөек үр югалтуларсыз гына яуланмый бит. Ә дошманнар... алар мине күргән бер сөяккә ташлана торган йолкыш эт хәленә төшерергә ашыкмасын әле. Мин түзәргә өйрәнгән. Вакыт үтсен, аннары мин алар каршына өненнән чыккан аю кыяфәтендә килеп басачакмын!..

### 3

Борис озак интекте, әмма савыга алмады һәм икенче яз житкәч, вафат булды. Әлеге хәбәр Суздальдан Боголюбовога шактый сонарып килде һәм Андрейга искитмәле авыр тәэсир ясады. Ул кенәз сараена кереп бикләнде, атна буе һичбер кешенең күзенә күренмәде. Әмма җиһаннан никадәрле генә качарга җыенмасын, аны әле үкенү, әле икеләнү хисләре эзәрлекли һәм ул үзен газаплаган уйлар өермәсеннән һич кенә дә котыла алмый иде.

Башка кенәзлекләрдән килгән хәбәрләр аның өчен яңалык та булмады, һичбер юаныч та китермәде. Рус иле үзгәрешсез һәм ул һаман элеккечә тоташ кан, дәгъвалашу, жимереклекләр эчендә ята иде.

Бөек кенәз тәхетенә менгән Изяслав Давидович юаш булып чыкты. Ул угры юл белән Туров каласын эләктергән Юрий Ярославичны акылга утыртмакчы булып, аңа каршы гаскәр туплап барган иде дә, әмма жинелеп кире кайтты. Ә Юрий-угыр ташлаган яман чир ул арада инде башка кенәзләргә йокты. Көнбатышта Полоцк кенәзе Рогволод Друцк каласыннан Глебны куып чыгарды. Беренче уңыш Рогволодның нәфесен генә котыртты, күрәсең. Бераздан ул инде жинелгән дошманы Глебнын улы Всеволод биләмәсенә дә бәреп керде һәм аннан Изяславль каласын тартып алды. Аннан шундый ук кан коюлар Галич белән Волынь жирләренә күчте.

Ул да түгел, бер баба оныклары булган бөек кенәз Изяслав белән Чернигов хуҗасы Святослав Олегович дружиналары да үзара бугазга-бугаз килеп сугыша башлады. Ә аннары инде рус жирендә кайнаган мәхшәрне шайтан үзе дә аңлый алмас булды. Кичә генә үзара кан коешып яткан Галич белән Волынь дружиналары сәер солых төзеп, бергә кушылдылар һәм мона кадәр бөек кенәзнеке булып исәпләнгән Белгород каласын яуладылар. Аптырап калган Изяслав үзенә ярдәмгә торки-бәрәндиләрне, алардан тыш тагын егерме меннән артык кыпчак яугирен чакырды. Ләкин беренче яуда ук торки-бәрәндиләр бөек кенәзгә хыянәт итте һәм дошман гаскәр ягына күчеп чыкты. Изяславның бу кадәрле көчкә каршы торырдай куәте юк иде. Киевына, тәхетенә, байлыгына төкереп, ул да яу кырын ташлап качарга мәжбүр булды.

Жинелгән кенәз—үги бала сыман, тәхет тирәсендә һәрчак артык. Шул мәсләктән чыгып киевлылар бөек кенәз урынына Смоленскидан Ростиславны чакырып китерделәр. Монысы «Озын кул» Юрийның бертуганы, моннан утыз ел элек бөек кенәз урынында утырган Мстиславның

уртанчы улы иде. Әмма туган тиешле булса да, ул «Озын кул»ыныкылар файдасына аркылыны буйга да салып карамады. Баерак, мәртәбәлерәк биләмәләрне ул фәкать үзенең улларына гына өләште. Ә рус кенәзләре арасында һаман сугыш дәвам итте. Хәзер инде тәхеттән куылган Изяслав белән Чернигов, Смоленск кенәзләре үзара кан коешты. Изяслав акчага яллаган кыпчаклар Смоленск өлкәсеннән генә дә ун меңгә якын халыкны коллыкка алып китте. Һәм бу мәхшәр-кыяматнең ахыры мәңге күренәчәк түгел кебек иде...

Бик озак баш ватканнан соң, Андрей бер карарга килде. Үз-үзен япкан тоткынлыктан чыкты да, ул Суздальдан воевода Борис Җидиславичны чакырып кайтарырга әмер бирде. Кыпчак яугире Боголюбовога килеп житүгә, Андрей аның белән янә сараена кереп бикләнде. Сүз башлаганчы воеводаны энә күзеннән кичереп чыкты.

Болай да куна тактасыдай киң җилкәле, эре сөякле дала улы Суздальда ятканда тагын да тазара, юаная төшкән. Куллары элеккечә гер шикелле авыр. Йөзе кырыс. Мыек чылгыйлары ияген каплап тора. Яңак сөякләре тупас булып ике якка тырпайган. Бер-берсенә кушылып үскән куе кашлар астыннан текәлгән соргылт күзләрендә Андрейга тугрылык хисләре чагыла, тик тасрайган карашы кургаш сыман авыр.

—Мин сугышчан поход ясарга карар кылдым, воевода,—дип, ниһаять, Андрей сүз башлады.—Безнең гаскәр шуңа әзерме?

Дала улы мыек чылгыйлары астыннан көлемсерәп кенә куйды.

—Кайсы дошманга каршы кылыч күтәрәбез бит. Гаскәрне дә шуңа карап сафка бастырабыз.

—Урыс җире болганчык чор кичерә. Ана—улны, ата кызны белми. Һәммә кенәзләр диярлек үзара суешалар. Һәркайсы өстәмә биләмә, яңа шәһәр даулый. Бердәмлек юк. Әтәче, тавыгы, хәтта чебеше дә канлы елга эчендә ялгыз йөзә. Көчлерәк кулга ия икәнсең, кил дә теләсә кайсын батыр. Менә, безгә дә үз көчебезне сынар вакыт житте. Дүрт-биш ел буена бер йодрык, бер әләм астына туплаган гаскәребезне яуга кертеп карыйк. Дөрес юл салабызмы без, хилаф эзме—шул сынау күрсәтер.

—Ә шулай да кемгә каршы кузгалачакбыз соң без, Андрей кенәз?

—Көчлегә каршы, воевода, фәкать иң зур көчкә каршы. Ә көч бүген бөек кенәз булып йөргән Ростислав ягында.

—Димәк, безнең максат—Киев?—дип сорады да Борис Җидиславич хупларга ашыкты.—Сиңа бөек кенәз булырга күптән вакыт.

Андрей кырыс тавыш белән шундук аның телен тешләтте.

—Тумаган тайның билен сындырырга ашыкма, дала кешесе бит син, воевода. Киевка селтәнергә иртәрәк әле безгә. Мин биредә туплаган кенәзлек тә, гаскәре дә әле тай хәлендә. Аны әле ияр астында йөрергә өйрәтәсе, сынап карыйсы бар. Менә шуңа күрә без хәзергә Ростиславка түгел, ә аның улларына гына каршы чыгачакбыз. Алайса анда Ростислав бик юмартланып киткән, һәрбер малаена шәһәр өләшә. Святославына—Бөек Новгородны, Давыдына Торжок каласын биргән. Ә без тотыйк та кимсетелгәнне, ягъни бөек кенәзлектән куылган Изяславны яклыйк һәм Новгород белән Торжокны Ростиславныкылар кулыннан тартып алыйк әле. Урыс җирендә үзенә күрә гаделлек дигән әйберне урнаштырып карыйк...

Бер атна дигәндә Суздаль, Владимир һәм Рязаньнан Боголюбово янындагы кырга ун мең кешелек гаскәр килеп басты. Сугышчыларның күбесе ат менгән, яртысы диярлек тимер көбәдән, шәп коралдан иде. Тагын әле Муромнан биш мең кешелек дружина чыгуы турында хәбәр алынса да, Андрейның вакыт әрәм итәсе килмәде, ул үз кул астына баскан гаскәргә Мәскәүгә таба кузгалырга әмер бирде.

Чапкын аша Әрбәткә дә инде күптән әмер җибәрелгән иде. Андрей гаскәре Мәскәү елгасына якынлашып килгәндә һәм бөтенләй көтелмәгән бер минутта инкүлектән биек ур өстенә чылбыр булып тезелгән дружина калкып чыкты. Андрей уң кулын югары күтәреп капылт тукталырга әмер

бирде. Ертауллар һәм менбашлары алларында стена булып калыккан билгесез гаскәргә таба төбәлделәр. Таныш түгел дружинадагы сугышчылар саны биш йөздән дә артмый, әмма чылбырдагы җайдаклар бер-берсенә игезәкләр шикелле охшаш иде. Һәммәсенең дә өстендә корыч тәнкәләрдән тезеп ясалган озын көбә, кулларында түгәрәк тимер калкан, очына ат ялы бәйләнгән озын, дәү сөңгеләр. Һәр җайдакның бил каешын тагын кынлы хәнҗәр, кәкре кылыч бизи, байтагының тез өстендә япьләре тимер япма белән ныгытылган авыр чукмар ята.

Суздаль-Рязаньныкылар билгесез дружинаны әле ныклап күз алдыннан кичереп үтәргә дә өлгермәде, Мәскәү ярындагы урман эченнән көтмәгәндә яман сызгыру авазы яңгырады һәм ур өстенә тасма кебек сузылып җайдакларның яна бер төркеме килеп чыкты. Аргамакларын бар көченә куалап чапкан бу җайдакларның һәммәсе дә өсләренә корыч чыбыклардан челтәр сыман үреп ясалган җинел көбә кигән, иңнәрендә— җәя, башларында матур кош каурыйлары куелган текә, биек очлым. Тасма булып тезелгән яугирләрнең һәркайсы өзәнгеләренә басып күтәрелгән, кәкре, озын ятаган тоткан кулын алга таба сузган һәм барчасы да бүре улагандай яман авазлар кычкырып, үкереп килә. Ятаганлылар чыгарган усал аваз шулкадәр көчле дәһшәт бөркеде ки, Андрей гаскәрендәге атларның байтагы арткы аякларына күтәрелеп, зәһәр кешнәргә тотынды, сугышчылар коралларын алып, яуга ук әзерләнә башлады. Ә ташкын-өермәдәй уйнап килгән дружина тәнкә-көбәлеләр чылбыры каршына сузылып урнашты да, ятаганнарын йөзләре каршына күтәреп капылт туктап калды. Андрей ятаганлылар белән тәнкә-көбәлеләрнең бертигез үк санда булуларын шәйләп өлгерде. Әкияттәге кебек җир астыннан калыккан һәм ике катлы чылбыр булып баскан бу гаскәрләрнең кыяфәте, әлбәттә, гаярь, дәһшәтле һәм хәтта гүзәл иде. Андрей алардан карашын аера алмыйча, шаккатып тик торды. Ул билгесез бу көчнең Әрбәт дружинасы булуын, әлбәттә инде, чамалаган иде.

Беркадәр вакыттан соң, «гаеп иясе» үзе дә пәйда булды. Бактың исә, Әрбәт тә ятаганлылар сафында «улап» килгән икән. Әнә, ул шулар сафыннан кубып алга чыкты, гаярь атын кәс-кәс атлап йөргән борнай кызлар сыман вак-вак сикерткәләп, Андрейга таба якынлашты. Ә Андрей Мәскәү воеводасына текәлде дә, күзләренә ышанмыйча торды. Әрбәт үз өстенә чип-чиста көмештән ясалган вак-вак тәнкәле озын көбә кигән, ә очлымы, күрәсең, саф алтыннан иде.

Андрейның каршына килеп җиткәч, Әрбәт аргамагыннан җинел сикереп төште. Ул үзенең «гаебен» бик тиз аңлап өлгергән иде, ахры. Башындагы очлымын салып, аны алга таба сузды да, бер аягы белән җиргә тезләнеп басты.

—Мәскәү дружинасы сугышчыларын да үз канатың астына алсаң иде, данлыклы кенәз.

Әрбәтнең барча сугышчыларга ишетелерлек аһәңле тавыш белән аны зурлавы Андрейның күңеленә, әлбәттә, хуш килде. Ул да эреләнеп тормыйча атыннан сикереп төште, кызу-кызу атлап килде дә, Әрбәтнең иңнәреннән тотып күтәрмәкче булды. Куллары белән алтын очлымны алга сузган килеш Әрбәт һаман кузгалмыйча торды. Ниһаять, Андрей да Мәскәү воеводасының ниятен аңлап өлгерде. Ул күңелендә купкан канәгатьлек хисен яшерә алмыйча җинелчә генә көлемсерәп куйды. Икенче мизгелдә инде ирләр очлымнарын алышып өлгерделәр. Андрей түбәсенә матур каурыйлар куелган алтын очлымны киеп алгач, сугышчылар сафында бердәм рәвештә соклану һәм тантана авазлары купты.

Ирләр өстенә менеп кабат юлга чыккач, Андрей шатлыктан тургай сыман очынган күңелендәге тойгыларын һич тә яшермәде.

—Син мина үземнең шанлы походларымны исемә төшердең әле, Арбат воевода. Кайчандыр Киев тәхете өчен сугышып йөргән чакта мин дә үз дружинам белән әткәй-мәрхүмне кызык иткән идем бит. Ул да минем дружинамны таный алмыйча хәвеф күтәрде, дошман дип кабул

итте. Бүген инде минә син борыныма чиерттең. Әмма үпкәләмим, афәрин, воевода! Синең мең кешелек дружинаң теләсә кайсы кенәз сокланырлык.

Кенәзнең тел шартлатып әйткән мактау сүзләре күңеленә сары май булып ятса да, Әрбәт, үз алдына елмаеп, эндәшмичә барды. Андрей аның халәтен аңлый иде бугай, сөйләшүгә сусап, тынлыкны үзе бозды.

—Бер мең дигәннән, әйт әле, син улкадәр сугышчыны каян гына җыеп өлгердең? Минем белүемчә, кичә «Кучкәй», бүген «Мәскәү» дип аталган сезнең бистәгездә аның чаклы халык яшәми бит.

—Үз биләмәләреңне ешрак әйләнергә кирәк сиңа кенәз. Югыйсә, син моннан икеме-өчме ел элек үк бер килдең дә, шуның белән тәмам тынычландың. Ә мин инде ул арада Мәскәү яры буйлап яңа ике урам төзеп өлгердем.

—Ә кешеләр каян аласың син?—дип, түземсез, Андрей янә шул ук сорауны бирде.

—Каян булсын, кенәз? Шул ук урыс җиреннән. Биләмә кенәзләре арасындагы туктаусыз кан коюдан игенчеләр, һөнәрчеләр күптән гарык булган. Көчлерәк яклаучы, тыныч тормыш эзләп минә шулар синең җиреңә килә. Ә мин тар күңелле түгел, синең исемеңнән һәммәсен кабул итеп барам. Әнә шулай итеп синең биләмәңдә куәтле бер шәһәр үсеп килә.

—Ә син нык хәйләкәр кеше, воевода,—диде Андрей, шат елмаеп һәм Әрбәтнең җилкәсенә сыңар кулы белән шапылдатып алды. Аннан инде янә җитдиләнде.—Аннары, мин тагын бер нәрсәгә игътибар иттем, Арбат. Минем гаскәрдәге сугышчылар тулысынча диярлек чабатадан, ә синекеләрнең һәркайсында күн итек тә, читек. Анысы каян инде?

—Миндә һөнәрчеләр буа буарлык, шулар киендерә.

—Ә нигә минекеләр өчен дә тектермисең?

—Анысы да мөмкин булыр иде, ләкин...—диде дә, текә кыяга килеп төртелгән шикелле Әрбәт туктап калды. Беркадәр тын барды, аннан гына сүзен дәвам итте.

—Синең бер тапкыр да «Болгар дәүләте нишләп мул тормышта яши икән?»—дип уйлаганың юкмы? Җавабы бик гади. Анда хәтта хан да бер генә остаңы да бушлай эшләргә мәҗбүр итми, һәрбер эшкә һимая түләп килә. Шуңа күрә анда һөнәрчелек, сәүдә чәчәк аткан, шул юл белән Болгарның куәте арта бара. Минә шуларны барлаганнан соң мин дә бер генә остаңы да камчы белән эшкә җикмәскә булдым. Чөнки камчы уйнаклаган җирдән оста барыбер кача. Һәм осталык кача.

—Тел төбеңне һаман аңлый алмыйм, әйтеп бетер инде.

—Ә асылы болай: сугышчыларыңа итек кирәк икән, акча түлә, кенәз. Мин бит сиңа яңа шәһәр төзим, сәрмая бик кирәк.

—Ну, саран! Ну, хәйләкәр!—диде дә, Андрей янә Әрбәтнең җилкәсенә шапылдатып алды. Урман юлы буйлап йокымсырап барган сафларны кенәз белән воеводаның шаркылдап көлгән авазлары сискәндереп куйды.

## 4

Андрей үз походын шулкадәр дә каршылыксыз, җиңел булыр дип һич уйламаган иде. Ул ниятләгән һәммә максатына бик тиз иреште, әмма... гаскәрен яуда бер тапкыр да сыный алмыйча кире борылып кайтты.

Дошман дип билгеләнгән кенәзләр белән ул тәүге тапкыр Вщиж каласында бәрелешкәндәй булды. Биредә кала эченә Киев тәхетеннән куылган Изяслав белән аның туганнан-туган энекәше Святослав кереп бикләнгән, ә аларны төрле яклап Чернигов кенәзләре һәм яңа илбашы булып утырган Ростиславның уллары Роман белән Рюрик дружиналары урап алган иде. Андрей, әлбәттә инде рәнҗетелгән Изяславны якларга карар кылды һәм гаскәрен икегә бүлеп, Ростиславныкылар лагерена һөҗүм итәргә әзерләнде. Ләкин Андрей гаскәренең куәте-кыяфәте үк

Ростиславлыларның өнен алган иде. Алар Андрейның килеп житкәнен көтеп тә тормыйча кала янындан кубып югалдылар. Андрей тәүге жиңүен нәкъ әтисе гадәте буенча билгеләп үтте. Ул чолганыштан котылган союздашлары белән Волок-Ламск каласында очрашты да, шунда үзенең беренче хатыныннан туган өлкән кызын Изяславның туганы Святославка бирде.

Владимир-Суздаль биләмәсендә көннән-көн куәтләнә баручы Андрейның даны болай да рус кенәзлекләре буйлап киң таралган иде. Вщиж янында дошман гаскәрен яусыз-нисез генә куып таратуы, күрәсең, түземлеккә соңгы тамчы булды. Хәзер инде Бөек Новгород халкы үз теләге белән Андрей канаты астына ашкына башлады. Гомер-гомергә хөрлеге белән масаеп яшәгән Новгород халкының чираттагы бузасы үзе үк житә калды: Торжок каласына хужа булып утырган Давид кенәз биләмәсен ташлады да, Смоленск ягына качып китте. Ул да түгел, Новгородныкылар инде үзләрендә кенәз булып торган Святославны да кулга алды һәм бераздан аны әтисе янына, Киевка үк сөрде. Кулына корал да тотып карамаган Андрейга хәзер, новгородлылар гозере буенча, аларга хужа итеп, үзенең туганнан-туган энесе Мстиславны жибәрәсе калган иде.

Андрей әнә шулай итеп, «озын юллар» урап кайтты да, башка тарафларга кузгалып маташмады. Ә рус жирендә үлем биюе һаман дәвам итте. Үзен гомерлеккә рәнжетелгән дип исәпләүче Изяслав, кыпчакларны дәшеп, ике тапкыр пайтәхетне штурмлады, аның урамнарына бәреп кереп, йорт-ихаталарына ут төртте. Бөек кенәз Ростислав Киевны калдырып, Белгородка чигенде, Изяслав куа чыкты. Бу кала янындагы сугышлар дүрт атна буена дәвам итте, бер генә як та жиңүгә ирешмәде. Нәтижәдә каннан туймас Изяслав шушында үз үлемен тапты. Бер яу барышында Ростиславның Выйбор исемле жансакчысы Изяславның башына кылыч белән чапты...

Иң төп дошманыннан котылгач, тәхет хужасы Ростиславның тоташ үч белән сугарылган угы Андрей тарафына борыла башлады. Әлбәттә инде, Ростислав кайчандыр уллары хужа булып торган Бөек Новгород белән Торжок калаларын кабат үз канаты астына кайтармакчы иде. Ростиславның шул хактагы таләбен алганнан соң, Андрей дәгъвалашып та тормады, Новгородта утырган туганнан-туган энесе Мстиславны шундук Суздальга чакырып кайтарды. Чөнки Андрей «хөр, азат» Новгородның башбаштаклыгыннан, ялкаулыгыннан, азгынлыгыннан инде туеп беткән һәм андагы буйсына белмәс халыкны йөгәндә тоту өчен әледән-әле дружина юллаудан да тәмам гарык иде. Шулай итеп, Андрей үзенең туганын корал-мазар белән якламады, Мономах нәселе янә бер шәһәрдән мәхрүм калды. Ә мондый пошмаслыкның үзенә нинди бәла-хәвеф булып әйләнеп кайтасын Андрей әле һич кенә дә күзалламый иде.

Үзенә жиган[1] тиеш булган Мстиславның Суздальга кайтып яши башлавына ике ай чамасы да вакыт үтмәгәндер, Андрейга воевода Борис Жидиславичтан чапкын килеп төште.

—Мондагы кенәзләр, синең туганнарың, түнтәреш әзерлиләр! Бик күп кенә бояр, сәүдәгәрләрне дә үз якларына аударып өлгерделәр. Алар Суздаль халкын, каланы синең кенәзлектән аермакчы. Бәла-мазар булмый калсын дисәң, тиз килеп жит.

Ачудан зәһәрләнеп чыккан Андрей, беренче эш итеп, үз янына олы улы Изяславны дәшеп алды. Унбиш яше генә тулса да, ул әтисенә охшап озын буйлы, эре сөякле егет булып житлеккән һәм усал итеп кысылган юка иреннәре өстенә каракучкыл төк тә төрткән иде.

—Теге юнан[2] хатыны котырткан, күрәсең. Минем мәрхүм Ростислав абыйның малайлары белән сиңа жигән тиеш булган кардәшләрең безгә каршы фетнә күтәргәннәр,—дип аңлатты ата кеше, гаять коры итеп.—

[1]жиган—туганнан туганның баласы.

[2]юнан—грек яки византияле.

Каты куллылыкны күрсәтмичә булмас. Син дә юлга җыен.

Әлеге хакта каяндыр Байгөл белеп алды һәм Андрей кайтып керүгә үк, күз яшьләре белән аңа ябырылды.

—Изяслав акны—карадан, хакны нахактан аерырга да өйрәнмәгән чебеш кенә бит әле. Нигә син аны шушы яшьтән алып кансызлыкка, үчкә өйрәтәсең?

Андрейның җавабы шактый дорфа чыкты.

—Ул минем варисым. Алла теләсә, олуг кенәз булыр. Ә кенәз кешегә изге, йомшак булу, сыртка чыккан ямьсез бөкре сыман, артык йөк кенә ул. Фәкать кансыз йөрәк һәм тимер кул гына бу җиһанда аңа җиңү китерәчәк.

Байгөл күз яшьләренә күмелеп калды, ә Андрей исә котырынып-ярсып юлга чыкты. Күңелендә кайнаган нәфрәт кайнарлыгы гүя ташны эретерлек иде. Син бөртекләп җыйган кенәзлекне, яна бер дәүләтне ниндидер мокытлар җимерә башлый икән, ничек түзмәк кирәк? Мин үзем дә мокыт. Урамда калган үги инәй, энекәшләр бит, дигән булып шул комсыз бирәннәрне куеныма керттем. Ә алар ашаган табакларына кәкәй итә торган кара еланнар булып чыкты. Юк, башкача түзеп тормыйм. Яман чир ул бик тиз башкаларга да күчә...

Кенәз дружинасын Борис Жидиславич шәһәр читенә чыгып каршы алды.

—Кала боярлары арасыннан кемнәр миңа дошман, шуларны санап чык,—дип, Андрей сәламләшү сүзләреннән соң ук кистереп сорау бирде.

—Евлампий, Степан, Акакий. Тагын... сәүдәгәрләр арасыннан Бакырчы Василий белән Җирән Иоким да җан-тәннәре белән сиңа каршы.

Андрейның йөзенә ярсудан кып-кызыл тимгелләр бәреп чыкты.

—Ул хәшәрәтләрнең һәммәсен хәзер үк кулга ал да, Тимерче Борис алачыгына илтеп бикләǃ—дип, әүвәл воеводасына әмер бирде дә, Андрей шундый ук усал йөз белән улы Изяславка таба борылды.

—Алардан сорау алуны башыннан-ахырынача син үткәрәчәксең. Ул кара еланнарның берсен дә кызганып торма. Элмәккә күтәрт тә, һәммәсенең җиде кат тиресен салдыр. Башлап кем котырткан аларны, тагын кемнәрне үз якларына аударып өлгергәннәр—бүген кич үк миңа бәйнә-бәйнә җиткер. Мин хыянәтчеләрнең һәрберсен сасы чуан урынына тотып сытачакмын!..

Авыр ишекне аяк белән тибеп кенәз сараена килеп кергән Андрейны күрүгә үк йорт эчендәгеләр өнсез калды. Ялгыз көе залның уртасына кереп баскан кенәзнең кыяфәте үк җан алырга килгән Газраилгә охшап калган иде. Как шикелле кибеп усал кысылган иреннәр, кара көеп чыккан ачулы йөз, нәфрәт-дәһшәт бөркеп торган очкын сыман күзләр. Ярсуы шулкадәр дә көчле, күрәсең, аның яңаклары әледән-әле тартышкалап куя, кулындагы камчы зәһәр елан сыман бөтерелә, дер-дер килә.

Андрей залда утырганнарның һәммәсен каш астыннан гына айкап чыкты. Болар аның килү хәбәрен инде күптән алып өлгергәннәр бугай, барчасы бергә җыелганнар. Ростислав вафатыннан соң ятим һәм биләмәсез калган ике җигәне Мстислав белән Ярополк мич буенда утыра. Ә үги анасы Гайда балалары Суздальга баш булып калдырылган Василий кенәз янына җыелганнар.

Андрей шул Василий энекәшенең йөзенә текәлде дә, тешләрен үк шыгырдатып куйды. Василий әллә каян иске кенәз тәхетен табып алган һәм хәзер бик эре кыяфәттә шуның өстендә җәелеп утыра иде. Андрейның зиһенен шул мизгелдә «һе, бу хәшәрәт үзен инде бөтенләй мөстәкыйль хаким шикелле тоя башлаган лабаса!»—дигән уй яндырып узды. Икенче мизгелдә инде залда Андрейның гөбедән чыккан шикелле усал һәм карлыккан тавышы яңгырады:

—Мин бирегә сезне хөкем итәргә дип килдем. Гафу итәсем юк. Эшләр җәза станында газаплауга кадәр барып җитмәсен дисәгез, барчасын

да үзегез аңлатыгыз. Сезнен башлап котыртучыгыз кем дә, башка кенәзлекләрдән ярдәм чакырттыгызмы?

Гайданыкылар белән Ростиславныкылар бер-берсенә күз атышып алды. Тагын да дәһшәтлерәк тавыш белән Андрей янә дәште:

—Мин алты ел элек биредә өлкән кеше итеп сине калдырып киттем, Василий кенәз. Димәк, мина каршы корылган фетнә өчен дә ин беренче чиратта син җавап бирәчәксең!

Василий инде элеккеге яшүсмер малай түгел, сакал-мыек җибәргән һәм асыл ир булып җитлеккән балигъ егет иде. Ул йөзенә җитди кыяфәт чыгарып, дәрәҗәсен югалтмыйча җавап кайтарырга тырышты:

—Син хөкем итәргә, хәтта җәзаларга ук җыенып килгәнсең. Инде илле яшенне тутырсан да, әле һаман кан коюдан туя белмисең икән. Мәгәр син кемнең җанын кыймакчы буласыңдыр, шунысын һич аңламыйм. Синең каршыңда Суздаль каласының тулы хокуклы кенәзләре утыра. Шулай икән, энекәшләреңне үзенә тин күреп сөйләшсән дә буладыр...

Андрейның күзләре һәм йодрыклары усал кысыла төште, әмма үз-үзен тотышында һичбер төрле үзгәреш чагылмады.

—Сезгә андый хокукларны кем бирде? Яле, аңлат.

—Ошбу кала әле Бөек Мономах заманыннан бирле безнен нәселнең бишек биләмәсе булып торган түгелме соң, хөрмәтле абзый кеше? Һәм шул заманнан бирле, гомер-гомергә, бу калага нәселдәге төпчек балалар хуҗа булып торган. Бу ниндидер Андрей кенәз түгел, ә Бөек Мономах билгеләгән тәртип. Ул канунны бозарга һичкемнең хокукы юк. Шулай икән, Суздаль биләмәсе дә безгә, энеләреңә тиеш.

Василийның дәлилен башка туганнары да эләктереп алды.

—Мономах канунын синең әтиең дә, аның абыйлары да бозмаганнар.

—Кенәз дөрес әйтә, Суздаль безгә тиеш!

Андрейның йөзендә бер генә кыл да селкенмәде. Тавышы да тыныч, ипле чыкты.

—Сез бит монда бишәү. Бер каланы үзара ничек бүлешерсез соң?

Күрәсең, бу нечкәлек туганнар арасында инде күптән тикшерелгән иде. Василий көттереп тормыйча җавап бирде:

—Урыс җирендә калалар йөзәрләгән. Дружина туплыйбыз да, яна биләмәләр барып яулыйбыз.

—Монысы яңалык түгел, урыс җирендә гомер-гомергә шулай булды. Кан коюлар, сугыш шуна күрә һич тукталу белми. Ләкин алай барса, берзаманны сез корал күтәреп миңа каршы да килеп җитәрсез бит. Миндә шәһәрләр күп, ә нәфес дигән мәлгуньне, бер котыра башласа, һич тә тыеп булмый. Инде менә шуңа җавап биреп кара.

Андрейның утлы карашы гүя өтеп алды. Василий беравык сүзсез торды. Башка туганнарына күз йөгерткәч кенә янә телгә килде.

—Туган туганга каршы кул күтәрми. Урыс җирендә Долгоруклар тантана итәргә тиеш.

—Эх, син, йолкыш!—диде Андрей, ухылдап, тагын да түзә алмыйча.— Сакал җибәрсәң дә, акылын үсмәгән шул. Синең әле, хәтта, лапаска кергән сасы көзәннең дә ниләр кыйланганын күргәнең юк. Ә ул хәшәрәт бер тавыкны будымы, аннары, кан исеннән исереп, лапастагы бөтен кошны рәттән кырып сала. Аның инде тамагы да туйган, мәгәр котырынушашудан ул үзен тыя алмый. Сез дә шулай. Ирек бирәм икән, сез иртәгә ук бер-берегезне суеп чыгачаксыз. Менә шул бәлане булдырмый калу өчен дип, мин бит урыс калаларын берәм-берәм үз кулыма туплыйм.

—Аның ише сүзне күп ишеттек,—дип, төпчек улы Всеволодны кочаклап утырган Гайда кул селтәде.—Анысы үз комсызлыгыңны олы максат белән буяп күрсәтә торган бер аклану гына. Ә чынлыкта исә бертуган энекәшләреңнән дә биләмә кызгана һәм нәфес белми торган бер бирән син.

Тамагына сөяк килеп кадалган кеше сыман Андрей сүзсез калды.

Тагын беркадәр вакыт узар һәм Андрей инде камчы белән үги анасы өстенә очып кунар төсле кыяфәттә иде. Әмма ул үзен кулга ала белде.

—Урыс жирендә кан коюлар кимемәсме дип, мин сигез ел элек үземнең газиз атамны ташлап бирегә кайткан идем.—Андрейның карлыккан тавышы зал эчендә гүләп ишетелде.—Шуннан бирле, сигез ел буена, минем биләмәмә бер генә дошман да аяк басмады. Суздаль, Владимир, Муром, Рязань, Ростов кешеләре кылыч тавышын, кан исен онытты. Дошман талавының да ни икәнен алар онытып бара. Мин бер хаким, бер падишаһ кул астына берегеп яши торган дәүләт төзүгә алындым һәм, Аллага шөкер, эшләрем әлегә уңышлы гына бара. Мин үзем өлгермим икән, әлеге изге эшне алга таба улларым, оныкларым дәвам итәр. Мәгәр олы эшләр артыннан йөреп күзләрем сукырайган, хата жибәргәнмен. Мин нигә дип сезгә үземнең биләмәмдә яшәргә рөхсәт иттем икән?!—Андрей ук шикелле корган бармагын энекәшләренә таба төбәде, тавышы зәңгәрле-яшелле төсләр өстәлеп яңгырады.—Мин чит дошманнарны оныттым. Ә бактың исә, үз туганнарым үз жиремдә миңа дошман булып үсеп житкәннәр икән. Башкача түзеп тормыйм. Мин сезнең һәммәгезне менә бүген үк үз жиремнән куам!

Иң беренче булып, үги ананың еламсырак тавышы ишетелде:

—Әле жәза станына салу, әле илдән сөреп чыгару белән куркытасың. Нинди жанвар соң син?!

—Мин сезне рәхәтләнеп жәза станына да салыр идем, күршеләрдән оят. Долгорукныкылар бер-берсенең канын коя башласа, дошман сөенәчәк. Менә шул хакка дип кенә мин сезне канлы жәзага тарттырмыйм, гади куып чыгару белән канәгатьләнәм.

Инде чын кенәз булу бәхете тәтемәгән энеләре тавыш күтәрделәр:

—Ничек оятың житә? Хокукың юк!

—Без соң кая барыйк?

Хәтта сигез яшьлек Всеволод та вәкарь белән генә әйтеп салды:

—Без моннан китмибез!

Андрей салкын гына итеп аңа карап алды. Абыйларыннан калган киемгә төренгән, шуңа күрә үз яшеннән тагын да кечерәебрәк күренгән шушы энекәшенең тиздән, бик тиздән «Зур оя» дигән кушамат һәм бөек кенәз исемен аласын да, нәкъ менә аның, үз эзеннән барып, Русьны берләштерү өчен көрәшәсен дә Андрей, әлбәттә, бу минутта хәтта гоманлап та карый алмый иде. Жавабы бик усал һәм кансыз яңгырады:

—Чебен, дулап, тәрәзә вата алмый! Китәрсез, энеләрем, йөгерәчаба чыгып олагырсыз. Минем эт өере жибәреп үзегезне адәм мәсхәрәсенә калдыруымны теләмисез лә сез. Шулай булгач, тизрәк кузгалыгыз.

Мәрхүм Ростислав һәм Гайда балалары икенче көнне таң ату белән үк юлга чыкты. Суздаль кешеләренең күбесе аларны явыз кенәз күзеннән яшеренеп кенә һәм ихлас күңел белән, елый-елый озатып калды. Икеөч айдан соң, алар хакында тагын да кызганычрак хәбәрләр килеп житте. Киев хакиме Ростислав аларны үз канаты астына сыендырмаган, Гайда өч баласы белән Византия императоры Мануил янына ук китәргә мәжбүр булган икән. Тәхеттән мәхрүм ителгән кенәзләр токымы өчен уртак, аяныч язмыш. Нихәл итмәк кирәк?..

## Сигезенче бәйләм

### 1

Бөек Болгар илендә ничәнче ел буена коточкыч мәхшәр хөкем сөрә һәм мәмләкәт өстенә яткан караңгы төн инде мәңге таралмас, ачылмас сыман тоела иде. Бу мәхшәрнең бөтен сәбәпчесе һаман да шул буйсыну, туену, әдәп белмәс кансыз Хәмбәл булды. Ул һаман

элеккечә Бәрәж ханга баш бирмәде, буйсыну күрсәтмәде. Бәрәж фәкать Биләрдәге хан сараена, аны әйләндереп алган таш кальгага гына ия һәм ил белән ул түгел, әйтерсең лә, комсыз, кыргый Хәмбәл идарә итә иде. Дөрес, Хәмбәл идарәсе кала әмирләре, түбә бәкләре һәм тарханнары өчен күбесенчә дошманныкы төсле талау походларын хәтерләтте, нигездә көчләү һәм кимсетүгә генә кайтып калды. Илдә ризасызлык, нәфрәт көне-сәгате белән үсә, әмма һичбер түбәдә дә Хәмбәлнең биш мең башкисәрдән торган курсыбаена каршылык күрсәтердәй көч әлегә юк иде.

Соңгы тапкырында кансыз сәрдәр Казансу һәм Зәя буенда яшәгән арлар, кыр ягындагы чирмешләр янына барып котырынып кайтты. Гаеп эзләгән түрә тумыштан кылый хезмәтчесен дә кыек караган өчен чит-ят итә. Хәмбәл дә яңа талау походы өчен сәбәпне әллә ни ерактан эзләп маташмады. Бәрәж хан малае Чилбирнең туена килгән чакта Мәртүбә түбәсенең олугбәге Танай Хәмбәлгә бүләккә берни китермәде. Ә Чилбир шаһзадәгә бүләк ителгән тимеркүк айгыр мәһабәтлеге, гаярьлеге генә түгел, көмеш тәңкәләр тезеп бизәлгән ияре һәм йөгәннәре белән дә күз явын алып тора иде. Хан малае, әлбәттә, мондый бүләктән бик канәгать калды. Ләкин, ни үкенеч, гаярь айгырның гомере төнге күбәләкнеке сыман гаять кыска булып чыкты. Туйлар узганнан соң өч көн үткәч, таңда сөлек кебек бу малкайның гәүдәсен хан утарында җансыз көе таптылар. Явыз җәлладның кулы ялгышмаган, аның пычагы айгырның бугазын кыл урталай ярып узган иде.

Хәмбәл сәрдәр үзе белән биш йөз углан һәм газиләр алып, нәкъ менә шул көнне юлга чыкты. Аның кая юнәлгәнен һичкем белми, ә бу исә якын-тирәдәге һәрбер бәкне һәм әмирне калтыранып торырга мәҗбүр итә иде. Ләкин сәрдәр Биләр-Идел юлындагы кала-авылларга туктал белән «вакланып» маташмады, Казансу елгасына кадәр араны бик тә елгыр узды. Казансудан соң ике көнлек юл үткәч, әле анда, әле монда куе урманнарга һәм кечкенә инешләргә сыенып утырган ар, чирмеш авыллары очрый башлады. Хәмбәл аларның һәммәсен диярлек талап, сытып барды. Ашыт суыннан соң авыллар ешайды. Аларның күбесендә ислам динен тотучы ак чирмешләр яшәүгә карамастан, явыз сәрдәр аларны да тоташ талап чыкты. Инде алда кара чирмешләр күмәк яшәгән яңа аймак башланды. Монысы түбә хуҗасы Танай бәкнең туган аймагы иде, Хәмбәл анда озаклап «күңел ачарга» карар кылды.

Ярмол дигән зур гына бер авыл ерактан ук сорнай, кубыз авазлары белән каршы алды. Бирелә—туй, аймак хуҗасы Яраңгы би үзенең кызын кияүгә бирә икән. Авыл читендәге яланга озын булып өсталләр тезелеп киткән, һәммәсе сый-нигъмәттән сыгылып тора. Ә авыл халкының яше-карты, барча кунак, ду китереп, чирәмдә биеп йөри.

Беркатлы би куе урман эчендәге юлдан буар елан сыман сузылып чыккан алайның көч-куәтенә әүвәл игътибар да биреп маташмады. Коралллы угланнар һәм газиләрне күрүгә ул ашыгып аларга каршы чыкты, эчкерсез күңеленнән һәммәсен өстәл янына чакыра башлады.

—Олуг мәмләкәтнең баш сәрдәре хакында мин әле ишетеп кенә белә идем. Менә, инде тәүге тапкыр күрешү бәхете дә насыйп булды. Гомеремнең бик бәхетле чагына туры килдең, олугбәк. Берүк табын янына рәхим итеп, кунак була күр.

Хәмбәл баштан-аяк коралланган гаскәр күрүдән тынсыз калган туйга, сынаулы караш белән текәлгән йөзләргә күз йөгертеп чыкты да, кулын селтәп, алайга әмер бирде.

—Туй итәбез, туй!

Усал сәрдәрне ярты сүздән дә аңларга өйрәнгән йөзбашлары җайдакларны иярдән төшерделәр. Тиз арада яланда яңадан-яңа өсталләр, хисапсыз сый-ризык пәйда булды. Хәмбәл белән аның йөзбашларын, әлбәттә инде, түргә, кияү-кәләш өстәле артына үтәргә чакырдылар. Хәмбәл ачы бал тулы беренче тустаганны әйләндереп куйгач та игътибар итте: сандугач канатыдай кыйгач кашлы, иң чиста суларда кайнатып юылган

житен кебек аксыл, йомшак чәчле, бит алмалары алсуланып торган кәләш, һичнинди хәзинәгә дә биргесез чибәр иде. Аның чибәрлеге чәченә, иңбашларына, күкрәгенә тезгән көмеш тәнкәләрне алып ташласаң да, һич сүнәчәк түгел. Ул тәнкәләр аңа өстәмә бизәк кенә өсти, аны әкиятләрдә генә була торган хан кызларына, хур кызларына якынайта иде.

Ялан өстенә энгер-менгер ингәч, ерактагы авыллардан килгән кунаклар юл чыгарга җыена башладылар. Хуҗа кеше, әлбәттә инде, аларны күңел ачарга үгетләвен белде.

—Кузгалмыйбыз әле, кунаклар, кузгалмыйбыз. Әүвәл кияү белән кәләшне, икесен генә ак йортка озатыйк. Аларның үз эше, зөфаф төнен тәмләп уздырсыннар. Ә яшь егетләр монда учаклар кабызыр да, без туйны янә дәвам итәрбез.

Менә шулчагында Хәмбәл көтелмәгән сүз-әмере белән һәммәсен дә утсыз өтеп алды:

—Чирмеш йоласы буенча кәләш белән зөфаф төнен үткәрү хокукы аның хуҗасына тиеш бугай. Әллә син шул канунны оныттың да, мине мыскыл итәргә җыенасыңмы, Ярангы би?

Ата кеше, пычаксыз суелган сыман, Хәмбәлнең аякларына сыгылып төште.

—Ул канунны беләм. Мәгәр, зинһар, рәнҗетмә син кызымны, олугбәк. Ул минем бердәнбер һәм әнисез үстергән балам бит. Бәхетле булырга комачаулама аңа. Кирәк икән, мин сиңа авылның теләсә кайсы кызын күңел ачарга бирәм.

—Авылның кызлары угланнарыма, газиләремә булыр. Ә синең сылуыңны мин үзем авыз итәм,—дип, сөйләшүгә нокта куйды да, җелеге суырып алынган шикелле карангы йөзле Хәмбәл тамак төбе белән генә шундук сөрән салды.—Үтәк, Абдул, Җияш!

Күз ачып йомганчы Хәмбәл янына йөзбашлар килеп җитте.

—Ярангы би авыл кызларының барчасын да бүген безгә бирә. Карагыз аны, ялгыш сынатмагыз. Чирмеш кызлары, алаша дип, сезгә үпкәләп калырдай булмасын.

Камыт бавын кысарлык та ара үтмәгәндер, яланда коточкыч мәсхәрәләү, яман суеш купты. Ярымисерек Хәмбәл башкисәрләренең бер өлеше аргамаклар өстенә сикереп менде һәм туйдагы барча халыкны шундук урап алды. Җәяүле газиләр, кунаклар арасына ташланып, яшь кызларны ялан читенә, инеш буена өстери башлады. Ялан өстен әле ачыргаланып кычкырган һәм үкереп елаган, әле әшәке, пычрак итеп сүгенгән авазлар каплап китте. Аларга өшәнгән, куркынган аргамаклар кешнәве кушылды. Камчы, чыбыркы чыжлаулары күкне ярып узды.

Берникадәр вакыттан соң Хәмбәл каршына елаудан ярсыган сылу кәләшне китереп бастырдылар. Аның толымнарындагы көмеш тәңкәләре коелып беткән, саргылт гәрәбә муенсасы да юк, ә күлмәк изүе кендегенә кадәр аерылган иде. Яшь һәм ярсу кызның күпереп торган алсу күкрәкләре нәфес, оят чиге белмәс кансыз сәрдәрдә кыргый җанвар дәртен кузгатты. Тәне калтырауны көч-хәл белән басып, ул башкисәрләренә яңа әмер бирде.

—Кичекмәстән учаклар кабызыгыз, ошбу ялан уч төбендәге шикелле күренеп торсын. Аннары чирмеш кызларын ут яктысында, авыл халкы алдында иркәләү дә ирләре, аталары өчен саваплырак булыр. Ә мин киттем. Мине кияү назына сусаган ять-яшь кәләш көтә...

Бизгәк тоткан шикелле калтыранган сәрдәр инеш буендагы шалашларның иң зурысына таба атлап китте. Куллары артка каерылган сылу кәләшне дә ике углан шул ук шалаш янына озаттылар. Әлләни күп вакыт та үтмәгәндер, ул тарафтан би кызының инде илереп, инәлеп кычкырган тавышы яңгырап ишетелә башлады...

Таңда шалаштан чыккач та кансыз Хәмбәл үзенең йөзбашларына авыз ерып дәште:

—Би кызы—мал. Үзем белән алам.

Йөзбашлары ихахайлап көлде. Бераздан шалаш авызында кечкенә кәләшнең тырналып, күгәреп беткән йөзе пәйда булды. Ул йомырка кабыгын ватарга җыенган нәни кош баласы сыман хәлсез, дәртсез иде. Сүзләре дә талгын җил кытыклаган яфракларның леперләве кебек пышылдап кына чыкты.

—Мина инештә булса да юынып алу кирәк.

Хәмбәл тик берникадәр ара гына тутыккан балта сыман үтмәсләнгән акылын җигеп уйланды да, янә авызын ерды.

—Нәфесемнең тагын төшүе мөмкин. Бар сон, юын.

Би кызы алпан-тилпән атлап яр астына төште. Тал ботаклары артына ышыкланып туй күлмәген салды. Шул ук тал агачлары артында ул инешкә керде, бер-ике колач салды һәм уйнаган шикелле генә хәрәкәт белән су төбенә чумды. Хәмбәл һәм аның йөзбашлары тын да алмыйча бер минут көттеләр, ике... Сылу кызый су өстенә калыкмады. Сәрдәр үченнән өннәре алынган йөзбашлар берсен-берсе уза-уза суга сикерде. Әмма инде сон, кәләш кызый күптән җансыз иде...

## 2

Биләр өстендә ястү намазына чакырган азан тавышлары да инде күптән тынды. Пайтәхетне акрын гына куе караңгылык каплап алды. Хәмбәл башкисәрләренә юлыгудан куркып әле көндез дә урамга чыгарга бик үк атлыкмаган сәүдәгәрләр, төзүчеләр, чүлмәк ясау, тимер кою һәм балта, күн эше осталары, барча йортларны һәм ихата капкаларын ныклы келәләр белән бикләп, хәвеф-хафалардан яшеренделәр. Икешәр катлы имән диварлар белән әйләндереп алынган дәү каланың урам-тыкрыклары кургаш сыман авыр тынлык эченә чумды. Хәзер инде шәһәр капкалары янында гына сүрән учаклар яна һәм аның тирәсендә тоткавыллар йөренә, ә каланы, әйтерсең лә, үләт афәте сытып үткән иде.

Шулай да пайтәхет бөтенләй үк үле түгел, анда шушындый караңгы төндә, хәвефле заманда да, барыбер, урамыннан үтәргә батырчылык иткән ир-егетләр бар икән. Менә, агач башмакларын урам ташлары өстендә шалт-шолт китереп, Айкапу янынннан «Мөхәммәт Бакырыя» дип аталган зур гыйлем йортына таба әүвәл бер ир узды. Аннары яна хан төзеткән ике биек манаралы Бәрәҗ мәчетенең ишекләре шыгырдап ачылды да, урамда янә ике шәүлә пәйда булды. Берсе кулына тоткан таягынарак иелеп, икенчесе бик төз, мәһабәт гәүдәле булса да уң кулы белән юлдашының терсәгенә кагылып атлаган бу ике ир дә дарелфөнүн ихатасына якынайдылар. Мәһабәт ир озын күгәннәр белән ныгытылган кече капканың тимер келәсенә кул салуга, эчке яктан тонык кына эндәшкән сорау ишетелде:

—Нинди йомыш йөртә?

Мәһабәт ир пышылдап диярлек җавап кайтарса да, сүзләре сорнай тавышы сыман яңгырап чыкты.

—Ил, дин.

Эчтә тимер ыштыр шалтырап куйды һәм бераздан кече капка авызында сакал-мыеклары пөхтә итеп киселгән ир-ат йөзе чагылды.

—Сез хәзрәтләрне инде күптән көтәләр булыр, гыйззәтле сәетемез. Голүм йортының дәрвишләр бүлмәсенә уза күрегез.

Таш бинадагы бер тәрәздән тар ихата эченә тонык кына яктылык төшә иде. Кунаклар шул тәрәз тарафына карап кузгалды һәм, яндагы авыр бер ишекне шыгырдатып, йорт эченә узды. Бүлмәдә җиде-сигезләп ир сүзсез генә утыралар иде. Ишектә Давыт сәетнең чал сакал белән капланган йөзе күренүгә үк, һәммәсе дә урыннан кузгалды. Беренче булып, сәет каршына аның белән бер баба оныклары булган туганнан-

туганы, шагыйрь Сөләйман-Сувари, ике кулын сузып, күрешергә килде.

—Сине элеккечә үк исән-сау итеп күрә алуыма чиксез шатмын, гамуҗәм. Янә дә килеп, синең хозурында төпчек углың Мирхаҗины да күрүем өчен күнел шәрифләрем аеруча мәмнүн. Угланыңа ошбу яшеннән үк гадел, туры, хак юл күрсәтәсең. Димәк ки, Бөек Болгар мәмләкәтендә киләчәк сәнәләрдә дә хак эш өчен көрәшчеләр бетеп тормаячак.

Шагыйрь соңгы сүзләрен атасыннан беркадәр читтә, ишек катындарак торган япь-яшь егетнең йөзенә текәлеп әйтте. Ә бераздан аны инде үзенең кочагына ук сосып алды.

—Хәл-әхвәлләрең арумы соң, борадәр? Ошбу мәдрәсәдә гыйлем эстәүне тәмам кылгансың бугай, мин шулай дип ишеттем.

Яшь Мирхаҗи кыенсынудан керфекләрен түбән төшерсә дә, Сөләйман-Суварига елмаеп кына җавап кайтарды:

—Әйе, шаирь агам, гыйлем алуны инде төгәлләдем.

—Хәзер кая китеп укырга исәплисең инде? Нишанурга барырга җыенасыңмы, Бохарагамы, Гыйраткамы, әллә Газнәгәме?

—Юк, әлләни еракка китеп йөремәмдер сыман. Атам да олыгайды.—Мирхаҗи әтисе ягына керфек сирпеп алды.—Аннары мәмләкәтемезгә вә динемезгә хезмәт итәр өчен байтак кына башка төрле эшләр дә бар ич. Әйтик, мәмләкәтемезнең ерак почмакларына үтеп, андагы кара чирмешләргә, башкорт вә истәкләргә үземезнең динемезне иңдерү, алар хак юлга бассыннар өчен ярдәм кулы сузу һәмишәмезгә дә фарыз эштер, агам.

—Сүзләрең җаныма сары май булып ята. Алар, мотлака, хактыр, борадәрем,—диде дә, шагыйрь Сөләйман кардәше Мирхаҗины кочагына ук алды.

Ике туган ишек катында сүз алышкан арада Давыт сәет түргә үк узып утырган һәм бүлмәдәге барча ир дога кылырга әзерләнә иде. Шагыйрь белән Мирхаҗи да бик тиз генә идәнгә тезләнделәр.

Дога укып амин тотканнан соң, сәет һәммәсен дә янә бер мәртәбә күздән кичереп чыкты.

Әнә, тәрәзә катында Әбүбәкер белән Гомәр утыра. Икесе дә тимер эше осталары, кулларыннан, әйтерсең, гөл тама. Сәетнең аеруча Әбүбәкер-оста ясаган тимер йозакларны, каеш аелларын, хатын-кыз алкаларын күреп шаклар катканы бар. Томшыгына энҗе бөртеге капкан сылу үрдәкле бер алка—Әбүбәкер-останың аеры горурлыгы, ә сәетнең аны күргәч исе киткән иде. Менә шушы алтын куллы оста хәзер Хәмбәл җәзасыннан куркып Болгарда, әмир Ибраһим ышыгына посып кына көн күрергә мәҗбүр. Гомәр-оста да Биләрдәге барча тимерчеләрнең башлыгы булып исәпләнә, ләкин, барыбер, ул да пайтәхет урамнарыннан күкрәк киереп уза алмый. Аның инде күптән чит төбәкләргә, ерак базарларга сәүдә олауларын юллаганы юк. Каладагы алачыкларның күбесе хәзер ярты куәтенә генә эшли, тимерчеләрнең кулы китә, осталыгы сүнә. Димәк, һөнәрчелек, сәүдә генә түгел, ә бөтен бер мәмләкәт сүнүгә һәм җимерелүгә таба бара.

Әбүбәкер-оста янәшәсендә иягенә таянып уйга чумган шактый яшь пәһлеванны Давыт сәет бер-ике мәртәбә күреп кенә белә. Ул—кылган-әремле ерак даладан килеп Болгар каласында хәрби хезмәткә ялланган кыпчак баһадиры Корнай батыр. Кайчандыр әмир Ибраһимның хассә алаенда* йөзбашы гына булып йөргән иде, ә хәзер инде ышанычлы сәрдәр. Болгар мәмләкәте аның өчен икенче Ватан гына булса да, Бәрәҗ ханның җебегәнлеге, Хәмбәл явызның башбаштаклыгы йөрәген, горурлыгын, барыбер дә ут шикелле талый, күрәсең. Әнә, чит-ят кеше диеп тормаган, мәмләкәт кайгысы турында гәпләшергә Болгардан ук килеп җиткән бит әле. Дөрес, аны Әбүбәкер-останың үзе белән дәшкән булуы мөмкин. Әмма, ничек кенә булмасын, сәрдәр Корнайның Биләргә нинди сәбәп белән юл тотуын, һичшиксез, әмир Ибраһим да яхшы белә булыр. Ә инде иң мактаулы әмирнең, хассә алайның, хәтта олы бер вилаятьнең

ил кайгысы белән көюе—болар инде, әлбәттә, зур көч һәм зур сөенеч.

Давыт сәет карашын унъяк стена ягына күчерде һәм йөзе шундук яктырып, ачылып китте. И, газиз җан! Нур-Сувар вилаятенен ахуны Бакир хәзрәт белән елмаеп һәм пышылдап кына гәп корып утыручы ир уртасы кеше кайчандыр Давытка бер адым да калмыйча ияреп йөргән малай—шаян Идрис бит ул. Идрис... Малай... Мона инде күпме еллар үткән?

... Мең бер йөз дә утыз бишенче елда Болгар иленә бөтенләй дә көтелмәгән зур кунаклар килде. Дистәләгән олау һәм аларны озата баручы җайдаклар кәрваны җиһан читендәге әллә нинди Әндәлүсия дигән ерак җирдән үк чыккан. Тирә-ягын нәсарилар камап торса да, ул Әндәлүсия дигән мәмләкәттә дә мөселманнар яши икән. Шуларның менә бер төркем сәүдәгәре бөтен кыпчак даласына, Идел-Чулман буйларына, Таш билбау аръягындагы далаларга, алай гына да түгел, җиһанның әле икенче читенә кадәр үк таралып утырган барча мөселман дөньясы белән дуслык-кардәшлек элемтәләре урнаштырырга дип, ерак юлга чыккан.

—Сәүдәгәрләр эргәсендә Әбү-Хәмит атлы гыйлем иясе вә юлъязмачы да сәфәр чигә икән,—дигән хәбәр Давытның бабасына—Биләр каласының җәмигъ мәчетендә казый булып торган Якуб Ногманга Болгардан ук килеп ишетелде. Шушы хәбәр Давытның ак сакаллы бабасын, әйтерсең лә, унбиш-егерме елга яшәрткәндәй булды. Якуб бабасы үзе белән инде егет булып житлеккән Давытны да ияртте һәм ерак Әндәлүсиянең зур кәрванын пайтәхет тышына ук чыгып каршы алды. Ике галим берсен-берсе бик тиз табыштылар. Чандыр гәүдәле, кылыч борынлы, ябык һәм каракучкыл йөзле Әбү-Хәмит Әндәлүсиянең Гарнат шәһәреннән, шул мөнәсәбәттә әле тагын «Әл-Гарнати» дигән ләкаб та йөртә икән.

Болгар мәмләкәтенең ханы Тулгак Хәйдәр сәүдәгәрләр белән бергә сәяхәтче галимне дә үз сараена олы кунак итеп дәшкән иде.

—Сандугачлар читлектә сайрамый. Аннары минем ханиярләр, падишаһлар илә уртак жырым да юк,—диде дә, хан сараена керүдән Әбү-Хәмит зур кыюлык белән баш тартты. Сәяхәтче туганының бу адымы Давытның бабасын тәмам әсир итте. Ул аны чын күнеленнән үз өенә кунакка чакыра башлады.

Әбү-Хәмит Якуб казыйның ихатасына һич тә көттермичә килеп керде. Ул үзе белән ун-унике яшьләрдәге малаен да ияртксн, йөзе ачык, теле татлы иде. Тамак ялгап алуга ук ике галим, өй артындагы агачлар күләгәсенә күчеп, тарих турында әңгәмә башладылар. Икенде намазыннан соң, Якуб казый үз кунагын пайтәхетнең иң иркен һәм иң шаулы бинасы—Алтын мунчага дәште. Озын, авыр юллардан соң мунчаның эссе ләүкәләрендә истирәхәт кичереп юынса да, Әбү-Хәмит белән Якуб Ногманның әңгәмә-бәхәсе бер генә минутка да тынып тормады. Озын төнне дә алар янә гәп эчендә үткәреп җибәрделәр.

Ике тәүлек буе Биләр базарында сәүдә иткәннән соң, әндәлүсиялеләр янә юлга җыена башлады. Шулчагында Әбү-Хәмит Якуб казый өенә тирән уйга чумып, кара көеп килде.

—Урыс кенәзлекләре аша үткән чагында да безнең кәрванга ике мәртәбә юлбасарлар өере һөҗүм итте. Берсендә Идрис улымны кулга төшерделәр, соңыннан көч-хәл илә генә кире тартып алдык. Алда тагын да хәвефлерәк юллар. Ул шөһрәтле Бохара, Харәзем калаларына житкәнче ярымкыргый карлуклар, аймыклар, каныклылар яшәгән киң далалар буенча үтәселәр бар, ди. Мин улымны шул Бохара, Харәзем дарелфөнүннәрендә гыйлем эстәмәсме, дигән нияттән чыгып юлга алган идем. Мәгәр кыргый далалар аша аны исән-имин көе алып чыгасыма бик шикләнәм. Сиңа гозерем бар, казый. Сезнең «Мөхәммәт-Бакырыя» атлы гыйлем йортын да бик мактыйлар. Син минем улымны үз канатың ышыгына алып калып, аны пайтәхетенезнең шул үзәк мәдрәсәсенә урнаштырмассыңмы икән?

—И, борадәр! Һичнинди шик-шөбһә кичермичә берүк калдыра

күр. Идрисен минем өчен төпчек углым булыр,—дигән казыйның җавабын ишеткәннән соң гына, Әбү-Хәмитнең йөзенә беркадәр яктылык инде.

—Мин ничек тә тизрәк әйләнеп кайтырга тырышырмын вә юлларда көн дә сиңа саулык теләп дога укырмын, казый...

Сәяхәтче Әбү-Хәмит әнә шул рәвешчә үзенең улын Биләр каласында калдырып китте. Юлларда, мөгаен, догаларны да бик күп укыгандыр ул. Әмма Давытның бабасы әллә ни озак яши алмады шул. Комсыз Тулгак-Хәйдәр ханга каршы чыгып телсез калды, аннары пайтәхет базарларында хәер эсти-эсти җан да бирде. Әбү-Хәмит тә суга төшкән балта кебек булды, аның тарафыннан бер төрле дә хәбәр ишетелмәде. Очсыз-кырыйсыз, киң далалар аша үткән чакта юлбасарлар гомерен кыйдымы аның, әллә берәр авыру-фәлән эләктереп, үзе җан бирдеме—моны кемнәр белсен? Ә Биләрдә малай килеш кенә яшәп калган Идрис хәзрәт быел инде, әнә, дүртенче дистәсен тутырып килә. Ул хәзер Тотыклар урамындагы мәчетнең баш имамы.

Давыт сәетнең каш астыннан гына төбәлеп утыруын, ниһаять, Идрис хәзрәт үзе дә сизеп алды. Ул бермәлгә генә югалып калгандай булды, аннары ирен читләрендә, карашында елмаю чаткылары кабынып куйды. Тынлыкны өзеп, беренче сүзне дә ул башлады.

—Без син галиҗәнап хәзрәтләрне көттек. Монда утырган барча инсан синең шифалы сүзләреңә мохтаҗ, сәетемез.

Дин башлыгы кыйммәтле вә үзгә сүзләр эзләп маташмады, турыдан ярып сөйләүне хәерлерәк күрде.

—Ошбу йортка яшерен рәвештә вә ерак юллар үтеп килгән мөхтәрәм инсаннарның һәммәсен дә мин афәт илә тулы мәмләкәтемезнең хәсрәтен үз җилкәләренә күтәрергә әзер батырлар, дип беләм. Безнең морадымыз—газиз мәмләкәтне вә мөселман халкын җаһил Бәрәҗ хан илә аның катил сәрдәре япкан кара корым юрганыннан азат итү. Бәс, шулай икән, шифалы вә балдай татлы сүзләр сайлап утыру һич мантыйк эш булмас. Безгә мәмләкәтемезнең йөрәк тибешен тәгаен белеп тору күпкә отышлырак. Мөхтәрәм кунакларымызның тәфсилләбрәк сөйләгән хикәятен ишетәсе иде. Шуңа күрә, тәүге булып, курсыбай хәлләрен син бәян кылсаңчы, Корнай батыр?

Болгар каласының сәрдәре иңбашларын киңәйткәндәй итте, тамак кырып куйды.

—Минем әмирем эргәсенә, Хәмбәл бәктән качып, аның ике йөзбашы кайтып егылды. Хәмбәл үзенең алае илә Мәртүбә вилаятен тоташ талап үткән, байтак карьяларны яндырган. Аның газиләре чирмеш вә арларның йөзәрләгән кызларын мәсхәрә кылганнар вә йөзәрләгән ирләрен һәлак иткәннәр. Хәмбәл бәкнең нәфесе алай гына басылмаган, мәгәр. Ул үзе илә янә йөзәрләгән ар вә чирмеш кызларын, колчуралыкка вә кәнизәклеккә дип, мал көтүе урынына алып кайта икән.

Корнай, хәрбиләргә хас булганча, фикерләрен бер учка җыеп, бик төгәл сөйләсә дә, Давыт сәет, башын чайкап, гаҗәпләнү белдерергә мәҗбүр булды.

—Ә ул сезнең эргәгә кайтып егылган йөзбашлар колчура кызларны камчылаудан арып кына качмаганнардыр ич инде?

—Юк, гыйззәтле сәет. Алары аның Хәмбәл бәкнең үч алуыннан өркеп качкан.

—Ә үчнең сәбәбе нинди?

—Ул йөзбашлар бер чирмеш биенең кызын качырганнар. Шуңа күрә Хәмбәл бәк, җәлладына боерып, Җияш атлы бер йөзбашының билен сындырттырган. Ә болары үлем көтеп йөрүгә түзә алмаган.

—Мөгаен, монафикълардыр инде алар, үзләренә берүк таяна күрмә, батыр,—дип йомгак ясады да, Давыт сәет Әбүбәкер-оста тарафына йөзен борды.—Ошбу яу вә ошбу хәсрәтләр һөнәркяннар иңенә нindирәк йөк булып ята? Җаһил хан илә катил сәрдәр сезләргә тын алырга ирек калдырамы?

—Безнен мәгыйшәтне гомер сару, диеп атап була микән, вәли сәет? Ул тоташ сызлану илә сыкранудан гына хасил бит.

Анын сүзләрен раслагандай яндагы Гомәр-оста да ияк кагып куйды. Әбүбәкер, авыр сулаганнан сон, сүзен дәвам итте.

—Хәмбәл сәрдәр, мәмләкәтне талап, бар нигъмәтне үз өенә ташый. Анын артыннан ук ханиямез вилаятьләр, аймак вә түбәләрне янә талап үтә. Ул сонгы ике сәнә агымында гына да салым микъдарын өч тапкыр арттырды. Байтак һөнәркян илә субашларнын, игенчеләремезнен хания салымнарын түләргә жегәре юк. Мәгәр курсыбай бүреләре мона ташлама ясап тормый. Һөнәркяннарнын салым түләрлек байлыгы юк икән, алар анын ихатасындагы малын, коралларын, юрган-ястыкларын, кыскасы, сонгы кадагын да талап чыга.

Бик чәчелеп китмичә генә сүзгә Гомәр-оста да кушылды.

—«Кол кайгысы—бер качмак, би кайгысы—бер чапмак»,—дип дөрес әйтә халык. Хәлләремез тап-тач шунын кеби. Байтак һөнәркяннарымыз үзләренен алачыгын япты. Мәгъдән эзләү, аны чыгару эшләре тәмам сүнде. Ул гына да түгел, хәзер инде әллә никадәрле һөнәркянымыз кыпчак далаларына вә Бохара, Сәмәрканд әтрафларына качып китте. Әгәренки мәгыйшәтемез һаман шулай акса, янә ун-унбиш сәнәдән сон мәмләкәттә сынар һөнәркян да калмаячак.

—И-их! Сүзләрен хактыр, оста,—диде дә, Давыт сәет бер ухылдап алды.—Һөнәркяннарын, гомумән, халыкны талау бәрабәренә генә хакимиятне сакларга омтылган мәмләкәтнен нигезе черек бит анын.

Берара һәммәсе дә, уйга чумып, дәшми утырдылар. Бераздан сәетнен карашы Сувар ахунынын йөзендә туктап калды.

—Синен әле иртә язда ук Нур-Сувардагы «Ил-һун» мәчетендә яшерен фирка нигезләвен хакында мин тәгаен беләм, Бакир хәзрәт. Хакыйкатькә бәһа бирүгә калса, бүген безнен ошбу әтрафка жыйналуымыз да нәкъ синен шул мактаулы гамәлләрен үрнәгендә булды. Яшерен фиркагез кылган гамәлләр илә анын кануннарын без фәкыйрьләргә дә бәян итсән иде.

—Каламызда яшерен фирка пәйда булуга мин фәкыйрегез түгел, күбрәк сезнен борадәрегез Идрис хәзрәт гаепле, сәет тәкъсир. Ул—кыйтгамызнын жәнүби тарафында туып үскән инсан, анын каны безнен илә чагыштырганда күп мәртәбә кызурак. Умырткасыз хан илә анын катил сәрдәренә гомер буе буйсыну беллереп вә мәсхәрә кичереп мәгыйшәт итеп булмаячагын да без томаналарга нәкъ менә Идрис хәзрәт анлатты. Яшерен фирка төзү зарурлыгын ул раслады, анын кануннарын да нәкъ шул борадәрегез язды.

—Син һәрвакыт минем янда йөренгән сымак буласын. Ә ул Нур-Суварга сәяхәт кылырга кай арада гына житешәсен сон?—дип, Давыт сәет Идрис хәзрәткә карап елмайды да, аннары янә Бакир ахун тарафына ияк какты.—Сөйлә, хәзрәт.

—Безнен ерак бабаларымыз—һуннар—заманында бөтен жиһанны, барча халыкларны дер селкетеп торган. Мөселман кардәшләремез арасында өзелгән жепләрне янә тергезү вә ялгау—хәзер ин фарыз гамәлләр. Менә шул ният илә без фиркагә «Ил-һун» намен куштык. Морадымыз—һуннар мәмләкәтен янадан төзү, ягъни.

—Мин элгәре чакта бер тапкыр кисәткән идем инде, Бакир хәзрәт. Ерак бабаларымызнын наме «һун» булса да, алар кылган гамәлләрне бүген янә кабатларга ымсыну туры юлдан язуга тиндер. Һәрбер инсанга, һәммә мәмләкәткә үз гакылы, үз жегәре илә генә гомер кичерү фарыз. Куәте житмәс йөкне инбашына алган инсан да, мәмләкәт тә ахыр чиктә, барыбер, сытыла, егыла ул.

Давыт сәетнен усал кысылган керфекләр арасыннан төбәлгән утлы карашын үз йөзендә тоеп, мона кадәр авызына су капкандай дәшмичә утырган Идрис хәзрәт тә телгә килде. Ул инде сүзләрнен өресен генә сайлап тезде:

—Бакир ахун берникадәр ашыгып бәян кылды. Ерак бабалары һуннар булган барча мөселман халкы арасында кардәшлек вә берлек булдыру—безнең иң ахыргы морадымыздыр. Ә бүген без фиркамезгә азамат вә тугры инсаннарны Болгар мәмләкәтен җаһил хан илә аның катил сәрдәре талавыннан вә мәсхәрәсеннән азат итү өчен туплыймыз.

—Фиркагезгә инсаннар ниндәен шарт илә кабул кылына соң?

Җавап бирү бурычын янә Бакир ахун үз җилкәсенә алды.

—«Ил-һун» кардәшлегенә инсаннарның күбесе үзләренең йортларын, малларын сатканнан соң керә. Туплаган байлыкларын да тулаем көе шул кардәшлеккә тапшыралар.

—Андый гайре фидаилык илә андый фәкыйрьлек нигә кирәк инде?

—Моны мин уйлап тапмадым. Фиркане тәүге булып нигезләгән ирләр үзләре шундый таләп куйды. «Югалтыр малы, байлыгы булган бәндә һичбер вакытта да олуг гамәлгә бар гомерен багышлый алмаячак. Безнең фиркагә кабул кылынган һәрбер адәм дәрвиштән дә баерак булырга хокуклы түгел. Дәрвиш хәлендәге инсан гына ихтилал явына тәшвиш, икеләнү белми кушыла вә кире чигенә алмый». Тәүге ирләрнең таләпләре әнә шундый булды. Ә хәзер, чыннан да, фиркадәге кардәшләрнең байтагы дәрвиш алачыкларында гомер кичерә.

—Ишкәнсез ишәк чумарын,—дип, үз урынында чакматаштай кабынып, Әбүбәкер-оста сүз ыргытты.—Ихтилал явына сезнең таләпне әләм итеп чыксаң, ошбу мәмләкәттә тиздән бер һөнәркян дә, субашы вә игенчеләр дә калмый икән. Барча мал вә мөлкәтеңне сат та, гидай хәленә төш. Улчак син ихтилалчы. Гайре ансат ысул тапкансыз сез, менә истирәхәт.

Әбүбәкер-останың чәнечкеле сүзләрен Корнай батыр да бик тиз эләктереп алды.

—Сезнең Нур-Суварда төзелгән ул дәрвишләр фиркасендә газиләргә, азатларга вә казанчыларга бөтенләй дә урын юк икән бит. Ихтилалны корал күтәрмичә, корбаннар бирмичә генә яуламыйлар. Шулай түгел икән, сезнең фирка анда ниндәенрәк ысул илә Бәрәҗ ханны чәнчелдереп төшерергә, житмәсә янә һуннар мәмләкәтен тергезергә үк җыенадыр—бөтенләй аңлашылмый, мондый мәсләк мине аптырашка сала.

Усал төрттерүләрнең ызгыш-талашка күчүеннән шүрләп, Давыт сәет тә, ниһаять, тамак кырып куйды.

—Байтак гамәлләрегезнең хилаф икәнлеген инде төшенгәнсеңдер, дип беләм, Бакир хәзрәт. Без сезнең шарт вә таләпләрне кабул кыла алмыйбыз. Бүген безнең иң тәүге вә иң олуг морадымыз—Болгар мәмләкәтенең иминлеген, мөселман халкының азатлыгын, изге динемезнең пакълыгын саклап калу. Шуна күрә безнең фиркамезнең исеме дә, көрәш максаты да гайре кыска вә ап-ачык: ил вә дин—«Ил-дин». Ихтилал явына да безнең барчамызны ошбу чакыру дәшәр.

## 3

Талау-мәсхәрәдән азат тормыш өчен яуга күтәрелергә әзер торучылар саны айлап түгел көнләп үссә дә, яшерен фирканең гомере учак өстенә килеп эләккән күбәләкнеке сыман гаять кыска булды. Нинди ысул белән иснәнгәндер, әмма явыз Хәмбәл аның эзенә бик тиз төште. Салкын жиле, тукталу-ял белмәс янгырлары белән үзәкләргә үткән көзгә бер иртәдә курсыбайның тимер көбәләргә төренгән ике йөзләп җайдагы Тотыклар урамына таба чабып узды. Намаз вакыты булмаса да, мәчеткә бу көнне фирканең егермеләп әгъзасы тупланган, өстәвенә анда, бәхетсезлеккә каршы, Сувар каласыннан килгән бер дистәгә якын дәрвиш тә җыелып утыра иде.

[1]Хассә алай—шәхси гвардия, дружина.

Тигез итеп түшәлгән урам ташларында йөзәрләгән дага тавышлары ишетелгәч тә, Идрис хәзрәтнең йөрәген гүя зәһәр учакта кыздырылган инә өтеп алды, каракучкыл йөзе көл шикелле агарынып чыкты. Курсыбай башкисәрләренең нәкъ мәчеткә атап килүен ул күнеленең кайсыдыр бер өлеше белән хаталанмый-нитми тоемлады. Ярдәм көтәрдәй кешесе бар сыман, ул беркадәр кысыла төшкән озын керфекләре арасыннан төбәлгән хәвефле карашы белән бөтен мәчет эчен айкый башлады, кызуланып-янып кемнедер эзләде. Әмма вакыт үткән саен карашына хәвеф һәм шом гына өстәлде, янак читләрендә усал итеп кысылган урт сөякләре үк калкып чыкты. «Җәмит мөәзин кайда соң, яшь мөәзин кайда? Сабах намазыннан сонра битекче Госсам хозурына барып кайтам», дип кенә киткән иде бит, кая югалды соң?»

Колакларны сытып янгыраган тояк тавышлары мәчет каршына житкәч тынып калды. Ләкин икенче мизгелдә үк әллә сөнгеләр, әллә бүрәнә белән ордылар инде—урам якта дөбер-шатыр килеп ачылган капка шыгырдавы ишетелде. Кемдер кыргый тавыш белән жикереп сорау бирде:

—Әҗнәби[1] шайтан нәзарәттәме, юкмы? Аннан гайре мәсжеттә янә ни тиклем гыйсъянчы бар?

—Белмим.

Бу жавапны мәчет ихатасының капка төбендә торучы мөтәвәллият вәкиле бирде, күрәсең. Күкрәк тутырып тын алырдай ара узуга ихатада әүвәл ниндидер тонык чыжылдау авазы һәм аның артыннан ук ачыргаланып кычкырган тавыш ишетелде.

—А-а-эх!

Намаз бүлмәсенең йомшак келәмнәренә аяк бөкләп тезелешкән ирләрнең бер өлеше урыныннан купса да, мәчет имамының салмак һәм ипле ишарәсен шәйләп, кабат утырыштылар. Идрис хәзрәтнең каракучкыл йөзе күл өстедәй тыныч, фәкать карашында гына ниндидер шик, икеләнү газаплары пыскып яна иде. «Тыштагы бер бәндә «гыйсъянчы», дип әйтеп шәрран ярды. Бәс, димәк ки, кайсыдыр бер сатлык йә монафыйк жан безнең фирка хакында Хәмбәл этләренә барып тишкән. Кайсы кабихның гына денсезлеге вә наданлыгы булыр соң бу? Фирка хакында хәбәрдар бәндә икән, ул шәят, безнең илә янәшәдә генә йөргәндер. Ул икейөзле бәндә кем соң, алайса? Әллә инде Җәмит мөәзинме? Тфү-тфү, телемнән шайтан алсын. Ә шулай да?.. Аны безнең әтрафка ике сәнә элгәре үк таш кирмән эчендәге хан мәсжетеннән күчерделәр. «Аятел-көрси»не дә хаталанмый гына укый белми, мәкаме нәзек, имеш. Ә биредә ул колак сызлатырлык хата жибәрмәде, аһәне дә түзәрлек булды. Мәгәр нишләп диндар борадәрләре илә аралашмыйча, ике сәнә буе әкәм-төкәм сыман үз кабыгына йомылып хәят кылды соң ул? Вә бертуктамый ул нинди битекчеләр, кәтибләр, мөгаллимнәр хозурына йөрде? Әллә Җәмит мөәзин Бәрәҗ хан вә Хәмбәл яллаган шымчы идеме соң?..»

Тышта баскыч такталары авыр ыңгырашты. Мәчет ишеген күгәненнән суырып чыгарырлык гайрәт белән кисәк йолыктылар. Ишек түбәсеннән саклау өчен башын ия төшеп намаз бүлмәсенә Хәмбәл курсыбаеның иләмсез зур гәүдәле һәм кылый күзле йөзбашы Шәкүр жил-жил атлап керде. Әлбәттә, ул ялгыз гына түгел, як-ягына ханның хассә алаендагы азатлар да, курсыбай угланнары да тезелешкән иде.

Җанында курку әсәре бөтенләй булмаса да, Идрис хәзрәт йөзбаш Шәкүрнең кыяфәтен күргәч, калтыранып куйды. Бастырык шикелле озын, мәһабәт буй; һәркайсына дәү чүмәлә өярлек калын иңбашлары; бала башы кадәр зур йодрыклар; тегермән ташына охшаган яссы, тупас ияк; чиертсән кан чәчрәргә торган таза, кин яңаклар һәм карт сыерныкы кебек үк хиссез-төссез, аңгыра-надан караш. Йә, Ходаем! Канлы, шакшы бармаклары белән күкрәк читлегендәге жан-бәгырьнең төбен-тамырын

[1]Әҗнәби—чит ил, чит милләт вәкиле.

да калдырмыйча суырып алырга килгән Газраил үзе түгелме соң бу?

Гөбедән чыккан шикелле калын һәм тәннәрне чымырдатырлык усал тавыш яңгырады:

—Фетнә күтәреп инкыйлаб ясарга җыендыңмы, Иблис?—Бөерләренә таянып баскан кылый йөзбашы Идрис хәзрәткә төкерекләрен чәчеп җикерде.—Барып чыкмас! Синдәй Иблис коткысына түнгән һәрбер гыйбад та үзең кебек үк мордар китәр[1]. Әйдә кузгал! Хания зинданында син килмешәкне юксынып тимер эскәк вә камчылар еглый.

Ерак Әндәлүсия вәкиленең йөзе иң хәтәр давылларны да өшкереп бирми торган мәгърур имән сыман үзгәрешсез калды.

—Аллаһы Тәгалә йортына тәһарәтсез сыйракларың илә иңеп өрмә, кассап[2]! Җаһил ханыңның зинданы илә дә өркетмә! Минем андый туным инде күптән тузган.

—Ах, син әле чәңгелди дә беләсеңмени, көчек?—дип, янә кабынды да, тырмадай кулларын канат сыман җәеп, йөзбаш Шәкүр алга омтылды.

Идрис хәзрәт мәчетнең михрабында аякларын бөкләп утыра иде. Үгездәй иләмсез гәүдәле Шәкүрнең чандыр хәзрәт өстенә юнәлүе нәни чебине алырга төшүче кансыз тилгән кыяфәтенә охшап калды. Хәзрәтнең як-ягында утырган дистәләп ир капылт кубып урыннан күтәрелде. Кайсыдыр ирнең җилән эчендәге билбавында көмеш хәнҗәр сабы ялтырап китте. Ихтилалчыларның урыннан кузгалуы азатлар һәм угланнар өчен дә әмер сыман булды. Кылычларын кыннан суырып, алар яуга ташланырга әзерләнде.

Идрис хәзрәт боларның һәммәсен дә күз кырые белән ачык күреп торды. Һичбер төрле шик юк: ихтилалчылар тагын бер саксыз адым ясый-нитә калса, Хәмбәл җәлладлары аларны утын әрдәнәсе урынына тураячак иде. Идрис хәзрәт ашыгып аяк очларына калыкты. Тыныч тавышы чишмә суы сыман агып чыкты.

—Денсез кяферләр сыман кыйланып, Аллаһ йортын кан илә таплый күрмәгез, инсаннар! Йөзбаш Шәкүр! Угланнарыңа кылычларын яшерергә боер. Тәртә арасына җигеп куйган атка буталак та салу кирәксез вә артык бер гамәлдер. Мин синең ул ханияң хозурына кылыч илә төртмәсәң дә барам. Хан тиклем хан шәрифләре илә бәхәс илә гәп кору бәхете теләсә кайсы әҗнәби гайбадына тәтеми ул.

Идрис хәзрәт үзенең каршында ике яклап тезелешкән ихтилалчыларга күз йөгертеп чыкты да, кыю атлап, ишеккә юнәлде. Тыны чыккан туп шикелле шәлперәеп калган кылый йөзбаш сүзсез генә аңа иярергә мәҗбүр булды. Ул мәчет ихатасында гына кабат айнып китте һәм иярченнәренә борылып, боз чәйнәгән кеше шикелле тешләрен шакылдата-шакылдата усал ырылдады:

—Иллебашы Тәхәү үзенең угланнары илә монда кала. Без киткәч тә, мәсҗет эчендәге гыйбадларның һәммәсен кулга алыгыз. Гауга куптармагыз, калага шылт иткән тавыш та ишетелмәсен. Ошбу гыйсъянчыларның очына чыгасы бар, шуны онытмагыз.

## 4

Утызга якын фиркаченең кулга алынуына ун көн вакыт үтте. Зинданнан хак-тәгаен бер хәбәр дә чыкмый, кала буйлап күбесенчә имеш-мимеш кенә йөри иде.

—Төн саен зинданнан ыңгырашкан-сыкранган тавышлар ишетелә. Тоткыннарны тәүлек буена җәзалыйлар икән.

—Җәлладлар Идрис хәзрәтне аеруча кансыз җәзалыйлар, ул бичарага нә йокы, нә су бирмиләр, ди...

[1]Мордар китү—гөнаһларыңны юарга өлгермичә вафат булу.

[2]Кассап—ит чабучы. Биредә ул «җәллад» рәвешендә.

Давыт сәет шушы ун көн эчендә күзгә күренеп бетеренде, кипте. Ул күп вакытын Җәмигъ мәчетенең нәзарият бүлмәсендә үткәрә, гыйбадәт сәгатьләре житкәч кенә, олы залның михрабына чыгып утыра иде. Ун көн буена ул бер тапкыр да мөнбәргә күтәрелмәде, хәтта, жомга намазларында да вәгазь укымады. Аның суырылып калган, кара көйгән йөзен барча диндар мөселман да күрде, әмма аны гаепләп тел тибрәтүче бер генә имам-хатыйб яки ахун да табылмады.

Бүген дә өйлә намазыннан соң, Давыт сәет беркемгә бер сүз кушып тормыйча, янә нәзарият бүлмәсенә кереп бикләнергә ашыкты. Бүлмәгә ишекне каты ябып узды, тәрәзә буенда, келәм өстенә тезелгән йомшак мендәрләргә таба озак карап торды, ләкин утырмады. Тагын да бөкрәя төшкән гәүдәсен, чал сакалын алга таба сузып ишекле-түрле йөренгәли башлады, тәрәзәләр буена килеп житкән саен урам якка караш ташлап алды. Аның кемнедер түземсезләнеп көтүе йөзенә чыккан иде.

Икенде намазы житкәндә, ниһаять, мәчет болдырында таныш аяк тавышлары ишетелде. Ләкин тавыш иясе ялгыз гына түгел, ул үзе белән ниндидер юлдаш та ияртеп кайта иде. Сәет йөзе белән ишек тарафына борылып басты. Бүлмәгә Мирхажи белән Сувар имамы Бакир хәзрәт узды. Соңгысын тануга Давыт сәет гажәпләнеп, хәтта, куркып калды.

—Әссәләмүгаләйкүм, шәриф сәетемез.—Җавап урынына Давыт сәет ияк кенә какты, озак сузмыйча, теленә килгән беренче соравын да бирде:

—Ә син Биләрдә нишләп йөрисең соң әле, Бакир хәзрәт? Зинданда газап кичүче тоткыннарның санын арттырмакчы буласыңмы әллә?

Көтелмәгән кунак та күңелендәге уен яшереп маташмады.

—Мин дә кул кушырып кына утырыйм да, хан жәлладларының «Ил-һун» мәсжеден килеп туздыруын көтеп ятыйммыни?

Бакир хәзрәт сүзләрендә әче киная тоюдан сәетнең карашында усал ут кабынды. Ләкин ул жавап кайтарырга өлгерә алмый калды, кунак хәзрәт әйткән авыр хәбәр аның өчен күсәк белән орган кебек булды.

—Бүген танда хания зинданында безнең ике фиркачемез жан тәслим кылган.

Сәет үзенең Бакир хәзрәт жиңенә барып ябышуын тоймыйча да калды. Карашы ялварулы да, кызганыч та иде.

—Зиндан ихатасына якын да барып булмый, аны угланнар саклый бит. Син соң каян белдең? Ялган хорафат кынадыр ул син ишеткән хәбәр. Иректә калган фиркачеләремезне тәгаенләү бәрабәренә индерелгән бер хәйлә генәдер, бәлкем.

—Э-э-эх, ялган хорафат кына булса икән! Юк шул, сәет. Минем бажайның угылы мәгълүм курсыбайда унбашы бит. Бүген төнлә зинданны ул саклаган. Иртән өенә кайткач, шәһит борадәрләремез хакындагы сагышлы хәбәрне миңа тач шул әйтте.

Сәетнең тәнендә гүя жегәр бетте, буе бер карышка чүгеп, кечерәеп калды. Аның иңбашлары гына түгел, инде чал сакалы да дер-дер килә иде. Сагыш тулы моңсу карашы да күбесенчә башкалардан олы киңәш, ашыгыч ярдәм көтте.

—Нишләек соң инде, Бакир хәзрәт? Зиндандагы гөнаһсыз борадәрләрне йолып алу өчен ниләр генә кылыйк?

—Җәллад илә таждарларның[1] һәммәсе дә асылда барыбер чукрак була. Аларны иманга килергә өндәп кенә борадәрләребезне зинданнан йолып алу акылга сыешлы гамәл түгелдер. Чапан астында йодрык төйнәп вә аны да әле таждарларның шәүләсенә генә селеккәләп бәгъзе дошманны да өркетеп булмый. «Иелгән башны кылыч кисми»,—дип тәкърарласалар да, ошбу тәгъбирнең киресе дә бардыр. «Күп иелгән бәндәнең башына төкерәләр». Ат кеби түземле булган без фәкыйрьләргә дә инде тештырнагымызны күрсәтә башларга бик вакыттыр.

[1] Таждар—падишаһ, хаким, таж иясе.

Кунакның тәвәккәллеккә өндәгән мондый тәкъдиме дә икеләндерде бугай, сәет аңа шөбһәле карашын төбәп, байтак дәшми торды. Аның акыл казанын кыргычлап әйткән алдагы сүзләре дә җавап тан бигрәк үзалдына сөйләнүне генә хәтерләтте.

—Ходай Тәгалә безне җәлид корбаннардан, кан коюдан араласын иде.

—Минем тәгбиремне генә азсынасың икән, Корнай батыр бәян иткән асыл искәрмәне дә исенә ал син, сәет. «Азатлыкка корбаннарсыз гына ирешеп булмый».—Бакир хәзрәтнең тавышына корыч чыңы өстәлгәндәй булды.—Азатлык—ул эссе табада пешкән майлы коймак түгел. Аны берәү дә безгә үзе китереп бирмәс. Бер кирмән, бер кальга да үз ихтыяры илә бирелмәстер. Аны һәрдаим тимер кыршау сыман тулгамага алып, кайнар вә гаярь һөҗүм илә яулау гына җиңү китерәдер.

Сәет уйга чумды. Аның каш астыннан төбәлгән карашы улы Мирхаҗи белән Бакир хәзрәтнең йөзләре буенча күченеп йөрде. Шик юк, аны уйларында ике яр, ике чик газаплый, ләкин ул шуларның берсен дә сайлый алмыйча җәфалана иде.

Бакир хәзрәтнең түземлеге сынды, күрәсең, ул әүвәл акрын гына тамак кырып куйды. Тавышы да ипле, тыныч чыкты.

—Мине Тотыклар урамында Нур-Сувардан бергә килгән борәдәрләрем көтеп тора булыр. Мин кузгалыйм, сәет.

Келәм өстенә чүгеп, сүзсез генә дога кылдылар. Аягүрә кабат күтәрелгәч, сәет кунакның йөзенә тәкәлмичә генә телгә килде.

—Ходай Тәгалә үзе сакланганны гына сакларм ын, дигән бит. Син берүк үзеңне дә, бәгъзе инсаннарны да кайгы-хәсрәттән араласаң иде, Бакир хәзрәт. Ауга чыккач җәнлекләрнең һәммәсен дә ук очына элеп кенә түгел, киресенчә, күп нәүбәттә хәйлә вә сабырлык илә кулга төшерәләр.

Кунак ирен читләре белән генә елмайгандай итте, әмма йөзендәге тәвәккәллек һич тә кимемәде.

—Мин үз фикеремне әйттем инде, сәет. Кире танасым юк. Бәхәсфәлән кормый гына бәхилләшик.

—Ничек «бәхилләшик?»

Сәетнең күзләре янә шөбһә-хәвеф белән тулды. Ә Бакир хәзрәтнең йөзе һаман тыныч калды.

—Шулай, сәет. Без һәммәбез дә Аллаһ колларыдыр. Алда ни язганны белеп булмый. Аерылышкан саен бәхилләшүне таләп итә торган читен замандыр бу. Сау бул, сәет.

Бакир хәзрәт кыю адым белән чыгып китте, ә сәет әле байтак вакыт ишеккә төбәлеп торды. Инде берзаманны ул карашын Мирхаҗи йөзенә күчергән генә иде, тегесе көтелмәгән бәя белән гүя өтеп алды.

—Ә Бакир хәзрәт хак сөйли бит, атам. Азатлыкны корбаннарсыз гына яуламыйлар.

Давыт сәетнең янак тирәләре тартышып-тартышып куйды, җикерәсе килде. Ул мыегы да ныклап куермаган Мирхаҗиның хаклы булуын аңлый, ләкин газиз улына да үз йөрәген ачып сала алмый иде шул. Ул бит сәет кеше, Мөхәммәт галәйһис-сәламнең ерак оныгы, изге дин башлыгы. Шулай икән, ничек инде ул бер үк Адәм балаларының кулларына корал күтәреп сугышуга, үзара суешуга фатиха бирә алсын, ди?..

Бераздан нindидер хәйлә табып, Мирхаҗи да нәзарият бүлмәсен ташлап чыкты. Сәет стена буендагы миндәрләр өстенә чүгәләде дә, хәрәкәтсез калды. Менә, бервакыт манараларда мөәзиннәрнең азан әйткән тавышлары яңгырап ишетелде. Сәет тәрәзәгә караш ташлады һәм хәйран аптырап китте. Урамнарга инде караңгылык яткан, ахшам намазы да килеп җиткән икән.

Азан тавышлары беткәннән соң, бөтен шәһәр мәгарә тынлыгына чумган кебек булды. Бу тынлыкның давыл алдыннан була торган бер бушану, ял алу икәнен Давыт сәет, әлбәттә, әлегә тоймый иде.

... Сәетне кара төн уртасында йокыдан урам буйлап сузылып килүче

хәвефле бер тавыш уятты.

—Курсыбай бистәсендәге йортлар яна! Торыгыз, торыгыз! Янгын, янгын!

Сәет әүвәл әле бар хәвефне аныша алмыйча да ята иде. Әмма зиһенендә калыккан беренче уй ук аны түшәгеннән сикереп торырга мәжбүр итте:

—Бакир хәзрәт! Мирхажи кайда?

Сәет үзенә ут капкан шикелле ашыгып киенде дә, өеннән атылып чыкты. Урам буйлап кулларына кайсы—чиләк, кайсы тимер ыргаклы колга тоткан ирләр йөгерешә. Бәрәж хан төзеткән яна мәчет ягын, әйтерсең лә, шәфәкъ кызыллыгы каплап алган. Көчле ут яктысы мәчетнең ике биек манара стеналарыннан кайтарылып уйный. Сәер, гажәп: мондый яктылыкта Бәрәж мәчете яман сөзешергә хәзерләнгән усал тәкә кыяфәтенә охшап калган.

Давыт сәет, жил-жил атлап, шул тарафка ашыкты, гыжлап чыкты. Әле Бәрәж мәхәлләсенә караган урам-тыкрыклар ук халык белән тулган, ә Курсыбай бистәсе эченә һич үтмәле түгел. Шулай да халык сәетне бик тиз шәйләп өлгерде, әле теге, әле бу төркем, читкә түнеп, ана юл арчыды. Әмма һәр төркем саен диярлек ярымкөенеп, ярымсукранып пышылдаган сүзләр сәет колагына эленеп-эленеп барды.

—Үч алырга ният итүчеләр юкка гына мондый гамәл кылган. Дуамаллык бит бу. Беткә үч итеп, тунны утка ягалар димени?

—Хәмбәл-кассап элгәре көннәрдә дә этләр кеби котырына иде. Моннан ары бәйдән тәмам ычкыныр инде.

—Янә нинди хәсрәтләр илә газап кылырсын икән безне, йә Раббем?!

Сәет өеннән чыкканнан бирле кара көеп һәм авыр хәсрәткә чумып килә иде. Бер төркем тарафыннан шактый сәер, хәтта, кыю янгыраган фикер ирексездән сәетне дә башын чайкап куярга мәжбүр итте.

—Монысы-монысы, мәгәр янгын ошбу бистәдән гайре жиргә күченмәсә генә ярар иде инде, и Ходаем?!

Сәет Курсыбай бистәсе чигенә килеп житкәч, барча бәла-каза ана бөтен чынбарлыгы белән ачылгандай булды. Янгын нигездә ике якта зилзиләдәй ярсып котырына, әмма бистә уртасындагы ике йортны да хәтәр ялмап алган. Бер як читтә аерым төркем сыман тезелеп баскан мөәзин һәм имамнар Давыт сәеткә хәлне өзек-өзек кенә итеп аңлаттылар.

—Казачылар бистәнең ике башына да утны бер үк вакытта салган. Мәгәр алардан да элгәрерәк булып йөзбаш Шәкүр илә меңбаш Сөләйманның нигезләрен ут ялмаган, диләр. Сыбайларның[1] берсе дә өйләреннән тышка чыга алмаган. Катил казачылар ике нигезнең дә ишек-тәрәзәләрен тимер чөйләр илә бикләп киткән булган.

Сәет агарынып калган йөзен күтәрде дә, тик бер сорау бирде:

—Явыз бәндәләрнең эзенә төшкәннәрме?

—Юк әлегә. Һәр капуга фәрман юлласа да, сәрдәр сонга калган. Шәрекъкапу эргәсендәге тоткавыллар үзләре дә гаип булганнар, ди.

Сәетнең күңеленә беркадәр тынычлану ингән кебек булды. Әмма сабырсызлык һәм хәвеф тулы карашы белән ул һаман бистә урамнарын, халык төркемен айкап чыга бирде. Бәла янына жыелган таныш кешеләр бик күп, тик алар арасында аның төпчек улы Мирхажи юк иде...

Тан атканда ут давылы тынды. Кара корымга, шабыр тиргә баткан йөзәрләгән ирләр өйләренә жир сөргән ат шикелле алжып таралдылар. Бер чынаяк кайнар чәй эчү дә алар өчен иң мөкаддәс һәм иң тансык гамәл булып тоела иде. Ләкин аларга шул бәхетле изрәү ләззәте дә тәтемәде. Урамнар буйлап ярсу юртакларга менгән ярсу мөнадиләр[2] чабып узды.

—Барчагыз да әгъзам хан кирмәне янына жыелыгыз. Бүген жинаять-

---

[1]Сыбай—гаскәр, отряд башлыгы. Офицер мәгънәсендә.

[2]Мөнади—урамнарда хан әмерен кычкырып йөрүче, глашатай.

[3]Салкын таш—жәза бирү урыны.

ләре ачылган гыйсъянчыларны Салкын таш[3] янында гадел җәза көтә. Әгъзам ханиямез фәрманына буйсыну күрсәтмәгән инсаннарга да кичекмәстән җәза биреләчәк.

Мөнадиләрнең тәүге сүзләрен ишеткәч тә, сәет коелып төште. «Йә, Ходаем! Мирхаҗи углым да ут салуда катнашып, хан җәлладлары кулына тарымады микән?»—дигән зәһәр уй зиһенен яшен сыман капылт яндырып узды. Тәнендә җеп өзәрлек җегәр калмады, әмма үз-үзен мәҗбүр итеп булса да Давыт сәет урыныннан купты. Хан фәрманына сүзсез буйсынырга тиешле кара халык арасына кушылып, таш кирмәнгә таба йөз тоту аның бөтен мин-минлеген изә, үкенечле уйлар йөрәген утлы күмер сыман талый иде.

«Элгәре заманнарда хан-әмирләр үз мәмләкәтенең сәетләрен урамда очратса да, иярләреннән төшеп аларның җиң очларыннан үбә, бил бөгә торган булганнар. Болгарга ислам динен кабул кылдырган әгъзам Алмыш малик, хәтта, Баһдад хәлифәсенең илчесе Сәһсән әр-Рәсиби илә аның сәркатибе Әхмәт ибне Фадланны да тезләренә чүгеп каршылаган. Ә ябай халык исә сәетләрне мәгыйшәттә хакимнәрдән һәрдаим өстен күргән. Нә бәрабәренә? Чөнки сәет—Мөхәммәт галәйһис-сәламнең ерак оныгы ул, ягъни изге заттыр. Мәгәр индеге көндә Болгар мәмләкәтендә таҗдар булып Бәрәҗ хан кеби җаһил вә дәһри бәндә утырганда үзеңне аннан да югарырак яисә аңа тиндәш вәли инсан итеп санау муафыйк гамәлмени? «Тибешкәндә тинең булсын»,—дигән ата-баба. Җаһил залим илә тибешмичә яшәү хәерлерәк. Җитмәсә... җитмәсә әле Мирхаҗи угылымның да кайда йөрүләре нәмәгълүмдер. Шулай икән, мин аның бәрабәренә булса да җаһил таҗдар катарында бил бөгәргә мәҗбүр. И, Ходаем! «Бер бәндә дә үзенең кендегеннән ары сикерә алмый»,—дигәннәре шушы микәнни соң?..»

Хан сараен һәм Хан мәчетен ике катлы таш диварлар белән әйләндереп алган дәһшәтле кирмән каршындагы иркен мәйдан халык белән шыгрым тулы иде. Сәет алга узды. «Салкын таш» дип аталган җәза урыныннан бер читтәрәк өсте киң такталар белән түшәлгән калку мәйданчык янына килеп җитте. Галәмәт зур сәкене хәтерләткән әлеге мәйданчык өстенә чит мәмләкәт кунаклары, эре сәүдәгәрләр, йомышы төшеп пайтәхеткә килгән кала биләре, байтак мәчетләрнең имамхатыйблары тезелешеп баскан.

Юл ярып, сәетне түргә уздырдылар. Анда вак мендәрләр белән түшәлгән келәм дә бар иде, сәет шуңа инде, дога кылды. Аннары кирмәннең таш стеналары бизәкле гөмбәз белән каплап ясалган зур балконга сабырсыз һәм хәвеф тулы караш ташлап алды. Олуг фәрманнарны игълан иткәндә яисә дәүләткүләм җинаятьчеләрне үлем җәзасына тарткан чакта Бәрәҗ хан, гадәттә, үзе дә балконга чыгып утыра һәм мәйдандагы хөкем үтәлешен манзара кылырга ярата торган иде. Сирәк кенә, елына бер-ике мәртәбә, аның кайбер җинаятьчеләрне гафу иткән чагы да булгалады. Бүгенге фәрман ни белән төгәлләнер дә, бичара тоткыннарны ниләр көтә икән?..

Билгесезлек, тынлык белән бик озак итеп газаплагач кына, таш кирмән дә уянгандай булды. Менә, бервакыт авыр шыгырдап, имән капкалар ачылды һәм мәйданга җайдаклар ташкыны агылып чыга башлады. Алдан килешенгән шарт булган, күрәсең, шул минутта ук Курсыбай бистәсе ягыннан да йөзәрләгән җайдак килеп керде. Алар санаулы мизгел эчендә халык ташкынын вак-вак түтәл-төркемнәргә бүлеп бетерделәр. Салкын таш ягыннан кирмән капкаларына кадәр булган араны да кылычларын кыннарыннан алган җайдаклар сафы әйләндереп чыкты. Шул ук Салкын таш өстенә мөнадиләр һәм җәлладлар калыкты. Бар мәйданны мәгарәдәй тынлык биләп алды, Меңәрләгән күз таш кирмәннең биек диварлары өстенә текәлеп, хәрәкәтсез калды.

Ниһаять, анда да җанланыш сизелде. Әүвәл зур балконга тәхет чыгардылар. Кулларына тәвис каурыйлары белән бизәлгән җилбәзәләр

тоткан ике ир анын як-ягына басты. Аннары балконга Хәмбәл сәрдәр, хассә алай башлыгы, ханнын наиблары, тәхет варисы булган уллары берәм-берәм чыгып тезелеште. Ин ахырдан гына Алыптай гәүдәле дүрт жансакчы әйләнәсендә Бәрәж хан үзе дә пәйда булды. Барча халык билен түбән иеп сәждә кылды. Давыт сәет кенә таш сын шикелле хәрәкәтсез калды. Ул карашын әле хан, әле сәрдәр тарафына күчерә-күчерә аларнын жирәнгеч йөзләрен күзли иде.

Кайсы ишарә биргәндер, сәет улкадәресен шәйләп өлгермәде, әмма ул арада инде бер мөнади Салкын ташнын уртасынарак чыкты. Анын тамак ярып кычкырган усал тавышы күк күкрәүгә охшап янгырады.

—Җәнаб әгъзам хания хәзрәтләре бүген танда олуг мәмләкәтемезнен бар халкына шундый фәрман житкерергә түбәнчелек кылды. Мәмләкәтемезнен кайсыдыр ки затсыз, мәкерле вә нәжес адәмнәре, яшерен фирка төзеп, пайтәхетемездә канлы инкыйлаб оештырырга, шундый ысул илә хания хәзрәтләренен гомерен кыярга ният корган булган. Очраклы рәвеш илә генә ошбу гыйсъянчылар төркеме фаш ителде, бәгъзеләре кулга алындылар. Мәгәр ошбу зобани вә бәдбәхет бәндәләрнен гайре яман чире мәмләкәтемезнен инде башка калаларына житеп тә тамыр жәйгән. Шул гыйсъянчыларнын мөридләре бүген төнлә зиндандагы жинаятьчеләр өчен үч алмакчы вә әгъзам таждар хәзрәтләрен өркетмәкче булып Курсыбай бистәсенә ут салдылар. Үкенечкә каршы, зобанилар пайтәхеттән качып котылдылар...

Йөзенә үк бәреп чыккан авыр кичерешләрне чит-ят күзгә күрсәтмәс өчен башын түбән иеп утырган Давыт сәет үзе дә сизмичә жинел сулап куйды. «Бакир хәзрәт тә, Мирхажи да жәлладлар кулында истиһза кичермиләр, Аллаһка шөкер!» Әмма мөнадинын мәйдан янгыратып кычкырган алдагы сүзләре янә сәет йөрәген кайнар хәнжәр сыман телеп узды.

—... Мәгәр зобанилар әгъзам хания жәнабларынын гадел хөкеменнән һич тә котыла алмас! Нур-Сувар каласынын «Ил-һун» мәсжетендә дә гайсъянчыларнын шундый ук төркеме оешкан булу инде тәгаенләнде. Аларны кыйрату вә кулга алу өчен әгъзам таждар жәнаблары курсыбайнын ике менлек алаена Нур-Суварга төбәп юл чыгарга катгый фәрман бирә. Ә гыйсъянчылар төркемен нигезләгән вә зинданда килеш тә ирektәге зобаниларны Курсыбай бистәсенә ут салырга котырткан төп язькычы, бәдбәхетләр башлыгы Идрис-әжнәби бәгъзе инсаннарга сабак булсын өчен ошбу Салкын таш эргәсендә кабыргасыннан асып куелачак!

Кемнәрдер «аһ» итте, күпләр өлгермәде. Кирмән диварлары өстендә сорнай, дулбаз авазлары янгырап алды. Янә кирмән капкалары ачылды һәм тоташ кызыл киемнәргә төренгән жәлладлар әйләнәсендә Идрис хәзрәт күренде. Аны тану түгел, төсмерләү дә авыр, ун көн элек гайрәт бөркеп торган имам-хатыйб хәзер инде шәүлә булып кына калган иде. Анын ике кулын да жилкәсенә салынган юан колгага каерып бәйләгәннәр. Шул ук колга очларына бәйләп куелган өстәмә арканнарны жәлладлар ике яктан усал тартып килә. Хәзрәт аякларын сөйрәп кенә атлый, жәлладлар арканнарны тартып бармаса, шундук авар төсле.

Идрис хәзрәтне Салкын ташка терәлеп үк торган дар астына сөйрәп китерделәр. Мәйданда көткән жәлладлар бер башына тимер ыргак аскан сүс арканны дар агачы өстенә аркылы ыргыттылар. Кирмән диварларындагы дөмбакчылар күн барабаннарга кагып куйды. Тәннәр чымырдады. Тагын бер минут чамасы вакыт үтәр һәм мәйданда коточкыч жәзалау башланыр сыман иде.

Шулчак Давыт сәет урыныннан купты. Чебен очкан аваз да ишетелерлек булып урнашкан шомлы бу тынлыкта анын калтыранган тавышы янгырады:

—Гөнаһсыз инсаннарны нахак жәзага тарту хакындагы фәрманнарынны кире алсан вә төзәтү кылсан иде, Бәрәж таждар. Жәлладларын жәза ысулы илә сорау тоткыннарга нахак яла якканнар вә шулай итеп сине алдаганнар. Идрис-әжнәбинен вә зинданында газап чигүче

тоткыннарның да, Сувар каласындагы «Ил-һун» мәсҗеде муллаларының да һичбер языгы юк. Асылда, Болгар мәмләкәте тәхетендә инкыйлаб кылырга кирәклеген фәкать мин төшендем, шул хакта бәгъзе бәндәләргә үзем бәян кылдым. Курсыбай бистәсенә ут салган, үч салган, үч алучы да мин булырмын...

Кирмән өстен котырынып, ихатайлап көлгән тавыш каплап китте. Бәрәҗ хан башын артка ташлап, бот чабып шаркылдарга тотынды, аңа сәрдәрләрнең, наибләрнең мәсхәрәле көлү тавышлары да килеп кушылды. Бәрәҗ хан уң кулын югарыга күтәрде һәм мәйдан өстен янә тынлык биләп алды.

—«Җинаятьче зобанины йолып калудан вә аклаудан да зуррак гөнаһ юктыр». Ерак бабаң Коръән шәрифләрендә бәян кылган ошбу канунны ничек онытасы иттең, Давыт сәет? Аннары бөтен гавам хозурында көфер сүз сөйләүдән, җаһил бәндәләрне түнтәрешкә котыртудан, янә дә килеп кылмаган гамәлләр өчен үз-үзеңә яла ягудан вә языкка алудан ничек шүрләмисең?

—Үземә языкка итеп алган бер генә дә ялган сүзем юктыр. Ошбу әҗнәби Идрис хәзрәтне дә инкыйлаб юлына басарга мин котырттым. Минем гөнаһ сәбәбе илә ул газаплар кичте. Моны тәгаенләү синең ихтыярыңдадыр. Гадел таҗдар икәнсең, үзең сорап кара.

Бәрәҗ ханның да, мәйдандагы барча халыкның да сабырсызлык тулы карашы Идрис хәзрәткә төбәлде. Ул өстәмә сораулар көтеп интекмәде, усал тавыш белән ярып салды:

—Давыт сәет ерак бабасы Мөхәммәт галәйһис-сәлам кеби үк изге заттыр. Тоткыннарны кызгану бәрабәренә генә үз өстенә яла җыя бит ул. Үзеңнең җаһил вә зәгыйфь зиһенле хания булуыңны барча гавам хозурында бәян итмә, залим. Синдәй бәдбәхетне тәхетеңнән кыйратырга җыенган зобани—фәкать миндер. Синең дар агачы өстенә дә мин курыкмый менәм.

Йөзе бурлат сыман кызарынган хан дөмбакчылар тарафына борылып ияк какты, шул мизгелдә үк мәйдан өстен куәтле барабаннар тавышы каплап алды. Идрис хәзрәтнең өстендәге чапанын һәм күлмәкләрен умырып төшерделәр. Какча тәнле җәллад тимер ыргак очын хәзрәтнең касыгына китереп тыкты. Мәйдан ташлары өстенә кайнар кан чәчрәде. Беркадәр вакыттан соң инде һушсыз калган хәзрәт сүс аркан очында эленеп тора, башы исә күкрәгенә салынып төшкән иде.

Бәрәҗ хан балкондагы тәхетеннән купкач, дөмбакчылар тавышы да тынды. Күпләр, күрәсең, ханның ярлыкавын көтә иде, яңа фәрман көтеп ана текәлделәр. Ләкин Бәрәҗ читкә атлады да, инде балкон ишегенә таба карап басты. Шулчак аңа кызган тавыш белән янә Давыт сәет мөрәҗәгать итте.

—Ошбу газапларны туктат, Бәрәҗ! Юкса...

Җирәнгеч йөзен яртылаш кына борып, җилкәсе аша хан да сүз ташлады:

—«Юкса», ни кылырсың?

Сазлык эченә кереп баткан һәм хафага калган бичара шикелле якягына карап алды да, Давыт сәет такта мәйданчыктан Салкын таш өстенә йөгереп менде. Икенче мизгелдә исә иңнәрендәге җиләнен салып ташлады һәм шуңа сузылып ятты.

—Син Идрис хәзрәтне дардан төшермичә вә Нур-Суварга курсыбай юллау хакындагы фәрманыңны кире алмыйча торып, минем ошбу урыннан мәңге кубасым юк. Син иманга килгәнчегә тиклем мин үземә «Кол» ләкабын алам, янә ошбу урында ук ачлык игълан итәм.

—Ихтыярың, сәет. Олыгайган бәндәдә сабый бала акылы да калмый, дигәннәре хактыр, шәят,—дип, борын астыннан гына бер көлемсерәде дә, Бәрәҗ балкон ишегенә кереп, гаип булды.

## 5

Давыт сәетнең гаделлек, иман, тыныч хәят, дип җан атулары—бары да юкка гына тырышу булып чыкты. Курсыбай бистәсендә купкан янгын ул әле барыр юлында котырып-ташып агачак зур дәрьянын инеше, чишмә башы гына булган икән. Болгар җирендәге туфан-зилзиләләргә охшаш коточкыч давыл көннәр, сәгатьләр саен көчәя барып шашты. Ике яман көч арасындагы тәүге бәрелеш һәм кан коюлар һаман да шул кирмән мәйданында булып узды.

Идрис хәзрәт дар агачындагы коточкыч газапларга озын тәүлек буе түзде дә, икенче көнне таң атканда мәнгелеккә тынды. Сәет анын үле гәүдәсен ыргактан төшерү турында таләп куеп каравылбашына мөрәҗәгать итте. Әмма ул да үз теләге белән һични кыла алырдай ирекле зат түгел иде, шуна күрә кулларын ике якка җәеп биргән җавабы да гаять кыска чыкты:

—Хан яисә сәрдәр җәнабларынын шәхсән фәрманыннан гайре мәетне дардан төшерергә һичбер хакым юктыр. Минем дә башым ике түгел бит, ни кылыйм сон, сәет?

Дар агачында газап чигүче Идрис хәзрәт һәм Салкын таш өстенә сузылып яткан сәет янында калучы теләктәш имам-хатыйблар, мөәзиннәр, мөридләр, һөнәрчеләр, гомумән, гади халык мәйданда әле байтак кына иде. Шулар арасыннан бер имамны сәет нык гозәрләп әүвәл Хәмбәл, аннары Бәрәҗ хан янына илче итте. Ләкин илче имам ике тарафтан да бер үк төрле җавап алып кайтты.

—«Актык гыйсъянчыны кулга алганчы аларнын башлыклары булган ошбу әҗнәби дарда эленеп торыр. Канлы карачкы вак кош-кортны гына түгел, эре-эре тилгәннәрне дә яман өркетә ул».

—Ходай Тәгалә хайваннарга әгъза өләшкәндә берникадәр хыйлафлык вә хата җибәргән шул. Ошбу көфер тәгъбирләрем өчен Аллаһ мине үзе ярлыкасын. Мәгәр ишәкләрнең бер төренә ул колакларны гайре мул өләшкән, ә бәгъзе чатак төркем гел колаксыз калган. Менә бәла кайда,—дип, Давыт сәет инде сынып төште.

Көн яктыргач, хан кирмәне диварларында янә сорнайчылар белән дөмбакчылар төркеме пәйда булды. Мәйдандагы халык: «Әллә бүген башка тоткыннарны җәзалау көтеләме?»—дип пошаманга төште. Ләкин хәвефле тәшвишкә һавада озак вакыт буе эленеп торырга ирек бирмәделәр. Бермәлне Курсыбай бистәсе ягыннан дүртәр-дүртәр булып сафка тезелешкән җайдаклар ташкыны агып чыкты. Кирмән мәйданына якынайган саен җайдакларнын бер сафтагы саны әүвәл алты, аннары ун булып гел кинәя барды, әмма дәһшәт бөркеп торган бу ташкыннын актык очы һаман күренмәде. Кайсы—тоташ, кайсы челтәр көбәгә төренеп утырган, билләренә-иннәренә авыр гөрзиләр, сөнге, садак, җәя, хәнҗәр, кылыч аскан сугышчыларнын тыгыз сафлары тора-бара кин мәйданнын барча почмагын да биләп алды. Җайдаклар кирмән диварына карап тезелеште, иң алдагы сафка очлым түбәсенә берәр каурый тыккан йөзбашлары басты. Очларына ат ялы бәйләнгән озын сөңгеләрен куккә төбәп һәм шул сәбәпле куе урмандагы агачларга охшап тезелгән әлеге гаскәр каршында хәзер инде көмеш очлымнарын пар каурый бизәгән ике менбашыннан ары һичкем калмаган иде. Карашларын таш балконга төбәп, барчасы да Бәрәҗ ханны һәм сәрдәрне көтте.

Ләкин кирмән диварлары өстендә бүген һичбер төрле җанланыш сизелмәде. Укчылар ышыкланыр өчен ясалган уемтыклар һәм манараларны тирәләп баштанаяк коралланган шыгавыллар гына йөренә, әле аларнын да күбесе диварларда койма такталары сыман тезелеп торган таш калканнар арасыннан сузылып, курсыбай газиларын манзара кыла иде.

Шактый вакыт көткәннән соң гына таш кирмәннең тимер күгәннәр белән ныгытылган зур капкасын өскә күтәрделәр. Тол калган һәм инде тешләре коела башлаган җиңгәсенә өйләнергә мәҗбүр ителгән бичара

кияү егете шикелле ашыкмыйча, ялындырып кына, шул капкадан мәйданга Хәмбәл сәрдәр бер ялгызы чыкты. Аның акбүз аты гына утар тарлыгыннан котылу шатлыгын тоеп, әледән-әле уйнаклап ала, саф алтыннан коеп ясалган очлым түбәсен бизәүче өч тәвис каурые да вакытлыча җанлангандай була. Әмма җайдакның йөзенә, әйтерсең лә, кара сөрем яткан. Күз карашларында һичбер төрле тойгы-нур юк. Кара мыек чылгыйлары чалшаешып тора. Калын кашлары, дугаланып, борын өстенә килеп өелешкән. Усал кысылган нечкә иреннәре яргаланып беткән. Шакмаклы, олы ияге соскы сыман алга чыгып каткан.

Газилар аны иярләреннән беркадәр калка төшеп һәм ятаган-кылычларын очлымнары каршына күтәреп каршыласа да, сәрдәр һәр йөзлек яныннан җинелчә ияк кага-кага гына, тулпар атын юыртып диярлек үтеп китте. Үзен таш сын сыман хәрәкәтсез көе көткән меңбашларга да бүген сәрдәр тарафыннан игътибар һәм ихтирам тәтемәде. Хәмбәл шахмат тактасындагы сыннар шикелле тигез сафларга тезелешеп торган гаскәрнең нәкъ уртасына килеп туктады да, асылташлар белән бизәлгән кынындагы кылычын суырып алып, аның очын кыйбла тарафына төбәде һәм берничә сүз ташлады:

—Нур-Суварга! Гыйсъянчылар оясын туздырып бетерергә! Ганимәт булып кулыгызга төшкән җәмгы зиннәт үзегезгә кала. Хания үзенә тиешле өлешкә бөтенләй дәгъва кылмый. Хания үз өлешен сезгә бүләк итә. Амин!

Моны кайсының йөзенә канәгатьләнү-шатлык чаткылары калыккан, кайсы аптырап калган йөзәрләгән җайдак кабатлады:

—Амин! Амин!

—Хәзер инде юлга.

—Юлга! Юлга! Беренче йөзлек, кузгал!—дип, сәрдәр әмерен әүвәл меңбашлар эләктереп алды. Шул мизгелдә үк сафлар буенча дулкын булып янадан-яна әмерләр кушылып китте.

—Йөзлек, унга! Шәрекъ дәрбазасына!

—Йөзлек, Кырым урамыннан Айкапуга юнәл!

Бер минут узуга мәйдан эче таяк тыгып болгаткан зур кырмыска оясына охшап калды. Җайдаклар сафка кабат дүртәр-дүртәр булып тезелә башлады. Өзәнге, кылыч, калканнар бәрелешүдән бөтен мәйдан өсте корыч чыңы белән тулды. Кайдадыр авыр пошкырып аргамаклар тешләште, ирләр сүгенде, ярсудан атлар кешнәп-кешнәп алды. Ләкин җайдаклары да, атлары да бик тиз эзгә төште. Урам-тыкрыкларны тау өстеннән ургып аккан ташкын сыман тутырып, сафлар Алтын капка һәм Шәрекъ капка тарафына юл алды.

Бераз вакыттан соң, мәйдан өстенә килеп ингән тынлык—ул газаплый һәм тетрәндерә торган тынлык иде. Салкын таш тирәсенә тезелешеп баскан биләрлеләр ни кылырга белми гаҗизләнде. Сөнге, кылыч тотып үз халкына каршы яуга чыккан барча җайдак мондагы мәйданның һәр карыш җиренә, әйтерсең лә, учак ягып, күмер өеп китте. Алда, сувар каласында, бәрелеш һәм кан коюларның котылгысыз икәнлеген тоемлау биләрлеләр аңын тегермән ташы шикелле изде, сытты. Шуңадырмы Салкын таш тирәсе хәзер гаскәр озатып калган зур мәйданны түгел, бәлки җеназа чыгарылган йортны хәтерләтте. Биләрлеләр көчсез һәм чарасыз иде. Кайберләре, хурланудан башларын түбән иеп, мәйданны ташлап китте. Икенчеләр алда көткән бәлаләрдән котылу өчен беркадәр өметле җеп эзләмәкче булып, һәм имеш, киңәш-урнашка, дип әкрен генә чыгып сыпырттылар. Ләкин Салкын таш тирәсендәге халык төркеме барыбер кимемәде, китеп югалганнарны һаман саен яңалары алыштыра торды.

Ахшам намазы якынлашкан чакта Айкапу ягыннан мәйданга таба атларын куалап килүче ике җайдак күренде. Иярдәгеләр түземсезләнеп әледән-әле хайваннарның касыгына тертkәләсә дә, чаптарлар бик ыжламый, алар болай да шабыр тиргә баткан иде инде. Чапкыннарның кем булуын бик тиз шәйләделәр. Мәйдан читендәге пышылдаулар дулкын

булып Салкын таш янына барып житте.

—Сөләйман шаирь бит бу, сәетемезнең жигән борадәре. Нур-Сувар тиклем ерак каладан кай арада монда килеп житкән!

—Икенчесе—Гомәр, һөнәркяннарымызның аксакалы. Ул Чирмешән кичүе эргәсендәге базлардан мәгъдән чыгара, бакыр коя иде. Бәс, мондагы хәлләр хакындагы хәбәрләр аларга да барып житкән икән.

Чапкыннар шау тузанга баткан, хәтта йөзләрендә дә тик күзләре генә ялтырап тора иде. Ләкин мәйдан читендә иярләреннән сикереп төшкәч, алар өс-баш кагу, үзләрен ипкә-сапка китерү белән дә азапланып маташмады. Тезгеннәрен һәм камчыларын шул тирәдә буталып йөргән шәкертләр кулына гына ыргыттылар да, икесе тиң жил-жил атлап, Салкын таш баскычлары янына ашыктылар. Давыт сәет аларны шул баскычларның берсе өстенә утырып, талчыккан, өзлеккән кыяфәт белән каршылады. Сөләйман-Сувари алны-артны карап тормыйча, килә-килешкә үк күнелендәге уен ярып салды:

—Нинди ният илә син монда ачлык тотып ятарга булдың, гамужә[1] агам? Яу кырында коралларын жуеп, дошман каршында тез чүгәргә ашыккан саугат[2] булма инде. Мөхәммәт пәйгамбәрнең ерак оныгы булудан гайре мәмләкәтемезнең баш сәете дә ич син. Төкер ул Бәрәжгә. Хозурына килеп ул тез чүксен.

—Ипләп, жигән, ипләп. Шымчылар колагын санга сукмасан да, шәһид борәдәрен эргәсендә гауга кылмау фарыз,—дип, Давыт сәет аны тынычландырырга ашыкты.

Ике чапкын да гаепле кыяфәт белән дар агачына караш ташлап алды. Идрис хәзрәтнең һәлак булуы алар өчен, әлбәттә, үкенечле иде. Икесе тиң кайгыга чумып, беркадәр тын тордылар. Күкрәгендә кайнаган ярсуны тыюдан, күрәсең, шагыйрь Сөләйманның яңаклары тимгел-тимгел булып кызарынып чыкты.

—Әгәр ул жаһил Бәрәж хозурында һаман да колчуралар кеби тез чүгеп, сәждә вә буйсымчаклык кыйлып кына гомер итсәк, безне дә нәкъ Идрис хәзрәтнекедәй язмыш көтә булыр, гамужәм,—дип, Сөләйман барыбер дә тәүге кеше булып телгә килде.

Давыт сәет туганының холкын яттан белә иде.

—Тартар теленнән табар, ди. Сине дә шул бәла-казаларга балта сыман үткен телең генә илтеп кертер инде. Бигрәкләр дә түзә, тыела белмисең, йә Ходаем!—диде дә, Давыт сәет кул аркасы белән яндагы инсаннарга читкәрәк китәргә ишарәләде. Сүзсез буйсындылар. Салкын таш тирәсендәге ирләрнең барчасы да дилбегә озынлыгы арырак китеп басты. Әмма бу юлы да башлап Сөләйман шагыйрь дәште.

—Ул кассап Бәрәж эргәсендә усак яфрагы сыман калтырап торуярдан кайчан туктарсың син? Ошбу жиһанда ханнар, хәтта, мәмләкәтләр дә мәңгелек түгел, алар да алышына. Фәкать шәриф ислам дине генә мәңгелек гайрәт вә зиннәттер. Шулай икән, ул диннең ошбу мәмләкәттәге иң вәли башлыгы вә мөхтәсибе әүвәл син икәнсең, ул чагында инде жаһил Бәрәж эргәсендә дә, Болгар халкы хозурында да үзеңне лаек вә горур сәет итеп тоту фарыз, гамужәм. Ә Бәрәж ише мүкләк таждарлар бүген—бар, иртәгә юк бит алар.

—Мәгәр мәмләкәтемездәге барча адәм балаларын шул мүкләк тез чүктереп тота бит әле, ни хәл итик?

—Һәммәсен дә түгел, гамужәм. «Кара халык—кара сарык», дип бертуктаусыз тәкърар кылсалар да, бар бәндә дә бер чыбыктан сөрелгән күндәм хайван түгел. Аллага шөкер, мәмләкәттә һәрбер залим хозурында билен бөгә белмәс, «ләббәйкә»не әйтмәс, гаделлекне яклар батырлар да байтак. Иң караңгы вә иң хәтәр төннең дә таңы була бит ул. Безнең урамга да бәйрәм килми калмас, иншалла.

[1]Гамужә—әтисе белән бертуган абыйсы.

[2]Саугат—сугыш әсире.

Сәетнең йөзе агарынып чыкты, карашында шомлану һәм хәвеф пәйда булды. Ул үзе дә сизмичә шагыйрьнең иннәреннән үк эләктереп алды.

—Һәммә шаирь, мотлака, гыйсъянчылар дигәннәрен беләм. Мәгәр менә син янәниләр генә уйлап таптың да, тагын нинди фетнә куптарасың, жигән?

—Үз халкына каршы фетнәләрне мин түгел, ә бәлки хания илә сәрдәр куптарадыр, вәли сәет,—дип, сүзгә һөнәрчеләр башлыгы Гомәр дә кушылды.—Гәрчә ханнан Нур-Суварга юнәл, дигән фәрман алса да, катил Хәмбәл гөнаһсыз гавамның канын коймыйча гына тора аламыни?! Ул бит бүре сымак. Бүре бер сарыкны ботарлаган чакта күзен икенчесеннән алмый ди. Хәмбәл дә тач шулай. Нур-Суварга житкәнче ул юлдагы барча карьяларны туздырып йә талап чыгачак, меңнәрләгән инсаннарның күз яшен вә канын агызачак. Әнә, ул инде сәфәренең тәүге көнендә үк Чирмешән эргәсендәге Шәрбән кальгасы илә Исмәгыйль карьясын жимергән, әллә ничаклы йорт-куралы нигезенә тиклем талаган вә яндырган.

Гомәр авызыннан сүзне шагыйрь тартып алды.

—Гавамның да сабырлыгы нык корыды, гамужә. Әнә, бүген Хәмбәл катилнең Шәрбән илә Исмәгыйльдә ни рәвешле газап кылуы хакында ишетүгә үк, Чирмешән эргәсендә мәгъдән чыгаручы барча халык эшен ташлады вә кулларына кәйлә илә көрәк тоткан хәлдә нөгәр[1] булып басты.

—Андаен гына нөгәрне Хәмбәл кассаплары сытып үтәчәк, димәк, мәмләкәттә янә юкка гына кан коелачак бит.

—Юк, гамужәм.—Сөләйманның күзләрендә очкын кабынды.—Әгәренки ошбу нөгәр япа-ялгыз вә яклаучысыз калса, ихтимал, Хәмбәлнең алайлары аны сытар да, туздырыр да иде. Мәгәр алар ялгыз булмас, иншалла. Без Чирмешән эргәсеннән Әбүбәкер-останы Болгар каласына илче-арадашчы итеп кудык. Ул әмир Ибраһимнан Корнай сәрдәрнең Нур-Сувар каласына, андагы халыкны якларга баруын гозерләп үтенәчәк. Ул гына да түгел. Без әле янә Сувар вилаяте бәге Торгын илә дә сүз беркеттек. Торгын бәк элгәре айларда да кала диварларын ныгыту өчен хәттин күп гамәлләр кылырга өлгергән иде. Хәзер инде ул Хәмбәл кассапларын капуларны бикләп вә тоташ коралга төренгән алай азатлары илә каршылаячак. Өстәвенә, Торгын бәк әле Саксин каласының тарханы Сарычин эргәсенә дә чапкын куды. Алар бер-берсен яклашырга күптән инде ант беркеткән булган.

—Янә дәген сиңа бер сер ачыйк, вәли сәет,—дип, Гомәр дәвам итте.—Курсыбайда кыпчаклар мененең башлыгы вә әйдәүче булып Саран атлы батыр тора. Үзе Суварны туздырырга дип чыгып киткән чакта кабих Хәмбәл шул батырны Биләрдәге газиларның төп сәрдәре итеп калдырган. Ә ошбу Саран сабый чагында ук ятим калып, Сарычин тархан тәрбиясендә үскән сыбай булыр. Янә дә килеп ошбу Саранны Корнай батыр илә карендәшләр, диләр. Шулай икән, Саран-сәрдәр Сарычин тархан илә Корнай батырның һичбер сүзеннән дә чыга алмый. Ул аларга каршы яуга да кузгалмастыр. Һәммәсе дә без күзаллаганча барып чыга икән, кабих Хәмбәлнең вә Бәраж ханның көннәре санаулы гына калып бара.

—Йә Хода, йә Хода!—дип сызланып, Давыт сәет ике куллап чигәләренә ябышырга мәжбүр булды.—Болгар мәмләкәтендә фетнә генә түгел, коточкыч гарасат куба, адәм балаларының каны олуг дәрья булып коелачак икән. Нигә кузгатасыз соң сез мондый гарасатны? Болгар халкының кыл уртага бүленеп кан коюы янә кемгә кирәк?

Уртларын усал шыгырдата-шыгырдата жавап сүзен Сөләйман шагыйрь тотты.

—Колчура кеби изелеп интегүләрдән арыну өчен ошбу гарасат, ин

[1]Нөгәр—отряд.

әүвәл, ябай халыкның үзенә кирәк, гамужә бораләрем. Ул Бәрәж хан илә Хәмбәл кассап эргәсендә кан косып тормыш итүдән инде күптән гарык. Болгар халкындагы сабырлык савытлары хәттин ашты. Гавам күкерт кеби кабынырга вә ихтилал явына кузгалырга әзер. Ошбу гамәл өчен очкын ташлау лазим. Ә анысы, менә, фәкать синнән тора.

Давыт сәет куырылып калган кебек булды, аяк-иреннәре бизгәк өянәгеннән җәфаланган сырхауныкы сыман тиз-тиз калтыранды.

—Ни... ни... ничек инде миннән?

—Ходайның амин дигән вакытына туры килә икән, Болгар халкы иртәгәдән залим ханга каршы орыш башлаячак. Мондый изге яуга чыгу өчен ябай халыкка синең хәерхаһлыгың кирәк, гамужәм. Җимгә тилмергән кош балалары кеби ябай халык синең сүзне көтә.

—Син безгә хәер-фатиханны бирсәң иде, сәет,—дип, Гомәр-оста да Сөләйманның сүзен куәтләде.

Давыт сәет агарынып катты. Аяк-иреннәре генә түгел, хәзер инде кул-аяклары да дер-дер килде.

—Юк, юк!—диде ул бераздан, нык итеп.—Андаен акылга сыймаслык фетнәгә, кан коюга мин фатихам бирмим. Авыз да ачмагыз. Киресен кыла калсам, мине җирләр йотсын.

Башларын игән көенчә Сөләйман белән Гомәр байтак кына вакыт сүзсез торды. Шулай да беренче булып тагын шагыйрь баш күтәрде.

—Шуышып кына җан асрарга яратылган бәгъзе җаннарга да мәңге канат үсмәс, нә үкенеч. Мәгәр мәгыйшәтнең олуг тәгәрмәчен тезгә чүккән колчуралар түгел, киресенчә, сәҗдә кыла белмәс гыйсъянчылар гына алга тәгәрәтә. Азатлыкны тезләнеп яуламыйлар. Ошбу канунны онытмасаң иде, олуг сәет.

Бер-ике адым читкә атлаганнан соң гына Сөләйман шагыйрь кире борылып дәште.

—Бигайбә вә сау бул, гамужәм.

Икенче көнне кирмән мәйданында адәм әйтеп адәм ышанмаслык, чаң сугардай коточкыч хәл булды. Тоташ билгесезлек, сызлану эчендә үткән хәвефле көн күптән тәмамланган һәм болай да ачлык, гажизлектән интеккән Давыт сәет камыштан үрелгән чипталар өстенә сузылып, хәзер инде салкынлыктан кача алмый изалана иде.

Ястү намазыннан соң беркавым ара үтүгә мәйданга шактый сәер кәрван килеп керде. Ул бер-берсенә баулар белән тагылган өч-дүрт дөядән хасил, алар янәшәсендә арыклыктан кабыргалары балта сабы сыман тырпаешып торган ике генә ат та күренә иде. Ияр һәм өркәчләр өстендә һичбер юлаучы юк. Кәрван янәшәсендәге биш-алты ир аякларын көч-хәл белән генә сөйрәп килә.

Мәйдан уртасында янган ике нәни учак янына житкәч кенә, юлчыларның килеш-килбәтләрен төсмерләп була башлады. Алар һәммәсе дә өсләренә буйлы-буйлы озын җилән кигән, башларында бизәк төшерелгән дүрткырлы түбәтәйләр. Кайсылары мәйдан ташлары өстеннән инде тетелеп беткән чүәк сөйрәп атлый, бер ишләре бөтенләй яланаяк. Һәммәсе дә бауга асып киптерелгән балык кебек ябык, янак сөякләре терсәк очы сыман төртеп тора.

Кәрванның иң алдыннан атлаучы чал сакаллы картны ике яктан башка киемдәге ирләр култыклаган. Учак яктысында аларының йөзен бик тиз шәйләделәр. Картны озата килүчеләрнең берсе—Айкапуны саклаучы тоткавыллар башлыгы Гафур-сыбай, икенчесе Шәрекъ мәхәлләсенең имамы Хатыйп хәзрәт икән. Икесенең дә йөзләре сагышлы һәм уйчан, бер сүз эндәшмиләр. Алар уртасында гыж-гыж килеп атлаучы чал сакаллы картның йөзендә-карашында бер төсмер юк, ул бөтенләй җиһаннан ук аерылган кебек. Каратуткыл яңаклары сәхрәдәге корыган күл сыман тәмам эчкә баткан, нәзек иреннәре янгыр күрми тилмергән буразна шикелле ярганланып беткән. Төсен әллә җилләр, әллә еллар юып алган күзләрендә мөлдерәп торган сагыш.

Учакларны үтеп Салкын таш янына җиткәч, кәрван туктап калды. Йөзбаш Гафур белән Хатыйп хәзрәт шәүлә сыман гына булып калган арык картны дар агачына таба озатмакчы иде. Әмма юлчы, терсәкләрен тегеләрнең кулыннан арындырып, шундук каршы төште. Тып-тын калып аларны күзәтүче халык төркеменә тик ялгыз сүз килеп ишетелде.

—Үзем, үзем.

Юлчы карт, чыра сыман нечкә аякларын гаять авыр сөйрәп, дар агачына таба ике-өч мәртәбә атлагандай итте. Сагыш-хәсрәт тулы карашы белән ул элмәк очында урталай бөгәрләнеп төшкән Идрис хәзрәт мәетенә текәлде, хәрәкәтсез калды, канатлары салынды, сыны катты. Аннары аякларында кинәт җегәр бетте, тезләре мәйдан ташлары өстенә бөгелеп төште. Карт арык ике кулын мәет аякларына таба сузды, дерелдәгән иреннәре арасыннан сүзләре аһлап чыкты:

—Улым, улыкаем!—Салкын ташны тирәләп баскан кешеләрнең баш очында, әйтерсең лә, яман күк күкрәде, зәһәр яшен угы бәгырьләрен телеп-телеп узды. Мондый гайре табигый кайгы-хәсрәтне күреп, күк йөзе менә-менә убылып төшәр кебек иде. Күпләр торараштай капылт катып калды, кайберләре авыр ыңгырашты да сыгылып төште.

Давыт сәет әле мәйдан өстенә шомлы тынлык ингән тәүге минутларда ук чыптасына торып утырган һәм еракта килгән сәер юлчыларны тын да алмый күзәтеп тора иде. Көтелмәгән, чәчләрне үрә торгызырдай коточкыч сүзләрне ишетүгә, ул каударланып урыныннан купты, талчыккан һәм зәгыйфь аяклары белән дарга таба атлагандай итте.

—Әллә синме соң бу, Әбү-Хәмит хәзрәт? Йә, Ходаем!

—Мин шул, Давыт сәет, кызганыч ки, бу мин бичарадыр. Егерме сигез сәнә элгәре мин нарасый угылымны синең тарихчы бабаң Якуб хәзрәт хозурына, шәкертлеккә калдырып киткән идем. Ошбу язык гамәлем өчен Ходай Тәгалә мине ярлыкамаган, хәтта, минем егерме сәнә буена чиннәр эргәсендә кушчы[1] сурәтендә михнәт чигүләремне дә үтә азсынган шул.

Давыт сәет, йөрәген каната-каната, сәяхәтче бичара карт каршына якынайды да, тезләренә чүкте. Ап-ак чәчле башын түбән иеп, хәрәкәтсез калды.

—Газиз угылыңны ошбу коточкыч золым вә афәттән коткарып кала алмадым. Идрис угылың Болгар халкының азатлыгы өчен шәһит булды. Ошбу гөнаһымыз өчен Болгар мәмләкәтенә шәфәгать кыла күрсәң иде, Әбү-Хәмит хәзрәт? Ә үземә нисбәтән гафу сорамыйм да. Мин биниһая языклы бәндәмендер. Шул гөнаһларым өчен кыямәт көнендә миннән Аллаһы Тәгалә илә Исрафил фәрештә үзе җавап алсын.

—Угылыма нисбәтән хурлану вә кимсенү хисләре кичермимен. Әҗнәби халыкның азатлыгы бәрабәренә шәһит булу—һәр мөселман өчен мактаулы сәгадәттер. Угылым халык моң-зарына нисбәтән сизгер, уяу булган. Моңа угылымны гаеп итеп булмый. Синең дә, Давыт сәет, һичбер языгың юктыр. Угылымның шәһит булуына фәкать мин гаепле. Бүре булып бүреләр дә үз пәраларын тәмам тернәкләнми торып язмыш ихтыярына ташлап китмиләр бит. Мин ташладым. Менә шуның өчен Ходай миннән угылымны дар агачына эленгән мәрхүм көе күрсәтеп җәза ала. Нә үкенеч, мин аны хәтта кочаклый да алмыйм, адәмчә ясин укырга да мөмкинлегем юк.

Шул минутта Давыт сәет белән гүя нииндидер бер зур үзгәреш булды. Ул каударланып аяклары өстенә калыкты, күзләрендә зәһәр ут кабынды.

—Җитте, җитте!—дип телгә килде ул, чит-ят тавыш белән, Аннары усал йомарланган йодрыкларын югарыга чөйде.—Җигән дөрес әйтте: «Азатлыкны тезләнеп яуламыйлар». Елан сыман гомер буе тездә килеш җан асраганчы бер көн бөркет булып яшәү мең мәртәбә артык.

Сәеттәге мондый кискен үзгәреш һәммәсен тетрәндерде, гаҗәплә-

[1]Кушчы—кәрвандагы хезмәтче рәвешендә тотылган кол.

нүдән бары да тын тордылар. Ә сәет урыныннан капылт кузгалды да, елгыр барып, йөзбаш Гафурның биленәдәге кынынннан кылычын суырып алды. Икенче мизгелдә ул инде азамат егетләрчә бер житезлек белән Салкын таш өстенә йөгереп менде һәм кылычын усал кизәнеп дар агачындагы сүз арканны чапты. Аркан һаман саен тизләнә барып сүтелә башласа да, Идрис хәзрәтнең мәете мәйданга төшәргә өлгермәде, аны дистәләгән куллар эләктереп алды.

Беренче булып каравылбаш акылына килде. Ямьсез тавышы белән бар мәйданны тутырып, сөрән салды:

—Хания җәнабларының фәрманын үтәмиләр. Фетнә бит бу, фетнә! Давыт сәетне тотып тыешлы да түгел иде.

—Мәет тиклем мәетне мәсхәрә итәргә базган синең ул дәһри ханияна ләгънәт яусын!—дип ачыргаланып, ярсып кычкырды ул.—Ярты җиһанны манзара кылып үткән вәли сәйяхка үз угылына тәһлил әйтергә, ясин чыгарга да ирек тудырмаган андый ханияга барча мөселман халкы ләгънәт вә бәддога яудырыр. Ләгънәт вә бәддога! Ләгънәт вә бәддога!

Сәет сүзләрен әүвәл чал сакаллы Әбу-Хәмит юлчы, аннары Идрис хәзрәт мәетен әйләндереп баскан имам һәм мөәзиннәр эләктереп алды.

—Ләгънәт вә бәддога!

Каравылбаш берникадәр вакытка югалып калгандай булды. Хәвеф һәм өшәнү тулы ярсу караш белән кирмән капкаларына таба карап-карап алды. Әмма бераздан инде мәйдан өстен янә аның ямьсез җикерү тавышы каплап китте:

—Ясавыллар![1] Нәрсә уклау йоткан сыман кузгалмыйсыз? Гыйсъянчының җеназасын урынына кире кайтарыгыз!

Кирмән диварлары буена тезелешкән кораллы сакчылар шөкатьсез кыяфәттә халык өстенә ыргылды. Салкын таш әйләнәсендә торган берничә ир аларның юлына каршы чыккан иде, һәммәсе дә диярлек сөңге очына алынып, җиргә ауды. Мәйдан өстен Давыт сәетнең кайнар фәрманнары ярып узды:

—Колчуралар булып яшәү житте. Кабих Бәрәҗ җәлладларына һич тә буйсынмагыз! Идрис хәзрәтнең җәсәден яшерү фарыз.

Мәйдандагы барча һөнәрчеләр, шәкертләр, имам-мөәзиннәр Идрис хәзрәт мәетен тулгамага алды һәм тар урамнарның берсенә таба чигенә дә башлады. Моны күреп, кирмән капкалары янында торган атлы җайдаклар да ясавылларга ярдәмгә ашыкты. Кылыч-сөнгеле җайдаклар һәм коралсыз төркем уртасындагы ара кузгә күренеп кими бара иде. Шулчагында бушлык уртасында ике кулын күккә чөйгән сәет калкып чыкты.

—Аллаһ хакы өчен кан коймагыз?! Иманыгызга килегез, мөселманнар!

Тимеркүк ат өстендә ажгырып килгән җайдакның күзе-башы тәмам тонган иде. Ул үз каршында пәйда булган шәүләне шәйләмәде дә, ахры. Менә, аның ярсу аты башына ак чалма уралган шәүләне усал бәреп узды. Давыт сәет гәүдәсе ат тояклары астында аунап калды, ак чалмасы читкә тәгәрәде.

—Сәетне, вәли сәетемезне харап иттеләр!—дип, кемдер сөрән салды. Әмма Давыт сәет моны инде үзе ишетмәде.

## 7

Хәмбәл юлда атна буе котырынды, шашты. Әле Биләр каласыннан чыккан чагында ук гаскәрен кыл урталай бүлгән һәм берсенә башкорт батыры Селәүсенне меңбаш итеп куеп, аны Мораса елгасының тамагына таба куган иде.

—Уч төбен күрсәткән иргә—аның хатыннары, ә камчы кызганган хакимгә ябай халык һич буйсыну белмәс. Менә шул мәсләктән чыгып,

[1]Ясавыл—эчке сакчы, тәртип сакчысы.

Мораса эргәсендәге карья-кирмәннәрне талап уз да, ябай халыкны өнсез калдырып кит. Андагы карьяның бәгъзесе дә Сувардан качкан фетнәчеләрне үз куенына сыендырырга җөрьәт итмәсен. Ә аннары ул гыйсъянчылар каласына шәрекъ яктан килеп тач селәүсен[1] булып ыргылырсың.

Сәрдәр меңбашын юлга шулай өсли-өсли озатса да, ике-өч көннән соң һич тә көтелмәгән, гайре кыргый хәбәр алып, үзе өнсез калды.

—Үз артыннан дүрт йөзгә якын азамат ирне ияртеп, Селәүсенменбаш эстәрле илә Нокыш дәрьяларына таба чыгып тайган. «Алаша ат сыман булдыксыз хан илә үгез төсле ахмак вә котырган сәрдәр хозурында тезләнеп йөрүдән туйдым. Гөнаһсыз инсаннарны кырып хәрәм кан койганчы, кассап Хәмбәл илә гадел орышка чыгу—мең мәртәбә артык. Ә ул ахмак үгез үзенең билен сындырудан шүрләп калмый икән, мине Таш-билбау кыяларыннан эзләп карасын. Ул чагында мин аның билен генә түгел, әле муенын да өзеп, гөбе төсле ми-зиһенсез вә түн башын култык астына кыстырып җибәрермен»,—дип, газиләр эргәсендә каһкаһә илә сине мәсхәрә итәргә дә җөрьәт кылган икән.

—Ах, хөрәсән! Ах, мүкләк!—дип, Хәмбәл дию кебек үкереп җибәрде дә, тәмам дуамалланып әмер бирде.—Бөтен менне Морасага таба борыгыз! Ул хыянәтчеләрне куып җитәмез вә андагы дүрт йөз сораннын барчасын да кырып бетерәмез. Ә ул сатлык җан Селәүсеннең тәпиләрен мин үз кулларым белән умырып атам!

Чарасыз калган йөзбашлар мона кадәр Хәмбәл идарәсе астында килгән бер мең газины Чирмешән буеннан Морасага таба борырга мәҗбүр булды. Ләкин Ерыклы-тау янындагы беренче төнге тукталыш ук котырган сәрдәрнең явыз ниятләрен челпәрәмә китереп атты.

—Йөзбашлары Миһран илә Кәрим, үзләренең газиларын алып, Нур-Суварга качкан.

Таң атканда сәрдәр чатырына тоташ хәвеф тулы бу хәбәрне биш йөз җайдак өстеннән башлык булып йөргән Галиәскәр батыр алып кергән иде. Бичара сыбай шул чатырдан исән чыга алмады, шашкан Хәмбәл яшендәй кылычы белән аны икегә телеп атты. Соңыннан акылына килгән кебек булды да, ике чигәсен томалап, үзе дә чатыр эченә ауды. Котырынудан аның баш түбәсе, чигәләре учак өстендәге казан сыман шауларга тотынды. Сәрдәр, ниһаять, бермәл үзенең аяныч хәлдә калуын аңлагандай булды. Миһран белән Кәрим—әле Хәмбәл Тук елгасы буенда кыпчак бәге Манукны җиңгәннән бирле аннан аерылмыйча йөргән йөзбашлары һәм, иң мөһиме, алар тоташ кашанлылардан гына торган йөзлекләрнең сыбайлары иде. Кашан—аның туган шәһәре, заманында әтисе Колын-Хисам хаким булып торган нәсел каласы бит. Ә инде шул туган кала, газиз кала яугирләре дә башкисәрдәрдән йөз чөергән икән, ул чагында чит-ят вилаятьләрдән йә булмаса кыпчак, башкорт далаларыннан, чирмеш, мукшы урманнарыннан килеп алапа[2] вә ганимәт бәрабәренә генә курсыбайга ялланган газиларга ышанырлыкмыни?..

Качкын Селәүсен отрядын эзәрлекләү печән чүмәләсе өстенә төшеп югалган энәне эзләү кебек үк өметсез эш иде. Хәмбәл моны бик тиз аңлап алды һәм үз янына мона кадәр йөзбашлар булып йөргән Сәүбән белән Газдалыйны дәште.

—Ун-унбиш җайдаклы гына нөгәр алыгыз да, ашыгыч рәвештә Морасага карап юл тотыгыз. Анда ул мүкләк Селәүсенгә иярмәгән йөзбашларны вә иллебашларны аулак төшкә җыеп, шуны тәкърарлагыз. «Нур-Суварда Торгын бәк сараеннан талап алыначак барча казнаны, иң-иң соңгы әзгәриенә[3] тиклем, әүвәл итеп, мин үземә тугры булган сыбайларга бүлеп бирәчәкмен. Өстәвенә һәммәгезгә Суварның байлар кавеменнән җаныгыз теләгән чаклы җарияләр сайлап алырга тулы ирек бирәм».

---

[1]Селәүсен—урман мәчесе, рысь.

[2]Алапа—гаскәриләргә түләнә торган хезмәт хакы.

[3]Әзгәри—Болгарда сугылган озынча акча.

Ошбу вәгъдәләрнең сүзен-сүзгә илтеп житкерегез. Егет сүзе бер булыр. Мин вәгъдәмнән таймам.

Сәүбән белән Газдалый инде ияр өстенә менгәч, Хәмбәл аларның җанын кыздырырга, хыял канатлары куярга да онытмады:

—Ә сез мина тугры булып калган ул йөзлекләрне ошбу эргәгә тукми-чәчми алып кайтып җиткерәсез икән, мин сезнең икегезне дә курсыбайда менбашлары итеп куячакмын...

Хәмбәл Сәүбән белән Газдалыйны үлемгә җибәргән кеше шикелле өметсез, төшенке кыяфәт белән озатып калган иде. Шуннан соң да озын көн буена күнелен мең булмаса да, йөз төрле шик талады. Әмма гаҗәпләнүенә күрә, икенче көнне ике сыбай да Мораса елгасы ягындагы алты йөзлекне сәрдәр әләме астына тулы көенчә китереп бастырдылар. Хәмбәлнең күнеленә шундук гайрәт инде, ул Сувар каласына таба юлга янә инде очына-очына чыкты.

Хәмбәл бер йөз җайдаклы иравыл отрядын гаскәренең төп өлешен кузгатканчы ук алга куган иде. Ләкин Ата елгасын кичеп ике фәрсах арасы да уза алмадылар, иравыл башлыгы нибары җиде-сигез генә яралы җайдак, шулар арасында бөтенләй дә таныш түгел бер тотык ияртеп һәм үзе дә тоташ канга батып, кире әйләнеп кайтты.

—Зәнгәр күл буенда тулгамага эләктек. Ике-өч йөз чамасы һөнәркән вә мәгъдәнчеләр шул күл тирәли кәмин[1] корып көткән. Башлыклары Гомәр-оста илә мәнге тынмас фетнәче Сөләйман-шаирь икән. Менә, орыш барышында фәкать бер гидайларын гына саугатлыкка алып, тулгамадан көчкә генә качтык. Фетнәчеләр үзләре дә Зәнгәр күл буен шундук ташлап китте...

Ялгыз тотыкның табан астын телеп, яраларына кыл җибәреп газаплау да һичбер төрле юаныч китермәде.

—Бөтен җиһан сина каршы купты. Тантана итәсе көннәрең бетте инде. Минекендә түгел, юк, синең табан астында хәзер янгын яна. Шуны анла, җәллад,—диде дә, бичара ир башка төрле җавап кайтармады. Аның гәүдәсен соңыннан бер имәнгә асып, курсыбайныкылар янә юлга чыкты.

—Мәгъдән казучы кара эшчеләр дә, аларга кушылган башка ярлы халык та безнең алай өчен хәвеф түгел. Без аларны сасы көзән урынына ат тояклары илә сытачакмыз,—дип, Хәмбәл сер бирәсе килми шапырынса да, Сувар каласы янына җиткәч, аның кикриге күсәк белән орган шикелле шәлперәеп төште.

Сувар—сәрдәр элек күреп гадәтләнгән кала түгел, хәзер инде аның кыяфәте үк танымаслык хәлгә килгән иде. Каланың тоташ имәннән торган диварларын янә бер-ике аршын чамасы биегәйткәннәр. Дивар өстендә ук очырырлык ара үткән саен ярымтүгәрәк каланчалар үсеп чыккан. Диварлар алдындагы ерымнар тирәнәйгән, урлар биегәйгән. Суварлыларның бу эшләрне әле соңгы атна-ун көн эчендә генә башкарулары күзгә күренеп тора. Диварны биегәйтеп тезгән бүрәнәләрнең күбесе кабыгын да салдырмаган көе генә югарыга менгән, ур өстендә әле дымын югалтмаган, кибеп өлгермәгән юеш балчык ята.

Суварлылар явыз курсыбайны диварлар өстендә, калкыннар артына яшеренеп каршы алды. Күккә каратылган сөнге очлары бөтен дивар буйлап керпе энәләре кебек тезелеп киткән. Һәр калкан артына җәясенә ук элгән яугир яшеренгән. Кала эченнән егерме-утыз адым саен төтен күтәрелә. Димәк, курсыбайлылар өстенә коелырга тиешле сумала һәм кайнар су да инде күптән әзер.

Хәмбәл үз гаскәренә таба күз ташлады. Сафында хәзер унөч чамасы гына йөзлек саналса да, аның һәр җайдагы корыч көбәгә төренгән. Озын чылбыр булып сузылган бу җайдаклар сафы сүрән кояш нурлары астында бакыр еланга охшап гел ялтырап тора. Мондый шашкын көчне туктата алырлык каршылык бармыни ул?!

---

[1]К ә м и н —засада.

—Син юкка гына ошбу тарафка килгәнсең, җаһил кассап,—дип каяндыр югарыдан янгыраган мәгърур тавышны ишетүгә үк, Хәмбәл, өстенә кайнар су түгелгән шикелле куырылып, калага күз салды. Асылмалы капка янындагы дивар өстенә кала бәге Торгын чыгып баскан һәм бөерләренә таянган көенчә шул аңа тәкәллефсез төстә сүз ыргыта икән.—Бәгъзе кала да син катил пычагы астына сүзсез ята торган сугым малы түгел. Синең көнең бетте. Болгар мәмләкәте бердәм йодрык булып син катилгә вә синең умырткасыз ханиянә каршы гадел ихтилал орышына чыга. Пайтәхеткә җәдид таҗдарны утыртмыйча торып, орыш тынмаячак. Гөнаһсыз халыкның канын тагын да коймыйм дисәң, үз ихтыярың илә безнең мәмләкәттән чыгып олак. Монда сиңа хәят булмаячак. Сине алда дуадак каз язмышы гына көтә. Югал, сәрдәр!

Хәмбәл котырына-котырына кычкырып җавап бирде:

—Әле ияр өстендә утырган көемә үк син миңа ясин чыгарга җыенасың түгелме соң, сатлык Торгын?! Ай-һай, терсәгеңне тешләргә туры килмәсен, кабаланма. Юньле елан инде буарга рәте калмаса, үз дошманын кыядан аска сөйрәп булса да лаек төстә үлә. Ә мин әле синең кебек хөрәсәннәрне янә йөзләп буам.

Хәмбәл шундук кыныннан кылычын суырып алды, йөзлекләргә чылбыр булып таралырга кискен әмер бирде. Кала диварлары өстендә дә шул мизгелдә үк дистәләгән сорнай авазлары яңгырады, имән бүрәнәләрдән тезелгән түбәләр астында тагын йөзләгән яңа сугышчы пәйда булды. Аларның күбесендә кыпчак сугышчылары төсмерләрен күргәч, Хәмбәлнең йөзе-кыяфәте алышынгандай булды.

—Ах, Сарычин, сатлык! Заманында мин аны тархан итеп куйдым, ә ул миңа, әнә, елан сыман чагып җавап бирә,—дип сытып сүгенде дә, Хәмбәл Шам кылычын кала диварына таба айкап алды.

Сәрдәр ишарәсен сүзсез аңладылар, йөзлекләр дәһшәтле карчыгалар болыты булып һөҗүмгә ташланды. Талгын, тын һаваны меңәрләгән сәрпи ук авазлары ярып узды, дистәләгән газиләр ияр өстеннән җиргә очып төште. Ләкин җайдаклар моңа һич игътибар бирми, алар уклар яңгырын калкан сыман ерып һаман-һаман диварларга таба якыная иде. Артта сәрдәр тавышы торган саен дәһшәтлерәк булып яңгырады.

—Диварларга! Диварларга элмәк ыргытыгыз! Бар ганимәт сезгә! Кала сезгә!

Сугыш кыза, Хәмбәл газилары кайбер урыннарда инде дивар өстенә дә үрмәләгән иде. Сәрдәр күңелендә тәүге өмет чаткылары уянган бер мизгелдә кала эчендә тагын ниндидер бер яңа учак ялкыны пәйда булды. Ул йортларга кабынган янгынга да охшамаган, казаннарны кыздыручы учаклардан да аерыла. Күрәсең, кала эчендә махсус хәзерләнгән кура яки җитен яна иде.

Яна учак сере бик тиз ачыкланды. Вәтыйгъ елгасы янындагы калкулык өстендә хисапсыз җайдаклар гаскәре җир астыннан калыккан кебек кинәт пәйда булды. Алар тау очыннан чәчелгән борчак сыман калкулыктан аска томырылдылар да, чапкан шәпкә озын чылбыр булып, Хәмбәл курсыбаен камарга тотындылар. Хәмбәл әлеге дәһшәтле ташкынны күреп, янә көзге чебеш кебек куырылып калды. Аның ачулы карашы дошман чылбырын буеннан-буена айкый-айкый гаскәрбашны эзләде. Ниһаять, ул башына алтын очлым киеп үзенә таба очкан җайдакны күреп алды һәм аптыраудан тораташтай калды. Үзен Хәмбәл белән бер дәрәҗәгә куеп алтын очлым кияргә җөрьәт иткән җайдак Болгар әмире Ибраһимның хассә алай башы Корнай батыр, заманында аның әтисе Колын-Хисам янында, Кашан каласында гади җансакчы булып йөргән яллы кыпчак иде. Хәмбәл ярсудан тешләрен шыгырдатып кысты, маңгаена салкын тир тамчылары бәреп чыкты.

—Курсыбай, артка, сатлык болгарлар өстенә!—дип, шашып кычкырды да, Хәмбәл үзе беренче булып Корнай батыр каршына томырылды.

Ләкин Хәмбәлгә Корнай батырга якынаерга ирек бирмәделәр.

Хәмбәл каршында әллә каян гына әзмәвердәй гәүдәле ике жайдак калкып чыкты. Аларның берсе кулына кылдан үргән ятьмә, икенчесе каеш аркан тотып килә иде. «Ошбу сөлтекләр мине тере көе саугат итеп алырга ниятлиләр»,—дип кенә уйлап өлгерде дә, Хәмбәл кайнар судан качкан шикелле кабаланып-янып, атын кире борды. Сәрдәр тулпары бөтен Болгар илендәге беренче чаптар иде, хужасын хәвефсез калкулыкка бик тиз алып чыкты.

—Юк, сез мине ансат кына саугат итә алмассыз! Тешегез үтмәс! Минем газиларымның һәрберсе сезнең ун карачкыгызга тора. Курсыбай, курсыбай!—дип Хәмбәл үзен-үзе юатып кычкырса да, аның кул астындагы гаскәр инде пыран-заран килеп бара иде. Орыш кырына салкын акыл белән караш ташлауга ук башсәрдәрнең йөзе агарып калды. Әнә, кала капкалары да инде күптән төшерелгән. Капкалардан ташкын булып чыккан суварлылар белән кыпчак жайдаклары газиларны эреле-ваклы төркемнәргә бүлеп, тимер кыршау сыман тулгамага ала. Аллага шөкер, яна меңбаш Сәүбән житәкләгән бер төркем, әнә, дошман сафын майны телгән пычак шикелле икегә ярып үтте дә, Бизнә елгасы ягындагы далага чыгып качты. Ә Газдалыйныкылар кайда? Алар нишли? Хәмбәл шомлы-хәвефле карашы белән орыш мәйданың кат-кат айкады да, үзе дә сизмичә ике кулы белән чигәләрен тотты. Йә, Ходаем! Сөңгеләрен-кылычларын жир өстенә ташлап, ике-өч вак төркем Корнай жайдаклары каршына тезләнеп һәм баш иеп тора түгелме соң?

—Куркак жаннар! Сатлык карачкылар!—дип, Хәмбәл үз-үзен белештермичә яман сүгенде дә, ачуы белән тулпарының касыгына типте. Хужасы артык каермаса һәм кумаса да, бичара тулпар инде сизгән иде. Ул Хәмбәлне яу кырыннан Биләр ягына таба очырып алып чыкты...

Үз гомерендә тәүге тапкыр жинелгән сәрдәр янына юлда тагын вак-вак төркемнәр килеп өстәлә торды. Янә Кече Чирмешән елгасы буена кайтып житкән чакта сугышчылар саны ике йөздән артты, ләкин сәрдәр алар ягына бер генә караш та ташлап карамады. Ул, башына күсәк белән сугып мингерәтелгән мал шикелле, уйсыз һәм аның ияр өстендә каңгырап кайтуы да бауга тагып сугымга алып барылган бичара үгезне хәтерләтә иде.

Язмышның иң ачысы Хәмбәлне Биләр диварлары янында көткән булып чыкты. Пыран-заран китерелгән гаскәр калдыгын ияртеп кайткан сәрдәрне пайтәхет бикле капкалар һәм дивар өсләрендә оборона тотарга хәзерләнгән сугышчылар сафы белән каршы алды. Айкапу өстендәге мәйданчыкның бер ягына наиб, икенче ягына кылыч сабына кулын салган көе меңбаш Саран баскан. Тәкәллефсез кыяфәт белән текәлгән Саранның баш түбәсен өч каурыйлы алтын очлым бизи. Мөгаен, Бәрәж хан аны инде курсыбай сәрдәре итеп тә күтәргәндер.

Шулай да мәсхәрәле сүзләрне Хәмбәлгә биек дивар өстеннән иң беренче булып наиб әчте:

—Син хәзер ярык таба хәлендәсең, Хәмбәл. Борының илә жир сөреп күрсәтсәң дә, пайтәхеткә инде кирәгең бетте, монда сиңа юл юк. Тәртәләреңне тизрәк кире бор да, әйдә, моннан ычкын. Кыпчаклар йә булмаса карлуклар эргәсенә барып, башың орып кара. Синдәй оста сәрдәрне берәр кәрванбаш булса да, ихтимал, үзенә алапа хакына кассап итеп алыр. Кассаплык тәтемәсә, шәят, кәрванбашка йөк ташучы каранар[1] урынына да ярап куярсың син.

—Ха-ха-ха!—дип ыржаеп һәм кешнәп, наиб мәсхәрәсен дивар өстендәге йөзәрләгән ирләр эләктереп алды.

—Каранар!

—Кассап!

—Мәмләкәтеннән куылган мескен дуңгәләк син!

Хәмбәлнең күңелендә юеш, тынчу баздагы шәмдәл сыман тонык,

[1]К а р а н а р —бер өркәчле карт дөя.

зәгыйфь кенә булып янган соңгы өмет чаткысы да сүнде, күзләренә ачы яшь бәреп чыкты. Үзен-үзе белештермичә ул кыныннан кылычын суырып алды, кабыргаларына котырып тибә-тибә тулпар атын алга куалады. Ләкин бу минутта ат булып ат та хуҗасыннан акыллырак иде. Әле арткы аякларына кисәк күтәрелеп, әле башын чайкап, ул һаман бер урында бөтерелә бирде. Ул да түгел, Хәмбәлнең баш очыннан гына өч-дүрт сәрпи ук яман сызгырышып очып китте. Үз гомерендә беренче мәртәбә Хәмбәлнең йөзенә курку бәреп чыкты. Ул шөкәтсез, нурсыз булып калган карашы белән дивар өстен ялт-йолт айкады да, муенын инбашына җыергандай итте. Әмма соңга калды. Чираттагы бер ук «донк» иттереп аның алтын очлымына китереп бәрде. Очлым җиргә очты. Мәет шикелле агарынып калган Хәмбәл куркуыннан тулпарының ял өстенә ятты, янә атның касыгына котырынып-шашып типте. Инде ярсу ат та яман сызгырышып очкан сәрпи уклар астында биюдән туйган иде, ул лачын шикелле сузылып, читкә томырылды. Диварлар өстеннән янә ачы сызгырышкан, мәсхәрәләп көлгән тавышлар гына ишетелеп калды:

—Каранар! Кассап!

—Мәмләкәтен җуйган дуңгәләк!

## Тугызынчы бәйләм

### 1

Күз житүгә Козьма ватагасы янә урман эчендә тирән базлар казып, үзләре әйтмешли, аю өненә чумды. Әртилдәге сукбай ирләр саны хәзер инде дүрт йөздән дә артык, алар үзләре урнашкан Рязань төбәге белән генә канәгатьләнмичә, Муром, Белев юлларына чыгып та «кәсеп итә» иде. Әртилдәге ирләр саны арткач, ауга, балыкка йөреп кенә тамак туйдыру шактый кыенлашты. Әртилдә соңгы арада килеп кушылган угры-ушкуй отрядлары олы юлга чыгып сәүдә кәрваннарын талап көн итүне отышлырак күрде. Алай гына да түгел, алар инде, башкаларны да котыртып, әледән-әле Ука белән Идел аръягына чыга һәм андагы мукшы, ар, эрҗә авылларын талап йөри башлады. Шулар ук соңгы бер «походларыннан» әртил лагерына бөтенләй дә көтелмәгән әсир алып кайтты.

Лагерьга ике ай буе югалып торган ушкуйлар кайтып төшүен Козьма урман аланында купкан кыргый тантананың әле беренче авазларыннан ук чамалаган иде. Ул һәрвакыт шулай: олау-олау байлык төяп кайткан ушкуйлар күрендеме, әртил халкы аларны һичшиксез, барабаннар шавы, тоташ кычкырыш авазлары белән каршы ала. Аннары инде атналар буена сузылачак тантанада учаклар өстеннән сикереш тә, аю биетү, йодрык сугышы, исерек баштан өер-өер булып тәпәләшеп алу да—берсе-бер калмый.

Бу юлы аландагы шау-шуны ишетүгә Козьма да ашыгып үз базыннан чыкты. Ләкин инде соңга калган икән. Башка баздагылар аннан алдарак кузгалып, хәзер бөтен алан буенча сибелешкән. Биек наратлар, карагайлар арасындагы юлдан аланга биек итеп төялгән дәү олаулар белән шактый озын кәрван кереп килә. Олауларны тирәләп әле атка менгән җайдаклар, әле куе көртне ерып килүче җәяүлеләр атлый. Боларның кайсы походтан кайтучы да, кайсы аларны каршы алучыдыр—һични аңламассың. Барысы да озын, ямьсез сакалга батып беткән, һәммәсенең мыекларын-керфекләрен ак бәс сарган. Барчасы да иске чабатадан. Юкә бау белән буылган кафтан һәм туннары әле аннан, әле моннан умырылып төшкән дә «тел» күрсәтеп тора.

Шулай да походтан кайтучы ушкуйлар үзләрен каршы алучы ирләрдән хәтәр кискен аерыла икән. Ушкуйларның һәммәсендә корал, яңаклары суырылган, кыяфәтләре талчыккан. Арада яралылары да очрап куя.

Кайсының маңгаена, кайсының кул-аягына ак бәз чорналган. Юлдан кайтучыларның тавышлары да кимрәк. Бугазларын ерта-ерта күбрәк аларны каршылаучы ирләр кычкырыша.

—Һәрбер олау корал, икмәк, сәрмәт белән тулы. Ну, баедык та соң!

—Городец аръягындагы авылларына кадәр үтеп алтын-көмешенә тиклем талап чыккач, болгарлар элеккечә «без бай, без көчле», дип шапырына алмас инде...

Башка әртилчеләр кебек үк Козьма-атаман да юл читенә басып, олаулар кәрванын тамаша кыла иде. Кәрваннның нәкъ уртасында, ядаулап шыр сөяккә калган ат өстендә кылка киемнәргә төренгән, кул-аяклары бәйләнгән әсир ирне күргәч, Козьма кинәт әсәренеп калды. Шәп нәселдән икәнлеген югалтмаган тулпар, алтын-көмеш нәкышьләр белән бизәлгән ияр-йөгән, шундый ук затлы жепләр катнаштырып чигелгән бәрхет жилән аламасы, йомшак күн итекләр—һәммәсе дә әсирнең күренекле, бай катлам вәкиле булуы турында кычкырып тора иде. Дөрес, хәзер инде жайдак үзе дә, аның тулпары да күбесенчә өрәкне хәтерләтә. Аты саламы йолкынганнан соң бәбкәләре белән генә тырпаеп калган мескен өй түбәсе төсле. Җайдак үзе дә ябык, яңаклары оча сөякләре сыман тырпаешып тора.

Бөтен йөзен яңак очларына кадәр куе сакал баскан, ул касмак белән майлап чыккан кебек укмашып һәм буталышып беткән. Йөзе, муены, куллары кара тирдән хасил. Әле ушкуйлар кулына әсир төшкәнче үк байтак михнәт чиккән, күрәсең. Яңакларында, муенында инде төзәлеп килүче иске яра эзләре күренеп тора. Аны әсир булу халәте дә бик тилмертми, ахры. Ул урман аланы буйлап йөгерешкән әртилче ирләргә сирәк-мирәк кенә салкын караш ташлап, бөтенләй гамьсез, битараф кыяфәттә утыруын белә.

—Атаман! Муром отряды походтан жиңү яулап кайтты. Сугышчыларыңны да, тупланган ганимәтне дә үз канатың астына кабул итеп ал,—дип, ушкуйлар башлыгы Шадра Викул Козьма каршына килеп баскач кына, әсир жайдак авыр керфекләрен күтәреп, утлы караш атты.

Әртилдә чагында һәрчак атаман белән әрепләшергә яраткан, аңа баш бирмичә йөдәткән Викулга игътибар итмәскә тырышып, Козьма әле һаман әсир тарафына карап тора иде. Аның утлы карашы белән очрашуга ук атаманның тәннәре чымырдап китте. Бер мизгел эчендә ул шабыр тиргә баткан кебек булды. Зиһенендә йөз төрле уй капылт чагылып үтте. «Табан асларыңа кадәр үтеп керә торган тасрайган, кайнар караш. Сөзгәк үгезнеке сыман усал кыяфәт. Кайда очраттым соң әле мин кушылып үскән кашлар астыннан төбәлгән мондый үжәтлекне? Тукта, бу бәндә өстенә алтын жепләр белән бизәлгән яшел жилән кигән. Димәк, мөселман кешесе бу. Болгар, Кашан... йә, Ходаем! Бу Болгар илендә чакта безне озатып йөргән әмир түгелме соң? Ә юк, Колын, Колын. Боларга туган тиешле бер әмирләре инде күптән бездә. Анысы—Арбат, Мәскәү каласында олуг воевода. Ә монысының исемен хәтерләмим. Иң мөһиме, безнең якка ул ничек килеп эләккән?..»

Атаманның әсирдән күз алмыйча торуын күреп, Викул телгә килде:

—Менә, бу ганимәтне дә кабул ит, атаман. Монысын Городецның инде бу ягында, Клязьма ярындагы урман эчендә кулга төшердек без. Ирләр аның өстенә килеп чыккан чакта ул аю сыман көрт эченә күмелеп ята иде. Менә шушы ат тезгененә бәйләнгән бау буенча чамалап барып кына үзен казып алдык. Ә ул өеннән чыкты да, кышкы йокысыннан уятылган аю сыман котырып, безгә ябырылды. Телендә гел бер сүз. «Мин Андрей кенәзне беләм, ул да мине белә, шуңа озатыгыз». Ә үзе исемен дә әйтми. Әллә шымчы ул, әллә карак—шайтан белсен. Аптырагач, кул-аягын бәйләп йөртергә мәжбүр булдык.

Козьма сузып маташмыйча кискен әмер бирде:

—Бауларын чишегез. Ул кол түгел.

Кул-аягын чорнаган сус бауларны кисеп ташлагач та, Хәмбәл байтак вакыт буена кымшана алмыйча утырды. Ахырда ирләр аны сөйрәп диярлек иярдән төшерделәр. Ә ул аяклары җиргә тию белән йолкыш киемдәге ирләрне шундук читкә этеп җибәрде. Бер-ике мәртәбә чүгәләп аяк язып алды. Шуннан соң инде һичнинди михнәт-җәфа күрмәгән һәм дөньяның кендегенә басып йөрергә күнеккән кыяфәттә Козьма-атаманның каршына килеп төкәнде. Сүз дә юк, бу кешедә табигать тарафыннан бирелгән көч-куәт иксез-чиксез иде.

—Мин сине кайда күрдем соң әле? Элек кем идең син?

Хәмбәлнең шушындый халәттә дә тамак төбе белән генә, көрпәләнеп эндәшүен күргәч, Козьма хәйран калды. «Карале син моны. Әйтерсең, мин болгарлар җиренә килгән бер сукбай да, ул андагы әмир»,—дигән мәсхәрәле уй зиһенен яндырып узды. Икенче мизгелдә инде Козьма да ияген күтәрә төшеп, эре җавап бирде:

—Мин—Козьма. Заманында синең Болгарыңа Андрей кенәз сакчысы булып барган идем. Хәзер мин—атаман, ягъни үземә-үзем хуҗа. Бер генә кенәзгә дә баш имимен. Хәтта, байтак боярлар минем ватагамнан дер калтырап тора.

Хәмбәл барысын да бик тиз генә аңлап бетерә алмый изаланды бугай. Ул бераз вакыт буе күзләрен кыса төшеп, уйга чумып торды. Аннары бармагы белән Козьманың күкрәгенә төрткәләп, дөньяның ләүкәсенә менеп яткан кеше кыяфәтендә янә кыю дәште:

—Әйе, әйе. Моннан ун еллар чамасы элегрәк син минем йортымда кунак булган идең. Искә төшердем мин. Без синең кенәзеңне бөтен ил буенча йөртеп олы кунак иттек. Ә менә хәзер инде мин кунакка килдем. Атаман да булгач, үзеңнән әллә никадәр боярлар да куркып торгач, әйдә, мине элеккеге кенәзең янына илтеп җиткер.

—«Урманга ашыкма, кәҗә, барча бүре синеке»,—диде дә, Козьма әүвәл ихахайлап көлде. Бераздан тавышына җитди аһән инде.—Минем кенәз синең иленә яраннарын, сакчыларын, җитмәсә әле бүләк-санагын да алып барган иде. Ә син берьялгызың. Кесәңдә язгы йомран оясындагы шикелле җилләр улап тора. Кыскасы, сәяхәтең шикле. Шуңа күрә сиңа әүвәл минем базымда тукталып ял итәргә туры килер, ахры, кунак әмир.

—Мин Болгар мәмләктәнең олугбәге. Сезнең кенәзегезгә җитди йомышым бар. Юлда үткән һәр көн алтынга тиң. Кенәзең янына алып бар!—дип Хәмбәл төкрекләрен чәчеп җикерсә дә, атаманның төге дә селкенмәде.

—«Берәүгә күз кысу да җитә, берәүгә тукмак та аз»,—дип ул башта янә үзалдына сөйләнгәндәй итте, аннары инде Хәмбәлнең йөзенә текәлеп, ачу белән дәште.—Берәр атна чамасы миндә кунак буларсың. Кенәзгә булган йомышың турында энәсеннән жебенә кадәр башлап миңа сөйләрсең. Кенәз янына илтергәме сине, янә болгарлылар кулына кайтарыргамы—монысын инде үзем хәл итәрмен.

Кабат Болгарга кайту куркынычы хакында ишетүгә үк Хәмбәл тишелгән туп шикелле шәлперәеп төште. Аның йөзенә кара төс ятуын Козьма-атаман да күреп алды бугай. Ул Хәмбәл кайгысын гел оныткан сыман, кәрван ягына борылып, оран салды:

—Олаулардагы барча ганимәтне кызыл базга кертеп бушатыгыз. Ә аннары мәҗлес. Ватага Муром отрядының җиңү яулап кайтуын тантана итә. Карагыз аны, Суздаль белән Рязань юлларына каравыллар куярга онытмагыз.

«Ганимәт», дигән сүзне ишетүгә үк Хәмбәл Козьма-атаманның беләгенә килеп ябышты, сулышы кабудан сүзләре гел өзек-өзек чыкты:

—Минем хәнҗәрне талап алдылар... Синең башкисәрләрең... Алтын кынлы хәнҗәр. Якут ташлар белән бизәлгән. Атам истәлеге. Кире кайтар...

Козьма аланга чыгып бер генә җикерде, ике-өч минуттан соң инде атаман каршына ак чүпрәккә төрелгән хәнҗәрне китереп тә салдылар. Козьма аны күрде дә, бөтенләй «аһ» итте. Әйе, һичбер төрле шик юк: бу

кайчандыр аны Андрей кенәз исеменнән үз куллары белән Кашан бәге Колын-Хисамга илтеп биргән бүләк хәнҗәр иде. Козьма аны озак вакыт буе кулларында әйләндереп торды, аннары Хәмбәлгә төрттереп алудан да тартынмады:

—Андрей кенәзнен күнеленә бик хуш киләчәк бу. Югалта күрмә моны, бүләккә әзерли тор.

## 2

Ниндидер Болгар әмирен Боголюбово кальгасына китерүләре турындагы хәбәрне ишетүгә үк Андрей кенәз шактый аптырап калды.

—Нинди әмир тагын? Аны кайда тотканнар да, монда кем китергән?

Каравылбаш Довмонт үзе дә җилкәләрен сикертә-сикертә яна баштан кабатларга мәҗбүр булды.

—Әле генә алар Рязань ягындагы асма капка аша кальга эченә керде. Болгар әсире дигәннәре әллә Камбал, әллә Анбал атлы инде, төгәл анламадым. Анын белән син, кенәз, Болгарга сәяхәткә барган чагында кат-кат очрашкансын. Аны Рязань урманына тупланып яткан ушкуйлар Клязьма буеннан тотып кайткан, диләр. Шунын сина бик тә, бик тә ашыгыч йомышы бар икән. Әмирне кальгага Рязань ватагасынын башлыгы үзе озата килгән. Анысынын исемен кат-кат сораштырдым, мәгәр белә алмадым. «Мичкә керсәм, Андрей кенәз мине артымнан да танып аера», ди. Башка бер сүз әйтми.

Андрей кенәз инде йокларга ятарга җыенып йөрсә дә һәм кунакларны үз йортында кабул итә торган гадәте булмаса да, бу юлы кулын кискен селтәп ризалыгын бирде.

—Алай бик билгеле кешеләр дә булгач, әйдә инде, чакыр.

Берничә минуттан сон каравылбаш Довмонт шул ук кылка киемнәренә төренгән Хәмбәлне ияртеп, йорт эченә инде. Әлбәттә, тәүге минутта Андрей Хәмбәлне танымыйча торды. Җитмәсә, каравылбаш белән кунакнын—икесенен тин йөзләре кара көйгән иде. Чит-ятлар каршында һәрвакыт сак булырга күнеккән кенәз аларнын пошамангa төшүен күрүгә үк, капылт әсәренде. Дәү йодрыгын биленә асылган кылыч сабына куеп, тиз-тиз сорау бирде:

—Ни булды анда тагын? Нинди сәер тынлык?

—Менә бу әмирне озата килгән бәндә юкка чыкты,—дип Довмонт сүз башлады.—Әле генә шушы әмир белән каравыл йортында утырып тора иде. Коралларымны җыеп йөргән арада әйләнеп бер карасам, инде җилләр искән. Җир йоткан шикелле кинәт юкка чыкты.

Андрейнын йөзе агарынды, ул җикеренүгә күчте:

—Барча сакчыларга катгый әмер җиткер. Капкаларны барысын бикләсеннәр.

—Инде хәбәр иттем, һәммә капка бикле. Сакчылар ул качкынны йортлар, келәтләр буенча да эзли чыкты. Кибәндәге энә түгел бит, качып котыла алмас, аны тиз табарлар.

Каравылбаш кенәзне шул рәвешчә юатырга тырышса да, Андрей көтелмәгән кунакнын каршына килеп басты.

—Ә-ә, син Кашан каласындагы Колын бәкнен улы Анбал түгелме сон? Әтиен инде күптән вафат бугай. Ялгышмасам, син үзен әле кичә генә Бәрәҗ ханнын башсәрдәре иден. Монда нинди юллар һәм нинди максат белән килеп чыктын икән?

Андрей тиз-тиз генә шулай сөйләнде дә, мылтык аткан сыман яман тавыш белән кискен сорау бирде:

—Юлаучын кем иде? Аны кая куйдын?

Кырыс тавыштан коелып төшкән Хәмбәл берникадәр көттереп телгә килде:

—Козьма дигән бәндә озата килде мине. Ватага башлыгы ул. Заманында синең сакчың да, коралчың да булып йөргән кеше. Син аны бик яхшы беләсең бит, кенәз. Әле Болгарга да аның белән бергә килгән идең.

Инде хәзер Андрей коелып төште.

—Козьма? Минем сакчым Козьма? Ул бичара да, димәк, исән икән. Ә мин аны алты-җиде ел элек үк тәмам югалттым бит.

Аннары Андрей каравылбаш тарафына борылып әмер бирде:

—Сакчыларга житкер. Козьма-пәһлеванны эзләүне хәзер үк туктатсыннар. Бердән, мин Козьма белән очрашсалар, сакчыларның исән калуына нык шикләнәм. Икенчедән... икенчедән, минем ул егетне дарга асасым килми. Аның ватагасы турындагы хәбәрне күп ишеттем. Мәгәр башлыклары Козьма-пәһлевандыр, дип уйламаган идем. Алар Владимир кенәзлегенә зыян-зәүрәт итми, файда гына китерә. Әгәр шулай икән, әйдә, яши бирсен.

Каравылбаш Довмонт чыгып киткәч, йорт эчендә кабер тынлыгы урнашкандай булды. Андрей белән Хәмбәл бер-берсенә текәлеп озак вакыт буена сүзсез утырдылар. Кенәз булган кеше вәкарь дә, төксе дә караш ташлый-ташлый кунагына тамга сугып барды. «Һе, Кашан каласында булган эрелек юкка чыккан синдә, шыксыз батыр. Ул чагында син кыяфәтең, дуамаллыгың белән өнне алган идең. Хәзер, әнә, син йонын бүре талаган мескен бәрән төсле. Чит дәүләт кенәзе күзенә килеп күренергә өстендә юньле-рәтле киемең дә инде калмаган бит. Син үз илеңнән Әрбәт сыман җаныңны сакларга дип чыгып качтың микән? Әллә сине адәм рисвае итеп куып чыгардылармы? Синең эчендә күпме кара уй бар да, миннән нинди ярдәм өмет итәсең икән?..»

Балавыздан ясалган сын шикелле тып-тын утырган Хәмбәл берзаманны кылкаланып беткән күлмәген күтәрде дә ак чүпрәккә яртылаш төрелгән хәнҗәр суырып чыгарды. Сукбай кунакның кулында корал күргә үк Андрей кенәз шундук кылычына ябышты. Күз ачып йомган арада, кылычын югары күтәреп, Хәмбәлнең каршына ук килеп басты. Кунак саксызрак бер адым ясаса, Андрей аны урталай өзеп ташларга да инде әзер иде.

Хәмбәл шуны чамалады бугай, янып-пешеп, ашыгып телгә килде:

—Сиңа бүләк бит бу, кенәз. Начар уйлый күрмә.

Шуннан соң гына Андрей кылычын кынына яшерде. Дулкынланыпкаушап хәнҗәрне кулына алды һәм ул да, нәкъ Козьма шикелле, корт чаккандай сискәнеп үк китте. Һичбер ялгыш-мазар юк, кулына тоткан хәнҗәр—ул үзе үк Кашан бәгенә калдырган иң зур бүләк иде. «Һе, бик тә сәер фал бу,—дип уйланып куйды кенәз, беркадәр тынычлана төшкәч.—Бүләк итеп бирелгән кораллар да урыс җиренә кире кайта икән, димәк, хәлең бик тә хөрти синең, әкияти Болгар. Корал иясен алыштыра икән, димәк, куәт миңа күчкән. Димәк, әлеге хәнҗәр булып мин Болгар өстенә кадалырга тиеш».

—Сезнең илдә булып кайтуыма тиздән унике ел,—дип, ниһаять, Андрей талгын сүз башлады.—Төс-кыяфәтеңне дә оныткан идем, әмир. Сине нинди җилләр безнең якка китереп ташлады да, ул Рязань юлбасарлары кулына ничек килеп эләктең?

Хәмбәл күңел капкаларын ачарга ашыкмыйча, беркадәр көттереп кенә җавап бирде:

—Мин кичерергә туры килгәннәрне Ходай Тәгалә дошманнарыма да күрсәтмәсен, кенәз. Андый түбәнлекләрне бу җиһанда татымый китүен күпкә хәерлерәк...

Хәмбәл йөк күтәреп торган кеше шикелле авыр сулап алды. Монсу, ачулы күзләре керфекләре астына кереп чумды. Сизелеп тора—кунак күнелендәге сер һәм кайгыларын тулысынча ачып салырга читенсенә иде. Шуңадырмы, хатирә-кичерешләрен кенәз өчен бөтенләй дә әһәмиятсез бер тарафка борды.

—Ука елгасына кадәр араны чагыштырмача җинел үткән идем. Ибраһим кальгасыннан соң сезнең якка чыккач, юлны гел югалттым. Буранда урман эчендә адашып йөрергә дә, ач бүреләр өере белән очрашып сугышырга да туры килде. Ярый әле тулпар ат коткарды. Аннары инде юлбасарлар кулына килеп эләктем. Синен элеккеге сакчын, Козьма-карак, мине атна буе диярлек базга ябып тотты. «Чокырга егылып төшкән кәҗә бүрегә дә җизнәкәем, дип эндәшергә мәҗбүр»,—дигәннәренә элеккерәк елларда ышанмаган идем. Мәгәр шундый мескен хәлне, менә, үземә дә кичерергә туры килде. «Кенәзгә ашыгыч йомышым бар»,—дип, атна буе ялваргannan соң гына, мине бирегә китерде бит ул Козьма-карак. Анда да әле...

Кенәз белән ике арада ныклы күпер булдырырга хыялланган Хәмбәл тагын нидер тезәргә җыенган гына иде, Андрей аны кискен сорау белән шып туктатты. Хәмбәлнең кирәксез, буш сүзләре анын сабырлык чишмәсен коргаксытты бугай.

—Ябык сөт чүлмәге тирәсендә бөтерелгән мәче сыман урап йөрмә әле. Турыдан ярып сөйлә. Син ни сәбәпле безнең урыс кенәзлекләренә килеп чыктың? Болгарда ни булды? Миңа нинди мөһим гозерең бар?

Хәмбәл янә иннәренә тегермән ташы салган шикелле авыр сулап куйды, карашына кара корым ятты. Өметләнергә һичбер нигез дә юк: гаярь, шанлы кенәз аңа үз тиңе яки олы кунак итеп ихтирам күрсәтергә һич җыенмый иде.

—Болгар иленнән чыгып качарга мәҗбүр булган кеше шул мин, кенәз.—Хыял гөмбәзе җимерелеп кәефсез калган Хәмбәлнең тәүге сүзләре теш арасыннан сытылып кына чыкты.—Мин күптән инде олугбәк тә, башсәрдәр дә түгел.

«Елан сыман боргаланма инде. Мине үз илемнән куып җибәрделәр, дип дөресен генә сөйлә!»—Андрей кенәзнең шул рәвешчә кинәт кычкырасы килсә дә, ул һаман да тешен кысып түзде. Хәмбәлнең алдагы сүзләре аны сагайткандай итте.

—Хәзер Болгар дәүләтендә моннан ике ай элек курсыбай юкка чыкты, дип сөйләсәң дә була. Башсәрдәр булып торган чагымда минем кул астында биш мең гази иде. Анын ике мене Сувар каласына поход ясаганда таралышып бетте. Соңыннан Биләр каласыннан да меннән артык гази чыгып качкан, диделәр. Шулай булгач, Бәрәҗ хан кул астында бүген ике мең чамасы сугышчы да, яуларда тәҗрибә туплаган башсәрдәр дә юк. Инде ун ел буе диярлек кала диварларын янарту, яна кирмәннәр төзү белән беркем шөгыльләнми. Калалар тирәли казылган ерымнар яртылаш күмелеп бетте, аларның байтак урыныннан арбалы ат белән дә үтеп йөреп була. Һәрбер кала бәге үз кирмәне эченә бикләнеп кенә яши. Һәр бәк үзенә генә буйсына торган шәхси алай тота. Бәкләр бер-берсенә ярдәм кулы сузмый. Һәркайсы да күршесенең көчсезләнеп таркалуын һәм юкка чыгуын гына көтеп тора. Бәкләр, әмирләр күптән инде ханга буйсынмыйлар. Ә ханның аларны тезгә куярлык һичбер куәте юк. Һәрбер кала даладагы ялгыз агач яки сыңар бармак сыман аерым хөкем сөрә.

Хәмбәл сөйләгән саен Андрей карашында ниндидер зәһәр ут ялкынсына барды. Ул күбесенчә яралы кошчык өстенә ташланырга әзерләнгән ерткыч мәче карашын хәтерләтә башлады. Тагын да түзәрлек әмәле бетте бугай, Андрей сулышы капкан сыман кырыс тавыш белән капылт бүлде:

—Тукта, тукта, әмир. Син нигә дип бу хәлләрнең һәммәсен дә бәйнә-бәйнә тезәсең соң әле? Мин тел төбеңне аңлап бетерә алмыйм.

Хәмбәл куе керфекләре арасыннан кенәзгә күз ташлады. Ирен читләрендә генә мәсхәрәле елмаю чагылып алды. «Эх, мәгънәсез кенәз! Кәҗә дигән малдан да хәйләкәррәк вә сукыр чебеннән дә томанарак җан иясе булып күренергә маташмасаң иде син. Мин китереп житкергән һәр хәбәрнең асылын бише-уны белән аңлап барасың бит. Комсызлыгың,

әнә, йөзеңә бәреп чыкты. Телеңә дә мөлаемлык, хәерхаһлык инде. Хәбәрләрнең асылын аңлауга ук, тәүге тапкыр, мине әмир буларак таныргa түбәнчелек күрсәттең түгелме соң?» Хәмбәлнең ярымкысылып төбәлгән карашы шуларны сөйләсә дә, ул авызын уйлап-уйлап ачты.

—Мин аңларга теләгән кеше өчен шактый анык итеп сөйлим төсле, кенәз. Яклаучысыз калган, башбаштаклык эчендә яшәгән бай дәүләтне ялкау күрше генә таламыйча түзәр.

—Алай булгач, син мине Болгар өстенә яу белән барырга дип үгетләргә килдең инде, әмир?

Хәмбәл кышкы буран сыман кыюлана, әрсезләнә башлаудан да бик үк тартынмады.

—Юк ла, мин сине яу йөрергә, кан коярга мәҗбүриләмим, кенәз. Әйттем исә кайттым.—Хәмбәл юри туктап тын алгандай итте.—Мин Болгарның бүгенге хәле хакында дөресен сөйләп бирдем. Калган ягын инде үзең кара.—Хәмбәл янә бер тукталды.—Дөрес, син пошмаслык йә ачыгавызлык күрсәткән бер арада кыпчак, карлук ханнарының, һич югы Муром кенәзенең булса да Болгар өстенә шактый алда барып өлгерүе мөмкин. Ничек диләр әле? «Улы аягына ыштыр ураганчы, әтисе инде урманга барып житкән»,—диләрме? Әнә шуның сыман һәрбер эштә елгырлык вә тәҗрибә дигәннәре дә гел-гел кирәк бит ул.

Андрей каш җыерып тынлаган көенчә уйга чумып алды. «Ә син юкә кайрысы сыман беркатлы гына түгел икән әле, качкын әмир. Хәйләкәрлек белән мәкерлелек агулары синнән тау чишмәсе кебек ургып тора. Үз башыңны саклап калу өчен син, мөгаен, туган атаңны җәллад балтасы астына салырга да күп сорамас идең».

Андрейның чираттагы сораулары маңгайга китереп суккан шикелле кискен яңгырады:

—Ярар, иртәгә үк кубып бер Болгар өстенә яу походы белән бардык та, ди. Ә син үзең ул походтан ниләр отмакчы буласың соң? Җиңү яуласак, анда кем булырга инде синең исәп?

Йорт эчендә дары мичкәсе шартлагандай булды.

—Хан, бары тик хан!

Күкрәгенә тупланган үч-ачуны, кыргый вәкарьлекне тыя алмыйча Хәмбәл урыныннан ук торып баскан иде. Андрей аның кыяфәтен күреп хәйран калды. Хәмбәлнең борын яфраклары кискен киерелгән. Карашында усал кисәү яна. Тимер кыскыч булып җыелган авыр йодрыклары дер-дер килеп тора. Шикләнерлек түгел, үз максатына ирешү өчен кыйбласыз бәндә меңәрләгән кешеләрнең гомерен дә һич кызганмас иде.

—Ә сине үз илеңдәге халык хан кадәр хан тәхетенә кабул итәр микән?

Хәмбәл йодрыкларын селтәп һәм ниндидер билгесез ноктага төбәлеп усал җавап бирде.

—Әй, халык өере—карусыз ат бит ул. Аның муенына кем бугалак сала, гадәттә шул кеше хуҗасы да була. Аннары чыгымчылаган атны акылга утырту өчен бу җиһанда камчылау, чыбыркылау дигән ысул да бар бит әле. Җиде кат тиресе салынырлык итеп камчыласаң, иң чыгымчы ат та юньгә килә.

«Син башсәрдәр булып торган кеше, ил камчысы идең. Тик шулай да дәүләтегез халкы—чыгымчы ат—сине үз сыртыннан чәнчелдереп кенә калмаган, илеңнән үк читкә сөргән әле»,—дип Андрейның янә бер мәртәбә Хәмбәлне чеметеп аласы килсә дә, ахырда ул тыелып кала белде. «Ярар, бу бичара үзен булачак хан күреп хыяллана бирсен. Аннан кемгә зыян? Иң мөһиме, ул әлегә миңа Болгар эчендәге хәвефсез юлларны, калаларның йомшак урыннарын күрсәтү, дошман оборонасының алымнарын өйрәнү өчен кирәк. Ә инде Болгар иленә үтеп, аны тулы көе тез астына салсак, андагы тәхет өстенә кемне утыртырга—монысын күз күрер. Муен булса, камыт табыла ул. Тәхетен яуласак, хан да тиз табылыр. Ахыр чиктә, Болгар тәхетен Владимир каласына кайтарып кую мөмкинлеге булуын да

онытмаска кирәк».

Андрей кабат үз урынына сенгән Хәмбәлнең төс-килбәтен тагын бер кат күздән кичерде дә, йөзен чыгып куйды. «Киемнәре кылка, үзе бигрәк мескен. Аның мина хыянәт итүе шикле. Абруйлырак эш тапшырып, бу вәхшинең ышанычын казансан да ярыйдыр».

—Бер-ике атна эчендә генә зур походны әзерләү мөмкин эш түгелдер. Ул вакыт эчендә үзең монда нинди вазифа үтәргә җыенасың?

Хәмбәл инбашларын сикерткәндәй итте.

—«Кунак—хуҗаның ишәге»,—дип әйтергә ярата торган иде минем әткәй-мәрхүм. Шулай булгач, нинди эш кушасың, мин барысына да риза.

—Син бит әмир кеше. Вак-төяк эш биреп түбәнсетеп булмас. Болгар халкы укымышлылыгы, сәүдәгә хирыслыгы белән дә бик нык аерыла. Әйдә, булмаса, син кенәзлектәге бөтен казна эшләрен үз кулына ал.

Өмет канатлары тереләә башлаган Хәмбәлнең гаҗәпләнү тулы карашы белән очрашкач, Андрей өстәп куйды:

—Юк, казна малына кул сузарсың, дип һич тә шикләнмим мин. Туган иленә кайту юлың бикле. Ә ачкычы миндә. Шулай булгач, урыс кенәзе белән тату яшәү сиңа отышлырак.

Чарасы юк иде, Хәмбәл сүзсез генә ияк кагып куйды. Чираттагы качкын әмир өчен рус җирендә тормыш шулай тернәкләнде.

## 3

Андрей кенәз икенче таңда ук үз янына өлкән улы Изяславны дәште. Уналтынчы яше белән генә барса да, Изяслав әтисенә охшап эре сөякле һәм ул үҗәт кысылган ирен өсләрен, ияк тирәләрен каплаган җирән төстәге сакал-мыек төкләре белән җитлеккән егетләрне хәтерләтә иде. Әтисенең юк-бар өчен генә чакыра торган гадәте булмаганлыгын нык белгәнгә күрә, бүген дә ул кенәз йортына ашыгып килеп керде. Әтисенең талчыккан, суырылган кыяфәтен күргәч, егетнең йөзе дә бик тиз җитдиләнде.

—Исәнме-саумы, улым. Сирәк күренәсең. Зосим-атакай янында гыйлем үзләштерү ничек бара?—дип кенә сорады да, «әйбәт» дигән гадәти җавапны ишетүгә, Андрей аңа утырырга кушты.

—Бик җитди сөйләшү бар, улым, әйдә, утыр. Мин бүген төн буенча керфек какмый чыктым. Урыс халкы өчен кулай хәбәрләр күп. Менә шуларны бизмән аша үлчәп чыгу кирәк. Син инде унбиш яшь тутырдың, өстәвенә, кенәз токымыннан. Сиңа да ил кайгысын иңенә алырга вакыт килеп җитте. Яшьли чыныккан сөяк—нык, ә аң үткен була. Әйдә, фикерләшик.

Аксыл-сары озын чәчләрен иңбашына таратып салган Изяслав йомшак артлы кәнәфигә иңгәч, Андрей кенәз аңа текәлде дә, берникадәр вакыт уйга чумып торды. «Әниең сиңе бала чагында гел-гел Болгар илен, аның халкын, табигатен мактап кына үстерә торган иде. Ә менә хәзер минем ниятләрне ни рәвешле кабул итәрсең син? Ана сөте белән кергән хисләрме, йә булмаса, руханилар биргән тәрбияме өстенрәк—сынап карыйк».

—Мин синең белән Болгар дәүләте, аңа каршы яу оештыру турында сөйләшмәкче булам.

Изяславның йөзендә бер төк селкенмәде, хәтта, карашы да таш сынныкы кебек хәрәкәтсез калды. Андрей җентекләбрәк аңлатуга күчте.

—Моңа кадәр сәүдәгәрләр дә Болгар эчендәге хәлләр турында бик күп кенә хәбәр ташып торды. Анда тормыш хөрти, ил таркала иде. Кичә инде минем яныма качкын бер бәк килде. Андагы тормышны хәзер энәсеннән җебенә кадәр белдем. Тәхетләрендә буллыксыз хан утыра, дәүләт идарәсез. Калаларын сакларга бердәм гаскәре юк. Сиздермәстән барып таларга да, аларның җирләрен тартып алырга да гаять кулай

вакыт. Хәтта ки Болгарны тулаем көенчә урыс кенәзлекләренең тез астына салу да булдыра алмаслык авыр эш түгел. Мәгәр, моңа безнең көчнең генә житүе бик икеле. Заманында Арбат-воевода бик тә белеп әйтте. «Болгар дәүләте—ул бүген түшенә сәнәк кадалган үгезгә тиң. Ә үгезнең анын, яралы килеш тә, үз дошманын мөгезе белән эләктереп алып баш аркан чәнчелдерүе мөмкин». Шулай булгач, безгә бер яки берничә кенәз белән кушылырга, гаскәр куәтен арттырырга кирәк түгел микән?

Изяславта фикер бик тиз туды.

—Күршеләрне дә чакырсак, мөгаен, без җинәрбез. Тик бу очракта шәхсән үзебезгә генә тиешле зур данны без башкалар белән дә бүлешергә мәҗбүр булачакбыз түгелме соң, атай? Ә бу бит инде өстендәге киемнәрне салып чит-ятка өләшкән, үзе ярымшәрә йөргән ачыгавыз, сантый бәндә сыйфатында калган кебек була.

—Һе, мин-минлек хәтәр көчле икән бит синдә, күз тимәсен,—диде дә, Андрей әүвәл җинелчә бер кеткелдәп көлде, аннары гына йөзе җитдиләнде.—Иллә мәгәр үз борыныннан да арырак күрми торган малайшалай фикере генә шул бу, ачуланма, улым. Ә син—кенәз, киләчәктә ил тотасы кеше!

Андрей уң йодрыгын югарыга күтәрде дә уйнаклатып алды. Изяслав та кәнәфидә бер карышка үскән кебек булды.

—Әле нинди генә ил бит! Киләчәктә башкаласы Владимирга күчәчәк бердәм урыс дәүләте! Әйе, әйе, син безнең нәсел, дөресе минем нәсел алдында торган иң зур, иң җаваплы бурычны онытa күрмә, улым. Җиһанда мин тәгаенләгән иң зур максат—бөтен урыс кенәзлекләрен берләштерү. Безнең әле Киев каласын тез астына бөгеп саласы, андагы ел саен алышынып торучы мокыт-җебегәннәрдән «бөек кенәз» дигән дәрәҗәне тартып аласы бар. Безнең иң зур һәм иң куркыныч дошман әнә шунда—Киев каласында. Ә Болгар дәүләте—безнең өчен көчне сынап карый, талап кайта, тәҗрибә һәм байлык туплый торган бер биләмә генә бит ул. Болгарларның безнең өскә киләсе дә, безне җимереп яки көчсезләндереп китәсе дә юк. Алар өч-дүрт яшькә җиткән бала талаганда да имчәкләрен ачып тик утыра торган бичара ана сыман юаш, күндәм халык. Ә менә урыс кенәзләренең икесе-өчесе үзара кодалашып яки дуслашып алдымы—ул чак эшләр хөрти. Алар инде бер табын артында эчеп исерешкән шешәдәшләр төсле: урамда ялгыз йөргән бер бичараны эзләп табалар да, өелешеп шуны талыйлар, шуны дөмбәслиләр. Алар чама дигәнне дә, кызгануны да белми. Шуңа күрә, иң беренче чиратта, безгә үз туганнарыбыздан саклану, һәр тарафта уяу булу мөһим.

Әтисе тукталганны күреп, Изяслав сүз катты:

—Ә син Киевка яуны кайчанрак оештырмакчы буласың соң, атай?

—О-о, ашыкма, улым! Җитезлек, каударлык—борча эләктергәндә генә файдалы ул. Ә дошманыңа каршы кузгалганда көтеп тора, түзә белү мөһим. Анын чирле, яралы кеше кебек кан косып яткан чагын чамаларга да, өстенә менеп изгәләргә, йодрык кына түгел, хәтта, күсәк белән орып аны миңгерәтергә, юк итәргә кирәк. Йодрык төйнәгәнсең, яу чыккансын икән, кызганып маташкан булу, миһербанлылык күрсәтеп азаплану—гомумән, артык сыйфат. Дошманыңны бер сугуда имгәтү—менә шул чын ирлек. Ә Киевның әле кан косып яткан мескен чагы түгел. Андагы бөек кенәз үз тәхетендә иярдәге җайдак кебек әле нык утыра. Анын каравы, менә, Болгар иле хаста. Бәлки, әлегә аны дөмектереп булыр.

—Син кемнәрне ярдәмгә чакырмакчы буласың соң, атай?

—Төн буенча йокламый уйлап чыккан чакта мин Муром, Ростов, Рязань кенәзләрен үзем белән алырга ниятләгән идем. Ә менә бүген син бик шәп итеп төрттергәч, мин Муром хуҗасы «Карт Алаша» Юрий кенәзне дәшү белән тукталырга булдым. Ростов, Рязаньныкыларны да көтү итеп туплап, бөтенләй ыштансыз да калып булмас инде. Ә Юрие барсын. «Карт Алаша»га барыбер дан йокмый. Даннары бөтен нәселләренә

житәрлек итеп инде күптән чыккан.

Изяславның шактый сәерсенеп текәлүен күргәч, Андрей әүвәл кинәт кубып бер шаркылдап алды, аннары гына буразна эзенә кайтты.

—Моннан жиде-сигез ел элек болгарлар зур яу белән килеп Муром каласын кулга төшергәннәр[1]. Әсирлеккә эләксәләр дә, муромныкылар хәтәр генә үҗәтлек күрсәтеп, болгарларны котырткannardыр инде. Ярсыган болгарлар тотканнар да берзаманны Муром ирләренең яртысын алаша урынына печеп чыкканнар, ди. Биш елдан соң күрше кенәзләр килеп болгарларны куып жибәргәннән соң, ул печелгән муромлыларның беркадәре башка туганнары янында яшәп калырга хурланганнар икән. Җыенып кузгалганнар да, бер читкәрәк китеп менә шул алашалар яна кала корган. Үзләре елга исеменнән чыгып аны «Ока, Ока» дип атаган булсалар да, башка кенәзнекеләр аларга барыбер «Город обрезанных», «Резаный город» дигән мыскыл кушамат таккан. Тора-бара инде мондый кара тапны тарихка кертергә хурланганнар бугай, аны «Рязань» дип кенә йөртә башлаганнар. Мәгәр халык хәтере давылларда сынмас имән сыман нык бит. Менә, Юрий кенәз дә теге чакта печелгән бабасының кушаматын әле булса йөртә. Йөзгә-йөз килеп сөйләшкәндә «Юрий кенәз дә, Юрий Ярославич» инде ул анысы. Инде дә әз генә янга борыла икән, лач тегенә мөһер: «Карт Алаша», бөтен бәя шушы.

Ата белән ул икесе дә ихахайлап көлә башладылар. Андрей бер арада улының озын чәчләрен дә тузгыткалап алды, Изяслав карышмады.

—Мин сине сөйләшергә-уйлашырга дип кенә түгел, ә олы эш тапшырырга дип тә чакырдым бит, улым. Мин сине үз исемемнән, Юрий Ярославович белән сөйләшергә дип, Муром каласына озатмакчы булам.

—Мин бик риза, атай.

—Үзең белән биш йөз жайдаклы бер полкны алып, син бүген үк юлга чыгачаксың. Хатым инде әзер. Мәгәр, анда баргач син Юрий кенәз белән аяк терәп сөйләшергә, барысын да тик берүзен хәл итәргә тиеш. Идел боздан арчылгач та походка кузгалу безнең өчен иң-иң кулай вакыт. Без Болгар эченә үтеп кергәнче бер ай уза. Ә бу чакта Болгар ирләре, үләксә янына жыелган карга көтүе сыман, барысы да кырда казыналар. Аларда ул чак чәчү өсте була. Алар тиз арада гаскәр туплап безгә каршы күтәрелә алмый.

—Ә мин кайчан һәм кайсы калага кайтып сине каршы алырга тиеш булам, атай?

—Син кайтмыйсың, Юрий кенәз янында торып калачаксың,—дигән җавапны ишетүгә үк колакларын шомрайтып утырган Изяславның күзләре каш өстенә менгән кебек булды.

—Ничек инде?

—Бердән, Юрий Ярославович үз кул астына әлләни гаскәр туплый алмый. Ул төбәктә урыс авыллары да, калалар да бик аз. Икенчедән, безнең өстәге юрганны, ягъни безгә тиеш данны үз ягына суырып алмасын өчен ул «Карт Алаша»ның янына сине тегеп кую отышлырак.

—Алайса без кайда очрашабыз?

—Ука тамагында, болгарларның беренче кальгасы Городецка житкәч. Аны моннан йөз илле ел элек вафат булган Ибраһим төзесә дә, болгарлар үзләре әле һаман ул кальганы кайчакларда шул хан исеме белән атап йөртә бугай. Менә шул кальганы килә-килешкә үк һөҗүм ясап алу безнең тәүге күмәк явыбыз да булыр.

Үз гомерендә беренче мәртәбә әтисеннән житди вазифа йөкләнгәч, яшүсмер Изяславның иңнәренә канат үсте бугай. Ул инде кабаланып-янып урыныннан ук купты.

—Мин вакыт әрәм итмим, юлга жыеныйм, атай. Тизрәк Городец янында күрешергә язсын.

[1]Болгарлар Муромны 1088 елда яулап ала. Рязань каласы 1095 елда нигезләнә.

—Син, валлаһи, бәйгегә кузгалырга торган чабышкы ат кебек,— дип канәгать елмайды да, Андрей кенәз Изяславны кочагына алды.— Юлда артык каударланма. Дуамаллык һәм хис белән түгел, күбрәк акыл белән эш йөртергә өйрәнә күр, улым.

Әтисенең кочагыннан шуып чыгып, Изяслав тотып тыйгысыз рәвештә ишеккә ашыкса да, Андрей кенәзнең тонык, әмма кырыс тавыш белән дәшкән сүзләре аны идән сайгакларына кадаклап куйгандай итте.

—Әниеннең күзенә күренеп йөрмә. Ул Болгарга ясалачак поход турында белми-сизми калса, тавыш азрак булыр.

Изяслав артка борылып әтисенә текәлде. Карашы гаҗәпләнү һәм, хәтта, гаепләү хисләре белән дә тулы иде. Терекөмеш төсле мондый авыр карашны күтәрә алмыйча Андрей кенәз читкә борылды да, чарасызлыктан ихата эчендә хәрәкәтне күзәтергә тотынды. Изяслав бераз вакыттан соң гына, сүзсез-нисез рәвештә ишекләрне ачып, кенәз сараеннан чыгып китте.

## 4

Изяслав китеп атна-ун көн чамасы вакыт үткәч тә, Муром каласыннан чапкын килеп җитте. Юрий Ярославович походта катнашуга кош тоткан сыман шатланып риза булган, анда кала-авыллардан гаскәр туплау тулы куәтенә бара икән. Кайбер төбәкләрдә язгы чәчүне үткәрү турында уйлаучы да юк, алардагы ирләр, авылы-авылы белән кубып, дистә еллар буена читлек эчендә ятканнан соң иреккә чыгарылгач түшәктә үзен тилмереп көтүче шәрә хатын янына менәргә атлыккан тоткыннар шикелле, талау походында катнашырга ашкыналар, ди. Андый төбәкләрдәге ашкыну-әтәчлекне Юрий кенәз һәр авылга катгый саннар житкереп кенә берникадәр киметә, тыя алган. Әмма байтак ирләр барыбер дә тынычлану белми, алар әле теге, әле бу бояр кул астына барып, аның дружинасына ялланалар икән.

Андрей да үз кенәзлегендәге боярларга кичекмәстән Боголюб бистәсенә отрядлар, дружиналар җибәрергә боерып чапкыннар куды. Болгарга ясалачак поход турында байтак бояр инде алдан ук кисәтелгән иде. Шуңа күрә һичбер тарафта да тоткарлык-мазар, гомумән, күренмәде. Ике-өч көн дигәндә үк инде Боголюб бистәсе янындагы тигез ялан кырмыска оясы шикелле кайный башлады. Ә төгәл бер атна дигәндә походка кузгалачак гаскәр җыелып та бетте. Меңәрләгән кешелек гаскәрне ялан-кырда тоту ризык әрәм итеп кенә яту иде. Андрей озак сузмыйча походка кузгалырга да әмер бирде.

Юлда гаскәр икегә бүленеп барды. Җайдакларны Ука тамагына төбәп турыдан воевода Борис Җидиславич алып китте. Андрей кенәз үзе кораблар, баркаслар, зур-зур каеклар булып тезелешкән елга флотилиясен җитәкләде. Воеводага Андрей юлда ашыгып йөрергә фәрман биргән иде. Кенәз үзе дә елгада һәммәсен коры тотты, тукталып ял итәргә дә, ярда ашлар пешереп тоткарланырга да ирек куймады.

Алда Калачык яки Ибраһим кальгасы төсмерләнә башлаган чакта Идел өсте дә, Ука да язгы боз ташкыныннан арчылып өлгергән иде инде. Бу вакытта күп кенә вак елгалар ярларыннан ташып акса да, җайдаклар гаскәре дә юлда җитез йөргән булып чыкты. Флотилия Калачыкка килеп җиткән чакта Борис Җидиславич инде каланы тимер кыршау сыман камап алган иде. Йөзәрләгән кораб-баркасларга тулып килгән җәяүле гаскәрне дә күргәч, Калачыктагы болгарлар каршылык күрсәтергә дип омтылыш та ясап карамады. Кальга капкалары фәлән еллар буена сузылган ялгызлыктан соң, ниһаять, аның ихатасына да тәрәз шакучы ир табылган бичара тол хатын каршылавы сыман ялындыру, ятсыну катыш зур күндәмлек белән ачылды һәм рус гаскәре барабаннар шавы, тантана авазлары астында ургылып эчкә узды. Суздаль тарафыннан килгән кайсыдыр бер отряд җайдаклары калага керә-керешкә үк сәүдә кибетләрен

таларга ябырылган иде дә, Андрей кенәз юллаган махсус дружина каракларны бик тиз ипкә-сапка кертте.

—Калачыктагы бер генә кибеткә дә кул сузмаска. Без аларны кире кайткан чакта да таларга сонармыйбыз. Ә хәзергә һәр бояр каладагы барча коралларны жыеп чыга да, булган барлык каек, баркас, атларны үз дружинасына тигез бүлеп ала. Гаскәр башлыгы кенәз Андрейнын катгый әмере шундый.

Йорттан-йортка күчеп, әле бер, әле икенче бай сәүдәгәр янында кунак булып йөрү башланса да, Андрей кенәз үзе күзгә күренеп янды, сызды, көйде.

—Бер көн вакыт заяга үтеп бара бит инде. Юрий кенәз кайда йөри сон? Ул «Карт Алаша»нын бугазы ачы бал дигәндә мәнге чама белми. Әллә поход барышында да исерек микән? Алай дисән, боярлар да бар бит. Муром отрядлары ни сәбәпле һаман күренмиләр? Изяславыма, Изяславыма ул-бу булмагае...

Муром дружиналары төн кергәндә генә Калачык диварлары янына килеп житте. Андрей кенәзнен гоманлавы дөрес булып чыкты: Юрий Ярославович аягына да басып тора алмаслык исерек хәлдә иде. Андрей аны шундук хужаларыннан бушатылган бер йортка озаттырды. Яшүсмер Изяслав кырыс әтисе каршында кыскача жавап тотты.

—Сез Муромнан кайчан кузгалдыгыз?

—Сигез тәүлек элек.

—Кенәз еш эчтеме?

—Көн дә.

—Ул «Карт Алаша» никадәрле гаскәр алып килде?

—Дүрт мен жайдак, жиде мен жәяүле.

—Кораллары нинди?

—Күбесендә сөнге, кылыч, калкан. Жәячеләр бик аз. Гаскәрнен яртысында көбә бөтенләй юк.

—Ул «Карт Алаша»нын кораб дигәннәре сонарыбрак киләме, әллә?..

—Бер генә кораб та юк. Кенәз утызга якын баркас жыя алды, мәгәр аларнын Болгарга кадәр барып житә алуы бик икеле. Алар яртылаш черек. Сумалаланганнары да берән-сәрән генә.

—Андрей янак сөякләрен уйнатырлык итеп уртын шыгырдатты.

—Ярар, ул «Карт Алаша» эчеп йөрде дә, ди. Ә син дә бит Муромда ике атна яттын. Ул баркас янарту, сумалалау эшләрен нигә син оештырмадын?

Изяславнын күзләре кайнар аштан авызы пешкән кешенеке шикелле акаеп чыкты, аптырашка калды.

—Кеше йортына барып тузан туздырмыйлар бит инде ул, атай. Минем гаепмени?

Андрей житдиләнеп, бармак селкеп дәште:

—Хәрби поход вакытында ата да, ул да юк, чурт та юк, шуны ятла, углан. Сугыш сукмагына фәкать яу ирләре, воеводалар һәм ана буйсынучылар гына тупланышып чыга. Хәрби походта хәтта улын булып улына да ташлама ясау, аны үчтекиләп йөртү катгый тыела. Чөнки якынлык мөгамәләсе күрсәтү сугышчан тәртипне какшата, көтелмәгән корбаннарга китерә. Менә шунын өчен мин дә сина һич бернинди йомшаклык күрсәтеп тормаячакмын. Башкалар утка керә икән, син дә керәсен. Башкалар бәкегә төшә икән, син дә төшәсен. Ә инде куркаклык, жебегәнлек күрсәтәсен икән, яу кырында башкаларны ташлап качасын икән, ул чагында инде ин олы жәза сина әләгәчәк. Әгәр поход яки гаскәр таләп итә икән, мин синен муенынны үз кулларым белән кыюдан да чирканачак түгел. Менә шушы кануннарны ятла да, чын илбашы һәм уяу сәрдәр булырга әзерлән син, кенәз.

Әтисе каләр әтисенен «кенәз» дип үсендерүе яшүсмер егетнен иннәренә канат куйган кебек булса да, Изяславнын төсе-кыяфәте үзгәрешсез калды. Әнгәмә бик житди, хәтта, кырыс, усал, мондый чакта салпы

якка кыстырылган салам өчен дә һавалану анын тарафыннан тик малайлык кына булыр иде. Шуна күрә Изяслав әтисе яныннан чит-ят, гадәти бер сугышчы шикелле башын түбән иеп чыгып китте.

... Иртән Андрей кенәз йокыдан балтасын җуйган урманчы сыман бик кәефсез уянды. Ул әле һаман яшерен өмет белән Әрбәт-воеводаны көтә иде. Ләкин Әрбәт үзе дә, Мәскәү дружинасы да, барыбер, күренмәде. Әрбәт Боголюб бистәсенә килмәгәч, Андрей инде юлдан воевода тарафына өстәмә чапкын да куып караган иде. Кичә төн уртасында чапкын кире кайтты. Тик Мәскәү хакименең җавабы үзгәрешсез, кыска, катгый иде.

—Үз халкыма каршы корал күтәреп барырга башыма тай типмәгән. Мин үз анасын талап имә торган кансыз көчек түгел.

Шушы җаваптан соң кызган, ярсыган бер минутында Андрей, хәтта, Әрбәткә каршы махсус дружина юлламакчы да булган иде. Ләкин икенче мизгелдә үк инде анын хәтерендә моннан унҗиде ел элек әтисенең Кучкәй бистәсенә ясаган канлы походы янарды. Агач ботагында эленеп торган Кучкәй гәүдәсе, җиргә ятып өзгәләнүче мескен Байгөл күз алдына килеп баскан кебек булды. Андрей шул афәтне янә бер мәртәбә кичергәндәй кара көеп чыкты һәм күнелендәге ачу-ярсу да көчле янгыр астында калган нәни учак шикелле әкренләп сүнде. Үз халкынын хәтеренә әтисе кебек үк кансыз, вәхши булып кереп калырга бу кенәздә теләк гел юк иде.

Иртән аягына күтәрелгәч Андрей Әрбәтне янә бер мәртәбә исенә төшереп алды да, шундый акыллы һәм булдыклы воеводанын янәшәдә булмавы өчен эчтән сызып куйды. Берникадәр вакыт уйга чумып утырды, бераздан йөзе кискен кырысланды. Җансакчылар башлыгы Петроны дәшеп алды. Карашын күтәрмичә генә салкын әмер бирде:

—Минем янга Муром кенәзен сөйрәп китерегез...

Муром хакиме Юрий Ярославович беркадәр айныса да, йөзендә бер төрле нур юк, күз төпләре, яңаклары ат таптаган сыман җәелеп төшкән иде. Түшәктән йолкып торгызулары өчен дә анын кәефе явыз мәче туздырган кош оясы кебек хәтәр җимерелгән иде, күрәсең, ул үзен ике яктан култыклап керүче сугышчылар арасында чәбәләнә-чәбәләнә мыгырдады:

—Башыгыз икеме әллә? Мин бит кенәз! Мондый мәсхәрәгез өчен мин бит сезне Идел төбәнә олактырам!

Үз каршында Андрей кенәзне күргәннән соң гына, Муром хакименең кикриге шиңгән сыман булды. Шулай да әле аягында басып торырлык куәте юк иде, ахры, ул авыр ухылдап урындыкка ауды. Андрей үгет-нәсихәт укып маташмады. Янгыраган әмерләре коры, кыска чыкты:

—Петро! Кенәзгә тозлы кыяр суы алып кер. Күбрәк китер. Юрий кенәз икеме-өчме чүмеч каплап куйгач, Андрей тарафыннан һич тә аңлашылмас әмер ишетелде:

—Зур бер мичкә табыгыз. Аңа дәү аю да сыя торган булсын.

Озак көттермичә бу әмернең үтәлеше турында да хәбәр җиткерделәр. Шуннан соң инде Андрей кенәз чираттагы әмере белән бүлмәдәге бөтен җансакчынын ис-акылын алды.

—Ә менә хәзер кадерле кенәзне кулларыгызга күтәрегез дә, шул мичкәгә чыгарып утыртыгыз. Капкачын ябуны да онытып калдырмагыз.

—Син нәрсә, Андрей кенәз, ычкындынмы әллә? Мин бит синең кебек үк кенәз. Бер үк походка дип чыккан воевода. Кул астымда күпме гаскәр бара!—дип, Юрий Ярославович чәпчи башласа да, Андрейнын бер генә төге дә селкенмәде.

—Ул гаскәрен үзеннән нинди хәлдә баруынны сизенмәсен дисән, мичкә-сараенда тынынны да чыгармыйча утыр, «Карт Алаша!» Ә тынынны чыгарсаң, мин ул мичкәнең бөкеләрен каплап куярга да күп сорамам...

Чәбәләнгән-ыңгырашкан кенәзне җансакчылар алып киткәч Андрей үз янына Хәмбәлне чакырып кертте. Кичәге башсәрдәр мондый игътибарны походка чыкканнан бирле көтеп тилмергән, ахры. Күнелендә йөрткән үпкә хисен ярып салудан да тартынмады:

—Кашык дигән малның кирәклеге ашарга утыргач кына искә төшә шул ул. Тамак тук чагында аны искә алучы да юк.

Андрей да шундык ук пырдымсызлык белән җавап бирде:

—Кашык өйрә, шулпа ашаганда гына кирәк бит ул. Ә ит калҗасына кадәр төшеп житкәч, анысын кашыктан башка да ашап була.

«Тешен үтсә, билгеле». Хәмбәл теленә килгән шундый сүзләр белән усал төрттереп алырга теләсә дә, кенәздәге кырыс кыяфәтне шәйләп эндәшмәде. Андрей аның нурсыз күзләренә төбәлеп сорау бирде:

—Сиңа кинәшкә керергә дә вакыт житте. Фикереңне белдер. Болгар үзәгенә кайсы юлдан керү отышлырак? Гаскәрләрне ничек алып барыйк? Кай тарафта безне дошман көтми?

Хәмбәл уйга калды. Тик озакка түгел. Аның инде күптән уйлап куелган планы бар иде, күрәсең. Ул шуны хәзер янә бер мәртәбә акыл бизмәненә салып үлчәде дә, ашыкмыйча тезә башлады:

—Миңа калса, гаскәреңне ике өлешкә бүлү хәерлерәк. Синең яу белән килүең турындагы хәбәр Бәрәҗ тарафына инде күптән китте, моңа шигең юктыр. Ул, мөгаен, сине Чулман тамагында көтеп торыр. Билгеле, әгәр инде гаскәр җыя алса. Ул куркакның пайтәхеттә бикләнеп ятуы да мөмкин. Мәгәр күз кашында иң катлаулы хәлне тоту кулай. Әмир Ибраһим һәм башка кала бәкләре булса да, алайларын туплап, сине Чулман тамагында көтә дип фараз кылыйк. Ул чагында аларны шул тарафка бәйләп кую өчен бер өлеш гаскәргә кораб вә каеклар белән Идел буйлап төшү кирәк булыр. Ә гаскәреңнең икенче яртысын Мәртүбә вилаятенә төбәсәң һәм андагы ар, чирмеш, мукшы аймакларын талап үтсәң—сине ул тарафта һичкем көтми. Син бик җинел рәвештә Алабуга кальгасына кадәр барып житә аласың. Аннары инде Чулман буйлап Болгар каласына йә пайтәхеткә таба хәрәкәт итеп була. Кысла сыман ике яктан берьюлы китереп кыссаң, Болгар мәмләкәтенең умырткасын да сындырып кую мөмкин. Янә бер мәртәбә кабатлыйм: сине Мәртүбә-Алабуга тарафында һичкем көтми.

Сүз дә юк, Хәмбәл ниятләгән план ымсындыргыч, төпле, ул тирәнтен уйланылган иде. Ләкин аның эчкерсез һәм үзенә карата хыянәтсез булуы Андрей күңелендә шик уятты. «Әйе, Анбал үз иленнән куылган, дүңгәләк шикелле шыр тамырсыз бәндә. Ана Болгар мәмләкәте кызганыч түгел. Мәгәр шул ук вакытта урыс кенәзлекләренә, урыс дружиналарына да төкереп бирә бит ул. Алар никадәр күбрәк кырылса, ана шул файдалы. Көчсезләнгән, яраланган җанварны кулга төшерү һәм буйсындыру җинел. Ә бу бәндә янә хаким булып йөрергә өмет итеп яши. Димәк, аның планнары бик еракка, алга төбәп корылган булырга тиеш. Бәс шулай икән, дүңгәләккә ышанып бетәргә ярамас... Аннары, әлеге качак сәрдәр миңа гаскәрнең бер яртысын чирмеш, ар, мукшы аймаклары аша уздырырга куша. Бу юл урыс воеводалары өчен бөтенләй таныш түгел. Сәүдәгәрләр, ушкуйлар сөйләвеннән ишетеп төгәл беләм: анда гел карурман, йөзләгән вак елгалар. Авыллар бик сирәк. Елгаларында—күпер, урманнарында юл юк. Безнең дружиналар анда шундук адашачак. Ачлык үзе үк гаскәрне дошман сыман кырып салачак. Юк, миңа Ходай мәрхәмәтенә өмет итеп язмыш белән шаярырга һич ярамый. Мин илле өч яшькә житеп беренче мәртәбә чит дәүләткә сугыш явы оештырган кенәз. Минем өчен җинелү—үлемгә тиң. Ә гаскәремне бер йодрык итеп туплап барсам, мине Болгар чирүләре мәңге җинә алмый».

Андрей каш астыннан гына төбәлеп, кырыс тавыш белән әйтте:

—Гаскәр тәҗрибәсез. Миңа аны бер кул астында тоту отышлырак.

Хәмбәл тавышында үртәлү һәм ачу яңгырады:

—Сынар кул белән адәм муенын да буып булмый. Болгар җиренә ике яклап бердәм бәреп керсәң, син аны чебеш ботарлагандай итәр иден.

—Ә мин аны маңгаена йодрык белән сугып та тезләндерә алам.

Хәмбәл барыбер ризалашмады, һаман кызды.

—Ай-һай, Андрей кенәз, мин моңа нык шикләнәм. Ябыкса,

хөнжүләнсә дә, Болгар—үгез бит ул. Ә үгезне йодрык белән генә сугып тезләндереп булмый.

Андрейны гүя усал бер корт чакты. «Мондый сүзләрне элек миңа Арбат-воевода әйткән иде, хәзер менә бу хөрәсән сәрдәр кабатлый. Нинди хәл бу?—дип үртәлеп уйланды ул.—Болгар—үгез, имеш. Ну, булса соң! Әйтерсең, үгез муенына элмәк салып булмый, суеп булмый. Барып кына житим, Болгарны тез астына салмый торып кире кайтасым юк!..»

Шул сәгатьтә үк Андрей кенәз барлык гаскәргә дә походка кузгалырга ашыгыч фәрман бирде. Юлда да чамадан тыш кырыс, каты куллы булды. Дружиналарның һәммәсен берниндиял, тынгы бирмичә алга куалады. Көпшәк елга тамагына житкәндә үз туганнарына карата коточкыч кансызлык күрсәтеп алудан да тарсынмады.

Гадәттәгечә, юлда баручы дружиналарны тикшергән бер танда Рязань тарафыннан килгән өч йөз кешелек отрядның юкка чыгуы ачыкланды. Ул төнлә, Фатьян атлы йөзбашлы кул астында, якындагы чирмеш авылларын таларга дип, читкә киткән икән. Бу хактагы хәбәрне ишетүгә үк Андрей үз янына инде мичкәдән чыгарылган Юрий кенәзне чакыртып алды, Әмере кыска булды:

—Иң шәп биш йөз жайдагыңны сайлап ал да, ул Фатьян азгыннарын кире борып кайтар. Буйсынмыйлар икән, кылычыңнан үткәр.

Шул көнне беренче мәртәбә рус гаскәре урыннан кулгалмыйча торды. Ләкин моның ирексездән генә туган ял икәнен, баш воеводаның угрыларны каршы алу өчен генә тукталуын һәркем белә иде. Юрий кенәз дружинасы качкын отрядны кич житкәндә генә алып кайтты. Качак-угрыларның кулында бер корал юк, хәтта, күбесе арканнар белән дә богауланган иде. Андрей кенәз шундук дружиналарга тыгыз сафларга тезелергә әмер бирде. Качакларны да Идел ярына тезеп бастырдылар. Андрей кенәз үзе алга чыкты һәм бу юлы да сүзен кыска тотты:

—Яу походы вакытында башбаштаклык күрсәтү, фәрман бозу, угрылык нияте белән читкә ябырылу—ул сәламәт тәнгә чыккан азгын чуан сыман. Чуан бөтен тәнне капламасын дисәң, аны төбе-тамыры белән сытып чыгару кирәк. Фатьян «алашалары» күрсәткән угрылык та безнең арабыздан шулай сытылачак.

Фатьяннныкылар гына түгел, хәтта, булачак хөкемне тамаша кылырга тезелгән гаепсез дружиначылар йөзенә дә шөбһә бәреп чыкты. Ә ул арада инде Андрейның кансыз, усал әмере яңгырады:

—Юрий кенәз һәм Изяслав кенәз! Үзегезнең кылыч орышы осталарын алга чыгарыгыз. Фатьян отрядында һәр унынчы угры «алаша»ның шушы урында башы киселәчәк.

Юрий Ярославович һәм Изяславның күзләрендә үпкә катыш нәфрәт ялтырады. Яшүсмер кенәз карашындагы үпкә-рәнжү хисе ачыграк та иде. Ул әтисенә текәлеп, хәтта, берникадәр вакыт тынсыз калып торды. Әмма шул минутта ук колагында Калачыкта булган кисәтү кабат янгарады:

—«Хәрби поход вакытында ата да, ул да юк, туган да, чурт та юк... Әгәр поход яки гаскәр таләп итә икән, мин синең муеныңны үз кулларым белән кыюдан да чирканачак түгел!..»

Йөзе һәм карашы капылт кырысланган яп-яшь кенәз үз дружинасы ягына томырылды. Берничә минуттан соң Идел ярында, әйтерсең лә, Газраил үлем биюен бии иде...

## 5

Андрей бар гаскәрне мал көтүе сыман чыбыркылап-һаулап куаласа да, чит-ят мөлкәт күргәч, урыс каны барыбер дә үзенекен итте. Болгар каласына житәргә дә ерак ара калмаган, Чулман белән Идел кушылган төш борын төбендә генә иде, югыйсә. Әмма Иделнең уң ярында, сөзәк тау битендә алтын айлары, көмешләнгән манаралары белән балкып утырган Ашлы каласын күрүгә үк барча воевода һәм

сугышчыларны, әйтерсең лә, күзән жыерды, дружиналар алга таба кузгала алмас булды. Берничә көн элек кенә, Көпшәк елга тамагында, Фатьян угрыларын җәзалау да онытылды, күрәсең, очсыз-кырыйсыз булып тезелеп килгән баркас-каекларның бик күбесе рөхсәт-фәлән дә сорап тормастан, Ашлы ярына каерып туктала башлады. Андрей ашыгыч рәвештә үз янына барча дружина башлыкларын чакырып алды, кызарына-бүртенә походның төп максатын анлатмакчы булды.

—Элеккеге пайтәхет—бөек Болгар каласы да, бүгенге яна мәркәз—Биләр дә кул сузымында гына. Болгар ирләренең һәммәсе дә кырда, иген чәчә. Бәрәҗ ханның илне сакларлык, безгә каршы күтәрелерлек көчле гаскәре юк. Болгар мәмләкәте бөтенләй, зәхмәт суккан яман сырхау сыман, үлем көтеп ята. Без болгарлар көтмәгәндә, капылт бәреп керсәк, аларның йөрәген—Биләр каласын да әлләни кан коймыйча эләктерү бик мөмкин. Ул чагында инде бөтен мәмләкәтләре дә безнең тез астына килеп ятачак. Байлыклары дәрья булып безнең кулга агачак. Шуның өчен ашыгу һәм янә ашыгу кирәк.

Үгетләүләрнең файдасы тимәде.

—Ай-һай! Һавадагы торнага өметләнеп, кулдагы песнәкне ычкындырмыйбызмы икән без?—дип, әүвәл янә теш-тырнакларын күрсәтә башлаган Юрий Ярославович каршы төшкән иде, аны башка воеводалар да бик тиз эләктереп алды:

—Бәрәҗ ханның ил саклардай куәте юк икән, нигә ашыгырга?

—Авызына керәм дип торган шундый шәп калҗаны ташлап китәр өчен ахмак булу кирәк.

—Болгары да, Биләре дә, барыбер, бездән качмас. Иң әүвәл, бу «Ашлы» дигәннәрен талап чыгыйк әле. Сугышчыларның да кәефе күтәрелер. Тәгам, нәфсе дигән явыз, ашый башлагач, ныграк котыра ул.

Андрей кенәз воеводаларга бер-бер артлы текәлеп баш чайкап торды да, аннары «әйдә, тыгыныгыз», дигән сыман кул селтәде. Берничә минуттан соң Идел өстендәге барча баркас-каек, саранча шикелле, ярга ябырылды. Әмма рус воеводалары Ашлы каласын чәйнәмичә дә йота торган шәп калҗа дип күз алдына китереп юкка гына хыялланган икән. Читтән караганда юаш килен сыман тавышсыз-тынсыз гына утырган бу кала үз өстенә ургылып килгән баскын көчне биек урлар, сулы тирән ерымнар, бикле капкалар һәм тарак теше сыман тырпаешып торган ук-сөңгеләр карурманы белән каршы алды.

Баскынчыларны әйдәкләп яуга күтәреп маташу артык гамәл иде. Алар берсен-берсе сыта-сыта алга томырылды. Дивар өстеннән боз янгыры булып уклар яуды. Үткен чалгы кырып алган үлән тиземенә охшап беренче рәт ауды. Тәүге канны күрү рус сафларын дошман тешен татыган җанвар хәленә кертеп ярсындырды гына. Алар инде, нәкъ шул кыргый җанвар шикелле ырлап, гыжлап, үкереп, кала диварлары өстенә ябырылды.

Яу әлләни озакка сузылмады. Күк йөзеннән яшерен бер әмер алган сыман, ашлылылар берзаманны барысы күмәк кубып артка чигенделәр. Ул да түгел, Идел ягын каплап торган диварларның һәммәсен дә кипкән киндер япмаларыннан купкан янгын чолгап алды. Дистәләгән урыс баскынчылары ут эчендә калды, тәшвиш, мәхшәр купты. Баскынчылар янә бер-берсен сыта-сыта хәзер инде утлы дивар өстеннән җиргә сикерделәр.

Көнбатыш яктан җил кузгалып килә, янгын бик озакка сузылачак иде. Баскынчылар суга төшеп күшеккән йолкыш чебешләр кыяфәтендә янә яр буен сырып алган баркас һәм каеклар янына җыелыштылар. Андрей кенәз комсыз воеводаларын каһкаһәле көлеп каршылады.

—Нәрсә, торна тотарга хыялланып китеп, песнәкнең дә сөякләрен генә ялап кайтасызмы? Нәфсе дигән явызны авызлыклый белмәү шулай итә ул. Әйдә, бу Ашлыга ясин чыгыгыз да, корабларга төялегез. Болгарга житкәч, иң шәп торнаны мин сезгә үз кулларым белән тотып бирәчәкмен.

## 6

Андрей кенәзнең Болгар каласына ясаган һөҗүме, һичшиксез, аңа зур дан һәм мәртәбә китерә ала иде. Әмма дәүләтнең иске мәркәзенә булган бу һөҗүме урыс яубашына бик кыйбатка төште.

Ашлыны гаять җинел генә яулап алырга хыялланып авызлары пешкән баскынчылар икенче таңда хәтта Ага-Базар янына да зур саклану белән генә якынлашты. Тик данлыклы сәүдә мәйданы оста киленнәр юып төшергән сәке өсте шикелле буш һәм чиста, анда чатыр, кибет, арба ише әйберләрнең эзе дә юк иде. Ага-Базарда тау-тау тауар эләктерергә өметләнеп тә, янә бер мәртәбә алданган баскынчылар хәзер инде ярсый-ярсый Болгар каласына төбәлделәр.

Сүз дә юк, болгарлар иске мәркәзләрен теш-тырнагы белән яклаячак һәм әлеге кала өчен яуның бик кызу вә аяусыз булачагын Андрей кенәз тирән аңлый иде. Җитмәсә, каланың барча ныгытмаларын һәм дә төзелешен үз күзләре белән күреп кайткан кенәз аларны әле булса хәтерендә тота һәм калага һөҗүм иткән чакта берәрнинди хәйлә кулланып, үзенең хәлен җиңеләйтергә өметләнә иде. Шул исәптән чыгып ул гаскәрен Болгар янына житүгә үк өч кисәккә бүлде. Воеводаларны үз янына җыеп, төгәл, катгый фәрманнар да җиткерде.

—Юрий Ярославич!—дип, ул арада иң өлкән булган Муром кенәзенә беренче итеп эндәште.—Яшерен-батырын түгел, синең дружина арада иң хәлсезе. Сүзнең дөресе кыйбат, йә, йә, үпкәләмә. Мәгәр иң юньсез тәпәч турында да «дошман кыйнарга лаек түгел икән, мал көтүен куркытырга булса да ярап тора», диләр. Шулай икән, әйдә, син үз дружинаңны Чулман яры буенча тезеп бастыр. Дөрес, каланы текә яр буенча күтәрелеп яулау мөмкин түгел. Мәгәр шуңа карамастан сугышчыларыңны алга куала, алар дошманның билгеле бер көчен гел-гел шушы якка җәлеп итеп торсын. Һәм иң мөһиме, Болгар эченә ут ташларга тырыш. Янгын никадәрле күбрәк куба икән, башка яктан бәреп керү җиңелрәк булачак. Ну, Ходай Тәгалә фатихасы белән юлга!

Муром кенәзе үз дружинасы янына юнәлүгә үк, Андрей-яубашы Хәмбәл тарафына борылып басты.

—Менә, синең осталыкны, синең тугрылыкны сынарга да вакыт житте, Анбал. Бәрәҗ ханның нindirәк сәрдәре булгансың син, хан тәхете сиңа кадерлеме-юкмы, менә, яуда күрсәт. Әнә, минем воевода Борис Җидиславич канаты астында килгән Суздаль дружинасын үз кулына ал да, көнчыгышка юнәл. Үзең дә аңлыйсыңдыр, ул тараф—иң авыры. Бердән, син дала яклап һөҗүм итәчәксең. Икенчедән, сыртына Болгарга ярдәмгә килүче башка кала полкларының пычак кадавы бар. Мәгәр ничек кенә булмасын, сиңа да бер үк сүз. Ходай Тәгалә ярдәменнән ташламасын. Алга!

—Әмин!—дип сынар кулы белән генә йөзен сыпырды да, Хәмбәл авыз кырыйларына, иреннәренә килеп кунган канәгатьләнү, очыну хисләрен яшерә алмыйча, алга томырылды.

Инде берничә генә воевода әйләнәсендә калган Изяславка таба борылгач, Андрей әүвәл аны кочагына алды.

—Син бик яшьсең әлегә, улым, уналтыда гына. Мәгәр ил белән идарә итәсе кенәзне яшьли сынау кирәк. Боголюбта үткән сөйләшүне хәтерлисең булыр?

—Мин хәтерлим, мин әзермен, атай.

—Әгәр шулай икән, Владимирдан килгән дружиналарның һәммәсе—синең кул астыңа. Менә, үзең белән яуларда йөреп азау ярган Борис Җидиславичны да иярт. Сез менә бу тирән сулы ерым аша Айкапу яклап һөҗүм итәчәксез. Кара аны, борыныңны бик күтәрмә, яуда сак бул. Мин синең шәхсән үзеңнең һөҗүмгә баруыңны катгый рәвештә тыям. Ил белән идарә итәр өчен дуамал һәм мүкләк үгез түгел, акыллы ир кирәк. Колагыңа киртлә...

Һөҗүм алдан килешенгән сигнал буенча бер үк вакытта һәм бик уңышлы гына башланды. Аеруча Хәмбәл куалаган суздальныкылар өлгерлек күрсәтә һәм алар инде урыны-урыны белән хәтта диварлар өстенә дә менеп җиткән иде. Шул хактагы хәбәр, сугышчылар чылбыры аша күчә-күчә, яшүсмер Изяславка да килеп ишетелде. Мондый яналык яшь кенәз өчен яуда яраланудан да хәтәррәк иде һәм, әлбәттә инде, үтен сыткан сымак тәэсир итте.

—Әгәр Анбал шәһәргә беренче булып бәреп керә икән, атай монын өчен мине гомер буе да гафу итмәячәк!—дип, үзен-үзе белештермичә, Борис Жидиславич йөзенә кычкырды ул.—Аннары Боголюбка кайткач ул Мстиславны булачак хаким итеп үсендерсен дә, мин шул селәгәйнен йомышчысы гына булып калыйммыни?! А ну, давай, мине саклап йөрмә, син үзен дә дивар буена аттыр!

Андрей кенәзгә хезмәт итә-итә инде мыек чылгыйлары ук чалара башлаган воевода ярсуыннан дер-дер килсә дә, сүзсез буйсынырга мәҗбүр булды. Ә Изяслав исә һаман саен ярсый-шашына җикеренүен белде:

—Холопларны артларына сөнге кадый-кадый куалыйсыңмы, әллә үзен кылыч тотып яуга керәсенме—анысында минем эшем юк. Тик кара аны, кала эченә беренче булып бәреп керүче кеше син бул!

Карт воевода кин ерымнын аръягына күчкәч, чыннан да, һөҗүм активлашты. Инде бу тарафта да яу кин диварлар өстенә күчкән иде. Менә шул вакытта яшь Изсялав үзен-үзе тыеп кала алмады. Ана инде җинү кул сузымында гына булып тоела һәм ул шатлык, тантананын үзәгендә булырга ашкына иде. Ул, чабышка кузгалырга баскан ярсу чаптарга охшап, бераз вакыт кына урынында биеп торды да, аннары каударланып, зур сал өстенә сикерде. Сугышчылар озын колгаларны кулларына алып, салны ярдан эчкә этсәләр дә, барыбер җикерә-җикерә фәрманнарын бирде:

—Әйдә, тизрәк алга кузгалыгыз! Бөтен көч-куәткә кала диварлары янына! Без җинәбез! Мин, һичшиксез, беренче булачакмын!..

Яшь кенәз дуамаллыгы белән үзенен һәлакәтенә таба ашкынганын, әлбәттә, һич кенә дә абайламый иде. Ә бу вакытта кала эчендә хәлләр сонгы чиктә мөшкел, аны саклаучылар дошман һөҗүмен көч-хәл белән генә тыеп тора иде. Яуга кертергә үз янында бер резерв та калмагач, әмир Ибраһим шәхси дружина газиларына сонгы әмерен бирде:

—Нәсаралар калага бәреп керсә, утчагырлар барыбер дошман кулына гына эләгәчәк. Мона ирек куярга һич ярамый. Амбарлардан яшерен шәрҗирләрне тартып чыгарыгыз да, нәсаралар өстенә очырыгыз!..

Әнә шул, амбарлардан чыгарылган, утлы чүлмәкләрнен беренчесе үк нәкъ Изяслав баскан зур сал өстенә төшеп ярылды. Изяславны әле һава дулкыны ук сал өстенә күтәреп бәргән иде. Ә инде бөтен сал буенча котырып ут бии башлагач, ул анын да җуйды. Дружиначылар яну-пешуләргә карамыйча аны коткарырга ыргылдылар. Ләкин инде сон, ярты тәне янган-күмерләнгән Изсялавны үлем кочагыннан суырып алу мөмкин түгел иде...

Бу хактагы хәбәр килеп ирешүгә үк Андрей кенәз яшен суккан ялгыз агач сыман сынып төште. Болгар дәүләтенен бөтен байлыгы да аны югалтуын һич кайтара алмый, шунлыктан һөҗүмне дәвам итү дә кирәксез эш иде. Андрей кенәз дружиналарга кабат Ага-Базар янына кайтып тупланырга, дигән фәрман белән чапкыннарын куды.

## 7

Баркас-каекларга тезелгән рус дружинасы атна буена матәм тынлыгы эченә чумып кайтты. Мәрхүм Изяславнын җеназасы биек палубалы бер баркас борынына куелган, Андрей кенәз исә койрык өлешендә учларына таянып утырган да, кайгылы уйлар эченә кереп чумган иде.

Боголюбка кайткач, Байгөл бичаранын күзенә ничек күренер ул? Нигә, нигә диеп ул яп-яшь Изяславны үзе белән бу походка алды? Һәм нигә, нигә диеп яп-яшь Изяславны ялгыз көенчә канлы яуга кертте? Әллә соң Байгөл бичаранын Андрей кенәзгә дип юнәлтелгән усал каргышлары, язмыш шаяруы булып, Изяславка кайтып төштеме?

Эх, Боголюбка кайткач Байгөл күзенә ничек күренер ул?!

Авыр хәтирәле Көпшәк елгага якынлашкан чакта рус дружинасын шөбһә-хәвеф тулы хәбәр куып житте:

—Әмир Ибраһимнын икегә бүленгән гаскәре безнең эздән килә...

Бер ишкәккә икешәр сугышчы ябышып утырса да, дошман һөҗүменнән котыла алмадылар. Болгар гаскәре аларга таң атканда, ике як яр өстеннән дә бердәм һөҗүм итте. Баскынчылар дошман һөҗүмен һәр минутта көтеп барсалар да, тәүге ук янгыры ук йөздән артык сугышчынын гомерен кыеп китте. Болгарлар сызгырып-гүләп килә торган авыр ук очыра, алар исә иң калын көбәне дә үтәдән-үтәли тишеп чыга иде. Баскынчыларнын күбесе ихтыярсыз рәвештә баркас-каеклар төбенә сузылып ятарга мәҗбүр булды. Болгарларнын авыр уклары хәзер инде дан да дон килеп каек стеналарына кадала, баскынчыларга баш калкыту түгел, кымшанырга да ирек бирми иде. Әле ярый биек стеналы баркастагылар болгарларга каршы беренче җавапларын кайтара башладылар. Әмма алар да өстәмә дивар итеп тезелгән калканнар өстеннән калкып ныклап төзи алмый, шуна күрә болгарлар нигездә бер зыян да күрми иде.

Баскынчыларга ярдәм бөтенләй дә көтелмәгән яктан килеп җитте. Чирмеш урманы эченнән атылып чыгып болгарлар өстенә ташланган ике йөзләп җайдакны күргәч, һәр ике як аптырашка калды. Ул гына да түгел, урман эченнән янә ике-өч йөзгә якын җәяүле килеп чыкты. Алар теләсә нинди иске-москы, кылка киемнәргә төренгән, һәркайсынын йөзен-ияклəрен сакал басып киткән. Кулларындагы коралларын да адәм түгел, шайтан аңламаслык. Кайсында озын саплы сәнәк, кайсында чалгы, кылыч, ә шулай да күбесендә—җәя. Кемнәр болар—руслар ягына ауган чирмешләрме, кәрван таларга чыгып түземнәре төкәнгән юлбасарлармы?—беркем аңламады.

Болгар гаскәре эченә сөнге сыман бәреп кергән билгесез җайдаклар арасында өсте-башы көбә-очлымнарга капланган бер пәһлеван кылыч орышынын бар нечкәлекләрен белеп сугыша иде. Анын Дөлдөлнекедәй дәү кылычы астында болгар җайдакларынын ат өстеннән берәм-берәм очып төшүен күргәч, Андрей кенәздә кызыксыну һәм соклану арта гына барды. Бу пәһлеваннын үз-үзен тотышында, йөз-кыяфәтендә таныш чалымнар күп. Ходай рәхмәте белән ярдәмгә килеп житкән нинди баһадир бу?

Шулай да болгарлар тәшвиш-аптыраудан бик тиз айныдылар. Аларнын җайдаклары һөҗүмче якны «ә» дигәнче тулгамага алды. Көбәле баһадир каршына икеме-өчме пәһлеван тезелеп басты. Кылыч, калкан авазлары ныграк янгырап ишетелә башлады. Озак та вакыт үтмәде, көбәле пәһлеван берзаманны авыр ыңгырашып чаптарынын муены өстенә сыгылып төште. Елга өстен ачыргаланып кычкырган аваз ярып узды:

—А-та-ман!

Шушы аваз махсус фәрман булып янгырады диярсең, билгесез чирү сугышчылары тагын да ярсыбрак орыша башлады. Ул арада инде каеклар төбенә сузылган баскынчылар да күтәрелгән иде. Болгарлар өстенә Идел тарафыннан да ук янгыры очты. Ике яклап купкан үлем дәһшәтенә түзә алмадылар, күрәсен, Болгар җайдаклары чигенә үк башлады.

Яр өстендә беркадәр буш мәйдан пәйда булуга ук Андрей кенәз тәүге әмерен бирде:

—Яраланган гынамы ул, әллә мәет үкме—мина барыбер. Яу кырыннан теге пәһлеванны табып китерегез.

Казан асарлык та вакыт үтмәгәндер, пәһлеваннын гәүдәсен Андрей баркасына китереп житкерделәр. Пәһлеванны яу кырында чакта күргәч

үк чеметеп куйган күнеле ялгышмаган: менә хәзер аның алдында, баркас идәнендә хәрәкәтсез яткан әлеге ир-ат кайчандыр җансакчы һәм корал ташучы булып ана хезмәт иткән Козьма иде. Ул аның каршына тәүге тапкыр Днепр буенда, куаклар арасыннан атылып чыгып атның йөгәненнән эләктергән рәвештә килеп баскан иде. Кайчан булды бу хәл, ничә еллар элек?—Андрей моны үзе дә төгәл хәтерләми. Ә аннары... анннары ул кинәт юкка чыкты. Сигез еллап элек. Аны Андрейга Юрий кенәзне агулап үтергән явыз шымчы итеп танытмакчы булдылар. Мондый хәбәрнен ялган булуына иманы камил иде, Андрей ышанмады. Ә аннары Козьма пәһлеван шәүләсе озак вакыт буе югалып торды да, сәер бер ватага атаманы кыяфәтендә килеп басты. Бу ватага Андрей кул астында булган Владимир, Суздаль, Рязань, Ростов, Мәскәү сәүдәгәрләренә рәхим-шәфкать күрсәтсә дә, Киев базарына дип юлга чыккан барлык башка кала кәрваннарын энәсенә кадәр талый иде. Инде ачыкланды, менә нинди ватага атаманы булгансың син, Козьма. Сигез ел буе читтә югалып һәм качып йөрсән дә, фәкать кенәзенә генә тугры, аның өчен утка-суга керергә әзер булган Козьма! Инде олыгайгансың. Йөзләренне, маңгаенны җыерчыклар баскан, чәченә чал кергән. Димәк, ватага атаманы булып яшәү дә җинел түгел икән...

Козьма пәһлеваннын сулъяк иңбашында кылыч калдырган тирән яра эзе күренеп тора иде, аны сак кына юып бәйләделәр. Атаман үзе кичке караңгылык төшә башлагач кына, анына килде. Гафу үтенүне, анлашуны артык саный иде, күрәсен, Андрей белән кичә генә аерылышкан дуслар рәвешендә гади сорау бирде:

—Хәлләр ничек, кенәз?

Әлеге хәлдә мондый сорауны үзе бирергә тиеш кеше булгач, Андрей аптырап калды, ихтыярсызлык аны иңбашларын сикертеп куярга мәҗбүр итте.

—Ничек, дим... мактанырлык түгел.

—Өйгә нинди йөк, нинди нәтиҗә белән кайтасын соң? Нишләп болай, балтасы суга төшкән кеше шикелле, каңгырап утырасын?

Андрей баркас борынына аяк какты, бер сүз эндәшмәде. Козьма инде баркас идәненә торып утырган иде, алгы якка таба борылып карады да, талгын тавыш белән генә сорап куйды:

—Кем ул анда?

—Изяслав улыкаем.

Андрейнын башы күкрәгенә салынып төшкән иде, Козьма да озак вакыт дәшми торды. Ләкин тынлыктан соңгы соравы янакка китереп суккан шикелле усал яңгырады.

—Димәк, җиңүгә ирешә алмадын инде син, кенәз?

—Изяславнын вафаты хакында хәбәр алуга ук һөҗүмне туктатырга туры килде.

Андрейнын гаепле кеше кыяфәтендә аклануын Козьма пәһлеван гүя ишетмәде. Ул тәртәгә тибәргә ярата торган чыгымчы ат сыман «почмаклы» холкын күрсәтеп алырга да кыйбат сорамады.

—Синең каекларыңнын һәммәсе буш, сугышчыларын да кесәләренә һава тутырып кына кайта инде, димәк. Көнләшерлек түгел. Минем әртилдәгеләрнең берсенен дә өйгә буш кул белән кайту гадәте юк.

Козьманын бианай гөледәй төртмә теле Андрей кенәзнең дә мин-минлегенә барып тиде, ахры, тавышы кырысланды.

—Атаман булсан да, син чаманы бик белмисең бугай.

—Ә без ул чама дигәннәрен сугышчыларыңнын үзләреннән дә сорап карый алабыз, кенәз. Әйдә, кычкыр. Өйгә коры кул селкетеп кайту белән кайсы разый икән?

Андрей эндәшмәде, Козьма дәвам итте:

—Изяславнын вафаты—ул бит шәхсән синен генә олы кайгың, кенәз. Каекларга төялеп кайткан әлеге сугышчыларнын һәркайсынын да, нәкъ Изяслав шикелле үк, яу кырында ятып калуы бик тә мөмкин

иде. Мәгәр алар арасыннан кемнендер үлеме башкаларга зыян китермәячәк, калганнар, мөгаен дә, абруй һәм байлыкка күмелеп кайткан булыр иде.

Андрей Идел өстендә озын чылбыр булып тезелгән каекларга таба күз ташлады, әмма авызына су капкан шикелле дәшми калуын белде. Ә Козьманың тавышына инде ярсу, гасабилану аһәннәре дә өстәлгәндәй булды.

—Тәүге походтан ук коры кул белән кайту синең үзеңә дә дан өстәми, кенәз. Шушы рәвешчә өйгә кайтып керсәң, бөтен күрше кенәз—дошманнарың бот чаба-чаба сөенәчәк кенә. Урыс жирендәге бөтен кенәзлекләрне үз канатың астына тупларга ант иткәнсең икән, синең коры кул белән кайтырга хокукың юк. Ә иң мөһиме...—Козьма бик озак көттергәннән соң гына өстәп куйды.—... Бу рәвешчә кайтсаң, Байгөл сине гомер бакый гафу итмәячәк.

Козьма пәһлеваның соңгы сүзләреннән соң, Андрей кенәз сискәнеп үк китте, барыбер эндәшмәде. Ә бер сәгатьтән соң баркас-каекларның һәммәсе инде бар куәтенә кирегә ага иде...

## Унынчы бәйләм

### I

Черек агач төбе кебек шыксыз, карангы төн. Чулман диварлары өстендә тоткавыллар бөтенләй юк диярлек. Диварларның эчке ягында берничә генә урында учак яна. Тоткавыллар шул учаклар тирәли җыелып утырганнар. Аларның да күбесе әле кырын ятып, әле тез башларына таянган көенчә тирән йокыга талган. Әле кичә генә кара болыт булып килгән көчле, гаярь дошман диварлар тышында йөзәрләгән мәетләрен өеп калдырды да, бернинди дә зыян-зәүрат китерә алмыйча, утта йоннарын көйдергән һәм койрыгын өздергән бүрегә охшап, кире үз өненә ычкынды. Бүген Болгар аз-маз яраларын да онытып битарафлыкка чумган тук бер жанвар төсле. Гаме бөтенләй юк сыман.

Дошман аның менә шушы хәленнән оста файдаланды. Куе карангылыкта төрле яктан килеп, дивар өстенә менгән баскынчыларны Болгарның кире куып төшерә алырдай куәте юк иде. Шуңа күрә диварлар янындагы алыш көтелмәгәнчә кыска һәм аяусыз булды. Ике-өч минутлык гыжлау, корычка-корыч бәрелгән тавыш кына ишетелгәләп алды һәм шуннан соң барысы да тынды. Ә берникадәр вакыттан соң шәһәр капкалары шыгырдап ачылды да, кала эченә ташкын-ташкын булып дошман полклары бәреп керде. Коточкыч булып купкан мәхшәр тавышыннан өшәнеп, өйләреннән атылып чыккан ир-егетләр, кыз-кыркын, карт-коры, бала-чага—һәммәсе дә аяусыз дошманның балта һәм кылычы астында утын әрдәнәсе шикелле ишелеп-ишелеп ауды.

Шәһәрнең үзәк мәйданында гына дошманга каршы яу оештыра алдылар. Яше-карты, һөнәрчеләр, шәкерт, сугышчылар үз-үзләрен аямый орышты. Дошман нәкъ менә шундагы фидаиларча каршылыкка очрагач кына, мангае белән таш диварга килеп бәрелгән шикелле капылт тукталырга мәжбүр булды. Ләкин оборона тотучы ирләр саны бик аз, ниндидер бәхетле очракка, аеруча жиңүгә дәгъва кылу язгы бозга таяну кебек үк өметсез эш иде.

Әмир Ибраһим үзәктәге таш кальга дивары өстенә күтәрелгән килеш бар дөньясын сытып сүгенде.

—Ә шулай да бу Бәрәж хан, һай, куркак жан вә сатлык! Безнең өскә Әндри-кяфер килгәнне әле теге чакта ук белде бит ул. Нигә, нигә дип ул Болгар каласына ашыгыч төстә чирү җибәрмәде? Нишләп Болгар яландагы карт наратка охшап бер ялгызы гына торып калды?

—Нәсаралар кулы илә Бәрәж хан синнән үч ала булыр, әмир. Үгез

үлә икән, аның кеби козгыннарга бәйрәм. Шулай булгач, нигә диеп ул сина ярдәм итсен?

Әмирне шул рәвешчә юатып карасалар да, әлләни зур файдасы күренмәде.

—Ул Ашлыдагы Тимер бәкне әйтер идем инде. Борын төбеннән генә никадәрле кяфер газилары үтеп киткән, ә шулар хакында безгә хәбәр җибәрә белмәгән. Анысы да ангыра бер бозау! Аягүрә төш күреп йөрүдән гайре бернәрсәне белми. Әгәренки Идел буйлары минем вилаятькә керә торган җирләр булса, мин инде ул кяфер кенәзлекләре илә ике арада әллә ничә кирмән кордырыр идем. Ә Тимердән юк. Ана үгез үлсә—ит, арба ватылса—утын. Әнә шул мүкләк бозауның пошмаслыгы илә ошбу гайре үкенечле хәлләргә каламыз да.

—Үзенә—хан, үзенә таждар булырга вакыт, әмиремез.

Бер мәчет имамы күрсәткән әлеге ялагайлык әмир Ибраһим өчен кызган мунча ташына су сипкән рәвешле тәэсир итте.

—Әле үзем хуҗа булып утырган бердәнбер каланы кяферләрдән саклап калалмадым, ни сөйлисең, хәзрәт? Нинди хан булу, ди?.. Асылда ошбу газап-мәсхәрәләр кичкән өчен үзем гаепле шул, мотлака, берүзем гаепле...

Көн яктырып беркадәр тын алгач, баскынчылар янә һөҗүмгә күтәрелде. Рус сугышчыларын камчылап таш кальга диварларына таба куалаучы сәрдәрләрнең берсе Хәмбәл иде. Кальга өстендәгеләр аны танып алуга ук иң каһәрле сүзләр яудырдылар:

—Бил бөгәргә үзенә яна хуҗа таптыңмыни, каранар?!

—Муеныңдагы нәсаралар тәресен күрсәт, сатлык!

—Кяфер хуҗаларың ташлаган сөяк илә тыгылып дөмексәң иде, ангыра кассап!

—Сатлык! Иблис! Атан!

Ул да булмады, кайсыдыр бер гази Хәмбәлне пычаксыз суя торган сүз ыргытты:

—Һи, төшенмисезмени, борадәрләр? Кяферләр колы илә Болгар тәхетенә менәргә дип кайткан ләбаса ошбу кассап. Шул мәсләктән кяферләргә барып ялланган да, аларны безләр эргәсенә алып килгән.

—Хан, хан, Хәмбәл хан!—дип күмәк кычкырдылар да, дивар өстендәгеләр каһкаһәләп көлә башладылар. Һәммәсе дә бот чаба-чаба, буыла-буыла шаркылдый, ә таш кирмән өстеннән яңгыраган һәрбер аваз Хәмбәл өчен яңагына суккан төсле тәэсир итә иде. Шушы мәсхәрә каршында ул бөтенләй кешелеген җуйды. Берзаманны аның күзләре шар булып акаеп чыкты, куллары гына түгел, бөтен тәне дер-дер килеп калтырарга тотынды. Һәм хәзер инде Хәмбәл камчысын гына азсынып, рус яугирләрен кылыч очы белән төртә-төртә алга куалый башлады. Баскынчылар җан ачысы белән берничә мәртәбә һөҗүмгә күтәрелеп тә карады. Ләкин диварлар һәр очракта аларны таш һәм ук яңгыры, кайнар су һәм сумала ташкыны белән каршылый, кирмән буена якынаю да мөмкин түгел иде. Бәлки, төнлә нинди дә булса хәйлә корып эш итәргә мөмкин булыр, дигән өмет белән рус сафлары кире чигенде.

Әмма төнне баскынчылар гына түгел, таш кирмән сакчылары да көтеп торган икән. Караңгы төшеп күзләр бәйләнгәч тә, әмир Ибраһим янына чал сакаллы Әбүбәкер-оста, вилаятьнең сәрдәре Корнай батыр һәм каланың тагын берничә иң абруйлы имамнары белән һөнәрчеләр килеп җитте. Боларның сүзе шактый җитди булачагын Ибраһим бәк алдан ук сизенгән иде, сабырланып көтте. Делегация исеменнән кереш сүзне шома таякка таянган Әбүбәкер алды.

—Без әйткән тәкъдимнәрнең һәммәсеннән дә мәмнүн калмассың, шәт, ә шулай да гаепкә алмыйча гына тыңла әле, әмир.—Чал сакаллы оста тамак кырып куйды.—Мәмләкәтнең бәгыре кеби олуг каламызга кяфер басып керде, үкенәсең булыр, моны сизенәмез. Мәгәр мәмләкәтнең язмышы монда хәл ителми. Безләрнең иң куркыныч дошманы Әндри-

кяфер түгел, ә Биләр тәхетендә утырган Бәҗәр хандыр. Болгар каласына бәреп кергән кяфер чирүен куып җибәрү һич тә читен түгел, мәмләкәткә чын ачыну илә оран салу житә. Ә җаһил Бәрәҗне куар өчен оран салу гына да аздыр. Ул икейөзле таждарны алыштырыр өчен бөтен мәмләкәткә абруйлы вә булдыклы әмир табу катлаулырак. Синең асыл бәһаң нәкъ шушыдыр.

Ибраһим бәк карашын бер дә аермыйча күзәтте-күзәтте дә, ахырда барыбер белдерми түзә алмады.

—Байтак сүзләрең илә килешәм, оста, мәгәр тел төбеңне аңлап бетерә алмыйм.

—Син үзең илә ин тугры яраннарыңны ал да, юлга җыен, әмир. Ошбу сүзләр сиңа Болгар каласының иң абруйлы картлары ясаган тәкъдим генә түгел, ә бөтен мәмләкәт гозере.

—Каланы дошман кулына ташлап китиммени?—дип, Ибраһим бәк ярсый-ярсый сүзгә керешкән иде дә, мәчет имамнары аны бик тиз чигендерде.

—Биредә, дошманга каршы яуга кергән чакта, кылыч тота алырдай ирләрне йөзләп табармыз без. Мәгәр синең кеби мәмләкәт тота белгәннәрен, көндез чыра яндырып эзләсәк тә, бөтен каламызга берне табалмамыз. Ахыр чиктә, син безнең каламызга караганда да бәһалерәк, әмир. Кала җимерелсә, янә төзеп була, ә ахирәткә күчкән бер генә бәндәнең дә кире кайтканы юк. Шулай икән, юлга җыен да, Биләргә бар, әмир. Иманымыз илә ант эчәмез, анда сине халык көтә булыр. Хан тәхетенә утырып, каламызны вә мәмләкәтемезне коткар.

Ибраһим бәк сынды. Ахырда ул инде бер тәкъдиме белән болгарларга изгелек кылмакчы иде дә, анысын да тынлаучы булмады.

—Алайса, минем урынга Корнай батыр калыр.

—Юк инде, бәк. Корнай батыр сиңа Биләр каласында, тәхет өчен яуда кирәклерәк...

Еракта, урманнар артында, энә күзе кебек кенә булып таң сызыла башлаган бер минутта таш кирмән капкалары капылт күтәрелде дә, дошман гәүдәләре белән тулы киң мәйданга җайдаклар ташкыны бәреп чыкты. Тыкрыкларда, урам читләрендә аркылы-торкылы ятып руслар йоклый, алар әле ни булганын аңлар хәлдә түгел иде. Фәкать шул шәһәр капкалары янында гына каяндыр бер чылбыр дошман калкып чыкты. Ләкин кылычларын усал болгап килгән җайдаклар ул чылбырны кавынга кадалган пычак кебек нәкъ икегә ярып узды да, гаярь атлар киң далага очты.

## 2

Болгар картлары фал китабын ачып әйткән диярсең, Биләрдә Ибраһим бәкнең килгәнен, чыннан да, ярты кала көтеп тора иде. Соткавыллар әмирнең санаулы гына җайдаклар төркемен капкаларны ачып каршылады. Әмир үткән чакта тоткавылларның һәркайсы кат-кат ияк кагып һәм елмаеп дәрт-куәт тә биргән төсле итте. Ә шәһәр урамнары буйлап хан сараена таба барган чакта аларны зур гына җайдаклар төркеме куып житте. «Хан гаскәре әллә тулгамага да ала инде?»—дип, Ибраһим бәк җайдаклары кылычларын кыннан чыгара да башлаган иде. Ләкин Корнай батырга таба авыз ерып килгән хан сәрдәре Саранны тануга ук кылычларын кире шудырдылар. Ә тегесе һаман шулай елмая-елмая якынайды да, Корнай батырны кочагына алды.

—Саумы, бирадәрем!—Аннары батыр гына ишетелерлек итеп пышылдады.—Сарайны тулысынча миңа тугры шыгавыллар саклый. Морад итсә, әмир турыдан-туры тәхет залына ук үтеп керә ала.

Сәрдәр Саран әмир Ибраһим эргәсенә күчте, аны да шулай ук кысып кочаклады.

—Саумы, сөекле бәк! Саумы, яңа таждар!—Янә тегесе кебек үк

пышылдау кабатланды.—Тәхет юлында сина һичбер төрле каршылык булмаячак.

—Бик хуп, бик мәслихәт,—дип, Ибраһим бәк аяк кагып куйды.— Мәгәр вакыйгаларны куаламыйк әле.

Сәрдәр Саран үзе үк озата килгәч, таш кирмән капкасы төбендә дә, сарай каршында да Ибраһим бәк төркемен тоткарлаучы шыгавыл табылмады. Әмирне инде: «Мин беркатлылыгым илә ышанып вә үз аякларым илә сәрдәр корып куйган тозакка кермимме сон?»—дигән шом да игәүли башлаган иде. Тәхет залына таба алып барган юлда айбалталарын орышка әзерләп баскан ике жансакчыны күргәч, әмирнен күнеле хәтта тынычланып ук куйды. «Тәхет юлында киртә булмаячак, диден дә бит, ай-һай, сәрдәр. Җиһанда синнән вә ханнан да куәтлерәк көч барлыгын онытып җибәргәнсен. Акча илә нигъмәт әллә нинди гайрәтле пәһлеваннарынны да капылт үз колы итә».

—Юлдан югалыгыз!—дип, Саран зәһәр ысылдаса да, жансакчылар хәтта кымшанмады. Ләкин шул минутта ук икесенен тин бугазына оста итеп ыргытылган хәнҗәрләр килеп кадалды һәм алар ыңгырашырга да өлгермичә сыртларына ауды.

Тәхет залында аларны инде егермедән артык жансакчы җәяләренә укларын корган көенәчә көтеп тора иде. Үзенен күкрәгенә берьюлы шулкадәр укның төбәлүен күргәч, Ибраһим бәк кайнап торган казан эченә чумган сыман булды. Бәрәж хан каһкаһә белән кеткелдәп зал түрендә утыра, ә бу мәкерле бәндәгә күнелдәге авыр хисне сиздерергә һич ярамый иде. Кылыч кыны очын таш идән сырларында зенләтә-зенләтә Ибраһим бәк тәхет тарафына атлап китте. Ул тәхеткә нибары ике-өч адым ара гына калдырып тукталды да, нәфрәт тулы күзләре белән Бәрәж ханга төбәлде. Гап-гади бер кала әмиренен үз каршына кереп баш имәве Бәрәжне чыгырыннан чыгарды, ул үзенен зәһәрләнеп кычкыра башлавын да абайламый калды.

—Әһә, артына ут капты да, Болгардан чыгып качтынмы, куркак жан?! Пайтәхеткә килеп ансат кына хан булырга морад иттенме? Кабаланма. Сакларга, якларга тиеш каланны кяфер кулына ташлап киткән өчен сине бүген үк дарга астырам мин!

Эче тулы ут булса да, Ибраһим бәкнен йөзендә бер генә төк тә селкенеп карамады. Тавышы корыч чыны сыман янгырап ишетелде.

—Мәмләкәтне, калаларны саткан өчен ул дар элмәкләрен үзенә дип сабынлый тор, Бәрәж.

Залга әмир белән бергә сәрдәр Саран һәм Корнай батыр да кереп баскан иде. Өстәмә сакчылар чакырырга ниятләп, Бәрәж хан үз янында асылынып торган бауны тартырга үрелә башлаган гына иде, сәрдәр Саранның җинелчә бер ым кагуы житте. Шул мизгелдә хан сараенын ян-якларындагы тәрәзә пыялалары коелып төште һәм шул ачыклык аша зал эченә дистәләгән яугир сикереп керде. Орыш башлап торунын мәгънәсе юк иде. Акча бәрабәренә ханга ялланган жансакчылар садак һәм җәяләрен идән өстенә ташлап, шундук залдан чыкты. Гаҗәпләнүдән телсез-өнсез калган Бәрәж тәхет култыксасына авып төшкән иде. Таза гына ике гази аны кулларыннан сөйрәп алып чыкты. Кичкә таба инде кала халкы үзәк мәйданга җыйналып элеккеге ханга җәза бирүләрен көтеп тора башлады. Әмма Ибраһим бәк Бәрәжгә бер генә сугышчысынын да кулын тидертмәде.

—Ул Биләргә ат өстендә килеп кергән иде. Хәзер дә шул рәвешчә каладан чыгып китсен!

Тик әлеге ханга да халык үченнән исән-сау килеш котылырга насыйп итмәгән шул. Бәрәж шәһәр капкасыннан чыгып биш-алты дилбегә буе ара үтәргә дә өлгермәде, әллә каян очып килгән сәрпи ук кичәге ханның бугазын ярып узды...

Мәйдандагы халык хәрби сыбайлардан, мәмләкәт сәетеннән, сәрдәр, наиб, вәзир, ахуннардан Болгар әмирен кичекмәстән хан итеп игълан кылуларын һәм ак дөя йонынннан сугып ясалган зур келәм өстенә

күтәрүләрен даулый-даулый таләп итә башлаган иде дә, Ибраһим бәк үзе сөзгәк үгез сыман катгый каршы төште.

—Ил канга күмелеп яткан чакта туй итмиләр. Кяфер дошманнан арынып, азат тормышка ирешкәнче мәмләкәт бөтенләй дә хансыз яшәячәк.

—Ай-һай, әмир! Учактагы утыннар дөрләп янган мәлдә алар өстенә асылган казанны күзәтүсез, ялгыз калдырмыйлар. Ялкынның ян-яктагы терәкләргә күчеп, казанны бөтенләй әйләндереп каплавы да бар бит.

—Терәкләре ышанычсыз, нечкә, черек икән, андаен казанның мәмләкәткә гел дә кирәге юк...

Ныклап кабынырга да өлгермәгән бәхәс шул урында өзелде. Иртәгә танда ук Болгар каласы тарафына чирү җибәрүләрен таләп итеп Ибраһим бәк төрле якка чапкыннар куды. Инде бу эш тә үтәлеп Корнай батыр белән ялгыз гына калгач, күңелен тырнаган тагын бер шик-шөбһәсен Ибраһим бәк үзенең сәрдәре каршында ачып салды.

—Мин Болгар тәхетенә асылда сәрдәр Саран ярдәме илә менеп киләм, батыр. Мәгәр күңелем һич тә тыныч түгел. Иске хуҗасын таларга ташланган эт яңа хуҗасына карата да тугры була алмас. Шул мәсләктән чыгып, мән Саранны мәмләкәтнең кыпчаклар ягындагы чигенә озатмакчы булам. Ул тарафта чикләр шар ачык, аларны саклап торучы бер капка юк. Саран шунда юл алсын да бер-ике булса да яңа кирмән корсын...

Корнай уйга калды. Хәле авыр иде. Ул мона кадәр Ибраһим бәк кул астындагы вилаятьтә гади сәрдәр генә булып хезмәт итте. Менә, әмир Ибраһим пайтәхеткә күчте, иртәгә хан булачак. Мантыйк буенча фикер йөртсәң, әмиренә гомер буе тугры хезмәт иткән, житмәсә аңа ияреп пайтәхеткә килгән батырга монда да сәрдәр урыны һәм хәзер инде гади генә түгел, баш сәрдәр урыны тиеш. Әмма баш сәрдәр, олуг сәрдәр урыны азат түгел, ул урынны бүген Саран яулый. Димәк, Корнай үзе тәрбияләп үстергән, Корнай күтәргән Саран аның юлында киртә булып тора. Бер казан тирәсендә ике тәкә башы кайнаша, дигән сүз инде бу. Корнай берчакта да Саранга каршы этлек эшләп, үзенә юл арчый алмаячак. Саран аңа бертуган энекәше кебек газиз, якын. Менә, олуг сәрдәр баскычына таба алып барган юлны аңа Ибраһим бәк үзе арчып бирә. Бер уйласаң, Корнайда гаеп юк, сөенәсе генә. Әмма... әмма Саран елга аша кичкән чакта гына кирәк була торган бурсак капчыкка охшап калды түгелме соң? Әмир аны тәхеткә юл арчыган чакта гына файдаланды да, хәзер инде табаны тишелгән иске кәвеш сыман тышка чыгарып ата. Ә иртәгә Корнайның үзен дә шундый ук язмыш көтми, дигән нинди ышаныч бар?..

Вакыйгалар агышын тәкъдир куәтенә калдырды да, Корнай батыр елга уртасында бата башлаган чакта ике як ярның кайсысын сайларга да белми аптыраган бичара ир сыман бер төрле дә җавап кайтармады. Ә икенче танда Ибраһим бәк, кул астына ике-өч дистәгә якын һөнәрчене биреп, кичәге сәрдәрне ил чигенә куды. Саран батырдан бик озак вакытлардан соң гына хәбәр килде. Ул җәнүби якта, коры дала уртасында ике кирмән корган, төзүчеләр гозеренә күнеп аларның берсен үз исеме белән атаган, икенчесенә шул тирәдә яшәгән кабиләләргә баглап «Мукшы» атын кушкан... Мондый зур эшләр майтарган Саран батыр кайтыр да, Ибраһим хан аны мул-мул бүләккә күмәр, дип пайтәхеттә бик озак көттеләр. Әмма Саран батыр суга төшкән балта кебек булды, аны белүче-күрүче кеше табылмады...

### 3

Идел! Никадәр яуга, кырылышка шаһит булган елга. Синең болганчык суларың күпме генә канны юмагандыр да, күпме генә шәһит-корбаннарны үзенә йотмагандыр?! Ләкин дәшмисең син, үзең белгән бер генә серенне дә кире чыгармыйсың. Әгәр телең булса,

син Андрей кенәзнең атасы Юрий Долгорукий походлары турында сөйләп бирер идең. Шулардан соң, бәлки, Андрейның бүгенге походын олылап бер җыр сузар идең.

Хәер, аңысын ук синнән таләп итү, мөгаен, артык булыр. Әнә, синең өстең болай да баркас-каекларда тезелеп кайтучы сугышчылар җыры белән тулган. Һәркем шат, канәгать. Болгар каласына икенче кат бару бөтенләй дә корбаннарсыз диярлек үтеп китте. Таш кирмәнне яулый алмадылар-алуын, ә шулай да кала йортларын умарталыкка төшкән аю сыман нигезенә тикле актарып таладылар. Саксызлык күрсәтсән, корбаннар да булыр иде, шаять. Ходайның мәрхәмәте, каладан чыгып качкач, Ибраһимның яңа гаскәр белән кире кайтуы турында әле ярый вакытында кисәтеп өлгерделәр. Кала бистәләренә ут төртеп болгарларга юлны каплады да, Андрей кенәз үз гаскәрен каек-баркасларга һичнинди зыян-зәүрәт күрмичә тезеп утырта алды.

Әнә, хәзер алар ничәнче көн буена хәвеф-хәтәр күрми кайтып килә. Баркасларның һәммәсе дә таланган мал һәм ганимәт белән тулы. Һәр каек борыны саен диярлек нәни учак яна. Сугышчыларның күңеле көр, кәефе күтәренке. Таланган мал, шәраб, исәнлек, дан—канлы яудан кайтып килүче ир-атка үзен бәхетле итеп тояр өчен шуннан гайре тагын ни кирәксен?..

Биек баркас борынына сузылып яткан килеш, артта чылбыр булып сузылган каеклар өстенә караш ташлый-ташлый, Андрей кенәз шулар хакында уйлап кайта иде. Төн тамга таба авыша башлагач, Идел өсте суытты, җиләсләнде. Кенәзнең салкынга тагын да түзәргә исәбе юк иде. Ул якындагы бер каекны ымлап чакырды да, аңа утырып, өсте, ян-яклары калын киез белән корулы буш баркаска күчте. Тиздән аның янына кәнизәклеккә алынган болгар кызларының чираттагысын китереп җиткерделәр. Дөнья онытылды...

Берзаманны кинәттән купкан кычкырыш һәм яман сүгенү авазлары ишетеп тышка атылып чыккач, Андрей кенәз әүвәл һичбер нәрсә аңлый алмый торды. Елганың әле теге, әле бу ягыннан, бал кортлары сыман зәһәр чыжылдап, каеклар өстенә уклар ява. Су өстендә томан, ике як яр буйлап тезелгән дошманның көч-куәтен чамаларлык түгел.

Вакытны сузу корбаннар санының артуына гына китерәчәк иде. Андрей кенәз барча каектагыларга ишетелерлек итеп ашыгыч фәрман бирде.

—Һәммәгезгә сулъяк ярга юнәлергә һәм яр өстенә менеп тезелергә!

Фәрман бик кырыс һәм көчле яңгыраса да, аны үтәү кыюлык, бердәмлек һәм, һичшиксез, корбаннар да таләп итә иде. Чыннан да, каеклар яр читенә килеп борын төрткәнче алар өстендәге ничәмә-ничә дистәләгән ир кин Идел дулкыннары эченә йомылып гаип булды. Шулай да санаулы минутлар эчендә яр өстенә менеп тезелделәр. Болгарлар куе томан артына кереп әүвәл юкка чыкты. Аннары бераз вакыт кына көттерделәр дә, дулкын артыннан килгән дулкын сыман, сафларны бертуктаусыз алыштыра торып, руслар өстенә уклар яудырдылар. Болгарларның мондый яу алымына каршы торып булмый, берьяклы кыйнау болай дәвам итсә, хәтта, аларның көчен ачыклау да мөмкин түгел иде.

—Басурманнар өстенә ыргылыгыз! Алга!—дип әйдәкли-әйдәкли воеводалар сугышчыларны берничә мәртәбә һөҗүмгә дә күтәреп карады. Ләкин һәрбер һөҗүм саен дистәләгән яугир җуя-җуя, руслар кире чигенергә мәҗбүр булды. Ул да түгел, берзаманны болгарлар баскынчыларны янә төрле яклап яр читенә китереп терәде һәм тагын дулкын-дулкын сыман алышынып ук яңгыры коя башлады.

Рус гаскәре болай, чылбырга утыртылган эт хәлендә торса, җиңү түгел, хәтта, исән калуга өмет баглау да шик астында иде. Андрей кенәз шуны аңлады да, гаскәрен үлемнән коткару өчен нинди чара күрергә белми изаланды. Күз алдына кинәт кенә инде дистә ел элек үк, Вышегород каласының чиркәвендә билгесез атакай белән булган очрашу килеп басты.

Асылташлар белән бизәлгән иконаны бүләк иткән чакта нинди сүзләр әйтеп хәерхаһлык кылган иде соң әле ул?

—«...Дәүләтләрне, халыкларны тик дин көчле итә. Шуна күрә һәр эшенне бөек Иисус исеме белән башла...»

Тукта, әлеге атакай тылсымлы ядкарь итеп биргән ул Изге Ана иконасы Андрейнын үз янында бит!

Андрей калын киезләр белән капланган баркас эченә чумды да, кыйммәтле ядкарьне күкрәгенә кысып кочкан хәлдә, кире атылып чыкты. Күнелгә ышаныч өстәлгән, йөзе якты иде. Ярга таба ишкән каекчы ирләрне дә «тизрәк, тизрәк», дип ашыктырып барды.

Сугышчы ирләр кырыс кенәзне яу кырында күрергә өметләнми иде. Ә Андрей әллә каян гына пәйда булды да, япа-ялгыз көе бар гаскәрнен ин каршына ук барып басты. Һава ярып һәр тарафтан дошман угы оча, тик, ни гажәп, аларнын берсе дә кызыл, кин япмага төренгән Андрей кенәзгә тими үтә иде.

Менә, ул иртәнге яктылыкта җәүһәр ташлары белән ялт-йолт килеп торган иконаны баш очына чөйде. Шунын артыннан ук аһәнле, гаярь тавышы үзенчәлекне ярып янгырады.

—Газиз туганнарым, христианнар! Без бу олы походка урыс халкын дан-шөһрәткә күмәргә дип чыктык. Иисуска һәм Изге Анабызга мен шөкер, безнен походыбыз бик уңышлы булды. Көймәләребез тулы байлык-нигъмәт, сафларыбыз исән. Инде туган жиребезгә кайтып житкәч кенә сынатмыйк. Бу денсез басурманнар өстенә һәркайсыгыз ярсу бөркет булып ябырылсын. Инде яуда яра алсагыз да, шәһит булсагыз да, урыс жиребезне данга күмеп, динебезне олылап, изге җаннар булып каласыз сез. Шәһитләрнен һәркайсы гасырлар буена безнен илдә изге саналачак, шуны онытмагыз! Бөек динебез хакына, Изге Ана, Иисус хакына үз-үзегезне аямый сугышыгыз! Изге Ана фатихасы белән алга, басурманнар өстенә, христианнар!

Әйтерсен лә, нindидер бер могжиза булып узды. Мона кадәр хужасыз көтү сыман йөргән сугышчылар зәһәр чөй ясап сафка бастылар да, болгар жайдакларына каршы ябырылдылар. Авыр, канкойгыч яу тәмам төш житкәнче, сугышчылар эсседән арып-талып, жиргә егылганчы дәвам итте. Ике яктан да сафлар яртылаш кырылган, ике якнын да яна һөҗүмгә күтәрелердәй куәте юк иде. Кояш офыкка таба авышып эсселек сүрелә башлагач кына, болгарлар чаптарлары өстенә менделәр дә, калкулык һәм куаклыклар артында томан сыман эреп югалдылар. Русларнын хәтта тантана авазлары белдерерлек тә көч-куәтләре юк иде. Алар дошманнарын күз карашы белән генә, сүзсез озатып калды. Андрей гына якындагы бер воеводадан капылт сорап куйды:

—Бүген елнын нинди көне әле?

—Беренче август булыр, Андрей кенәз.

—Хәтеренә киртлә, воевода. Моннан ары беренче август көне урыслар өчен изге саналачак. Без аны Изге Ана бәйрәме итеп билгеләрбез. Шулай итсәк, безнен исемнәр дә гасырларга калыр...

## Унберенче бәйләм

### I

Ак киез тирмә эчендә дәү юлбарыс тиресенә сузылып яткан да, Ясүгәй баһадир тирән уйга чумган. Бармаклары җәүһәр ташлардан ясалган шакмакларны тәгәрәтеп уйный, ә йөзе-кыяфәте кышкы зәмһәрир салкыннарга бирешкән шәрә агач сыман жансыз, катып калган. Йөзендә каранrылык, иреннәр кысулы, карашы билгесез ноктага төбәлгән. Мәнге ару-талу белмәс баһадирнын иннәренә бүген, әйтерсен лә, дәү-дәү ташлар яткан.

Тыштан чыр-чу килгән бала-чага тавышлары ишетелә. Ике төркемгә бүленеп «яу» уйныйлар бугай. Тимучин белән Җәмуганың «әмер-фәрманнары» еш янгырый. Мөгаен, бу юлы да Ясүгәйнекеләр белән тайжутлар һәм чатжиратлар бер-берсенә каршы «сугышадыр». Алар мәнге шулай. Яше буенча аз гына өлкәнрәк булганга күрә Тимучин Ясүгәйнен энеләре Дәритай, Тайчу, Канунңардан туган малай-шалайның барчасын үзенен кул астына туплый. Бертуган энекәшләре Билгүтәй белән Хасар да, һичшиксез, абыйлары Тимучин канатында инде. Ә менә Котул хан уллары булган Алтын, Кучар, Сачә бәкләрнен малайлары берчакта да Тимучин кул астына басмыйлар. Алар Тимучин әмерләренә буйсынуга караганда чит кабилә—чатжиратлар башлыгынын улы Җәмуга яклы булуны артык саный, ахры. Алар шулай хыянәт иткән өчен Тимучиннын әллә ничә тапкыр елап кайтканы бар. Дөрес, алар Җәмуга белән һич бозылыша белми. «Яу» барышында гына «дөнья» бүләләр дә, аннан туйгач ауына да, балыгына да гел бергә йөриләр. Хәзерге чыр-чу килүләре дә бик озакка бармас, тиздән тынар әле.

Әйе, бала-чага явы бәла түгел, зурларныкы яман. Менә, магул кабиләләре ничә еллар буе кайгы-хәсрәт күрми гомер сөргән, аякка ныграк баса гына башлаган иде дә бит, татарлар тагын көтелмәгән яу белән килде дә, аларнын бар ыруын кырмыска оясы шикелле капылт туздырып атты.

Татарлар магулларнын кыят, тайжут, чатжират, нирун кабиләләрен Буир-Нур күле буендагы җәйләүләргә керүдә гаепләгән булдылар. Ә Ясүгәй яхшы белә бит, татарларның магулларга каршы яна яу башлавынын асыл сәбәбе җәйләүләрдә түгел. Чин дәүләтендәге биләр дә, андагы тәхетне үз кармакларына эләктергән җүрҗән бәкләре дә магулларнын сонгы елларда көчәеп китүеннән курка башладылар. Мондый курку да нигезсез үк түгел, бер Ясүгәй баһадир кул астындагы кабиләләрдә генә дә күчмә арбалар саны кырык менгә житкән, ә Котулны исә тугыз магул кабиләсе дә үзләренен бердәнбер һәм бөек ханнары итеп таный башлаган иде. Менә шушы хәл чин һәм татарларнын үтенә генә тиеп калмады, күрәсен, аларны йокысыз да итте. Аеруча чин биләре яман тырышканнар. Шуларнын «жаухури»[1] дәрәҗәсен йөрткән яубашлары барып ак татарларнын чаган, алчы, дутаут, алухай атлы кабиләләрен яуга котырткаңнар. Тегеләр сынмыйчарак торгач, чиннәр бишме, алтымы мен чамасы сугышчы да биргән. Ә кара татарлардагы жыен белән төрбән кабиләсе ирләрен кушу бөтенләй дә авыр булмагандыр, шаять, алар болай да үчле. Менә шушы кадәр көч бергә тупланып килеп, магуллар өстенә төнлә һөҗүм итте. Котул хан белән Ясүгәйнекеләр арбалардан корылган күрем-бoжралар артында каршылык күрсәтеп караса да, әлләни озакка түзә алмадылар. Дарылы чүлмәкләр һәм ялкынлы ук атып чин осталары магуллар ыстанында котчыкмалы янгын куптарды. Әллә ничә мен арба һәм тирмә янып бетте. Ирләр, хатын-кыз, бала-чага гына түгел, хәтта Котул хан да авыр яраланды. Тагын меңнәрләгән арба-тирмәләрне дошман кулына ташлап, магуллар янә Онон елгасы буена чигенергә мәжбүр булды.

Ә ничәмә-ничә йөз ир әсирлеккә төшеп, дошман кулында калды! Ясүгәй өчен аеруча әтисе Бәртән белән бертуган Әнбагай агасы һәм анын улы Үкин-Бәрхан кызганыч. Гәрчә Котул хан белән бертуган булса да Әнбагай агасы Алтын, Кучар, Сачә бәкләрне түгел, Ясүгәйне якын итә иде. Хан нойоннарны, баһадир һәм бәкләрне корылтайга, мәжлес-бәйгеләргә жыеп алганда бәхәс купты исә, Әнбагай агасы гомер-гомергә Ясүгәйнен һәрчак кыл шикелле төз була торган фикерен яклап чыкты. Инде менә хәзер агасы да, анын улы Үкин-Бәрхан да юк. Шуларнын язмышын ачыклау өчен дип, Ясүгәй инде ничә шымчы куды. Татарлар кулыннан сатып алып булмасмы дип, ничәмә-ничә яраннарын юллап карады. Юк кына бит, һичкайсыннан хәбәр ишетелми. Кайда йөри болар?..

[1]Жаухури, дөресе «чжаохури»—чик буендагы дала комиссары.

Ясүгәй баһадир озаткан шымчыларның берсе, ниһаять, берәр атна үткәч, таң атканда кайтты. Аның ишек аша мүкәләп керүеннән үк Ясүгәй җылы сүзгә өмет өзгән иде. Ә шымчы кайтарган хәбәр тәннәрне чымырдатырлык дәрәҗәдә коточкыч булып яңгырады.

—Мин сиңа бик тә авыр хәбәр алып кайттым, ачуланма, батыр,—дип, шымчы ир-ат урап башласа да, Ясүгәй туры юлга аны тиз күндерде.

—Мин хатын-кыз түгел, яшермичә сөйлә.

—Әнбагай бәк белән Үкин-Бәрхан вафат. Чиннар аларны җәзалап үтергәннәр.—Шымчы беркавым гына тын алгандай итте.—Бәк белән аның улы чаган татарлары кулына әсирлеккә төшкән. Башта аларны җүрҗән бәкләре кулына тапшырганнар. Тегеләр җәзалап-җәзалап та Әнбагай бәк белән Үкин-Бәрханнан һичнинди сүз алуга ирешмәгәч, аларны чин җәлладларына илтеп ыргытканнар. Чиннар бәк белән Үкиннең табан асларын, аркаларын телеп, шулар буенча ат кылы йөртә-йөртә җәзалап үтергәннәр...

Ясүгәй күзләрен йомып, озак вакыт буена торatаштай торды. Исен кабат җыйганда йөзеннән инде каны качкан иде. Иләсләнеп җикерә башлавын да абайламый калды.

—Әле син һаман да мондамыни, кабих?! Кара хәбәр китергән кешенең башын чабып өзә торган йола барлыгын син беләсең булыр? Шулай икән, күземә күренәсе булма! Иң яхшысы, чит-ят җиргә китеп, мәңгелеккә югал!

## 2

Ясүгәй Тимучинны төрткәләп уятканда таң сызылып кына килә иде әле.

—Улым, тор, кузгалырга вакыт,—дип эндәшүдән генә Тимучин әле һичнәрсә дә аңышмаган иде, әтисенең алдагы сүзләре малайны түшәктән тиз күтәрде.

—Бүген сиңа тугыз яшь тулды. Ата-бабалардан килгән йола буенча сине булачак кәләшең белән ярәштерергә вакыт.

Тимучин өчен бу яңалык түгел иде түгелен. Шул ук кичә генә үзе белән бергә уйнап йөргән борадәрләре—Алтын бәк улларына да булачак кәләшләре күптән табылган, калым биреп куелган, антлары беркетелгән. Мәгәр әтисе менә Тимучинны нindирәк кеше кызы белән кавыштырмакчы да, аны кайсы кабиләгә алып бармакчы икән? Әтисе бөтен магул ыруына танылган баһадир, Котул ханга җигән тиеш кеше. Ул үзенең беренче һәм якын иткән улын кара магул кызы белән генә кавыштырмас анысы. Атаклы Ясүгәй баһадир белән кодалашу магул ыруындагы һәрбер бәк һәм нойонга шөһрәт. Тик менә ул үзе, тиндәш итеп, кайсы кабилә бәген сайлар икән?..

Ясүгәй урлап кайткан чакта Айлы бикә атлы булган яп-яшь кәләш инде күптән Айлун бикәгә әверелгән иде. Бөтен кыят кабиләсе өчен өлкән ана дәрәҗәсен йөрткән шул абруйлы хатын ире белән улын Балдак-Дала үзәнлеге буйлап байтак озата барды.

—Бар, кайт инде, хафаланып йөрмә,—дип, Ясүгәй әллә ничә тапкыр тукталган да иде, хатыны һаман-һаман иярүен белде.

—Син Тимучинны кәләшенә ияләшсен өчен булачак кодаларында калдырып кайтачаксың. Аны кайчан күрәм? Беренче балам бит, аерылуы кыен. Бераз барыйм әле.

Онон елгасындагы таныш шарламага барып житкәч, Айлун бикәнең күзләре бөтенләй юешләнде.

—И-и, ошбу шарламадан түбән сикереп качарга җыенган чаклар да бар иде бит. Синең кебек асыл ирдән баш тартып маташканмын, менә җүләр,—диде дә, айлун бикә Ясүгәйнең куенына сыенып торды.

Ниһаять, шушы яр буенда озаклап хушлаштылар. Саубуллашу вакытында була торган фатиха-теләкләрне күбесенчә Айлун бикә тезде.

—Юлда сак бул инде. Татарлар очраса, алар белән сүзгә килеп йөрмә. Җае чыгып юлын төшә икән, минем атайларга кереп чыксан ярый. Бәлки, үзенә әле озатучы да бирер... Килен буласы кызыйны, антлар беркеткәнче, Тимучинга да күрсәт. Яратмаган хатын ир-ат өчен артык мендәр рәвешендә кала. Ятсан—йонга батасың, чыгарып атар иден—кызганычрак. Тимучин улым алай интекмәсен... Йә, ярый, хушсау бул. Кат-кат гозерләп сорыйм, юлда сак йөре.

Үзенең кай тарафка таба юл тотуын Ясүгәй баһадир Тимучинга төнге ялга тукталгачтын гына әйтеп салды.

—Үзебезгә кардәш тиешле, якын кабиләләрдән кыз ярәшеп булмый, кан алмашу кирәк. Уранхайлар янына барыйк әле. Алар Далай-Нур буенда җәйләп йөри бугай. Аннары ул Далай-Нур йә Аргын тирәсендә татарларнын конгыратлар кабиләсе очрамасмы? Бабан—Сәмыйк бәкне күреп чыгар идек...

Шулай, төннәрен тукталып ял итә-итә, бер атнадан артык юл үттеләр. Аргын елгасы да инде артта калды. Уранхайлар җәйләвен төгәл генә күрсәтүче кеше һаман табылмады. Инде Далай-Нур күленең икенче очына житәргә дә күп калмаган иде. Көтмәгәндә татарларнын зур гына җәйләвенә тап булдылар. Баһадирны озата баручы ирләр, ул-бу була калса дип, инде орышка да әзерләнгән иде. Татарлар конгырат кабиләсеннән булып чыкты. Шуны белүгә үк, Ясүгәйнең инбашларыннан авыр ташлар төшкән кебек булды, йөзенә нур йөгерде.

—Мине бәгегез янына озатыгыз!—дип әмер аһәне белән генә эндәште ул үзен уратып алган жайдакларга.—Ана минем тугыз ел буе үстергән бик зур бүләгем бар...

Ак киез тарттырылган утыз алты киргәле дәү тирмә эченә килеп кергәч, таныш түгел ир-атны күрде дә Ясүгәй аптырап калды.

—Мин бит Сәмыйк бәкне күрергә ниятләгән идем.

Ясүгәйнең пошынып кына түгел, хәтта, үпкәләп тә эндәшкән сүзләренә җавап бирүче табылмады. Тирмәдә аларны каршылаган ир-ат Ясүгәйнең йөзенә текәлгән дә, балбал шикелле катып калган иде. Ясүгәй үз теләген шактый ярсу тавыш белән янә кабатларга мәҗбүр булды:

—Мина Сәмыйк бәк кирәк.

Ниһаять, «балбал»га жан инде.

—Сәмыйк бәк юк шул инде... Җәй башында сезнең чирү илә булган яуда ана ук аттылар. Шөйлә җәрәхәттән савыга алмады ул, менә бер ай тула булыр, мәңгелеккә күчте...

Ясүгәй улы Тимучиннын инбашына кулын салды да, кыскыч белән сөйрәгәндә дә бирешмәгән тутык кадак сыман кымшанмыйча, сүзсез басып торды. Тирмә хуҗасы аны сәер карашы белән һаман бораулады, аннары гаҗәеп ачышы белән шаккаттырды.

—Ә син Ясүгәй баһадир буласындыр, шаять?

Ясүгәй аптырап дәште:

—Әйе шул, нәкъ үзе. Моны каян белдең?

—Мин сине бүген төштә күрдем.

Тирмә хуҗасынын сүзләре, чыннан да, гаҗәеп иде, Ясүгәй әсәренде. Ә хуҗа кеше күптәнге танышы белән сөйләнгән шикелле тезеп китте:

—Шәхсән сине түгел, кабиләгезнең изге әләме—ак сүлдәне күрдем мин. Аермачык күрдем. Сүлдәнең өске ягына бабаң Бәдуанчар сөя торган шонкар сурәте төшкән, ә ул үзенең тырнакларына карга эләктергән иде. Аннары мин ул сүлдәнең чукларына тиклем ачык күрдем. Сүлдәдә тугыз чук бар, һәркайсына ат кылы тагылган, алар җилдә җилфер-җилфер килеп уйный иде.

Ясүгәй өчен дә бу төш шаккаттыргыч иде, ашыгып сорау бирде:

—Син моны нәрсәгә юрыйсың соң инде?

—Сезнең магул кабиләләренең тугызы да бүген таркатылган, тузды рылган хәлдә. Мәгәр кайчан да булса берзаманны тугыз кабиләгез дә күмәк сүлдә астына тупланачак. Мин шулай дип беләм.

Ясүгәй канәгать калып, башын түбән иде.

—Җылы сүзләрең өчен рәхмәт сиңа, хуҗа. Аларны Мәңгелек Күк Тәңре ишетә күрсен.—Ясүгәй тирмә хуҗасының йөзенә текәлде.—Син кем атлы буласың, мөхтәрәм бәк? Минем бабам хакындагы хәтирәләрне каян ишеттең син?

—Мин Дәй атлы чәчән булырмын, батыр,—дигән җаваптан соң сорау биреп тору артык иде. Ясүгәй елмаеп кына ияк какты. Ул арада чәчән инде үзе төпченүгә күчте.

—Сине мондый ерак җирләргә нинди җилләр ташлады? Нинди йомыш шулай йөртә?

Ясүгәйнең килен-кәләш турындагы сүзләрен ишетүгә үк, Дәй чәчән Тимучинга төбәп текәлде дә, берникадәр вакыт дәшми торды. Аннан көтелмәгән тәкъдим белән янә таң калдырды.

—Син мәрхүм Сәмыйк бәккә кияү тиеш идең, мәгәр туганлашу тәмен татып өлгермәдең. Инде улың Тимучин да шул кадердән мәхрүм булмасын, татар кавеме илә орыш кырында түгел, туй вә мәҗлесләрдә аралашып яши күрсен иде. Шул мәсләктән чыгып, сиңа тәкъдим әйтәм. Синең Тимучиныңа тиң булырлык, унынчы яше илә баручы бер кызым бар минем. Аты Бөртек булыр. Шуңа күз сал. Җаның ята икән, ул киленең булсын. Бүген сезнең кабиләнең сүлдәсе дә төшемә юкка гына кермәгәндер. Ходай Тәгалә насыйп итә икән, әйдә, кодалашыйк...

Ак ашъяулык өстенә ризык-нигъмәт тезеп, сый табыны янына утырышкач кына, тирмә эченә бер кыз җитәкләгән хатын керде. Сорау биреп, өстәмә сүз кузгатып тору кирәк түгел, әлеге кызчыкның Бөртек икәнлеге аңлашыла иде. Ясүгәй баһадир аңа күз салгач та, сискәнгәндәй булды. Гәрәбәдәй саргылт чәч, саф күк йөзе кебек зәңгәр күзләр, аккош канаты шикелле ап-ак куллар. Йә, Ходаем! Аның Айлуны —Айлы бикәсе дә кайчандыр аны шушындый ук сылулыгы белән гашыйк иткән иде түгелме соң?..

Ясүгәй батыр улына күз ташлады. Тимучин башын түбән игән, колакларына кадәр кызарып чыккан. Ашавы да ашау түгел, чемченеп кенә утыра. Беткән, теге чактагы Ясүгәй шикелле бу да бер күрүдә гашыйк булган бит, менә хикмәт! Хәзер моңа да башка кызый исемен әйтеп авыз ачма инде... Ясүгәй шуларны уйлап куйды да, елмаеп тик утырды. Сый-хөрмәт төгәлләнгәч, балалар тирмә эченнән чыгып югалдылар. Ясүгәй һәм Дәй чәчән берзаманны чыгып күз салганда Тимучин белән Бөртек чаган куаклары тирәли гөр килеп йөгерешә, аларның шул арада уртак тел табышуына шик калмаган иде...

Икенче көнне, коңгырат аксакаллары белән үткәрелгән мәҗлес барышында Ясүгәй баһадир да, Дәй чәчән дә бер-берсенә бүләк бирештеләр, вәгъдә беркеттеләр. Өч кич кунак булганнан соң, аерылышкан чакта баһадирның күнеле күтәренке, Тимучинга әйтер сүзләре дә анык иде.

—Мин сине бер биш-алты ел кадәр гомергә шушында калдырам, улым. Башлы-күзле булыр вакытың җиткәч, туйлар ясап, кәләшең белән бергә кире алып кайтырбыз. Миңа андый бәхетләр эләкмәде, монын кадерен бел. Дәй чәчән бу елларда сиңа атаң булыр, аның сүзеннән чыкма. Татарлар гыйлемле булулары белән дан тоталар, укырга-язарга өйрән. Тимер эретү, күкерт ясау эшләрен белү дә комачауламас, аларын да өйрән. Кыскасы, Байшонкар вә Томавыл мәргән шикелле атаклы бабаларың исеменә тап төшермә, үзеңне атаң урынына кыятлылар, тайҗутлар, чатҗиратлар юлбашчысы булачак батыр итеп таныт...

Ясүгәй артык нәзакәтлелек күрсәтеп маташмады, Тимучинны фәкать бер тапкыр гына күкрәгенә кысып кочаклады да, аргамагы өстенә сикереп менде. Инде үзәнлектән чыгып барган чакта гына Ясүгәй каерылып артка күз ташлады. Башын түбән игән Тимучин ак тирмә янында хәрәкәтсез тора, ялгыз калуын кичереп газаплана иде...

Кайтыр юлда өч көн барганнан соң, Ясүгәй татарларның җыен кабиләсе өстенә килеп чыкты. Үзен кинәт төрле яктан йөзләп җайдак

уратып алгач, Ясүгәй кылыч сабына авыр кулын салды. Ул кайчандыр яуда жыенлыларнын юлбашчысы булган Тимержан бәкнең гомерен кыйган иде. Татарларнын моны онытуы бик икеле. Үч алырга жыеналар икән, кылыч селтәп шәһит китү кирәк.

Әмма татарларның берсе дә ана каршы корал күтәрмәде. Киресенчә, арада өлкән булганы анын янына колач жәеп килде.

—Синен Дәй чәчән белән кодалашуың хакындагы хәбәрне инде ишеттек без. Бик хуп, бик хуп. Менә, безнең Мерәс батыр да үз йортына килен алып кайтты. Бөтен кабилә белән туй итәмез. Син дә кунагымыз бул, безне олыла, магул баһадиры.

—Мин инде бик күптәннән кунак булып йөрим. Үземнекеләр янына кайтып күренү кирәк иде,—дип, Ясүгәй каршы төшеп караса да, анын сүзләренә колак салучы кеше табылмады.

—Туемызга кермәсәң, безне рәнжетәсең. Туйдан баш тарту канлы үчкә тиң. Татарларга үчен юк икән, гозеремезне тынла.

—Ризыктан да өстен булма инде, туемызга рәхим итә күр.

Төрле яклап шул рәвешчә кыстый башлагач, Ясүгәй баһадир сынды. Аны алтмыш дүрт киргә тарттырып корылган иркен тирмә эченә кертеп утырттылар. Монда күбесенчә аксакаллар һәм яубашлары гына тезелешкән иде. Шулар арасында иң түрдән урын бирүләрен күргәч, Ясүгәйнең күнеле күтәрелде. Әле анын янында Дәй чәчәнгә биреп бетермәгән бүләкләр бар иде, яраннары аша шуларны Мерәс батырга озаттырды. Зур рәхмәтләр әйткәннән соң, ана әче бал тулы касә тоттырдылар. Беренче жамаяктан соң ук тәне буйлап гүя ут йөгерде, шуннан ары ул үзенең ничә касә бал һәм шәраб бушатканын санап маташмады...

Кайтыр юлга чыгып Онон буена житкәч, Ясүгәй баһадир һич тә көтмәгәндә ияре өстенә бөгелеп төште.

—Эчем, эчем.

Йөгәннәре бәйләнгән ике ат сыртына ботаклардан үрелгән чыпта салып, Ясүгәйне шунда күчерделәр. Селкенүләр шактый кимесә дә, баһадир юл буе һаман бөгәрләнеп һәм яман ыңгырашып кайтты. Балдак Далага кайтып ак тирмә эченә күтәреп керткән чакта Ясүгәй инде бөтенләй аңсыз иде. Вакыт-вакыт һушына килеп күзләрен ачкан чакта Ясүгәй баһадир бернинди эзлеклелек күрсәтмичә саташып аптыратты.

—Сүлдә тугыз чуклы, магулларның тугыз кабиләсе... Син яу серләрен өйрән, Тимучин улыкаем. Дай чәчәнне тынла... Бөртекне алып кайтыгыз, чәчләре бик матур, нәкъ Айлы бикәмнеке шикелле үк матур... Томавыл бабай, сине сагынам мин. Син бит безгә бөтен магул тирмәләрен бер сүлдә астына тупларга әманәт әйткән идең... Тимучин, Тимучин, улыкаем минем...

Ясүгәйнең шушы чакыруларын ишеткәч, Тимучин артыннан чапкын юлладылар. Баһадирнын энеләре Дәритай, Тайчу, Канун белән бергә Айлун әкә гел авыруның түшәге янында гына утыра торган булды. Ясүгәй өч тәүлек буе шулай интекте-саташты да, таң сызылып килгәндә уяу караш белән күзен ачты. Тик барыбер дә хәле авыр иде, күрәсең, әйткән сүзләре тонык һәм өзек-өзек булып яңгырады.

—Мине татарлар туйларына чакырып агулады... Тимучинны чакырып кайтарыгыз. Хушлашырга өлгермәмме икән?—Ясүгәй ачулы караш белән Дәритай йөзенә төбәлде.—Әгәр өлгермәсәм, минем сезгә әманәтем шундый. Тимучин баһадир урынына баса, ә сез барыгыз да аңа буйсынасыз. Дәритай, аңладыңмы?—Энесенең баш кагуын күргәч, Ясүгәй дәвам итте.—Магул кабиләләренең барчасы да изге сүлдә астына тупланырга тиеш. Бу—Тимучинның эше, ул гына булдыра ала аны, мин ышанам. Моны аңа иң олы әманәтем итеп тапшырыгыз...

Тимучин юлда бертуктаусыз чаптарлар алыштыра-алыштыра, үзе шабыр тиргә батып ашыкса да, барыбер, өлгермәде. Ул тирмә эченә атыла-бәрелә килеп кергән чакта Ясүгәй баһадирнын жаны инде күптән мәңгелеккә очып киткән иде.

## 3

Тимучин тормышындагы газаплы бер дәвер шулай канат җәйде. Ясүгәй үлем түшәгендә яткан чакта вәгъдә бирсәләр дә, энеләре Дәритай, Тайчу, Канун малай гына булган япь-яшь Тимучин каршын-да бил бөгәргә теләк итмәделәр. Алардагы тәкәбберлек тиз арада башкаларга йокты. Мәрхүм баһадирның кырыгын гына үткәргәннәр иде, икенче көнне таңда ук Тимучин тирмәсенә бер кыятлы атыла-бәреләкерде.

—Тайҗутлар тирмәләрен арбаларга төйи. Безне ташлап китәргә җыеналар.

Әлеге утлы хәбәрне ишеткәч тә, иң беренче булып Айлун бикә аягына басты. Үзе каушаудан тирмә буенча әрле-бирле сугыла, ә күзләре гүя кайнар очкын чәчеп яна иде. Көтмәгәндә ул Ясүгәйнең шонкар сурәте төшкән әләменә барып ябышты да, шуны сөнге сыман төбәп торткан хәлдә ишеккә томырылды. Тайҗутлар Балдак-Даланың Җиләкле тау белән тоташкан ерак читендә үк яши, хәзер исә күбесе инде арбаларга менеп тезелешкән иде. Ат өстендә ап-ак әләм җилфердәтеп килгән Айлун әкәне, аннан беркадәр ара калышып чаптарын куалаган Тимучинны ялгыз көе күргәч, тайҗутларның йөзе коргаксыган агачның җилгә бирешмәс кәүсәләре сыман хәрәкәтсез калды.

—Тайҗутлар, акылыгызга килегез, кая җыенасыз? Изге Бәдуанчар бабагыз да, Томавыл мәргән илә Кабул хан да бөтен магул кабиләләрен бер тугра астына, бер йодрыкка туплау уе илә янып яшәгәннәр. Ясүгәй баһадирның да теләге шул иде. Аерылганны—аю, бүленгәнне бүре ашар, диләр бит. Нигә бүленәсез?

Тайҗутлар өчен ике ел элек әтисе үлгәннән соң кабилә башлыгы булып калган Торгытай җавап бирде:

—Кайчаннан бирле безнең өстән чәчби хатын-кыз идарә итәргә җыена соң әле? Урының учак, казан тирәсендәдер, шуны онытма, Айлун бикә. Аннары син әле безнең кавем вәкиле дә түгел. Магул эшләренә тыгыласы булма!

—Әнә шул, тугыз кабиләгез илә бер йодрык булып туплана белмәгәнгә күрә сезне татарлар илә чиннар тар-мар итте дә бит инде,— дип, ачыргаланып кычкыра-кычкыра, Айлун бикә янә тезеп китте. Тайҗутларның аңа игътибарсыз рәвештә һаман арбаларын тутыруын күргәч, инде куркыту-кисәтүгә үк күчте.

—Хыянәтегез хакында барып ишетелсә, сезне Котул хан да гафу кылмас. Кан косарга туры килмәгәе!

—Хан өстендә үлем козгыны очып йөри. Юкка өркетәсең безне, әй, хатын-кыз. Кабиләләр язмышына түгел, ир-ат эшенә дә тыгыласы булма.

Торгытайның мәсхәрәле шушы җавабыннан соң моңа кадәр тешен кысып түзгән Тимучин да күз яшьләре аша ярсып кычкырырга мәҗбүр булды.

—Хыянәтең өчен гафу итәсем юк. Бөтен кыятлылар белән өстегезгә барып, пыран-заран китерәм мин сезне!

—Тирмәндәге ике энекәшеңә хуҗа була алсаң ярый. Син селәгәйнең сүзен тагын кем тыңласын?

Каһкаһәләп шулай кычкырды да Торгытай шаркылдап көләргә үк тотынды. Бераз вакыттан соң, ярсу чаптарының касыгына типте. Арба күчәрләрен авыр шыгырдата-шыгырдата, аңа башка тайҗутлар иярде.

Тимучин күз яшьләрен тыя алмыйча ярсып үкси-үкси иң өлкән агасы Дәритай янына атылып кергән иде. Җигәненең гозерләп гаскәр соравына каршы Дәритай кырт кистереп кенә җавап бирде.

—Әледән-әле татар килеп суйганы да җиткән. Магул канын магул кыясы юк...

Торгытай юраганнар да гел юш килеп барды. Тайҗутлар кыятлыларны ташлап киткәннән соң ике-өч көн дә вакыт үтмәгәндер, Балдак-

Далага Котул ханның вафаты турындагы хәбәр килеп ирешге. Яна хан сайлау хакында сүз кузгатучы да юк, магулнын һәр бәге үз кабиләсенә генә хужа булып аерым-аерым яшәргә жыена иде, ахры. Бәлки, шул үз хужалары янына кайту ниятеннәндер, мона кадәр кыятлылар белән янәшә урнашып көн иткән нирун кабиләсе ирләре дә тирмәләрен жыйнап ат өстенә менде. Болар—Котул ханнын уллары булган Алтын, Кучар, Сачә бәкләргә буйсынучы гаиләләр, аларга баш булырга маташу әрсез бер эш иде. Тимучин аларны төшенке, кызганыч кыяфәт белән, сүзсез озатып калды.

Алар артыннан ук чатжиратлар тирмәләрен жыйды. Аларны кабиләнең башлыгы Минай бәк кузгатса да, Тимучин анын улы Жәмуганы да хыянәтче сыман кабул итте, шуңа күрә балачак дустын озатырга чыгып маташмады. Гомумән, Тимучин соңгы көннәрдә үз кабыгына бикләнгән һәм һичкем белән аралашмыйча, бозау чәйнәп ташлаган чүпрәк сыман таушалган-изелгән кыяфәт белән тәмам кара көеп йөри иде.

Тирмә эчендә, кешеләр күз алдында газапланудан туеп, ул беркөннеауга чыгып китте. Онон буенда таллыклар һәм камышлыклар чутсыз, ә аларда эреле-ваклы жанвар мыжгып тора иде. Тимучин ярты көн буена диярлек житез жәйраннар артыннан йөгереп йөрде, ләкин һич югы берәрсен булса да атып ала алмады. Анын каравы әледән-әле сусар, әрлән, йомран очрап торды, Тимучин аларнын дисгәләбен аткы угы белән шундук чүкеп барды. Аучы һәвәсеннән айныганда инде кич житсә дә, Тимучин әллә нинди хәвефкә бирелеп маташмады. Яр читеннән корыган камышларны йолкып түшәде дә, шулар өстенә эт баласы сыман бөгәрләнеп, Онон буенда төн кунарга калды.

Икенче көнне төш житкәндә Балдак-Далага кайткач, Тимучин үз күзләренә үзе ышана алмый торды. Үзәнлек тулысынча, тәмам бушап калган. Хәтфә үлән арасында түм-түгәрәк булып тирмә эзләре генә ярылып күренә дә, берничә урында инде сүнеп баручы учак пыскып ята. Һәм берьяк читтә генә, чаган куаклары арасында, көтүеннән аерылып калган яралы каз шикелле монаеп, Ясүгәй баһадирнын үз куллары белән корган ак тирмәсе япа-ялгыз көе күренеп тора иде...

## 4

Тимучин бүген үзе белән ауга кече энекәше Хасарны да алып чыккан иде, ләкин юл унмады. Көзге салкында Онон яры буйлап иртәдән кичкә чаклы йөрделәр, һәвәс, комар кузгатырлык жанвар очрамады. Әле ярый Хасар ике сусар белән йомран атып алды. Төпчек энекәше үткен күзле, кулы ялгышу белмәс мәргән булып үсә, шунысы зур юаныч. Ул киләчәктә дан-шөһрәткә күмеләчәк сугышчы булыр, шаять, монысына шик юктыр. Ә Билгүтаен, менә, ауга чыгарып булмый. Имән сыман төптән юан чыккан өлкән энекәше балык тотуга дисән, жаны фида. Башка чакта арты йомшак жиргә тиде исә, мыш-мыш килеп шундук йоклый башлый. Дөрес анысы, өстенлеге дә бөтенләй юк түгел. Ике яшькә кечерәк булса да анын алышта әле бер тапкыр да Тимучинга билен биргәне юк. Кулларын билгә салыштылар исә, Билгүтай аны утын түмәре шикелле күтәрә дә ата. Ичмаса, ул бүген балыкны күбрәк тоткан булса гына ярар иде. Югыйсә, көн саен диярлек әрлән, йомран ташып, әнисенә шуннан аш пешерту Тимучинга оят.

Хәер, Тәнрегә мең шөкер, Айлун бикә зарлануны белми. Ясүгәй баһадирны жирләүләренә дә биш ел вакыт үтте, ачлы-туклы яшәгән чаклары да аз булмады түгел. Ә Айлун бикә беркайчан да балаларын гаепләп сүз әйтми, киресенчә, һәр кич саен әллә нинди риваятьләр, хәтирәләр сөйләп, ул аларны үсендерә белә.

Менә, бүген дә, тамак ялгап яткач, Айлун бикә кыятлылар кабиләсенә нигез салган ерак бабалар исемен кат-кат телгә алды.

—Кабиләнең иң тәүге атасын Кыят-Бүрежигән атлы кеше булган, диләр. Бүре туганы, бүре энекәше, дигән сүз буладыр ягъни. Аннан инде сездән унике буын ерак бабагыз Көрән-Бүре туган. Ул сылулыгы илә меңнәрчә ирләрне телсез-һушсыз иткән Гүзәл-Марал атлы кызга өйләнгән, ди. Менә шулар инде сезнең нәселегезгә нигез орлыгы салган. Шулардан башланган һәрбер яңа буын нәселегезгә абруй өстәп торган. Сезнең ерак бабагыз Кабулны магул кабиләләре хан дип игълан иткәч, чин императорларының берсе яман котырган да, үз хозурына чакырып алган икән. Ә бабагыз бер дә калтырап төшмәгән, чиннар хуҗасының үзен чик буенда очрашуга дәшкән. Шунда, санаулы яраннар илә генә очрашкан чагында, чин императоры җикеренә башлагач, Кабул хан гайрәтләнеп алга чыккан да, теге капкорсакны сакалыннан тотып сөйрәп йөрткән. Менә нинди тәвәккәл вә кыю булган сезнең нәселегез...

Ундүрт яшьлек Тимучин бу риваятьләрне йөзенче кат тынлый һәм күбесен инде яттан белә иде. Шулай да әнисенең хикәятен тәүге тапкыр ишеткән шикелле сүзсез тынлап ятты. Әмма ауда аруы җиткән булган күрәсең, бераздан ул йокыга оеды.

Ул тирмә артындагы киртә утар эчендә Соры айгыр ярсып кешнәгән тавышка капылт уянып китте. Әлеге утарда Тимучин күз карасы кебек кадерләп саклаган сигез чаптар тора. «Әллә бүре бармы?»—дигән тәүге уй ук аны яшен чаткысы шикелле дәррәү яндырып узды. Берничә мизгелдән соң ул инде җәя-кылычларын эләктереп, ук шикелле тышка атылды.

Җиһанда таң атып килә, үзәнлеккә берникадәр яктылык төшкән иде. Ә шулай да әле томан таралмаган, һәр тарафны аермачык күреп бетереп булмый. Йөгереп барган шәпкә җәя-кылычларын иңгә элә-элә Тимучин чаптарлар утары ягына томырылды. Утар янына килеп җиткәнче үк ул анда ат менгән ике-өч ир шәүләсен шәйләп өлгергән иде инде. Утар капкасын ачып куйганнар да, озын торыклар белән төрле яклап чаптар-ларны тышка куалыйлар. Димәк, ат караклары инде болар, Тимучинны ике кулсыз хәлдә калдырып китмәкчеләр.

—Атам, үтерәм, туктагыз!—дип яман үкерә-үкерә Тимучин ачык капка каршына йөгереп чыкты, әмма үз өстенә нинди бәла якынаеп килүен шәйләмәде.

Ат караклары өчәү генә түгел, алты җайдак һәм аларның өчесе чаган куаклары арасына качып тора иде. Утар каршында хуҗа пәйда булгач, яшеренеп торучылар арасыннан иң зур гәүдәлесе сиздерми генә аңа якынайды да, олы күсәк белән Тимучинның муенына орды...

Тимучин йөзенә су бөркүдән сискәнеп һушына килде. Айлун бикә аның каршына килеп тезләнгән, яңаклары буйлап яшь тамчылары тәгәри иде. Билгүтай белән Хасар да абыйлары янына чүгәләп утырганнар, карашлары хәвефтән тулып ташкан. Тимучин күзен ачуга, Айлун бикә сузып-сузып еламсырап алды.

—И-и, Ходайның рәхмәте, исән, исән!

—Ә чаптарлар бармы?

Соравына җавап ишетмәгәч, Тимучин көч-хәл белән күтәрелә төшеп, утар ягына караш ташлады да, авыр ыңгырашып, янә ауды.

—И-их, хайваннар! Соңгы байлыктан да коры калдырдылар.

Тешләрен кысып, сызлана-сызлана, Тимучин җирдән күтәрелде. Тугайлыкта аяклары тышаулап җибәрелгән берничә ат бар иде. Садактагы укларны барлый-барлый Тимучин шулар ягына таба атлап китте.

—Аттан бигрәк, баш кыйбат. Йөрмә, улыкаем?—дип, Айлун бикә кат-кат ялынса да, Тимучин артына борылып караш ташламады...

Балдак-Дала үзәнлегендә җайдакларның күптән йөргәне юк, шуңа күрә бер көтү булып үткән ат тоягы эзләре үлән арасында аермачык ярылып ята иде. Тимучин шул эзләр буенча көннәр буе барды һәм каракларны кичке карангылык төшкән чакта куып җитте. Кыялы тау буена барып җиткәч, каракларның күнеле тынычланган, ахры, алар казан асып ялга туктаганнар. Соры айгыр муенына бугалак салганнар да, аны,

озын аркан тагып, казыкка бәйләгәннәр. Башка чаптарлар—аның тирәсендә.

Тимучин үзенең көчсезлеге, ялгызлыгы өчен ачына-ачына чаптарларны озак күзәтеп ятты. Үч иткәндәй, карангылык та төшми, төн дигәннәре дә ялындырып кына килә иде. Муеныңдагы йодрык кадәр шешкә кулын салган хәлдә Тимучин байтак вакыт буе хәрәкәтсез ятарга мәжбүр булды.

Аны һич тә көтмәгәндә корыган үлән сабаклары сынган тавыш сискәндерде. Тимучин үзе яшеренгән чокыр эченә җәһәт кенә караш ташлады да, учак өстенә эләккән күн шикелле куырылып калды. Ана таба үзе шикелле үк ундүрт-унбиш яшьләрдәге яшүсмер шуышып килә, кичке сүрән яктылык аның кулындагы хәнҗәр кынынннан, җәя киргесеннән кайтарылып уйнаклый иде. Тимучинның кылыч сабына ябышуын күргәч, көтелмәгән кунак үзе телгә килде.

—Урыныңнан купма, каракларның сизүләре мөмкин.

Тимучинның әле һаман сәер караш белән төбәлүен шәйләп, кунак өстәп куйды:

—Мин каракларны да, сине дә әле безнең җәйләү яныннан үткән чакта ук күрдем. Үзем уранхайлар кабиләсеннән булам, атым Бавырчыдыр.

Тимучин барыбер түзә алмады, ашыгып сорау бирде:

—Ә шулай да син ни өчен минем янга килдең соң әле? Караклар янына барып мине саткан булсаң, син, һичшиксез, бүләк алыр идең.

Бавырчы үпкәләде, ахры, бераз дәшми торды, әмма сиздермәде.

—Бер ялгызы көе алты каракка каршы чыккан җүләр артыннан күзәтүе кызык. Менә шуна килдем.

Яшүсмер Бавырчы тик бераздан гына күнелен ачып салды.

—Алты каракка каршы бер үзең чыгарга курыкмыйсың икән, димәк, син кыю, куш йөрәкле егет. Ә мин әле үземнең нәрсәгә сәләтле булуымны да белмим. Менә, сиңа ярдәмнән бигрәк мин үземне сынарга, дип килдем...

Тугай өстен караңгылык катыш томан каплап алгач, ат караклары учак тирәли сузылышып ята башлады. Алар чаптарлар янына, хәтта, каравылчы да куеп маташмады. Шуннан чыгып Тимучин үз ниятен ачты.

—Атлар мине таный, шулай булгач, өркенеп-нитеп кешнәмәсләр. Мина шул тарафка китү отышлырак. Ә син биредә кал, җәяң корулы булсын. Соры айгырны арканнан ычкындыргач, мин караклар өстенә сәрпи ук очырырмын. Син дә тондыр. Әле ук очырып кына да калма, бүре булып та ула. Караклар синең арттан ыргылса, качып котыла белерсең бит, шаять?

—Кайгырма, мина монда һәрбер түмгәк таныш.

—Алайса соңгы сүз: кайда очрашабыз?

—Кыялы таудан бер фәрсах арада улаклы чишмә булыр, шуның янына кил...

Сызгырып очкан сәрпи ук бер карак сыртына килеп кадалуга, башкалары язгы боз кузгалганда елга уртасында калган балыкчылар сыман өшәнеп-каударланып аягурә купты. Учак яныннан читкә сибелергә дә өлгерә алмадылар, Бавырчы очырган уктан тагын берсе җир өстенә ауды. Исән калган караклар билгесез дошманның кайсы яктан һөҗүм итүен ачыклап интеккәндә якындагы калкулык өстеннән яман усал улаучы бүре тавышы яңгырап ишетелде. Тезгеннәре алгы аякларына бәйле атлар төрле якка сикереп әсәренде. Ул да түгел, уйсулыкта Соры айгыр талгын кешнәп куйды һәм үзәнлек өстен һаман саен ераклаша баручы тояк тавышлары күмеп китте. Дәү гәүдәле карак тезгеннәре бәйле якындагы ат янына томырылган иде, баш өстеннән ук сызгырып үткәч, чабылган үлән шикелле сузылып, шундук җиргә ятты...

Соры айгыр өстенә менеп алган Тимучин улаклы чишмәне эзләп тапкан чакта Бавырчы инде күптән килгән кеше кыяфәтендә аны су читенә утырып көтә иде. Ул сүз тезгенен дә үз кулына алды.

—Каракларның безне эзләп килеп чыгуы бар, монда калу куркынычрак булыр. Әйдә, безнең җәйләүгә кайтыйк. Атай утарында кунак

булырсың, хәвеф уздырырсың. Аннары мин бит әле синең кем икәнеңне дә белмим, шунда танышырбыз.

Бавырчының әтисе Нагу-Баян атлы һөнәр остасы икән, агач киртәләр уртасында әллә ничә тирмә һәм балчык алачыклардан хасил утары зур гына бер хуҗалык булып чыкты. Чаптарларны куалап утар янына кайткан җайдакларны үзләре шикелле үк яшүсмер бер егет каршылады.

—Бу бездәге тимерче малае, аты Җәлмә,—дип, Бавырчы таныштырды да, аннан өстәп куйды.—Ук атуда аңа житүче юк, тиен-йомраннарны күзләреннән генә чүкеп ала.

Җәлмәнең сызганулы җиннәре астындагы кулларының мускуллары ишелгән бау шикелле бүртеп-бүртеп тора. Егет әтисе янында тимерче чүкечен дә аз болгамый иде, күрәсең. Тимучин Бавырчы белән бәхәскә-мазар кереп маташмады.

Нагу-Баян әле тояк тавышларын ишеткәч тә урыныннан купкан икән, ул кунакны аягүрә басып каршылады. Чәй янында бәйнә-бәйнә сөйләнгән сүзләрдән соң, Тимучинның язмышын белеп алгач, аңа төбәлеп, шактый вакыт тын утырды. Әйе, кунак көтелмәгән, сәер, әмма аны гажәпләнеп күзәтмичә мөмкин түгел иде. Биек, чандыр гәүдә; магулга бөтенләй хас булмаган җирән чәчләр; кысулы, тар ирен һәм сискәнергә мәҗбүр итә торган очкынлы, ихтыярый караш. Ул моңдый карашы белән кешеләрне генә түгел, тимерне дә эретә алыр кебек. Йөрәгендә татарларга да, магулларга да нәфрәт тулып ашкан. Аларны кайчан да булса үзенең тез астына бөкләмәкче була. Аннары бу кунак, әле яшүсмер генә булса да, куркуны һәм чигенүне белми, үзенең бүгенге халәте белән һич тә риза түгел. Димәк, ул әле яше үсеп житкәч, үр артыннан үрләр яулаячак.

Нагу-Баянның алдагы сүзләре Тимучин күңеленә сары май булып ятты.

—Сез икегез дә яшьләр, бер-берегезне канлы орышта сынап танышкансыз. Гомерлек дуслар булып калыгыз. Мин угылым Бавырчыны, ярдәмчең итеп, синең белән озатам, кыят бәге. Әйе, әйе, ялгыш ишетмәдең. Мин ышанам, син әле кыятлылар бәге генә түгел, барча магулларның ханы булачаксың.

Бик озак вакыт буе дәвам иткән жәбер-битәрләүләрдән соң кайнана авызыннан тәүге тапкыр мактау сүзләре ишеткән киленнеке сыман Тимучинның да күзләре дымланды, шуны күрсәтмәс өчен башын түбән иде.

—Рәхмәт сиңа, оста.

Тимерче углы Җәлмә ишек катындарак утыра иде, көтмәгәндә ул да телгә килде.

—Мин туганнан бирле синең Бавырчың белән бергә уйнап үстем. Ул миңа ин-иң якын борадәрем төсле. Безне аермасаң, миңа да Тимучин бәк янына китәргә рөхсәт итсәң иде, хуҗам?

Нагу-Баян карар кабул итүдә инешне узган иде, иске ярга кире кайтып-мазар маташмады.

—Ярар соң, максат иткәнсең икән, хәерле юл сиңа да. Мәгәр күнеленә бик нык итеп киртлә: хыянәтне белмә...

Ике яна дусты янәшәсендә Балдак-Далага кире кайткан чакта бу жиһанда Тимучиннан да бәхетлерәк кеше булмагандыр.

## Уникенче бәйләм

### 1

Андрей кенәзне ачу-нәфрәт хисе йомшак алмага төшкән корт шикелле талый, ул теше сызлаган кеше сыман яңакларын тотып ни кылырга белми утыра иде.

Күпме дистә еллар, ничә гасыр инде рус кенәзләре үзара тынышуны белми. Кечкенә бер сәбәп табылдымы, котырган эт шикелле, шундук берсен-берсе таларга ябышалар. Ел саен ничәмә-ничә шәһәр җимерелә, елга-елга булып кан коела.

Соңгы елларда үзара яу чабулар котсыз туфан сыман көчәйгәндәй булды. Нигезенә Киевтагы бөек кенәз Ростиславның көтелмәгән үлеме сәбәп булды бугай. Аны Чечерск каласында кияве Олег янында кунак булганда әллә агуладылар, әллә инде үзе эчеп үлде—моны шайтан белсен. Бер мең бер йөз алтмыш җиденче елда Киев тәхетенә моңа кадәр Волынь кенәзе булып утырган Мстислав менеп алды. Менде дә, шундук үзенең җигән энекәшләренә, кардәш кенәзләренә каршы яу башлады. Ул башта Владимир атлы энекәшен Вышегород каласыннан куган иде, аннары инде Бөек Новгородлылар өстенә ябырылды һәм анда хуҗа булып утырган мәрхүм кенәз Ростиславның улы Святославны да куды. Рәнҗетелгән Владимир белән Святослав та, берничә еллар элек Андрей куганнан соң Киев тәхете янына барып елышкан, әмма яна бөек кенәз үченнән өннәре алынган энекәшләре Всеволод белән Глеб та—һәммәсе нәсел үгезе сыман көрәеп алган Владимир-Суздаль биләмәләренә килеп сыендылар.

Андрей Киев хакименнән үч алырга сәбәп кенә эзли, ул ниндидер Ростислав-Мстиславларның бөек кенәз дәрәҗәсен йөртүләреннән тәмам туйган иде. Мстиславның Бөек Новгородка хуҗа итеп кайсыдыр бер туганын утыртуы хакындагы хәбәрне ишеткәч тә, Андрей үзенең дружинасын походка күтәрде һәм Новгородка буйсына торган Торжок каласыннан көл калдырып узды. Ул арада Боголюб үгезеннән коты алынган яңа хуҗа качкан, Бөек Новгородта наиб булып хәзер халык үзе сайлап куйган Якун калган икән. Шул хактагы хәбәр генә Андрейны кире борылырга мәҗбүр итте.

Аның каравы Киевтагы Мстислав кенәз мондый җиңелү белән килешмәде. Хәзер инде үз чиратында ул да Бөек Новгород өстенә гаскәр белән барды һәм үзенең улы Романны кенәз урынына калдырып кайтты. Мстиславның мондый тәкәбберлеге болай да ярсыган үгезне кызыл чүпрәк күрсәтеп котыртуга тиң бер адым иде. Өстәвенә Мстиславның Смоленск җирендә Торопец каласын яндырып көлгә әйләндерүе турындагы хәбәр дә килеп иреште. Андрей шуннан соң чыгырыннан чыкты һәм үз янына баш воеводасы Борис Җидиславичны чакыртып алды.

—Бу Мстислав инде ике ел буе саруымны кайната, миңа тынгы бирми. Тәртә арасындагы үшән алаша сыман күндәм булудан туйдым, ул баш бирмәс Киевның умырткасын сындырырга вакыт. Үзебезгә буйсынучы һәммә каладан дружиналар чакыр, болгарлар да күрмәгән зур вә көчле гаскәр тупла. Суыгына-буранына карамыйча юлга чыгабыз да, Киев каласын тез чүктерәбез. Шунсыз җаныма тынгы табалмаячакмын мин!

Мең дә бер йөз алтмыш тугызынчы елның февраль башында Боголюб янына Муром, Рязань, Клязма, Мәскәү, Суздаль, Ростов, Владимир калаларыннан көчле дружиналар килеп җитте. Бу кадәрле гаскәр рус кенәзләре генә түгел, теләсә кайсы чит-ят дәүләт өчен дә куркыныч көч иде. Андрей аның белән генә дә канәгатьләнмәде, Дорогобуж, Төньяк Новгород, Переяславль, Полоцк кенәзләре янына да яшерен чапкын куды, аларга өстәмә калалар, яңа биләмәләр вәгъдә итте. Владимир-Суздаль хакименең тәкъдименә күнгән союзниклар Вышегород каласы янында бергә кушылдылар. Кала капкаларын ачып каршылаган Давид Ростиславич яубашларны кенәз сараенда кабул итте. Күмәк әләм астына унбер кенәз тупланган һәм, әлбәттә, Андрейның күнеле сөенечтән чүпрә сыман тулып ташкан иде. Ул сый өстәле артына тезелешкән кенәзләрнең кызышып алуын да көтеп тормады, күңелендәге ниятен аларга җиткерергә ашыкты.

—Мин инде алтынчы дистәмне тутырып киләм, һаман кылыч болгый-болгый яуда йөреп булмас. Әнә, угылым Мстиславка унҗиде яшь тулды, ул һәммәгез өстеннән дә төп яубашы булыр. Минем воеводам

Борис Җидиславичны белмәгән кеше юктыр, аны Мстислав янына ярдәмче һәм калкан итеп куям. Бөек кенәз нинди генә үгетләүгә ябышып карамасын, чигенү юк. Йә мин шушында үләм, йә тәкәббер Киевны тез чүктерәбез!

Иксез-чиксез гаскәр пайтәхетне алтынчы март көнне камап алды. Киев хакиме Мстислав Андрейның походы турындагы хәбәрне ишеткәч тә үзенә ярдәмгә угыз-бәрәндиләрне һәм «кара башлык» союзындагы сугышчыларны чакырып өлгергән иде. Мәркәз кала көтелмәгән туган-дошманнарын бикле капкалар һәм ныклы оборона белән каршылады. Киевны һәрьяклап ике көн буена штурмлау бер төрле уңышка да китермәде. Сигезенче март иртәсендә гаскәр каршына Андрей кенәз үзе атылып чыкты.

—Киевны алганнан соң мин сезгә каланы өч көн буена таларга рөхсәт итәм. Әйдә, бу пычрак пайтәхет өстенә карчыгага охшап ябырылыгыз да, капчык һәм олауларыгызны каладагы чиксез байлык-нигъмәт белән тутырыгыз.

Моннан да ялкынлырак үгетләү сүзләрен әйтеп тору артык шөгыль иде, суздальлылар агач диварлар өстенә ташкын булып менә башлады. Кала сагына баскан «кара башлыклылар» бушка гына кан коюдан бигрәк талау башлангач өлешсез калудан шүрләде, ахры. Беренче булып кала капкаларын нәкъ менә шулар ачты. Алардан күрмеш, угыз-бәрәндиләр дә Андрей гаскәре ягына качып чыкты. Хатынын һәм улын дошман кулына ташлап, бөек кенә Мстислав көч-хәл белән качып котылды.

Киев халкын өч көн, өч төн буе кычкыртып таладылар. Хәмер эчеп алган сугышчылар үзләренең христиан булуларын да оныттылар, ахры. Асылташлар, алтын, байлык күреп күзләре тонган ирләр София соборын да, башка чиркәү һәм монастырьларны да тоташ талап чыкты. Өченче тәүлек житкәндә собор-чиркәүләрдән алтын, рәсем, иконалар гына түгел, хәтта, бакыр чаң һәм Инҗил китапларына кадәр юкка чыккан иде...

Дүртенче көнне сугышчылар Киев халкын таланган София соборы янындагы төп мәйданга җыйды. Соборга терәтеп корылган агач күперчек өстенә кырыс йөзле Андрей күтәрелде. Сүзләре корыч аһәң белән, жан өшеткеч булып яңгырады.

—Кенәзегез качты, ә сез жиңелдегез. Киләчәктә идарә итәр өчен мин сезгә бертуган энекәшем Глебны калдырып китәм. Мәгәр моннан ары Киев—пайтәхет тә, башлыгыгыз бөек кенәз дә түгел. Мәркәз кала дәрәҗәсе Владимирга күчә һәм рус биләмәләренең бөек кенәзе тик мин булачакмын. Мин ул бөек кенәз! Мин ул хаким! Җир өстеннән юк булып көлгә каласыгыз килмәсә, шуны онытмагыз!..

## 2

Әмир Ибраһим хуҗа булып утырган иске пайтәхетне яулап кайтканнан соң, алты ел буена Андрей кенәз Болгар тарафыннан һичнинди хәвеф-хәтәр белмичә генә гомер сөрә иде. Хәтта, киресенчә, Идел буендагы соңгы яу тынгач та Биләр тәхетенә менеп алган Ибраһим хан Владимир-Суздаль кенәзлеге белән дуслык элемтәләре генә эзләде, бер-бер артлы сәүдә кораблары җибәреп торды. Ул гына да түгел, Андрей кенәзнең Изге Ана рухына багышлап Владимир каласында яңа собор төзергә җыенуын белгәч, шул ук Ибраһим хан кораб-кораб мәрмәр ташлар да юллады, Даур атлы оста житәкчелегендә төзүчеләр дә җибәрде.

Ә менә бүген Клязьма сәүдәгәрләре кайтарып житкергән соңгы хәбәр Андрей кенәз өчен карга каркылдавы сыман шыксыз, усал яңгырады.

—Арлар белән сәүдә итмәк булып Чулман, Нократ тирәсенә барган идек. Чипса тамагыннан үткән чакта Колын кальгасының каралары өстебез-

гә ябырылды. Арлардан тимер көбә, айбалта, көмешләнгән дирбияләргә алыштырып алган кеш, сусар, ак төлке тиреләренен һәммәсен, бөртеген дә калдырмый таладылар. Сакчыларыбыз белән салчыларнын барчасы һәлак булды. Үзебез чирмеш урманнары эченә качып кына котылып кала алдык.

Эт талаган шикелле кылка киемнәргә төренгән, йөзләрен укмашып, чукланып беткән озын сакал баскан сәүдәгәрләрне күздән кичерде дә, янак сөякләрен уйнаклата-уйнаклата Андрей авыр хисләргә бирелде. Юлбасарлар—алар гамьсез көтүгә һөҗүм иткән явыз бүреләр кебек. Беренче һөҗүмнәрендә үк сыртлары, борыннары көярлек итеп сабак бирмәденме, алар әрсезләнеп-азгынланып тагын ябырылачак. Болгар юлбасарларын да, коточкыч үч алып, азгынлыктан биздерергә кирәк. Ләкин алардан үч алырга яубашы итеп кемне озатырга соң? Улы Мстислав Бөек Новгород жирендә болай да яуда йөри. Киребеткән новгородлылар Аккүл янында Суздаль дружинасын тар-мар иткәннән соң Андрей кенәз Муром, Рязань, Смоленск, Полоцк дружиналарын биреп, улын шул тарафка озатып жибәргән иде. Аерым, ирекле кенәзлек булып исәпләнгән ул кала ягыннан күнел жылытырдай беренче хәбәрләр кайтып иреште дә инде. Мстислав Новгородка кадәр булган өч йөз чакрым арада барча авыл-кальгаларны көлгә калдырып узган, менәрләгән ир һәм хатыннарны әсирлеккә алып коллыкка озаткан. Роман кенәз белән наиб Якун капкаларны бикләп калада оборона тотарга жыена икән, диләр. Новгород Киев түгел, Ходай Тәгалә ярдәме белән Мстислав кенәз әлеге тәкәббер каланы да яулар. Ләкин андагы яу күпмегә сузыла да, дружиналар кайчан кире кайта бит әле? Ә болгарлардан үч алуны сузу һич ярамый. Андрейнын вакыт сузуын болгарлар анын йомшаклыгы, көчсезлеге дип кабул итмәгәе.

Озак уйлап, төрле яктан үлчәп карады да, бөек кенәз үз янына Козьма пәһлеванны чакырырга кушты. Козьма инде ватага атаманы да, ирекле кош та түгел. Идел буендагы яуда яраланганнан бирле ул янә Андрей янында хезмәт итә иде. Дөрес, анын кылыч белән чабылган сул кулы шул елда ук корыган агач ботагы шикелле кибеп,—корышты. Әмма Козьма пәһлеван сынар кулы белән дә яуда теләсә кайсы батырга каршы чыга ала иде әле.

—Мин сине болгарларнын арт сабакларын укытып кайту өчен Колын кальгасына жибәрергә булдым,—дип, Козьма күренгәч тә, Андрей кенәз үгезнен мөгезеннән эләктереп сүз башлады.—Көбәләргә төренгән гаскәр биреп воеводалар кусам, болгарларнын моны чираттагы житди яу, дип кабул итүе бар. Ә без аларны елан шикелле сиздермәстән генә чагып кайтыйк. Син Борис воевода кул астындагы биш йөз кешелек бер полкны ал да, аларнын һәммәсен гади киемгә төр. Болгарлар синен дружинанны гадәти ушкуйлар, юлбасарлар ватагасы сыман кабул итәрлек булсын. Мәгәр юлда уяу бул, жәһәт йөре. Колын кальгасы урынында көл генә калдырып кайт...

Козьманы озатып жибәргәннән сон, Андрей кенәз ике тарафтан да гел сөенечле хәбәрләр генә көтеп яшәде, әмма нык алданды. Бөек Новгород тарафыннан кайтып ирешкән сонгы хәбәр анын өмет канатларын рәхимсез рәвештә капылт көйдереп атты.

—Мстислав дүрт көн буе бертуктаусыз камау алып барса да, һичбер төрле жинүгә ирешмәде. Анын ялга тукталганын күреп, новгородлылар үзләре һөҗүмгә ташландылар. Менәрләгән сугышчыларын дошман кулына калдырып Мстислав кала яныннан качарга мәжбүр булды. Хәзер Суздаль әсирләренен унысын бер тиен хакына ләһләр базарында саталар, ди. Житмәсә, исән калган гаскәр кичә генә үзе яндырып үткән биләмәгә кергәч, әллә ничаклы сугышчылар ачлыктан һәм чирдән кырылалар...

Кайтып керүгә үк тотып янакламакчы булып Андрей кенәз коты-рына-шаша Мстиславны көтте. Әмма тегесе әтисенен холкын-гадәтләрен яхшы үзләштергән иде, күрәсен, күзгә күренергә ашыкмады. Бер ай чамасы да вакыт үтмәгәндер, бөек кенәзнен күнелендәге бозын эретердәй

яна хәбәр кайтты. Мстислав икмәк амбарларын яндырып бетергәнгә күрә Бөек Новгородта да ачлык башланган, чарасыз калган һәм ярсыган халык хәзер инде кенәзләре Романны да куып җибәргән икән. Тиздән Новгородтан Боголюбка илчеләр килеп җитте. Гозерли-гозерли Андрейдан үзләренә яна кенәз бирүен сорадылар. Чама белеп ялындыргач кына, Андрей аларга кайчандыр Киевта бөек кенәз булып торган Ростиславның улы Рюрикны хуҗа итеп озатты. Ләкин үзенең күнеле һаман китек калды.

Бер кичтә, инде йокыга ятарга әзерләнгәч, Андрей бүлмәсенә күктән иңгән сыман Козьма килеп керде. Бөек кенәз аны әле бик тиз генә көтми иде, Козьма пәһлеванның кайтып җитүен чираттагы бер хәвефкә юрады, ярасына тоз сипкән шикелле йөзе җимерелде. Чыннан да, яубашының тәүге сүзләре сәер яңгырады:

—Әмереңне боздык, Колын кальгасын көлгә калдырмадык.

Андрейның күзләренә кан савып, аларның тутык тимергә охшый башлавын шәйләп, Козьма хәлләрнең асылын анлатуга күчте:

—Сине яңа кальга хуҗасына әйләнүең белән тәбрик итәм, бөек кенәз. Моннан ары Колын Хлыновка әйләнер һәм ул Нократ буенда сиңа буйсына торган яңа кала булыр.

Андрейның ирен читләрендә елмаю хасил булгач, Козьма пәһлеван да туарылды.

—Без Нократ буенча Чипса елгасы тамагына чаклы бернинди тоткарлык-мазар белми төшеп җиттек. Колынны камап алып, утлы уклар очыра башлауга ук андагы ар, чирмеш, тезләренә чүгеп, Тәңреләренә ялынырга тотынды. Болгар сугышчылары санаулы гына иде, аларын минекеләр бик тиз чүкеп алды. Ә исән калган арлар безне кальга читенә чыгып һәм янә тезләренә чүгеп каршылады. Моннан ары фәкать сиңа гына ясак түләргә вәгъдә бирделәр. Мин анда шәһәр бәге билгеләп һәм йөз кешелек сак калдырып кайттым.

Үзе дә сизмәстән атылып килде дә, Андрей кенәз Козьма пәһлеванны кочагына алды. Козьма урынында Мстислав булмавына ул бик үкенә, соңгы араларда әллә нишләп ерактагы улын еш сагына иде.

Ләкин бервакытны Мстислав кайтып кергәч, бөек кенәз аңа ачык чырай күрсәтеп маташмады. Сүзләрен дә авызына ком тулган шикелле тешләрен шыгырдата-шыгырдата, усал тезде:

—Син бөек кенәз күрсәткән олы ышанычны акламадың, ярты гаскәреңне яуда югалтып кайттың. Гөнаһыңны фәкать кан һәм яңа җиңү белән генә юып була. Яңа походка әзерлән. Болгар көчсез, шуның өстенә яу белән барачаксың.

## Унөченче бәйләм

### 1

Курсыбай бистәсенә ут төрткәннән соң ук, Давыт сәет углы Мирхаҗи Биләр каласыннан качып китте. Ул әүвәл Болгарга килеп әмир Ибраһим канаты астына сыенды. Үзара кардәш тиешле Ибраһим аны Хәсән мәчетенә имам итеп куйды, якты йөзен, җылы сүзен бер дә кызганмады. Мирхаҗи, имам-хатыйб һәм мөхтәсиб вазифалары белән генә канәгатьләнмичә, Болгарның икенче катлам югары мәдрәсәсендә сабак бирә башлады, бик тиздән баш-аягы белән мөгаллимлек эшенә чумды.

Ләкин Ходай Тәгалә аны тынычлыкта озак вакытка калдырмаган икән. Башта пайтәхеттән Болгарга Давыт сәетнең аяныч үлеме турындагы хәбәр килеп иреште дә, Мирхаҗиның күңел канатлары сынган кебек булды. Аннары тоткавыллар төнлә әмир Ибраһим каршына бер шымчыны тотып китерделәр. Шымчы дигәннәре, тентегәч, чапан итәкләре астына һәм итек кунычына зәһәр хәнҗәрләр яшергән катил булып чыкты. Йөзенә

бәреп сорагач, ул үзен кәрваннар озатып йөрүче гади бер кушчы итеп кенә таныттмакчы иде дә, аягыннан асып баш астына утлы күмер тезгәч, шундук чишелде.

—Мин Мирхаҗи хәзрәтне үтерергә килдем. Бәрәҗ хан яллады. Йөз дә илле алтын дирһам бирде. Ул Мирхаҗиның мәрхүм әтисе өчен үч алуыннан да, аның Болгарда «Ил-һун» фиркасен оештыруыннан да шүрли. Биле ныкны сындыру берни тормый, ә гыйсъянчы бер голәмә чәчкән орлыкны инсаннар күнеленнән еллар, гасырлар буена да кырып алып булмый, ди. Шул мәсләктән чыгып ул Мирхаҗи хәзрәттән арынырга тели...

Әмир Ибраһим үз янына Мирхаҗины чакыртып китерде.

—Безне капчыкта яшереп тотып булмый, барыбер тишеп чыга. Җитмәсә, әле ул «без» дигәннәренең дә бер генә булмавы ихтимал бит,—диде ул аңа.

Соңгы көннәрдә болай да төшенке-боек, саран килен чәе сыман төссез йөз белән йөргән Мирхаҗи авызына су капкан шикелле сүзсез утыра бирде. Әмир Ибраһим җентекләбрәк аңлатуга күчте:

—Баш очына эленгән кылыч төсле сина хәвеф яный. Синең жаныңны кыярга озатылган бер катилне тотык. Андый кабихларның янә дә килмәсенә һичбер ышаныч юк. Сина вакытлыча югалып тору хәерле булыр. Инсан бәк мина кода тиешле. Шуның эргәсенә барып сыен. Бәрәҗ хан ошбу җиһанга мәңгелеккә килгән таждар түгел. Аның да муены сынар. Мәмләкәттә азат тормыш урнашуга, сине бирегә янә чакырырмыз.

Әтисен җуйганнан соң, Мирхаҗи өчен Болгар да, җиһан да шыксыз-нурсыз булып калган иде, ул карышып, бәхәсләшеп-мазар маташмады. Үзе белән яшь кенә бер мөриден ияртте дә, башкортлар яшәгән аймакларга чыгып китте. Шуннан соң аның дистә елга якын гомере Таш-билбау, Эстәрле, Агыйдел, Әй, Ашкадар, Үршәк, Дим, Нокыш, Сакмар буйларында йөреп үтте. Бу сәяхәте вакытында кайсы гына кабиләләр белән танышып бетмәде дә, нинди генә хәлләр күрмәде ул?

Кайсы гына җәйләүгә яки кышлауга барып чыкмасын, максаты бер—кабиләләргә ислам динен индерү, потларга һәм әллә ничә тәңрегә табынып, адашып яшәүче инсаннарны Хак Тәгалә юлына бастыру иде. Мең, табын, каныклы кабиләләрендәге ирләрне үгетләү, аларны мөселманнар өчен фарыз гамәл-гыйбадәтләргә ияләштерү, бер уйласаң, әлләни авыр да булмаган икән. Әлеге кабиләләрдәге байтак җәйләү ирләре кыш, җәй, яңгыр, җил, агач, кеше, хайван, көн, төн һәм тагын әллә никадәрле тәңреләргә табынып яшәсә дә, алар җиһан, тереклек һәм мәгыйшәт белән ниндидер өстен, билгесез көч идарә итүен аңлый, боларга Ходай Тәгаләнең барлыгын вә бер генә булуын төшендерү таш кисүдәй җәфа түгел иде. Ә инде Таш-билбау, Чулман буйларына ук үтеп, андагы Тол, Таныпп, Миас, Сакмар, Җаек, Тубыл елгалары тирәсендә бөрҗән, истәк, әйле кабиләләренең кайбер төркемнәре яшәгән тау-ташлы, чытырманлы төбәкләргә житкәч, Мирхаҗи гел шаккатты. Дошман түгел, илче дә үтеп керә алмастай почмакларга поскан байтак кышлаудагы халык ир-атның агачтан юнып ясаган женес әгъзаларын муеннарына тагып йөри, ихлас күңелдән шул агач потка табыналар иде. Мирхаҗи шундый гыйбадәтчеләрнең берсеннән бу хилафлыкның сере хакында кызыксынгач, тегенең җавабы гамәле сыман ук сәер, кыргый яңгырады.

—Мине шушы зиннәт дөньяга китергән бит. Мин җиһанда шушыннан да куәтлерәк көч барлыгын белмим...

Күрше кышлауларда әле тагын еланга, балык, торналарга табынучылар да байтак булып чыкты. Шуларга аларның хаталануларын, җиһанда Аллаһы Тәгалә атлы тинсез һәм бердәнбер көч булуын аңлата-аңлата Мирхаҗиның җыгы чыгып бетте, һәр кабилә, һәр кышлау саен ничәмә-ничә ай гомерен сарыф итте. Шуңа күрә инде Биләрдә тәхеткә Ибраһим бәк менүе турындагы хәбәрне ишеткәч тә, биш-алты ай буена Болгар тарафына кайта алмады ул.

Ниһаять, мең бер йөз дә житмешенче елның язында Мирхажи тәвәккәлләп юлга чыккан иде. Ләкин Сөнне кичеп Бәҗәнә елгасы буена житүгә, янә тукталырга мәжбүр булды. Бирегә күптән түгел генә ислам диненә иңгән бәҗәнәкләр килеп урнашкан, алар инде якын-тирәдәге тау һәм яланнарга, елга-күлгә үз атамаларын да биреп өлгергән, әмма үзләре мәжүсилек, күчмә тормыш гореф-гадәтеннән арынмаган икән.

Болгарларның күршедә генә урнашкан Чалмат, Тәмтүбә аймакларындагы ирләр белән бергә үткәрелгән язгы чәчү мәшәкатьләреннән арынгач, бәҗәнәкләр Сабан туен бәйрәм итә иде. Сөн, Сикия, Зәй, Калмыя, Шәбез, Игәнә, Мәллә тарафларындагы җәйләүләрдән килгән кунакларның күпчелеге Ык буендагы Аю-көйдергән үзәнлегенә жыелуын белгәч, Мирхажи да тантанадан читтә кала алмады. Кайчандыр яп-яшь шәкерт булып, ун ел дәвамында остазыннан һич тә аерылмыйча йөри-йөри хәзер инде чем-кара сакал-мыек үстереп җибәргән тугры мөриде Ирмәшне дә, әлбәттә, үзе белән алды.

Ык буена житеп гажәеп киң үзәнлеккә кергәч, мөһажирләрнең икесе тиң тәмам хәйран калды. Үзәнлекнең як-яклары буенча зур бер божра хасил итеп тезелешкән ап-ак тирмәләрнең, чатырларның саны мең белән генә дә бетми, ахры. Ул гына да житмәгән, бәҗәнәкләр һәм кунаклар тәртәләре югарыга күтәртеп бәйләнгән арбаларны бер-берсенә терәтә-терәтә тезеп хәрби ыстанга биргесез божра ясаганнар. Зур түгәрәк эчендә, һәр тирмә каршысына диярлек казаннар асылган. Шул казаннар тирәсендә чәч толымнарына көмеш таңкәләр, күкрәкләренә хәситә, билләренә чәчәкле-бизәкле алъяпкычлар бәйләгән киленнәр, кыз-кыркын, шулар белән рәттән үк чыр-чу килеп йөгерүче йөзләгән бала-чага кайнаша. Әллә ничә урында тирмә каршына чыгып хәтфә үләнгә тезләнгән чәчәннәр кубыз йә чән чиртә. Шулар сузган кобайыр авазлары, талгын гына пыскып ятучы учаклардан күтәрелгән сыек-зәңгәр төтен божралары шикелле үк, үзәнлек өстенә кабат кайта-кайта уйнаклый. Учак һәм арбалар тирәсендә ирләр бик күренми. Алар янәшәдәге дүрт-биш тирмәнең арадан зуррагына жыелып утырганнар да, сөжү яки кымыз сөзә-сөзә бәхәс куерталар.

Жыручы бер карт янына тукталгач, Мирхажи үзәнлек атамасы турында сорамый түзмәде.

—Һи-и, борадәр, ошбу атаманың хикмәте бар аның,—дип, жыручы карт, сайрар алдыннан канатларын төзәткәләгән кош шикелле мыек чылгыйларын сыпыра-сыпыра, тәмләп тезеп китте.—Элгәре заманнарда ошбу тарафларны күптин-күп урманнар хасил иткән. Искил атлы ыру бабаларымыз ошбу эргәгә иңгәннәр дә, йөзәр еллык имән илә карагайларны аударып, ышна арчыганнар. Ык тирәсендә сачәк-үлән бихисап булганга күрә умарта оялары да корып җибәргәннәр. Мәгәр боларның умарталыгына бер әрсез аю ияләшкән дә, тегеләргә тынгы бирмәгән генә бит. Килә дә умарталарын жимереп, балларын гел сосып китә икән. Бигеш атлы бик зиһенле бер карт шуннан ары ошбу әрсезгә мондый тозак корган. Тоткан да, бер умарта оясын тоташ балга буяп, салам кибәне эченә яшергән бу. Асылда да берзаманны аю килеп житкән, кибәнне актарып оя янына кергән. Шул чагында моны сагалап торган инсаннар кибәнгә ут элгәннәр. Бөтен йоны өтәләнеп-көеп беткән аю, мотлакадыр, ду китереп улап урманына качкан. Шуннан ары ошбу тарафта бер дә күренмәгән. Шушы вакыйгага нисбәтән ошбу үзәнлеккә «Аю-көйдергән» дигән исем ябышып калган да инде, менәтерәк...

—Чаптарлар бәйгесе башлана!—дигән хәбәр ишетелүгә үк ир-ат белән бала-чаганың күбесе халык телендә «Дәрвиш ермагы» дип атап йөртелгән инеш яры буенча тезелеп басты. Ир-атлар бар дөньясын онытып, сызгыра-әйдәкли, бәйге барышын күзәтте. Мәйдан эчендә исә иннәренә көянтә аскан киленнәр, авызларына йомыркалы кашык капкан малайлар йөгерешә, бер як читтәрәк чиратка тезелеп баскан егетләр шома баганага менәргә азаплана, икенче бер башта мәргәннәр алышы бара һәм, ин кызыгы—кыл уртада билләренә чуклы сөлге салган әзмәвердәй таза-таза

ирләр көч сынаша иде. Берсе утлы күмер эчендә пешкән бодай сыман кара-чутыр тәнле, икенчесе гөбе шикелле тәбәнәк һәм юан билле көрәшчеләрнең бил алышын карый-карый Мирхажины да комар сарып алды.

—«Юан корсак» ияреп кенә йөри. Аягында хәл юк, әйләндереп капла!—дип, һәвәсләнеп кычкырып куюдан да тартынмады ул.

Ләкин якын-тирәдә «Юан корсак» өчен жан атучылар да байтак кына икән, бер-икесе шундук аваз салды.

—Казан кызмый торып аш та пешми, куалама, мөһажир. Кәндел бөтен Чалмат аймагында батыр калган инсан. Анын билен алырдай пәһлеваннар бөтен Болгар мәмләкәтендә дә бик сирәктер.

Әлбәттә, кара-чутыр көрәшчене яклап чыгучылар да тиз табылды.

—Һе, әйтеп тә куясыз инде үзегез, борадәрләр. Ана китсә, «Бакыр» Зыя да арба мүчәсеннән төшеп калган кендек түгел инде. Аны алышта чалкан ыргытырдай бәдәнлеләр безнен Тәмтүбәдә гел дә юктыр.

Кәндел белән Бакыр Зыя мәйдан уртасында озак таптандылар. Кәнделнең аякларында, чыннан да, ныклык, куәт дигәннәре бик чамалы иде, күрәсең. Зыя суырып ала башлаган һәрбер алым саен Кәндел әле табаннары белән яшел үлән өстендә шуышып йөрде, әле көндәшенен күкрәгеннән качып читкә аву-янтаюны кулайрак саный башлады. Анын хәйләгә керешүен яндагылар да сизеп өлгерде, берничә тарафта ачулы аваз купты.

—Тавыклар кымтырыкларга да рәте калмаган йолкыш әтәч кеби качып йөрмә инде, житте сина!

—Әй, син, Кәндел! Бер тапкыр бил тартырдай гайрәтен дә юк икән, нәжес салган капчык сыман торма, сөлгенне ташла да ычкын!

—Үзегезне Бүзбикә чыгып урганчы сез алышны төгәлләгез, әйдә. «Бүзбикә» дигән атны ишетү үк Мирхажины аптырашка салды. Әмма әлеге исем мәйдан уртасындагы көрәшчеләргә дә чыбыркы сыманрак барып төште, ахры. Мона кадәр иренеп, үшән кыяфәттә генә бил алышкан ирләр йөгерә-сикерә йөри башладылар. Ул да түгел, Бакыр Зыя күз ачып йомарлык бер арада Кәндәлне баш-аркан әйләндереп тә атты. Икенче мизгелдә үк түгәрәктәге халык сузып-сузып чакыруга күчте:

—Бүз-би-кә! Бүз-би-кә!

Түгәрәк уртасында карап торышка егерме-егерме биш яшьлек, озын буйлы, таза бәдәнле бер кыз пәйда булгач, Мирхажи аптырашта калды.

—Әстәгъфирулла, нинди галәмәт бу? Сездә ирләр илә хатыннар да бил алышамыни?—дип, сөйләнүен күршедәгеләр, әйтерсен лә, бөтенләй ишетмәде. Ирләр, бала-чага, кыз-кыркын сузып-сузып алкышлавын белде.

—Бүз-би-кә! Бүз-би-кә!

Озак көттереп тормады, чирәмдә яткан сөлгене кулына алды да, беркадәр тарткалап-бөтергәләп торгач, Бүзбикә аны көндәшенен биленә салды. Әле бер, әле икенче якка авыша-авыша, Бүзбикә белән Бакыр Зыя мәйдан буйлап таптана, әвәрә килә башлады. Мирхажи әле һаман үз күзләренә үзе ышанмый, бу алышны ул Чалмат, Тәмтүбә, бәжәнәкләрнең сәер бер йоласы шикелле генә кабул итә иде. Ләкин инде көндәшләрнең гыжлый-гыжлый сөлге тарткалавын, бигрәк тә Бакыр Зыянын Бүзбикәне күкрәк өстенә суыра башлавын күргәч, Мирхажи кайнар су бөркегән шикелле куырылып калды.

—Кит инде, әкәмәт, шулай ярыймыни? Акыллы һичбер адәм мантыйк күрмәс нинди хилафлык бу?—дип, сөйләнә-сөйләнә Мирхажи түгәрәк уртасына чыгарга омтылса да, күршедәге ирләр терсәкләрен куеп ана юлны бүлде.

—Тик кенә тор, кунак. Узган ел Бүзбикә ошбу Бакырга оттырып киткән иде. Быел, менә, Бүзбикәгә жинү яулау өчен бик тә унай форсат.

Бу вакытта мәйдан уртасындагы Бүзбикә башын әүвәл көндәшенен култык астына тыкты да, кинәт нык талпынып, Бакыр Зыяны зур маһирлык белән үзенен күкрәкләре өстенә суырып алды. Менә, ир-ат

пәһлеванның аяклары җирдән аерылды, Бүзбикә яман кычкыра-кычкыра артка чигенә башлады. Тагын бер мизгел үтәр һәм Бүзбикә инде Бакыр Зыяны баш аркылы күтәреп атар кебек иде. Әмма шул мизгелдә Бүзбикә әллә үзе абынды инде, әллә көндәше сиздермәстән аяк чалып-фәлән өлгерде. Көтмәгәндә Бүзбикә чалкан ауды, ә Бакыр Зыя гөрселдәп кыз баланың күкрәкләре өстенә барып төште. Мәйданга «ы-ы-э-эһ» иткән аваз яңгырады, Бүзбикәне кызганудан байтак ирләр карашын читкә борды. Көрәшне күзәтеп торучы казыйларда гына ниндидер кичереш тойгылары һич тә чагылмады, алар үз вазифаларын башкаруны белде.

—Бер якка да өстенлек бирү юк, сөлгеләрне янә билгә салышыгыз.

Казыйлардагы мондый мәнсезлекне күреп, Мирхаҗи мәйдан уртасына атылып чыкмакчы булды.

—Алышны туктатыгыз! Шәригатькә сыймас язык гамәл, хилафлык ләбаса бу!

Ул үз юлында очраган терсәкләрне төрткәли-төрткәли, түгәрәкне ерырга чамаласа да, тирә-юньдәгеләр аңа ирек бирмәде. Ул гына да түгел, терсәкләренә катырак эләккән ике ир-ат, чапан изүеннән чорнап, Мирхаҗины түгәрәк тышына ук чыгарып атты. Йодрык төйнәгән берсе яман ажгырып, Мирхаҗи өстенә килә башлаган иде дә, артта Ирмәш тарафыннан яңгыраган сүзләр аны шып туктатты.

—Гөнаһа алудан куркыгыз, мөселманнар. Сез Мөхәммәт пәйгамбәр сөләләсыннан туган Мирхаҗи хәзрәтне, шәриф сәет Давыт углын рәнҗетәсез ләбаса!

Кызу канлы ирләр, гафу үтенә-үтенә, тиз арада күздән югалды. Мирхаҗи үзе тагын ни кылырга белми тора иде. Шулвакытны күк күкрәгән төсле тавыш чыгарып мәйдан телгә килде.

—Бүзбикә, Бүзбикә! Афәрин, мәрхәбә!

## 2

Ык ярында узган әлеге алыш Мирхаҗи күрәчәк сәер хәлләрнең башы гына булган икән әле.

Аның кайчандыр бөтен Болгар илендә абруй һәм шөһрәт казанган Давыт сәет углы икәнлеген белгәч, Тәмтүбә аймагының башлыгы Кормаш би Мирхаҗины кунакка дәшеп алды. Кормаш бинең егерме дүрт киргәле ак тирмәсе Дәрвиш ермагына терәлеп үк утыра, хуҗа исә Ык буена Сабантуена килгән барча аймак һәм ыру башлыкларын бәхәс белән сый тулы учак җылысы янына җыеп алган икән.

Мирхаҗи тирмәгә ингәндә Кормаш би табынның иң түренә кунаклаган иде. Аның янында сәйлән бөртекләре белән бизәп чигелгән калфаклы Бүзбикәне күргәч, Мирхаҗи югалыбрак калды. Моны табын хуҗасы үзе дә тоеп алды, ахры, көлемсери төшеп аңлатуга күчте.

—Катыннарым өчәү булса да, мине берсе дә углан китереп сөендермәде бит, хәзрәт. Апара әчеткечем үтә зәгыйфь булгандыр инде, каһәр.— Табындагы барча кунак тыенкы гына көлемсерәп куйды.—Аның каравы, менә, Бүзбикә кызкаем һичбер тарафта тыю-киртә күрмәенчә, ир-ат кавеменә биргесез булып үсте...

Бүгенге чаптарлар һәм көрәш бәйгеләрен искә ала-ала байтак кына вакыт утырдылар. Сый-нигъмәткә, чәйгә үрелгәндә Мирхаҗи әледәнәле Кормаш би ягына күз сала һәм Бүзбикәнең дә бик еш кына үзенә төбәлеп утыруын сизенә иде. Әмма карашлары очрашудан шүрләп Мирхаҗи күп чакларда үзалдына йомылып утырырга мәҗбүр булды.

Кояш шәфәкъ сызыгына авышкан бер вакытта тирмә тышында кыз-кыркын, егет-җилкенчәк җим күтәреп чыккан хуҗаны күргәч җанланып сөенүче тавык-каз өере сыман, чыр-чу килеп көлешкән тавыш ишетелде. Бераздан инде аңа су чәчрәткән, инеш чупылдаган авазлар да кушылды. Соңарудан курыккан шикелле җитез хәрәкәтләнеп, Кормаш

би кунакларны саф һавага дәште.

—Безнекеләр инештә су коена булыр. Әйдәгез, кунаклар ошбу изге йоламызга бер күз салыйк әле.

Башкалар белән бергә кузгалып тирмә тышына чыккач Мирхажи кайнар энә йоткан кеше сыман тынсыз калды. Дәрвиш ермагының ике яры тиң тамаша кылырга жыелышкан халык белән тулы, ә инештә исә яшь-жилкәнчәк, кыз-кыркын, егет-жилән анадан тума килеш су коена иде...

—Әстәгъфирулла, язык, гөнаһ!—дип пышылдый-пышылдый Мирхажи күзләрен чытырдатып йомса да, яхшы таныш тавыш аны тиз арада жиһанга кайтырга мәжбүр итте.

—Бар, ахирәтләрең илә син дә коенып чык, кызым.

Мирхажи шүрли-курка гына керфекләрен ачты һәм йөзе учакта пешкән кысла шикелле кызарып-янып чыкты. Инеш ярында Бүзбикә кыенсыну-тарсынуны белмичә өстендәге киемнәрен салып тора иде. Менә ул көмеш тәнкәләр белән бизәлгән матур хәситәсен, чигүле кин күлмәген, аның эчендәге ак итәген салып ташлады. Яр өстендә калын толымнарын инбашларына таратып салган тыгыз, мул күкрәле, озын, таза ботлы, шома, ал гәүдәле алиһә хасил булды. Сихри фәрештәләргә тиң әлеге сылу йомры имчәкләрен ике кулы белән каплаган хәлдә бераз гына вакыт торды да, колын сыман уйнап-сикергәләп инеш суына чумды. Ә Мирхажиның инде әлеге манзараны ташлап киту түгел, бал өстенә килеп кунган бичара чебенгә охшап аяк кыймылдатырлык та куәте юк һәм, иң сәере, хәзрәткә бу халәт ләззәт китерә иде...

Алар бер-ике айдан соң, тәмтүбәләләр үз аймакларына кайтып Зәй елгасы буенда яши башлагач кына, йөзгә-йөз килеп очраштылар. Анда да әле тәүге адымны ясаучы тәвәккәл жан иясе һаман да шул Бүзбикә сылу булды.

Ул чакны Кормаш би үзенең яраннарын, туган-тумачасын Кичү елгасы буена ауга дәшкән иде. Аерылгысыз Ирмәшне үзе белән алып Мирхажи да ерак юлга чыкты. Наратлы тау буендагы инкүлеккә житкәч, тәмтүбәләләр дистәгә якын тирмә корып урнашты. Кормаш би һәртөн ирләрне каравылга билгеләп кенә калмады, күз-колак булыр өчен Урсала, Куаклы, Каратай елгалары ягына да ертауллар куды. Әрәмтамак булып ятудан тарсынып, Мирхажи да әнә шул ертаул чапкыннары белән бергә Каратай буена, тирә-якны күзалларга китте.

Жир өстенә инде күптән карангылык иңгән, алар исә Акташлы чишмә буена житеп килә иде. Берзаманны ертаул нөгәре артында, алардан беркадәр калышып юыртучы ялгыз жайдак пәйда булды. Ертаул башлыгы Вәжи мәргән аны күреп чапкыннарны тыйган иде дә, ялгыз жайдак уңъякка каерылып, Артышлы тау өстенә менеп китте, якынаюны кирәк санамады. Мәһабәт, мәгърур чыршы, нарат, карагай өсләрендә елгыр тиен сыман сикергәләп йөзгән түгәрәк ай яктысында ул, әкиятләрдән калыккан гажәеп олы гәүдәле пәһлеванга охшап, озак вакыт буе тау сыртында хәрәкәтсез торды. Мондый билгесезлек ертаулардан бигрәк чабышкы атларның үзәгенә үтте, күрәсең. Урынында усал таптангалап, тау сыртындагы әкияти аргамак аваз салды.

—Иһ-һа-һа-һа!

Аңа жавап итеп ертауллар ияре астындагы чаптарлар да әүвәл тоякларын жиргә бәреп алды, аннары инкүлекне ат кешнәгән аваз күмеп китте. Ул тынуга ертаул башлыгы Вәжи мәргән көлемсерәп кенә кул селтәде.

—Әһ-һә, аңлашылды. Ошбу айгыр таныш, Буран ләбаса ул.

Аннары инде Вәжи мәргән шактый сәер итеп Мирхажига дәште:

—Мирхажи хәзрәт! Бар, тау башына чап та, ул жайдакны монда чакыр әле.

Юлга чыкканнан соң үзенә дә шәхси йомыш табылуга канатланып, Мирхажи тау ягына очты. Әмма тау сыртына менеп житсә, анда жайдак

күренми, һаман да шул әкияттәге пәһлеван сымак юкка чыккан иде. Мирхаҗи сыртның әле бер, әле икенче ягына төшеп карады, тау битендә ялгыз җайдак барыбер күренмәде. Балтасы елгага төшкән бичара шикелле, хәзрәт аптыраудан инде атның тезгеннәрен дә ычкындырган иде, Туры бия үзе аны артыш куакларына таба алып китте.

Куаклыкка җитәргә нибары бер дилбегә озынлыгы гына ара калган иде. Шулвакытны кинәт һаваны йомран сызгыруына охшаш тавыш кисеп үтте дә, Мирхаҗиның инбашларын кылдан үргән аркан чорнап алды. Җайдактан бигрәк ат өректе, ахры. Ул яман пошкырып тау битеннән югарыга таба сикерде, хәзрәт эреле-ваклы чуерташ белән аралашкан куе үлән өстенә мәтәлеп төште. Сырты, баш чүмече белән җиргә бәрелүдән сыны каткан иде, берникадәр ара тынсыз калып, кузгала алмый ятты. Шулчагында аның каршына серле шәүлә килеп тезләнде, кайнар, гаҗизләнгән тавыш ишетелде:

—Имгәтеп-мазар куймадыммы сине, Мирхаҗи? Эх, мин, тинтәк!

Мирхаҗи инде каршына килеп тезләнгән шәүлә иясенең кем булуын чамалаган иде, шулай да юри тын белдерми ятты. Шәүлә иясе исә тәмам еламсырауга күчеп, аның күкрәге өстенә капланды, назлы сүзләр тезде:

—Зинһар, күзеңне ач инде, бәгърем, җаныкаем?! Ык буенда күргәннән бирле йокысыз калдырдың бит. Сиңа зыян-зәүрәт китергән булсам, аннан ничек яшим?

Шәүлә иясе хәзрәтнең керфекләрен, яңакларын ук үбә башлаган иде дә, үзенең бер як читкә әйләнеп төшүен сизмичәрәк калды. Икенче мизгелдә исә инде кимсетелгән җайдак аны кысып кочаклады, кайнар, сусыл иреннәр төнге чәчәк таҗларына охшап бергә кушылдылар. Моңа кадәр күбекләнгән су өсте кебек болытлы күк йөзендә чалкан ятып гамьсез генә йөзгән дуадак ай да мондый талымлы-әрсез гыйшык учагына шаһитлектән читенсенде бугай. Ул да Каратай елгасы буйлап яр өстендә инеш каядыр качмасын өчен сакка куелган каравылчылар сыман тезелеп утырган биек, төз наратлар гаскәре артына чумып, тиздән юкка чыкты...

Зәй буендагы кышлауга әйләнеп кайткач та, шаулатып-гөрләтеп, Мирхаҗи белән Бүзбикәнең туен үткәрделәр. Кормаш би йортына кунаклар күп җыелган, сый-тантана мәңге йомгакланмас кебек тоела иде. Көтмәгәндә Ибраһим ханнан шәхсән Мирхаҗига атап җибәрелгән фәрман килеп төште. Ул кияү егетенең үзенә генә түгел, Кормаш би йортына да абруй китерә иде, шуңа күрә аны барча кунаклар каршында кычкырып укыдылар.

—Синең башкорт кавемнәре эргәсендә кылган бөтен гамәлләрең хакында яхшы хәбәрдармыз. Вәли сәет угылы булган олуг затка үзенең исемен мәмләкәт иминлеге бәрабәренә кылган зуррак эшләр илә бизәргә дә вакыт. Чулман дәрьясы буйлап төшүче кяфер ушкуйлары мәмләкәтемезгә һичбер тынгы бирми. Без Мәләкәс илә Чулман кушылган төштә, биек тау сыртында яңа кирмән төзергә карар кылдык. Ошбу мактаулы вә җаваплы вазифаны, Давыт, Сәет углы, сиңа тапшырамыз. Тәмтез, Чалмат, Тәмтүбә аймакларындагы мигъмарларны җый да, шушы эшкә кереш. Ул төбәктәге ярлар ак ташларга бай булу нисбәтеннән яңа кирмәннең исемен «Чаллыяр» дип тәгаенләрмез. Амин...

Шаулы туйдан соң тәгәл тугыз ай үткәч, Тәмтүбәдән Чаллыярга чапкын килеп җитте. Имән, карагай агачларыннан өелгән биек-биек буралар тирәсендә кайнашып йөргән Мирхаҗига төбәп әйтелгән хәбәре кыска, анык иде.

—Бүзбикә хатының таза олан тапты. Синең малаең бар. Сөен, хәзрәт...

Очынып-очынып Тәмтүбәгә кайткан Мирхаҗи терсәк буе гына малаен күккә чөя-чөя горурланып дәште.

—Мәңге үлем белмәс Мөхәммәтгаләйһиссәлам сөләласыннан бит ул. Аның исемен дә Мөхәммәтгали кушам. Угылым да үзенең исемен гасырлар буена онытылмас олуг гамәлләр илә бизәп калдырмасмы?..

Җиһанга инде мең бер йөз дә җитмеш икенче елның язы кергән иде.

## 3

Мирхажиның Бүзбикәне һәм Мөхәммәтгалине алып кайтуына җиде-сигез ай да узмагандыр, Чаллыярга җан өшеткеч хәбәр килеп иреште:

Чулман буйлап Болгар мәмләкәтенә таба урыс алайлары төшеп килә. Көймәдәге укчылар илә яр өстенә тезелгән җайдаклар саны җиде меңләп булыр. Башлыклары Вулдәмир кенәзе Әндринен углы Мстислав, ди. Аның артыннан ук Муром илә Рәзән кенәзләре дә үз чирүләрен алып килә икән.

Мәләкәс тамагы янындагы тауга җыелган халык ел дәвамы диярлек ал һәм ялны белми эшләсә дә, яна кирмәннең диварлары тулысынча төзеп бетерелмәгән иде әле. Шуңа күрә рус кенәзләренең яна явы турындагы хәбәрне ишеткәч тә, Мирхажи хәзрәт пошаманга төште, йөзе язгы кояш астындагы боз шикелле зәңгәрләнеп чыкты. Әле ярый Чалмат, Тәмтүбәдән нөгәр башлыклары булып килгән Адай оста белән ташчы Мөхтәр яуга әзерлекне үз өсләренә алды. Шулар ике көн дигәндә тирән чокыр казытып, шуның эченә кабыгы да салдырылмаган карагай бүрәнәләрен утыртып өлгерделәр.

Ләкин иркенне иртә таңда пәйда булган рус гаскәре Чаллыярны тулгамага алып маташмады, кенәзләр җайдакларны да яуга ташламады. Йөзен сирәк кенә сакал төкләре каплаган Мстислав әмере буенча каеклардагы барча сугышчылар кирмән өстенә башакларына ут һәм сүс элгән ук яңгыры очыра башлады. Ике-өч минуттан соң кирмәннең дистәләгән урынында янгын купты. Тәмтүбә ягыннан уйнаклап-уйнаклап усал җил исә, ә кирмән эчендә утка каршы көрәшергә коралы һәм суы да юк иде. Шунлыктан Чаллыярны тиз арада ташкынга тиң янгын чорнап алды. Кирмән эчен йөзәрләгән кешеләрнең тәшвишкә бирелеп, ачыргаланып кычкырган тавышы каплап китте. Шулай да, башларына ис тигән кешеләр шикелле әрле-бирле сугылып йөгерә торгач, Адай оста белән ташчы Мөхтәр тәшвиш авазларын бик тиз бастырдылар. Соңыннан кирмән диварлары буенда шул ике башлыкның эшлекле фәрманнары гына яңгырап торды.

—Орыш кораллары булган ирләр! Ике төркемгә бүленегез дә, шәрекъ капкасының як-ягына килеп тезелегез. Күперне төшерүгә үк, кирмән тышына чыгып, ике яклап яуга ташланыгыз.

—Орыш башлангач та, мөгаен, күпер каршында бушлык хасил булыр. Калган барча инсан шул мәйдан аша Мәләкәс ярына таба ашыгыч төстә чыксын. Аннары ике нөгәр, сыртымызны каплап, безнең эздән чигенер.

Сөңге, кылыч, җәя тоткан ирләр суярга дип сузып салганнан соң да тышауларын өзеп аягүрә баскан ярсу үгез сыман гайрәтләнеп тышка ыргылды. Рус җайдаклары чаллыярлыларның һөҗүмен көтми иде, байтак вакыт буе каршылыксыз-нисез күзәттеләр. Ул арада инде утлы кирмән эченнән карт-коры, хатын-кыз, бала-чага да чыгып өлгерде. Ике яктан уратып алган яугирләр ышыгында чаллыярлылар Мәләкәс яры буйлап чигенә башлады. Фәкать шулчагында гына рус җайдакларының икеме-өчме алае хәрәкәткә килде. Болар әле үзләрен яуда сынамаган Муром һәм Рязань җайдаклары иде, күрәсең. Алар рәхим-шәфкать күрсәтмичә болгарларны кылычлары белән телгәли башлады...

Сабый баласын күкрәгенә кысkан Мирхажи белән Бүзбикә ияргән төркем пайтәхеткә илтүче юл буенча качты. Ләкин артта әле яман сүгенеп дәшкән, әле ачыргаланып кычкырган тавышлар аермачык булып ишетелә, качакларның ашыкмыйча чарасы юк иде. Сулулары капкан, шабыр тиргә баткан чаллыярлылар чит-читләрен юка боз элпәсе каплаган киң инеш ярына килеп төртелгәнче шулай йөгерделәр. Яр читендә сал йә көймә түгел, сынар такта да юк, качаклар гаҗизлектән инде тәмам җебеп төшкән иде. Килгән юлдан тояк тавышлары тагын да яңгырабрак ишетелә башлагач качаклар да каударлана төште. Хәзер ни кылырга икәне һәркем

өчен анык билгеле булса да, Мирхажи хәзрәт куәт биреп берничә сүз катты.

—Өстегезгә дошман килгәндә вә һәммәбезгә үлем хафасы янаганда юк-бар гөнаһы хакында уйлап торып булмый. Өстемездәге киемнәрне салып төйнәгез дә суга сикерегез. Ошбу катилләрдән исән-имин котылсак, теге ярда учак ягып янә җылынырмыз.

Сабыен инбашына күтәргән Мирхажи инеш суына таба атлаган гына иде, аның каршына Бүзбикә килеп басты. Карашы үткер, кыю, ә сүзләре гүя йөрәгеннән суырылып чыкты.

—Баланы бир. Теге якка Галиемне үзем күтәреп чыгам.—Мирхаҗиның сәерсенеп төбәлүе кыенсытты, ахры, Бүзбикә елмая төшеп өстәде.— Янәшәдә хатын-кыз да, бала-чага да бихисап. Аларга ярдәм кирәк булуы ихтимал.

Инеш әлләни тирән түгел, ул Мирхаҗиның муеныннан артмый, әмма салкынлыгы тәннәрне өтеп-куырып ала, чымырдата иде. Еламсыраган, өшәнгән сабыйларны күтәреп йөзә-йөзә Мирхажи инештә байтак чияләнде. Каршы якка чыгып сабыен яр өстенә салган Бүзбикә дә читтән генә күзәтеп торуны яхшысынмады, күрәсең, ике яр арасында әрле-бирле йөзеп бәргәләнгән кешеләргә ярдәмгә ашыкты. Алар яр өстенә икесе дә иң соңгы кешеләр булып чыгып егылдылар.

Качаклар яр өстендәге куе куаклыклар эченә кереп качкач, баскынчылар инеш аша үтеп маташмады. Шулай да сакалбайларның яман сүгенгән, әче сызгырган тавышлары байтак вакыт буе яңгырап торды. Качаклар ябагасын яртылаш койган ат шикелле таланган, шәрәләнгән урман уртасында һаман учак яга алмыйча, тешне-тешкә бәреп интектеләр.

Төн житә башлаганда Бүзбикәнең тәнен, әйтерсең лә, ялкын чорнап алды. Анын маңгаена, беләкләренә кул тидерешле түгел, яп-яшь, таза хатын ут шикелле яна, калтырана иде. Таң атканда ул инде аңын ук җуйды, күзләре ачык көенчә саташа да башлады.

—Гали, Гали балакаем, әйдә инде минем җырны сузыйк. «Зөләйхамыз Йосыфка хуш зиннәт бирде, үз кулыннан Йосыфның ул чәчен үрде»... Мирхажи, их, Мирхажи жаным!.. Галине мин яраттым бит, аны мина китер...

Ике тәүлек буе шулай интекте дә, караңгы төн кереп килгәндә Бүзбикә мәңгелеккә тынды. Икенче көнне аны инеш суында юып ярда җирләделәр. Мирхажи өч көн, өч төн буена бер дә купмыйча кабер янында ялгыз утырып чыкты. Чаллыярлылар килеп жирдән аерганда анын инде бөтен чәче ап-ак, ә тәнендә исә кыл кыймылдатырлык та егәре юк иде.

Качаклар якындагы бер авылдан яллаган арба өстендә ауный-ауный Мирхажи пайтәхеткә кадәр ике атна барды. Биләргә керүгә үк ул ил башлыгы турында белешкән иде дә, аны, чирү туплап, шәхсән үзе урыс сакалбайларына каршы чыккан, диделәр. Мирхажи шуннан соң «Мөхәммәт-Бакырыя» атлы гыйлем йортының дәрвишләр бүлмәсенә бикләнеп, бер чит-ятның да күзенә күренмичә, җиһан белән алыш-бирешен өзгән хаста кыяфәтендә айга якын ятты.

Ерак походтан кайтып төшкәннән соң, Ибраһим хан аны үзе эзләтеп алды. Ул инде Мирхаҗиның кайгы-хәсрәте белән хәбәрдар иде, боргаланып-фәлән маташмады.

—Үлгән артыннан үлеп булмый, борадәр. Син сазлыкта үскән, үзәге черек усак түгелсең бит. Якуб казый, Давыт сәет кебек данлы нәселне дәвам итүче хәзрәт буласындыр. Бәс, бирешмә, нык тор. Гали угланың өчен дә юкка башың ватма. Илдә чыпчык үлми, Аллаһы боерса, аякка бастырырмыз. Чаллыяр кирмәне хакында да берүк хафаланма. Мәмләкәтемез эчендә колчура да, урманнар да чиксез. Ул кирмәнне янә тергезермез.

Ибраһим телендә «колчура» сүзе яна тәгъбир иде, Мирхажи сагаебрак калды. Гомумән, кичәге әмир белән бүгенге таждар арасында да Мирхажи

байтак кына аерма тоеп алды, шуна һаман дәшми утыра бирде. Ә Ибраһим хан аны янә яна сүзе белән хәйран итте.

—Мин сине бөтен Болгар мәмләкәтенең олуг сәете итеп тәгаенлим, тәкъсир. Моннан ары мәгыйшәтнен вак-төяк хафаларын онытырсың, шаять. Шәригатемезнен шәриф кануннарын мәмләкәтнен барча почмакларына житкерү, бар халыкны ханга вә пайтәхеткә тугры жанлы итү синең бурычың булыр.

Мирхажи бу юлы да башын иеп утырды, жавап кайтармады. Озак тынлыктан сон, Ибраһим янә телгә килде:

—Һи-и, ошбу ата-аналар! Сабыйларына карата мөгамәләдә берберенә бөтенләй капма-каршы да була ала икән. Синең Бүзбикән, менә, нарасыен коткарам, дип, үзе вафат булды. Ә Әнди, бирән, мал-зиннәт бәрабәренә угланын үлем бугазына үз ихтыяры илә озатып харап итте...

Мирхажи карашында кызыксыну уты кабынды. Ибраһим хан бәйнәбәйнә төшендерергә тырышты.

—Мстиславның Идел буйлап безнең карьяларны талый-талый кайтып китәргә ниятләвен шәйләгәч, мин Ашлы каласы эргәсендә тозак корып куйдым. Шунда Мстислав каекларының һәммәсенә дә ут элдек. Укчылары ярга чыга да алмыйча су астына китте. Шуннан соң Мстиславка бер генә юл—ар вә чирмеш урманнары аша качу гына калды. Мәгәр мин анда да кяферләрне Көпшәк елга ярына китереп кыстым. Үзең беләсең булыр, ошбу елга өсте кышын да юньләп катмый. Тулгамага алып төрле яктан чүки башлагач, сакалбайлар елганың бозлы суына чумарга мәжбүр булды. Мстиславның ярты чиреү шунда батып калды. Яшь кенәз үзе дә аргамагы илә елга өстенә сикерде. Әүвәл очлымы-ние илә су астына китеп күздән югалган иде. Мәгәр аргамагы бик шәп иде шул. Янә су өстенә калыкты. Иллә мәгәр тәкъдирдән котылмыш мөмкин түгел икән. Сәүбән мәргән очырган сәрпи ук аның беләгенә барып кадалды. Шул яра үлекли башлаган да, Мстислав өенә дә кайтып житәргә өлгермичә яман шешенеп, жан тәслим кылган.

—Менә сиңа тәкъдир,—дип, ниһаять, Мирхажи да берчак телгә килде.—Ул Әндри кенәз үзе болгар хатыны илә гомер сөрә бит. Хатыны аңа ничәмә-ничә углан китерде. Ә бирәнтамак Әндри Болгар мәмләкәте өстенә ике тапкыр килде, һәркайсында бер угланын яуда корбан итте. Йә, Ходаем! Ул Байгөл бикә шундый катил илә гомер эстәүгә ничекләр генә итеп түзә икән?..

*Ахыры киләсе санда.*

# ШИГЪРИЯТ



## Илдар Юзеев

### ЗАМАН ХИСЛӘРЕНӘ КАГЫЛАМ ДА

**Каләмемне таң нурына манып...**

**Әгерҗенең төнге урманында**
**Ядкарь-истәлекләр алыштык.**
**Юмарт табигатьле Гариф Ахун**
**Бүләк итте миңа галстук.**
**Төннең үткәнен дә сизми калдык,**
**Нуры төште йөзгә ал таңның.**
**Ал галстук таккан, учак яккан**
**Балачакка мине кайтардың.**
**Зыялылар өчен, Гариф туган,**
**Чорлар һаман авыр булдылар.**
**Әтиемне, допрос алган чакта,**
**Галстугы белән будылар.**
**Син дә кайчагында боегасың,**
**Әйтмәсәң дә, Гариф, беләм бит:**
**Яра булып калган йөрәгеңдә**
**Бандит дучар иткән ятимлек.**
**Сулыш алулары авырая,**
**Төшкә генә керә иркенлек,—**
**Зыялылар түгел, галстуклы**
**Зыянлылар итсә өстенлек.**
**Муеннарны кайчак бушаттылар,**
**Кайчагында каты кыстылар,**
**Килер еллар гүзәл булыр дигән**
**Зур хыяллар җилгә очтылар.**
**Их, чабасы килә ап-ак кардан**
**Галстукны ташлап җилләргә!**

Балачагын бигрәк сагынган дип,
Сүз әйтмәсләр бездәй җүләргә.
Иркенлек тә киңлек... Рәхәт монда...
Саф һавада җиңел тын алдык.
Күпме генә безне бусалар да,
Буылмадык, бик күп сыналдык.
Якты сагыш белән сагынырбыз
Кышкы карурманның ак карын.
Каләмемне таң нурына манып
Язган җырым булсын ядкарем...

*1999, март. Әгерҗе.*

## Урта Кирмән

Кемнәр киткән,
Кемнәр килгән?
Әйтче миңа,
Урта Кирмән?
Тауда—Кирмән,
Тауда—кала.
Кала тавы
Яуда кала.
Урта Кирмән,
Урта Кирмән,
Ирек өчен
Утка кергән.
Урта Кирмән
Башын игән:
Боз да күргән,
Ут та күргән.
Болгар бабам,
Болгар бабам,
Калатауда
Янган бабам,
Көл булса да
Югарыда,
Биек тауда
Калган бабам.
Алар өстә,
Һаман тауда,
Ә без шулай
Ник түбәндә?
Ни әйтергә
Тели икән:
Козгын оча
Баш түбәмдә?
Түгел микән
Омтылышлар—
Бик түбәндә,
Бик түбәндә?

*22 май 1998. Урта Кирмән.*

Җилкәбездә—авыр йөкләр,
Ат та булдык без.
Һаман алга китәлмәдек—
Артта булдык без.
Әтәч булып бар дөньяга
Тавыш чыгардык:
«Бездә—көч,—дип,—бүрек белән
Бәреп егарлык!»
Усалланып та карадык
Ел башларында.
Зәһәрлектә узып киттек
Юлбарысын да.
Маймыл, дуңгыз, елан булдык,
Булдык үгез дә:
Дөньяны тоттык куркытып
Ике мөгездә.
Менә быел мескен куян
Булып уяндык.

Бездә—курку, бездә—шөбһә
Миллион куянлык!
Мөмкинлекләр кечкенә дә...
Хыяллар—олы!
Килерме безгә, ниһаять,
Адәмнәр елы?!

*1998, декабрь.*

❊

Өзгәләнә каен көзге җилдә—
Туган туфрагында ят сыман.
Гомере буе яшәп шушы җирдә
Үз кадере беткән карт сыман:
Атларга да инде хәл калмаган,
Абынып-сөрлегеп тә киткәли.
Тирә-якка моңсу караш ташлап,
Яфракларын җилдә сипкәли.
Тик бер өмет аны юатадыр:
Туфрагында ныклы тамырлар.
Саф орлыклар сибелеп җирдә калыр,
Язда кабат яфрак ярырлар...

*1999.*

❊

Өй алдында үскән карт аккаен
Гарасаттан мине яшергән.
Утны үзенә алып, әнкәм белән
Саклап калган мине яшеннән.
«Саклан, балам, яшен утларыннан»...
Хәтерлим мин әнкәм әйткәнне.
Тик мин генә каен булалмадым,
Саклап калалмадым әнкәмне.
Каен гомерләре бирәлмәдем,
Шул үкенеч кала гомеремдә.
Әнкәемнең тынычлыгын саклап,
Карт аккаен үсә кабердә.

## Гомерләрең уза, былбылкаем...

Ерак чит җирләрдә йөргән чакта,
Тәрәзәдән бер җыр ишеттем.
Тирбәлүен тойдым балачакта
Туган тел көйләгән бишекнең.
Өзелеп-өзелеп кош сайраган кебек...
Каян килгән изге бу җырым?
Нинди салкын җилләр чит илләргә
Какты сине, сеңелем-былбылым?
Аңладым мин: очып киткәнсеңдер
Чит җирдәге кошка пар булып.
Гомерләрең уза, былбылкаем,
Әнкәң моңнарына зар булып...

## Кал инде, кал...

Кал инде бер генә төнгә...
Шулай итәләрмени?
Сандугачлар килгән көнне
Ташлап китәләрмени?
Төне буе сайрар инде,
Йокламас сандугач та.
Калмассың микәнни инде,
Шул кадәр ялынгач та?
Сандугач өзәр үзәкне
Язның бу чакларында.
Кал инде, кал—бер генә төн
Кайнар кочакларымда.
Киткән сандугачлар кайта,
Яшьлек кайтмас бит инде.
Икебез дә үкенербез,
Югалтсак шушы төнне.
Кал инде, кал...

*1999*

Иркәләр дә, сылулар да бетмәс,
Туып тормаса да гел генә.
Башка Галиябану инде тумас—
Татарда ул бары бер генә.
Шушы таныш көйне җырлый-җырлый,
Мин дә «бүрәнәгә абынам»,
Заман хисләренә кагылам да,
Галиябану, Сезне сагынам.
Еллар узган саен сагындырыр
Мәхәббәткә тугры корбаннар.
Килде Исмәгыйльләр—киллер булып
Акча өчен ата торганнар...

*1998.*

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



## Гариф Ахунов

## КҮЗ НУРЫМ

ХАСТАХАНӘ КӨНДӘЛЕГЕ

### 1

Көз иде. Сонга калып килгән көз. Инде ноябрь башлары булса да, кар яумаган иде әле.

Мине «Шәһри Казан» гәзитенә чакырдылар.

Күктә йөзгән сәләмә болытларга күз төшергәләп, салкын юештән куырылып, сукрана-сукрана Декабристлар урамыннан барам. Әлеге гәзит, ирен чите белән елмаеп, төртмә сүзләрне мул сибә торган Хәлим Гайнуллин гәзите, нигә дип бу юеш һәм салкын көздә язучыларны азаплап йөртә икән? Аяз, кояшлырак көн беткәнмени?

Редакция яна бинага күчкән. Аңа эләгү өчен гәзит-журналлар нәшрияты бинасы янында узып, Декабристлар урамына аркылы яткан Чистай урамына керергә кирәк. Урамда күлләвек-күлләвек пычрак сулар җыелып тора. Өзлексез узып торган машиналар ул суларны сыек боламыкка әйләндергән.

Әнә шул күлләвекле урамның пычрак суларын ерып чыкканда, мин уң күземне томан каплаганын сиздем. Кульяулык белән сөртергә тотындым. Бер сөртәм—бетми, икенче... томан һаман шул килеш...

Редакциягә кергәч тә бетмәде томан, гәрчә Хәлим дус ирен чите белән елмаеп, ягымлы итеп каршы алса да! Баш мөхәррирнең зур якты бүлмәсенә гәзит хәбәрчеләре кереп тулган иде. Бер-беребезне бүлдерә-бүлдерә гәзитнең тиражын арттыру турында кайнар сөйләшүләр алып бардык. Аңа карап гәзитнең тиражы артмады, ә минә минем уң күз тоныкланганнан-тоныклана барды.

Мин бу хакта хатыным Шәһидәгә әйттем.

—Врачка барырга кирәк,—диде ул.

Үзебезнең участок табибына барып җиткәнче тагын икеме-өчме ай узып китте. Ә күз һаман тоныклана, күзнең нуры кача бара. Шәһидә түзмәде, язуымнан аерып, участок врачына мине үзе алып китте.

Участок табибәсе булып үтә дә таныш кешенең кызы эшли икән. Кабул итү бүлмәсенең ишегенә «Миляуша Харисовна Амирова» дип язылган иде.

—Нәрсә, оныттың мәллә? Харис Зәйнуллин турында «Без бит Арча яклары...» дигән китап яздың. Арча райкомының беренче секретаре...— Шәһидә минем аптырабрак калуымны искәргән иде.

—Ә нигә ул Әмирова?

—Димәк, кияүгә чыккан.

—Алай икә-ә-ән...—дидем мин һәм, ишек шакып, эчкә кереп киттем.

—Исәнмесез, Миләүшә Харисовна!

Әллә ишетте ул минем исәнләшкәнне, әллә юк. Зифа буйлы, житди-кырыс чырайлы, урта яшьләрдәге ханым бик җәелеп китми генә каршы алды. Шәһидә дә мина ияреп кергән иде. Ул кабинеттагы кырыс атмосфераны йомшарту өчен булса кирәк:

—Бу Гариф Ахунов була. Врачларга йөрергә яратмый. Сукырая башлагач, үзем житәкләп алып килдем әле,—диде.

Миләүшә Харисовнаның Шәһидә сүзләренә дә әлләни исе китмәде, һаман да чибәр йөзендә кырыслыгын саклаган хәлдә:

—Утырыгыз,—диде. Үзе дә минем каршыга—өстәл янына утырды. Башка бер сүз дәшмәстән, озак еллар җыелган «авыру тарихы»мны актарырга тотынды.

—Уһу! Сез бит, Ахунов, инде биш ел участок врачына күренмәгәнсез. Ничек инде шулай гамьсез булырга мөмкин?—диде дә, зур кара күзләрен тутырып миңа карады. Кашлары сызылып киткән матур, бите чиста һәм яшь, түшләре калку иде бу табибәнең.

Аңа җавап бирәсе урында, никтер, үзем сорау бирүне кирәк таптым:

—Әниегез Мәдһия ханым ни хәлдә? Әтиегез Харис Зиннәтуллович вафат булды бугай инде, әйеме?

Миләүшә Харисовна, сызылып киткән кара кашларын югары чөеп, зур кара күзләрен тагын да зуррак ачып, миңа төбәлде:

—Ә сез аларны каян беләсез?

—Минем бит сездә, Арчадагы өегездә кунакта булганым бар.

—?!..

—Мин бит—Арча егете—Гариф Ахунов булам. «Без бит—Арча яклары...» китабының төп герое—әтиегез Харис әфәнде бит...

—Шулаймыни-и-и?!—диде ул, гап-гади чынлыгына кайтып.—Ә бит монда «Гариф Ахунов» дип язмаганнар, «Гарифҗан Ахунжанович» дигәннәр. Аннары бит минем сезне күргәнем дә булмады.

—Әйе шул...—дидем мин, янә бер мәртәбә уңайсызланып.

Ул миңа бу юлы гади генә итеп:

—Йә, Гариф абый, нәрсәдән зарланасыз?—диде.

—Күзнең рәте китеп тора әле...

—Ике күзегез дәме?

—Юк, уңы гына.

—Яхшы,—диде ул.—Мин сезне күз врачына юллыйм. Ул ни әйтер, аннары карарбыз.

Бәхетебез бар икән, күз табибәсе иртәнге якта эшли булып чыкты. Күрер күзгә инде урта яшьләрдән узган, авырулар кабул итә-итә шомарып беткән, калыная төшкән марҗа мине, исәнләшер-исәнләшмәс, бер аппарат янына утыртты, маңгайны һәм иякне ниндидер тимер араталарга терәтеп, уң күзгә көлтәсе белән ут төшерде. Мин, чыдый алмыйча, күземне йомдым.

—Күзне йоммагыз,—диде. Озаклап карагач, әйтте:—Катаракта!

Икенче күзне дә карады.

—Катарактаның монысында да булуы мөмкин. Хәзергә ул әле башлангыч хәлендә генәдер, мөгаен.

—Рәхмәт. Уң күзгә операция ясатырга буламы инде?

Табибә ханым миңа якты зәңгәр күзләрен тутырып карады:

—Кулыгызны күздән бер ярты метрга сузып карагыз әле.

Мин суздым.

—Күренәме?

—Күренә.

—Бармакларыгыз дамы?

—Бармакларым да.

—Менә бармакларыгыз күренми башлагач, килерсез.

—Кайда ясыйлар операцияне?

—Бутлеров урамындагы клиникада.

—Мин хәзер нишләргә тиеш?

—Әгәр чыннан да операция ясатырга уйласагыз, физик эш белән шөгыльләнүдән туктагыз. Бигрәк тә җир казу, мебель этү кебек нәрсәләрдән. Алкогольле эчемлекләр белән дә мавыкмавыгыз хәерле...

—Ә повестем басылса?—дидем мин шаяртып.

Маржа апай мин көткәннән акыллырак булып чыкты.

—Икенең берсе инде: йә бәйрәм, йә күзнең исән булуы... Ә бит сез моннан биш ел элек બездә йөрәк белән дә ятып чыккансыз.

—Әйе шул.

—Анысы ничек булды?

—Өч көн рәттән бакчада кар күрәдем: түбәдән төшердем карны, юлларны ачтым, урамдагысын бакчага ташыдым һәм..хастаханәгә кереп яттым.

—Кыскасы, катарактагыз өлгерү белән килерсез.

Шуннан соң өч айлап вакыт узды. Мин, әлбәттә, әкрен генә яздым. Язмый тора алмадым, юкса эч пошудан үләр идем. Март азакларында Шәһидә мине житәкләп, янә күз табибәсенә алып китте. Шул ук табибә иде. Аппараты янына утыртып карагач, бер генә сүз әйтте:

—Өлгергән.

Аннары ул үзе янында йөгергәләп йөргән шәфкать туташына нинди кәгазьләр тутырасы икәнен әйтеп, өф итеп кенә киенгән яшь бер хатынны аппараты янына утыртып, аның белән чамасыз елмаеп сөйләшә башлады. Мин ул хатынның «начальство бичәсе» булуын анладым. Күз табибәсе—маржа апай—белән житәкче хатыны авызны авызга куеп сөйләшәләр, әйтерсең, бер урамда аунап үскән ахирәтләр...

Күңел болгаткыч ул күренешкә шаһит буласым килмәде, коридорга чыгып киттем.

Ярты сәгать чамасы үз уйларыма чумып утыргач, шәфкать туташы минем янга чыкты һәм саф татарчалап:

—Гариф абый, менә сезгә юлламалар: ренгент белән теш врачына хәзер үк керә аласыз. Ә калган анализларыгызны иртәгә сәгать сигездә тапшырырсыз. Күңелсез булса да әйтим, язучы кешегә боларны ишетү кыендыр да инде, шулай да әйтми булмый, кагыйдәсе шундый: спид һәм башка йогышлы чирләрне тикшерү өчен сезнең венагыздан кан алачаклар. Ә менә бу юллама—канга гомуми анализ, шикәр диабетын белү өчен... Шөкер, аларны сездә юк дип исәплик, ләкин барлык больницаларда да тәртип бер үк.

Ренгенттан ансат кына узсак та, теш кабинетыннан үтү мин уйлаганча җиңел булып чыкмады. Стомотолог авызны ачып карар да: «Бирредә тәртип!»—дип юлламага кул куеп чыгарыр дип көткән идем, институтны бер-ике ел элек бетереп, азу тешен ярган шөпшә билле марҗакай, авызны каерып ачтырып, барлык тешләрне санап чыкты, селкетеп карады. Гөнаһ шомлыгы—урт тешләрнең берсе селкенә иде.

—Мондый селкенгән теш белән сезнең күзгә операция ясамаячаклар,—диде «шөпшә бил».

—Аласызмыни?

—Алырга туры килә...

## 2

Барлык анализларны тапшыргач, мин тыныч күнел белән йокларга тиеш идем. Ләкин йоклый алмадым. Бөтен гаеп Марсель Зариповта иде. Ул да узган елны катарактадан бер күзенә операция ясаткан.

Марсель—минем Әлмәттән үк килгән гаилә дустым. Беренче хикәяләрен чыгарышырга, Язучылар берлегенә әгъза итеп алдырырга булыштым. Ул бурычлы булып калмады. Без икәү, бергәләп, «Мы из Казани, с Волги» китабын язып, Мәскәүдә чыгардык. Шәһидә белән бергәләп Сәйарага өйләнүенә шаһит булдык, туйларында биедек. Марсель боларның берсен дә онытмый, жае чыккан саен мина булышырга әзер тора. Ул минем «Артышлы тау буенда» повестемны, хикәя-очеркларымны тәржемә итеп Мәскәүдә чыгарды.»Сонарып килгән бәхет» хикәямне, хикәя түгел бу, дип, калын бер әдәби журналнын редакторы бастырмый калдырган иде, Марсель тәржемәсендә башта «Литературная Россия» гәзитендә басылды, аннары Советлар иленең 60 еллыгы унаеннан чыккан жыентыкка бик дәрәжәле исемнәр белән бергә керде. Марсель—минем өчен кадерле кеше.

—Картлач,—диде ул бүген мина шалтыратып,—тынлап кара әле минем киңәшне!

—Тынлыйм, Марсель дус!

—Син, күзгә операция ясыйлар, дигән иден. Ул авыр операция түгел үзе. Наркоз бирсәләр, чебен йөргән төсле генә. Әмма аның операциядән соңы начар. Сакланырга кирәк. Авыр әйбер күтәрмәскә. Иелеп-бөгелеп эшләмәскә. Язу язмый торырга. Больницадан чыккач, көн аралаш уколга йөрергә...

—Нинди уколга? Күзгә укол кадыйлармыни?

—Ә син кадамаслар дип уйладың мәллә?—диде ул, мыскылчан сөйләшүгә күчеп.—Терпи казак, атаманом будешь! Ай буена уколга йөрисе була әле...

Марсель Зариповның мине якын күреп, үз итеп әйткән сүзләре борчуга салды. Күзнен кай төшенә кадыйлар икән укол? Керфек кырыенамы, аскаракмы? Ничә ай буена кадыйлар?

Моннан егерме еллар элек мин Мәскәүдә, Кремль хастаханәсендә ятып чыккан идем. Бавырдан таш эзләделәр. Таба алмагач, Казанга кайтардылар. Спецклиникада бер ай яттым. Атаклы табиб, хирург: «Резать, резать!»—диде. Мин ул чакта Харис Зәйнуллин белән бергә яткан идем. Зәйнуллин операция ясатуга каршы килде:

—Гариф абый, җүләр булма, ясатма! Пычак кергән урын—тәнгә зыян ул. Әнә, Лев Толстойның көн саен килә торган булган өянәге, тәки ясатмаган операция. Анарда да синдәге авыру—бавырында таш. Сиксәнгә кадәр яшәгән...

Спецклиниканың баш врачы Николай Иванович Чугунов әйткән:

—Вот подлец Ахунов! Безнең кызларны анекдот-мазар сөйләп, көлдереп йөрде-йөрде дә, операция ясатмый чыгып тайды, салага!—дигән.

Унжиде еллар узгач, Афзал ага Шамовны соңгы юлга озаткан чакта, мине кемдер арттан килеп кочаклады. Карасам, Николай Иванович.

—Ничә ел узды инде?

—Унжиде...

—Авыртмыймы?

—Юк.

—Сау-сәламәт яшәгез!—дип китеп барды ул.

Ике елмы, күпмедер яшәгәч, ул бавырында таш барлыгын сизгән, операция ясаткан да, бераздан үлеп тә киткән.

Мин операциясез котылуыма Зәйнуллинга һәм Миннехановка рәхмәтле. Казан санаториенда минем белән Нургали Миннеханов дәваланды. Мин аның белән карточкага да төштем. Анын хакында «Урман уртасында поселок»

диган очерк та яздым. Нургали безне, Шәһидә белән икебезне, парлап Саба урманына кунакка чакырды. Беренче мәртәбә мин ул очеркка кушып, шигырь бастырдым. Шигырьне Равил Фәйзуллин укып карагач, үземә килеп әйтте:

—Бу шигырь риваять төсле дә, әкият тә кебек!

Ул озын шигырьнең бер генә куплетын әйтеп күрсәтим:

Дөнья булгач, дөнья инде,
Төрле хәлләр булгалый—
Тарантаска айгыр җигеп,
Кыз урлаган Нургали.

Саба урманнарының матурлыгын, үзенең мәгънәле итеп яшәвен, берсеннән-берсе акыллы өч малай үстерүен күрсәткәннән соң, өстәл тактасының яртысы кадәр зурлыктагы бер китап бүләк итте ул миңа. «СССРның шифалы үләннәр атласы» дигән китап иде ул.

«Гариф Ахунов! Авырган чакларында шушы китаптан үзеңә кирәкле үләннәрне табып, мине искә алырсың. 12 март—1978. Нургали Миннеханов»,—дип язылган иде.

Мин чыннан да үземә кирәкле үләннәрне сайлап алдым китаптан. Нургалигә рәхмәт укып яшим. Азактан Нургали Миннеханов һәм аның югары урыннарда эшләүче уллары турында минем каләмдәш Мәгъсүм Гәрәев язып чыкты...

Бәлки, чынлап та күзгә операция ясатмаскадыр? Үләннәр белән генә дәваларгадыр?

Төнлә мин бик ямьсез төш күрдем. Имеш, минем күземә операция ясаганнар да, бер күзем агып чыккан. Мин кан дәрьясында ятам, имеш...

Йөрәгем дөп-дөп типкән хәлдә уянып киттем.

Төшемне Шәһидәгә сөйләмәдем. Куркыр дип уйладым. Тиз-тиз киендек тә хастаханәгә киттек.

Миләүшә Харисовна безне кояш кебек яктырып каршы алды. Ләкин, вазифасына чумгач, караңгылана башлады. Мин—язучылык һөнәрем буенчадыр—аңардан күземне алмадым. Миңа аның үзгәрүе ошамады. Без китергән анализ нәтиҗәләрен—кардиология сызыкларын карап чыккач, ул әкрен генә «аһ!» итеп куйды.

—Нәрсә, Миләүшә Харисовна, ялгышканнар мәллә?

—Ялгышмаганнар. Кәгазьләр барысы да дөрес,—диде ул акрын гына.—Әмма мин сезне операциягә җибәрә алмыйм әле.

—Ни өчен?

—Кардиология йөрәгегезнең хәле кыен икәнне күрсәтә.

—Нишли алам инде мин?

—Иртәгә мин сезне стационарга салырга тиешмен. Әзерләнегез.

Күңелсез генә кайтып киттек.

Улыбыз Рәшит Мәскәүдән кайткан икән, шалтыратты. Шәһидә алды трубканы. Ул сөйләсә, ашыкмый сөйли, тәфсилләп сөйли белә. Ләкин улыбыз ашыга бугай, шуңа күрә Шәһидә:

—Улым, безгә кил әле. Мин өчпочмак пешерәм бүген. Җылы ризык та ашап китәрсең, сөйләшәсе-киңәшәсе нәрсәләр дә бар,—диде.

Улыбыз, гадәтенчә, төнге унберләргә хәтле эшендә булды, төн уртасында гына безгә килеп житә алды. Әнисенең һәм минем битемнән үбеп күрешкәннән соң, жәйге пальтосын, пинжәген салып чөйгә элде, туфлиләрен салып, йомшак йорт башмаклары киде. Әнисе аны кайнар өчпочмак, тозлаган кәбестә белән сыйлады, карлыган вареньесы белән чәй эчерде, тик шуннан соң гына киңәшәсе сүзен әйтте. Юкса, ашап утырган чакта берәр сүз кыстырсаң, йә сорау бирсәң, ул яратмый, өнәмичә генә:

—Тынычлап ашарга ирек бирегез әле, өч көнгә өч сәгать кенә йокладым мин...—ди.

Мин улыбызга карап утырырга яратам. Минем кебек күп сүзле түгел ул. Әнисе кебек аз сүзле. Шомырт кара чәчләре дә әнисенә охшаган: табигый көдрә. Чәчен иң оста парикмахерлардан алдыра, унтугызынчы гасыр зыялылары кебек чибәр булып йөри. Яңагыннан ук башланып, чәченә килеп тоташкан бакенбард, кыска сакал-мыек аның туры борынын, уймак иреннәрен, тамак ялгаган чакта алсуланып киткән бит алмаларын матур итеп күрсәтә. Тик аның чалымнарында минем дә өлеш бар. Заманында мин дә төшеп калганнардан түгел идем. Их, яшьлек! Сагындырасың, малай! Менә хәзер Рәшит булсаң иде ул, Аяз әйтмешли...

Рәшит, гомерлек гадәте буенча, әнисенен ризыгын үтереп мактады, иренмичә, озаклап рәхмәт әйтте. Аннары безнең хәлләрне сорашырга тотынды. Әнисе аңа минем күземә операция ясатырга кирәклекне, хастаханәдә нинди юллар узганны сөйләп бирде.

—Әти, мин синең алты-җиде ай күзен белән матавыкланып йөргәненне беләм. Әйдә, күзеңә операцияне Франциядә ясатыйм,—диде Рәшит.

Мин дәшмәдем. Улыбыз сүзен җилгә очыра торган кеше түгел. Аннары ул Франциянең аркылысын-буен йөреп чыккан кеше. Халыкара Коммерция Союзының генераль директоры чагында ул Татарстанга француз технологиясе белән шикәр чөгендере үстерүчеләрне алып кайткан иде.

—Әти, ник дәшмисең?

—Мин бит, улым, Югары Совет депутаты чагында, чит илләргә күп чыктым. Хәзер бер дә читкә чыгасы килми.

—Алайса, Мәскәүдә ясатыйк. Атаклы күз врачы, академик Федоров—якын дус минем. Без аның белән кунакка йөрешәбез.

—Мәскәүдә дә ясатасы килми шул...

—Алайса, кайда? Чабаксарда ясатыйк! Анда бит Федоровның шәкертләре эшли.

—Минем хәтта Чабаксарда да ясатасы килми.

—Алай булгач, Казан гына кала инде. Юлламаны кая бирделәр?

—Бутлеров урамындагы клиникага...—дидем мин, бүтән дәшмәдем. Дәшмәвемнең сәбәбе шул: мин бит әле күзгә операция ясатканчы йөрәкне дәваларга тиеш. Ул хакта Рәшиткә әйтергәме-юкмы?

Мине бу бәладән Шәһидә коткарды:

—Улым, әтиеннең әле йөрәген дәвалыйсы бар. Иртәгә аны хастаханәгә салалар.

—Йөрәгенә ни булган?

—Эш дигәндә әтиең чама хисен белми. Мин әйтеп тә карыйм, тыңламый. Арчалар безгә бер йөк тирес китерделәр. КамАЗ машинасына ун тонна тирес сыя. Шофер аны безнең дача янына аударып китте. Әтиең шуны өч көн буена тирес чокырына ташыды. Менә шул аның йөрәгенә суккан.

Улыбыз дәшмәде. «Йөрисез шунда юкны киртәләп!»—дип уйлагандыр инде.

—Машина кирәкме? Мин машина җибәртә алам,—диде ул, байтак вакыт дәшми торгач.

—Кирәкмәс,—диде әнисе.—Сине борчыйсы килми безнең. Хастаханә ерак түгел бит, үз аягыбыз белән дә барып җитәрбез.

## 3

Иртәгесен мине хастаханәгә салдылар.

Дүрт кешелек палата.

Авыруларның икесе—урыс, сиксән яшьлекләр, Ватан сугышы инвалидлары. Берсе—татар, аңа әле җитмеш кенә. Мансур исемле. Без—

кордашлар—анын белән шундук дуслаштык. Татар булганы өчен түгел, ул мин язган китапларның барысын диярлек белә, мине күрергә бик тели икән. Мин аңардан сорашып, ул белергә теләгәннән күбрәк белеп өлгердем инде. Хуҗалыгын бик яхшы алып баручы булып чыкты ул. Тормышның ачысын-төчесен күп күргән, шулай да мөлаемлыгын җуймаган кеше икән. Зуррак борынлы булса да, йөзенә чыккан ягымлы-мөлаемлык аны сиздерми, гел үз яшеннән яшьрәк итеп күрсәтә иде.

Минем янга аз сүзле Лирон Хәмидуллин, күп сүзле Гарәф Шәрәфетдинов, монсу чырайлы Илдар Юзеев килеп киттеләр. Минем шаулап, ижат дәрте белән тулып йөргәнне күргәч, «бу адәм һаман да ихлас, һаман да ахмак килеш калган икән, авырса да»...—дип уйлаганнардыр инде...

Минем йөрәкне дәвалаучы табиб—Сирматов фамилияле егет. Сирматов—сирәк очрый торган фамилия. Беркөнне мин аңардан сорадым:

—Сез телевидениедә эшләүче Сирматовнын туганы түгелме?

—Мин—анын улы,—диде табиб.

Шаккаттым да калдым. Сирматов әле мин белгәндә генә япь-яшь егет, яп-яшь язучы иде, аны әле мин Язучылар берлегенә алдырырга тырышып йөрдем. Инде табиб улы үсеп җиткән. Үземнең житмеш яшьлегемдә әйткән халык җыры искә төште:

Аккошлар моңлы кычкыра,
Китүләредер инде.
Шулай итеп, яшь гомернең
Үтүләредер инде.

Шулай икән шул, шулай икән—уза икән гомерләр! Узмый торган булса, мин күземә операция ясатып йөрер идеммени? Бар иде заманнар, җитмеш яшьтәгеләрне без бик карт саный идек. Алтмышы гына узган Гариф ага Гобәйнең җәмәгать эшләреннән читләшүенә сәерсенеп карый идек. Күрәсен—сәламәтлеге какшаган булган...

Бер атнадан артык һавага чыгып йөргәч, хастаханә бакчасындагы койманы, каеннарны, йортларны фломастер белән рәсемгә төшергәч, кәефем әйбәтләнгәнне сизеп, дәвалаучы табибтан сорадым:

—Алмаз Индусович, мине кайчан чыгарасыз инде?

—Хастаханәдә дәвалау срогы бер ай, ин киме—өч атна. Сез бит әле ун көн генә ятасыз. Мин сезнең алай ашыгуыгызның сәбәбен аңламыйм.

—Мине бит бирегә йөрәкне нормага китерер өчен генә керттеләр. Ә ул күзгә операция ясау өчен кирәк. Күз табибәсе, миңа әйтте, катаракта өлгергән, операция ясарга мөмкин, диде. Мин операция срогы узып китмәгәе дип куркам...

—Узмас, тагын бер атнаданмы, биш көннәнме чыгарырбыз. Йөрәгегез, шөкер, рәтләнеп килә.

Мин хастаханәдән чыгар көнне көтеп яши башладым. Авырусырхауларга бик тә сабырсыз шул мин. Өзлексез эш эшләп тору ягында. Яза алмыйм икән, җәйләрен бакчада эшлим: тирес таратам, чүп утыйм, балта тотып юнышам. Кырык ел буена алып бара торган көндәлегемне язам. Һич югы бакча йортын тәртипкә китерәм...

Көннәрдән-беркөнне Язучылар берлеге житәкчесе Ринат Мөхәммәдиев белән анын ярдәмчесе Рәмис Аймәт килеп керделәр. Алар икесе дә чибәр, яшь. Ринат озын, Рәмис кыска—Тарапунька белән Штепсельне хәтерләтәләр иде. Алар мине сагынганны әйттеләр. Бүлмәләр тынып калган, миннән башка шаулап йөрүче юк, имеш. Ведомость белән 87 мең сум (хәзерге акча белән 87 сум) акча да алып килгәннәр иде. Монысы—Проза остаханәсен житәкләгән өчен. Элекке, мин язучылар житәкчесе булып эшләгәндәге акча белән исәпләгәндә, сигез сумнан аз гына артык дигән сүз. И дөньялар, калдык адәм хурына! Акчалы вакытта эшләп калдым мин, бәхетле икәнмен.

Ул чагында без иҗат чоры өчен дә язучыларга 150 шәр сум түли идек. Хәзерге меннәргә салсаң, мен ярым була бит ул...

Бераздан Луиза Әхмәтҗанова килеп керде. Ул—мәрхүм Рәшит Әхмәтҗановның тол калган хатыны. Рәшит белән безнең тормыш Әлмәттә чакта бик бәйләнгән иде. Луиза ханымның тәккә генә йөрмәвен белә идем. Минем Бутлеров урамындагы клиникада күзгә операция ясату планымны Луиза ханым—һөнәре буенча врач—челпәрәмә китерде.

—Гариф абый, сез һәм Шәһидә апа—заманында Рәшитне сыендырган кешеләр. Баулыга барып кайтыйк әле. Анда ана музей ачалар. Сез бит—халык язучысы, Рәшитнең, шагыйрь буларак, үсүенә ярдәм иткән әдип.

—Минем күзгә операция ясар чак җитте бит. Юкса, Рәшиткә бик теләп барыр идем. Ул соңгы елларда шагыйрь булып та, сәясәтче булып та бик нык үсте. Минем тырышканнарны җилгә очырмады.

—Кайда ясатмакчы буласыз операцияне?

—Бутлеров урамындагы клиникада булыр инде.

—Яхшы. Чабаксарда яки Мәскәүдә түгел икән.

—Юк, мин андый җиргә барырга теләмим. Туган җирдә булуы хәерлерәк.

—Алайса, мин үзем ясатам сезгә операцияне.

—Кайда?

—Тимер юлчылар больницасында минем дустым Резидә Галиуллина Шәүкәтовна эшли. Бик яхшы окулист. Шуның белән үзем сөйләшәм.

—Ул риза булырмы?

—Мин әйткәч, риза булыр.

—Ә Баулыга кайчан барасы?

—Озакламый китәбез...

Баулыда очрашуларда булып кайтканнан соң бер атна үткәч без Луиза ханым белән Тимер юлчылар хастаханәсенең капка төбендә очраштык.

Төгәл кеше булып чыкты Луиза ханым. Тугыз туларга ун минутта ул капка төбендә иде инде. Тоташ ак күлмәктән, ак эшләпәдән—аны танырлык та түгел. Яшәреп тә киткән дип әйтимме?

Хастаханәгә кердек. Ак халат бирделәр. Луизага да, миңа да. Тапочкалар—үкчәсе тапталган, бар җирдәге кебек. «Без минем коллегама керәбез, рөхсәт ит»,—диде Луиза ханым, ишек төбендә утыручы ак халатлы апа, пропуск сорагач.

Безне икенче катта 33-36 яшьләрдәге юка гәүдәле ханым каршылады. Ул да ак халаттан, биек ак калпактан. Аксыл чырае ягымлы, көләч иде. Елмаеп исәнләште.

Минем спецклиникада биргән язуларны озаклап карады. Бу кечкенә кысан бүлмә иде. Аннары минем иякне ниндидер аппаратына куйдырды, маңгайны терәттерде. Күзне туры карарга, өскә күтәрергә, аска төшерергә кушты. Мин боларны төгәл үтәдем. Аның кояш кебек нур төшергән уты күзне чагылдыра иде, түздем.

Шушы гамәлләрне үтәп бетергәч, ул минем иякне һәм маңгайны приборыннан алдырды.

—Әйе, катаракта,—диде.—Басымы югарырак—25, кирәк—20. Өлгереп җитмәгән. Дүрт-биш атнадан өлгерә... Июль азакларында килерсез.

Резидә Шәүкәтовна безне, Шәһидә белән мине, татар гадәте буенча, ишек төбенә кадәр озатып куйды.

—Нигә озатты ул безне?—диде Шәһидә.

—Чыннан да киттеләр микәнне белү өчен,—дидем мин, шаяртып.

Шәһидә көлмәде, шаяртканны чынга алды бугай.

Хәтер—үземнең дә тишек капчык хәзер, кайда шаяру, кайда хак сүз сөйләгәнне белер хәл юк. Ул гынамы әле? Бер минут эчендә ниләр сөйләшкәнне дә оныта башладым.

Мин Луиза ханымның чын кеше икәнен Баулыга барганда ук аңлаган идем инде. Ире Рәшит Әхмәтҗановның поэзия көннәрен нинди итеп оештырган ул. Музее мәгънәле булсын, шагыйрьнең мәшһүрлеге ачылсын өчен күпме көч салган! Өстәвенә—ярдәмчел, кайгыртучан. Инде менә бу юлы минем күземне тизрәк төзәтергә теләп, Тимер юлчылар хастаханәсенә алып керде, ахирәте Резидә Галиуллина белән таныштырды. Вакытын кызганмыйча, үзенең килүе (эштә бит!) аның ихласлыгын тагын бер тапкыр раслады.

Мин күземә операцияне Тимер юлчылар хастаханәсендә, бары тик шунда гына ясатырга дигән ныклы карарга килдем.

## 4

**1996** елның 2 сентябрендә мине Тимер юлчылар хастаханәсенә салдылар. Ул безнең янда гына. Җәяүләп биш минут барасы. Мин әле операцияне алай тиз булмас дип уйлаган идем, ялгышканмын. Иртәгесен сәгать сигезләр тирәсендә Резидә Шәүкәтовна килде һәм операциянең бүген ясалачагын әйтте. Ул чиксез дулкынланган, озынча аксыл битенә алсулык капкан. Ак халат аның нәфислеген аеруча сиздереп тора, озын ак калпак алсулык йөгергән чыраен балкытып ук җибәргән иде.

—Мин, әлбәттә, дулкынланам, —диде ул. Күкшел күзләрендәге ихласлыгы, буй-сыны белән берләшеп, аны ихтирамлы итәләр иде. Ихласлык һәркемгә килешә. —Мин бит операцияне рядовой кешегә ясамыйм...

Операция бүлмәсендә ике ир-атның ыгы-зыгы килеп йөргәннәре, беләккә укол кадаганнары гына истә калган, башкасын хәтерләмим, онытылганмын...

Күземне ачкач:

—Нишләп ясамыйсыз инде операцияне?—дидем.

—Ясадык инде...—диде хатын-кыз тавышы.

Мин аның Резидә Шәүкәтовна икәнен анладым. Көйле, йомшак тавыш иде ул.

Уң күзне марля белән бәйләгәннәр. Аннары мин йоклап киткәнмен. Реанимация бүлмәсенә керткәннәр.

Уянганда, минем янда Шәһидә утыра иде.

—Бәгырькәем, ясадылармы?—диде, марля бәйләгән күзгә карап торды, берәм-берәм кулларны тотып карады, табибә кебек, көйле йомшак тавыш белән әйтте.—Кулың әйбәт. Җылы. Чалкан ятып торырга куштылармы?..

...Резидә Шәүкәтовна бик тә шәфкатьле булып чыкты. Мин үзебезнең бүлмәгә кайтуга ук кереп житте, хәлне сорады. Аннары Шәһидәнең кан басымын үлчәде. Куркынып әйтте:

—220 дә 110!

—Минем нормальный кан басымы—170 тә 100 була,—диде Шәһидә.

—Мин сезне мондый югары басым белән больницадан чыгара алмыйм,—дип хатынымны минем белән янәшә салып та куйды. Анда буш койка бар иде. Шулай итеп, без Шәһидә белән бер палатада булып чыктык.

Операция ясагач, иң мөһиме—авыруны карау-багу. Әнә, Шәйхи абый Маннур, карый-бага белмәүләре аркасында, ике үпкәсенә дә салкын тидереп, үлеп китте. Мин аны вакытсыз үлде дип саныйм. Югыйсә әле ул үләсе кеше түгел иде, мина, операция ясатмыйм, анда авыру бага белмиләр, дигән иде. Күрәчәге булгандыр инде...

Мин ул яктан бәхетле булдым: беренчедән, хатыным янымда, икенчедән, Резидә Шәүкәтовна күзәтеп кенә тора. Ул миңа гел чалкан ятып торырга кушты. Аның кушканын төгәл үтим. Әмма мин хастаханәгә кайчан гына ятсам да, эч пошудан, йә шигырь язам, йә рәсем ясыйм. Бу юлы да, тәрәзәдән карап, безнең бинаның колонналы почмагын ясадым.

Ул саргылт төстә иде. Минем фломастерым бар, өйдән үк, керәге чыкса дип алып кергән идем, кәгазьдәге (көндәлектәге) рәсемне саргылт төскә буядым. Мактану гадәтем буенча, рәсемемне башта Шәһидәгә, аннары Резидә Шәүкәтовнага күрсәттем, бик йомшак табигатьле, бераүгә дә зыян эшләми торган Рәшидә сеңлебезгә—шәфкать туташына да күрсәтеп мактанырга уйладым. Алар, минем күңелем боекмасын өчен, тел шартлатып, хәйран калып торган булдылар.

Рәшидә, житәкчесе Резидә Шәүкәтовнадан аермалы буларак, түгәрәк битле, ифрат йомшак холыклы. Резидә Шәүкәтовнаны да йомшак түгел дип әйтеп булмый, ләкин ул рәхәтләнеп көлә ала, шаян сүз әйтә ала, кирәк икән, тапкыр сүзе белән үзен яклый белә, сине хур итеп куярга да күп сорамый. Кыскасы, икесендә ике төрле холык. Рәшидә сеңлебез минем күзгә дару салырга килә:

—Гариф абый,—ди ул, йомшак кына итеп,—күзегезне йомгалап торыгыз, яме...—Күнгә өч тапкыр дару сала, өчесендә дә йомшак-моңлы итеп дәшә. Ул әле, минемчә, кияүгә чыкмаган. Бөтен хәрәкәтендә шул сизелә. Тавышы сагышлы...

Рәхәтләнеп көлә торган Резидә Шәүкәтовна бер көнне сөмсерләре коелып керде. Мин куркып:

—Ни булды?—дип сорадым.

—Шәфкать туташыбыз кияүгә чыга!

—Моңа бит сөенергә генә кирәк!

Резидә Шәүкәтовна дәшмәде, чыгып китте. Икенче көнне Рәшидә сеңлебез күзгә дару салырга кергәч, сорадым:

—Нәрсә, шәфкать туташы кияүгә чыгамыни?

Рәшидә кып-кызыл булып кызарды, түгәрәк битенә тимгелләр чыкты, авыз эченнән нидер әйтте, мин аңламадым.

Резидә Шәүкәтовна хәл белергә кергәч, тагын аңа каныктым.

—Кияүгә чыга дип кайгырып йөрисез. Чыкса, ни була?

—Их, Гариф абый, мин бит иң булдыклы ярдәмчемне югалтам.

—Ничек югалтасыз? Ул эштән китәмени?

—Китә инде, китә... Жиде айдан декретка чыгар, аннары ике ел бала багып утырыр...

Шәһидә, кан басымы бераз көйләнгәч, бакчабызга китеп барды һәм дүртенче көнне генә кайтты. Төянеп минем янга керде. Шундук Резидә Шәүкәтовна да кереп житте.

—И Шәһидә апа, Гариф абый сезне сагынып үлә бит инде. Әнә шигырь дә язды,—диде.

Безнең мөнәсәбәтләргә катнашуы аның үзен күрсәтергә теләвеннән түгел, ихлас булуыннан иде. Әйе, мин аның чын күңелдән йөрүен бер күрүдә аңладым. Унбер ел эшли инде ул күз табибәсе булып, ике меңнән артык операция ясаган. Түрәме-юкмы—ул бар кешене дә тигез күрә, аның өчен адәм баласы бер, ул күзенә операция ясаган кешенең күрә алуын кайгыртырга тиеш. Боларны миңа ул үзе түгел, шагыйрь хатыны Луиза ханым әйтте. «Резидә, Япониягә барып, нинди эшләр эшләве турында доклад ясады, тиздән аның докладлары япон телендә басылып чыгачак»,—дип тә өстәде.

Минем аңа ышануым арта төште.

Күз күрә, көндез марля капламыйча йөрим, күз уртача күрә, мин аны картлыктан дип беләм. «Киләчәктә отыры яхшыра барачак»,—дип Резидә Шәүкәтовна мине тынычландыра, мин аңа чын күңелемнән ышанам. Ул Мәскәүдә медицина фәннәре кандидаты дигән дәрәжә алу өчен диссертация яклаган. Үзебезнекеләр яклатмаган, яһүдләр яклаткан. Шуңа күрә ул Мәскәүгә барган да! Боларны да миңа Луиза ханым сөйләде.

## 5

Бүген шимбә. Врачлар юк, шәфкать туташлары—кизү торганнары гына—йөри.

Кӧтмәгәндә палатага Резидә Шәукәтовна килеп керде. Сәгатькә күз төшердем—унынчы ярты. Бакча киемнәрен киеп алган, өстендә чалбарлы джемпер, килешеп тора.

—Бүген ял көнем, дежур көнем түгел, сезнең өчен килдем,—диде.

—Йа ходаем, нигә шулхәтле мәшәкатьләнәсез? Мине авыр хәлгә куясыз бит... —дидем уңайсызланып.

—Мин операциядән чыккан барлык авыруларыма да ял көне киләм.

—Рәхмәт инде, изге кеше икәнсез.

Минем күзне озаклап юды, уң күз янындагы калку сөяк тиресенә укол кадады, милисә үләнен чәй итеп кайнатып эчерде.

Тизрәк терелүемне теләп кайтып китте.

Сәгать уникедә оныгым Һидая килде. Сары чыпчык баласы. Салам чәчләре җилкәсенә таралып төшкән. Ул хәзер инглиз мәктәбенең соңгы сыйныфында укый. Ике букет чәчәк китергән. Берсе—миңа, берсе—дәү әнисенә. Уза гомер—әле кайчан гына безнең белән бакчага теркелдәп йөри, кул арбасы яныннан йөгерә иде. Мин аның хезмәт ярата торган булып үсүенә сөенәм. Бакча йортының чоланына бервакыт, әле Һидая өченче сыйныфта чакта, ап-ак чәчәктәге алмагач ясаган идем. Бер квадрат метрны Һидаягә дә бүлеп бирдем. Мин теләгәнчә үк итеп ясап чыккан, кешелеккә кия торган күлмәген дә буямаган иде. Шуннан соң дәү әнисе аны рәсем мәктәбенә илтеп бирде. Мәктәптә ул шәп укыды, юморлы булып чыкты, әллә ниткән әкәмәт колак мендәрләре, чәйнек каплагычлар ясап китерде безгә, кәгазьгә ясаган чәчәк рәсемнәре белән куандырды, майлы буяу белән картина язды. Аның шаян рәсемнәрен, академик Харис Якупов сүз башы белән, «Салават күпере» журналы бастырып чыгарды. Безнең өйдә язучылар гына түгел, рәсем белән мавыгучылар да байтак шул. Минем генә мавыгуым житмәгән, Һидаянең әнисе Наилә рәсем мәктәбен бетерде, улыбыз Рәшит рәсем мәктәбендә укыды, ә Һидая, әнисе белән бергәләп, ике күргәзмә оештырды...

Якшәмбе көнне дә кеше өзелеп тормады. Иртәнге якта Тимерхан Борһанов килде. Тәбәнәк буйлы булса да, чүкеч кебек таза ир, минем кордаш, житмеш берен тутырган чибәр карт үзләре бакчасының алсу алмасын, күп итеп көньяк жимеше—банан китергән иде. Кече улы Рафис турында, аның Казан шәһәре хакимияте башлыгы Камил Исхаковның урынбасары булып билгеләнүе турында иркенләп сөйләштек.

Инде шуның белән бетте дип торганда, Мәхмүт Әхмәтжанов килде. Фасонлы киенүнең аргы ягына чыккан фырт бу юлы да чибәр иде. Чытыр ак күлмәк, өр-яңа чуар галстук, күз явыңны алырдай зәңгәр костюм. Аңа һич тә 68 яшь бирерлек түгел. Эчми-тартмый. «Эшләгән яхшылыгы да шуннан артмый»,—дияр иде Әхмәт Исхак булса. Ул көне-төне яза. Язганында мәгълүмат күп була. Каян җыеп бетерә ул аны?! Мәхмүт сәер кеше. Әкрен сөйләшә, берәүне дә яманламый, әйләнә-тирәсендәгеләр белән конфликтка керми, уклау йоткандай, төз катып йөри, әмма... милләткә кагылсалар, самавырдай кайнап чыга. Эпитетларын да таба, хурлык баганасына кадаклап та куя.

Дөнья хәтле җиләк-җимеш төяп килгән. Алмасаң, үпкәли. Кая куеп бетерергә инде аларны?

Мәхмүт белән кочаклашып күрештек тә, кочаклашып аерылыштык. Сөйләшеп сүзләр бетмәде, кайткач сөйләшербез, дидек.

Мәхмүтне озатып та бетермәдем, Һидаям тагын килде. Миңа Мәскәүдә чыккан китабымны алып килгән.

—Каян алдың моны? Ул бер жирдә дә юк бит инде...—дим.

—Аны бер картка бүләк иткән булганнар. 1979 елны. Карт пенсиягә чыккач, бүләк китапларын калдырып, башка фатирга күчкән. Культурасыз кешеләр ул китапларны урамга чыгарып ташлаган. Менә шулар арасыннан бер кочак китап жыеп алдым—үземә кирәклене. Синең Мәскәүдә урысча чыккан «Клад»ың да бар иде араларында.

И сөендем дә соң оныгыбызның мәгънәле һәм туган җанлы булуына!

Кичке алтыда безнең гаилә дусларыбыз Әхмәт Гадел, аның хатыны Зөлфия, оныклары Әнвәр килде. Күп итеп өчпочмак пешереп китергәннәр. Помидор, боржом суы. Ике-өч яшьлек Әнвәргә шашка тактасын тоттырдык та: «Шашкаларын тез шуңа»,—дидек.

Өчпочмакны ашый-ашый, сүз куертып җибәрдек.

Зөлфия аз сүзле, ул Шәһидәнең яшь чагына охшаган, ләкин ул чибәррәк бугай, хәер, аның яшендә кем дә чибәр була.

—Ринат Мөхәммәдиев сиңа күп итеп сәлам әйтә, үзе килә алмый, каядыр бик ашыгыч чакырганнар—Әлмәткәме, Мамадышкамы, сайлаучылар белән очрашырга...—диде Әхмәт.

—Мамадышкадыр, сайлаучылар белән очрашырга булса. Мин Мамадышта, аны депутат итеп сайлар алдыннан ышанычлысы булып йөргән идем.

Мин шунда үземнең СССР Верховный Советына депутат булып сайланган чакларымны искә төшердем. Ышанычлым Илгиз Хәйруллин иде. Ул заманда Илгиз обкомның инструкторы иде. Без аңа Илгиз дип кенә дәшә идек, хәзер ул «Илгиз Кәлимуллович» булды. Шулай дәшәргә туры килә хәзер. Ләкин ул үзгәрмәде, элеккечә үк чандыр, элеккечә үк гади булып калды. Элек тә акыллы иде, хәзер дә акыллы. Минем ышанычлым булып йөргәндә, ул миңа әйтте: «Гариф абый, бүген телдән сөйләдең, иртәгә язып сөйләрсең инде, яме»,—диде.

Мин ул чакта анлап житмәгәнмен:

— Ник, мин начар сөйләдемме? —дип Илгиздән сорадым.

—Юк, син бик әйбәт сөйләдең, шулай да язып сөйләү кирәк булыр.

Мин бу сүзләрнең мәгънәсен хәзер генә төшендем. Безнең өстән шикаять керүе мөмкин ләбаса: алай сөйләделәр, болай сөйләделәр, дип... Акланыр өчен кәгазьне чыгарасың да күрсәтәсең. Алай түгел, болай ул, арпа түгел бодай ул!

Әхмәт Гадел белән гаилә хәлләрен, минем күзгә операция уңышлы ясалганмы-юкмы икәнен сөйләштек, мин шагыйрь дустыма «Багышлаулар» дәфтәреннән берничә шигырь укыдым.

Дару-сәдәфләрне йоттым, су эчтем. Температураны үлчәделәр—норма, 36,3 градус. Ул арада Резидә Шәүкәтовна килеп керде. Башка чакта ул уннар тирәсендә керә, бүген—сизенгәнме—сигездә үк килеп керде. Приборларыннан күзне карады, кемнәр килгәнен сорашты. Минем күп кеше кабул итүемә, шигырь язуыма, рәсем ясавыма үпкәләгәндәй булды. Ләкин ул бик тактлы. Бу сүзгә «әдәпле» сүзе күбрәк туры килә бугай. Күләгә кунган чыраеннан мин шуны аңладым.

—Мин сезгә юкка әйттем бугай, бераз язарга ярый, дип... әйтергә кирәкми иде. Ә сез арттырып җибәрәсез,—диде ул көйле тавышы белән.—Кеше китерүне туктатам, вахтага әйтеп куям. Гариф абый, сез бит минем эшемне юкка чыгарасыз. Сез дәрәҗәле, исемле кеше, сезнең күз бозылса, «ә-ә-ә, халык язучысының күзен бозучы Резидә Галиуллина икән» диячәкләр...

Бу сүзләр минем үзәгемне өзеп алды.

—Күз... ни... бозылмагандыр бит?

—Бозылуын бозылмаган да... Әйдәгез, күзегезнең басымын киметәбез. Күзне, сез әйтмешли, әлҗе-мөлҗе килүдән туктатабыз,—дип күз төбендәге

калкынчага һәм керфек төбенә укол кадады. Шәфкать туташы, чая хатын, савырга ике укол шапылдатты.

Хәлләр рәтләнде, күз аллары әлҗе-мөлҗе килүдән туктады. Резидә Шәүкәтовна мине култыклап палатага чаклы озатып куйды. Мин аның «тырышлыгын юкка чыгармаска» күңелемнән ант иттем. Шәһидә килгәч,ниләр булганны аңа да сөйләп бирдем.

—Әйттем мин сиңа Резидәнең тырышлыгын юкка чыгарасың, дип! Әтисе, язмый тор инде, зинһар. Язмый торганнан үлмисең бит.

—Ярый, сиңенчә булыр: язмый торырмын. Тик шуның белән генә эш бетсә...

Шуның белән генә эш бетмәде. Радиодан соңгы «Хәбәрләр»не тыңлап утырганда, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Фатыйх Сәүбан улы Сибагатуллинның, министр булудан азат ителеп, Нурлат районына хакимият башлыгы итеп билгеләнүен белдем.

—Бик әйбәт кеше иде. Кайнарлыгы подводить иткәндер инде,—дидем борчылып.—Без бит аның әнисе янында Апазда да булдык. Әнисе мактап бетерә алмый аны, «Фатыйхым» дип кенә тора...

—Сибагатуллин өчен юкка борчыласың, әтисе. Дүрт-биш ел эчендә Нурлатны Республикага әйләндереп кайта әле ул. Менә шушы тиле әйткәние диерсең.

Хатын белән бәхәскә керү—арслан белән сугышудан да хәтәррәк. Шуңа күрә авызны ачтым да күзне йомдым.

Ләкин шомлану бетмәде. Гәзитләрдән Нил Гафур улы Юзеевның вафат булуын белдем. Әлеге хәбәр яшен суккандай тәэсир итте. Зур укымышлы иде, юаш холыклы. Шигырь төзелешен тикшергән акыллы китабы өчен Тукай бүләген алды. Гази абый Кашшаф куйдырткан иде аны бүләккә. Мин яклаган идем. Биектау районының Сасмак авылы зиратына күмгәннәр. Шунда йорт сатып алып яшәгәннәр. Әйбәт кеше иде, урыны җәннәттә булсын...

Мин көне буе күңелсез йөрдем. Нигә күңелсез булуымны Резидә Шәүкәтовнага әйтмәдем. Болай гына, дидем. Кичке дүрттә, укол кадагач мин аннан сорап куйдым:

—Кайчан чыгарасыз мине?

—17 сентябрьдә булыр, ахрысы... 18 ндә сезнең туган көнегез бугай. Өйдә рәхәтләнеп ял итәрсез... Шулай да... өйдә рәхәтрәкме, мондамы?

—Биредә... башка хастаханәләрдән аермалы буларак, дару исе аңкып тормый...

Минем туп-туры җавап бирмәвемнән Резидә Шәүкәтовна көлеп җибәрде, аннары моңсуланып:

—Мин сезне сагынырмын,—диде.

—Сагынмасагыз, үпкәләрмен,—дидем мин, шаяртып.

Резидә Шәүкәтовна елмайды. Рәшидә сеңлебез әңгәмәне тыңлап тора иде, ул тыныч калды. Мин Рәшидә турында уйлап ялгышканмын, ул түгел, системалар куючы гүзәл кыз Гүзәлебез кияүгә чыга икән лә!

Бераз тын торгач Резидә Шәүкәтовна тирән итеп бер сулыш алды да:

—Шәһидә апа—дөнья бәясе кеше. Сез аны үртәмәгез, яме? Ул—бик ранимая. Андый гомер юлдашын көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың!—диде.

«Их, бу сүзләрне Шәһидә үзе ишетсен иде»,—дип уйладым мин.

## 6

Теләсә кайсы хастаханәгә килеп керсәң, иң әүвәл борыңга дару исе бәрелә. Тимер юлчылар хастаханәсенә керү белән мин аптырап калдым. Анда дару исе бөтенләй юк. Чөнки санитаркалар, җыештыручылар

иданнарне хлорлы чүпрәк белән көнгә өчәр-дүртәр тапкыр юып торалар. Монда тәртип шулай куелган. Ак калпаклы, чытыр ак халатлы санитаркаларны табибәләрдән, шәфкать туташларыннан аерып алып булмый. Син аларга ихтирам белән юл бирәсен, матур итеп исәнләшәсен.

Хастаханәдән чыккан көне үк кич белән Резидә Шәүкәтовна безнен өйгә килде. Төянеп килде.

—Бәйрәм ясыйбызмы-юкмы?—дидем мин.

—Ясыйбыз,—диде Резидә Шәүкәтовна.—Без Гариф абый белән шампан эчәбез. Шәһидә апайга бер рюмка коньяк,—дип сумкасыннан ике шешә, бер тартма конфет чыгарды.—Гариф абый тост әйтсен!

Минем тостым әзер иде.

—Бервакыт шулай гаилә дустыбыз Рәсүл Гамзатовка килдем дә: «Сез әниләрне саклагыз» дигән бик шәп поэма язгансыз. Без, татар язучылары, шуның өчен рәхмәт белдерәбез»—дидем. «О, кадерлем Гариф,—диде мина Рәсүл Гамзатов,—мин үзем дә беләм шәп поэма язганымны. Менә шуны син югары трибунадан әйтсән, йөрәккә сары май булып ягылыр иде».

Кадерле Резидә Шәүкәтовна, сезгә мен рәхмәт, кул-аягыгыз сызлаусыз булсын. Мин моны хатыным Шәһидә бар жирдә, ягъни югары трибунадан торып әйтәм. Сезнең саулыкка!

### КҮЗ НУРЫМНЫ КАБЫЗУЧЫГА

Резидәкәй—гүзәл ханым—
Яшисен син Казанда.
Уйга калып утырамын,
Исемеңне язам да.

Рәхәтләнеп көлүләрең,
Шаян сүз белүләрен,
Кайчагында кайгыргалап,
Моңаеп йөрүләрен—

Сина һәммәсе килешә,
Әй сенлебез Резидә,
«Таныш моңнар» диеп язды
Сине Илдар Юзи дә.

Күзләрнен нурын кабыза,
Йөрәгең жылы синен,
Һәркемгә шифасы тия,
Алтындыр кулын синен.

Шигырьне Резидә Шәүкәтовна моңаеп тыңлады. Мин аның хакында әсәр язачагымны әйттем, сораша башладым. Әсәр язуга ул каршы килсә дә, мин сораган сорауларга жавап бирде.

—Әтиегез, аңлашыла, Шәүкәттер инде. Чөнки сезгә «Резидә Шәүкәтовна» дип дәшәбез. Кайда эшли, кем булып?.. Әһә, институтта доцент. Ничә яшендә... 1930 елгымыни? Миннән биш яшькә яшьрәк икән. Энегез бардыр инде?

—Ә сез каян белдегез?

—Акыллы кеше бер бала белән генә тuктамас. Икенчесе—мотлак—ир бала була. Күп кешенеке шулай.

—Әйе, дөрес сукалыйсыз: энем бар. Искәндәр исемле.

—Әниегезнең кем булуын әйтмәдегез?

—Әнием Румана исемле, жәннәт жимеше дигән сүз бугай. Хирург булып эшли.

Ул китәргә ашыга башлады.

Хәзер сәгать кичке жиде. Дәрвишләр бистәсенә тикле кайтып житәсе дә, ял итәсе дә бар аның. Иртәгә сәгать тугызда тагын эш башлыйсы ич!

Без аны кыстамадык. Кыстата торган холкы юклыгын, эшенә төптөгәл йөрүен, намус белән эшләвен белә идек.

Озатканда аның кулын үптем.

*1996—1999 еллар.*

*Рашат Низамиевка 50 яшь*

# ҮЗ ЙОЛДЫЗЫ БАР

Егерменче гасырның кыл уртасында туып, быел үзләренең 50 яшьлек бәйрәмнәрен уздырырга җыенучы әдипләребез күп түгел икән безнең. Алар ике-өч бөртек кенә: Рашат Низамиев, Камил Кәримов, Фәүзия Бәйрәмова. Шулар арасында дөньяга «ашыгыбрак» килгәне—яз башында, 1 мартта ук туганы—Рашат Низамиев.

Саба яклары юмарт-бай табигатьле, матур як. Менә шунда, Мишә суы буена урнашкан татар авылы Олы Мишәдәге бер гаиләдә бер ир бала тәүге тапкыр дөньяга аваз сала. Малайның әтисе, Бөек Ватан сугышында бер кулын калдырып кайткан Мияссәр нык шатлангандыр. Шатланмыйча соң—малай бит! Малай! Нәсел дәвам-чысы. Үсеп житкәч, бер кулсыз әтисенә терәк-булышчы буласы «жегет»!

Рашат Низамиев бер шигырендә болай яза:

> Таза беләгеңне терсәктән үк
> Чабып өзгән сугыш балтасы.
> Сыңар канат белән кайткансың да
> Елаткансың... басу капкасын.

«Сыңар канат белән кайтканнарны да» зарыгып көтеп торучы кызларыбыз булган. Озакламый Мияссәр дә үз тиңен тапкан, Асия исемле чибәр кыз белән тормыш корып җибәргән. Ә ул еллардагы авыл тормышы... «Авыл тормышы—эт тормышы» дип зарланып утырыр вакыт түгел. Яшәргә кирәк. Һәм Мияссәр яши.

> Исән кулың, җиңеп кайткан кулың,
> Үч иткәндәй вәхши сугышка,
> Ничә еллар инде балта чаба:
> Тирә-ягың—ап-ак йомычка!
> ... Кырыс чагың—гүя кайгыларны
> Тураклыйсың салып бүкәнгә.
> Сыңар куллап печән чабасың син...
> Алып көче бардыр бу тәндә!

Шигырен Рашат:

> Әткәйләрнең кулын кискән фашист,
> Илнең кулын кисә алмаган!—

дигән юллар белән тәмамлый. Сугыш кырларыннан яраланып-имгәнеп кайтсалар да, тәннәрендә «Алып көче» булган ир-атларның уллары ул Рашат Низамиевлар буыны.

Минем белән бергә Минзәлә педагогия училищесын тәмамлаган шәриктәшем Фәһим Җәләев Саба районының Икшермә урта мәктәбендә директор иде. Районда бик абруйлы, данлы директор. Казанда күрешүләребезнең берсендә (алтмышынчы еллар уртасы булса кирәк), әдәбият турында сүз чыгып, ул: «Безнең мәктәптә дә «шигырь җене» кагылган укучылар бар. Берсе бик тиктормас, тере егет. Ул университетка килергә җыена, белүемчә. Син аңа игътибар ит әле, Рашат Низамиев атлы ул»—дигән иде.

Шәриктәш дусның сүзен аяк астында калдырырга һич ярамый иде. Һәм мин университет студентлары арасыннан Рашат Низамиевны аерып алып, аңа «игътибар итә» башладым. Гажәеп тере-эшчән, тиктормас холык-табигате өчен яратып, үзен «терекөмеш» дип тә йөртәм. Гажәп хәл! Рашат Низамиевның Рәсәй күгендә һәлак булган абыйсы Җәүдәт Низамиевның якты истәлегенә багышлап язган «Кызыл кар яугач» исемле моңсу-сагышлы повестенда да шундый юллар бар: «Син бит терекөмеш

шикеллерәк. Кая китсәң дә югалмассын. Чәчрәп килеп чыгарсын»,—ди әсәр героена бер персонаж. Рашат Низамиев үзе дә—иҗатында булсын, тормышта булсын, әнә шулай «чәчрәп килеп чыга» торган затлардан.

Рашат Низамиев Казан дәүләт университетын уңышлы тәмамлап, бер-ике ел авылда укытып та кайтты. Бик еш булмаса да, шигырьләре газет-журнал битләрендә күренә торды. Җитмешенче еллар уртасыннан ул инде башы-аягы белән журналистлык эшенә кереп чумды. Әүвәле күптиражлы «Ленинчы», аннары «Татарстан яшьләре» газеталарында, балалар журналы «Ялкын»да, «Казан утлары» журналында төрле вазифалар башкарды. Хәзер инде Рашат Низамиев яшьләр журналы «Идел»нең баш мөхәррире. Танылган әдип.

Рашат Низамиевның иҗаты күпкырлы. Шигырь дисеңме, ялкынлы публицистика дисеңме, хикәя-повестьлар дисеңме—аның каләме барысын да «коеп куя». Үзенең илле яшьлек бәйрәмен Рашат композитор Фәрит Яруллин турындагы роман-хроникасының тулыландырылган яңа басмасы белән каршылый. Элекке елларда, романның беренче басмасы басылып чыккан чакта әйтелеп бетмәгәнне, дөресрәге, «әйтергә ярамаганны» әйтеп бетерү өчен шул нияткә килгән Рашат Низамиев.

Күпчелек әдипләребез кебек, Рашат та иҗатын шигырьләрдән башлаган иде. Бүген дә шигъриятгән китеп беткәне юк: әледән-әле яңа шигырьләрен укып торабыз.

Әмма шулай да, минемчә, Рашат Низамиевның төп иҗаты—чәчмә әсәрләр, проза. Бигрәк тә соңгы елларда ул хикәя жанрында аеруча актив эшли һәм менә дигән хикәяләр иҗат итә. Шулардан берничәсен, татар хикәяләре хәзинәсенә кереп калырлыкларын гына атап үтик. Менә алар: «Билгесез кыз сурәте», «Беренче мунча», «Кайтарыгыз!», «Өчәү» һәм башкалар.

Рашат Низамиевлар буыны, Егерменче гасырны кыл уртага ярып, Егерме беренче гасырга аяк басачак буын. Әле Зур Сугышларны күрмәгән, әтиләре яудан сирәк исән-сау кайтканнан соң туып-үскән буын. Алар бер гасырдан икенче гасырга ил-халыкның, кешелек дөньясының нинди уй-гамәлләрен эстафета итеп алып китәчәк? Бу гасырда алар ил-халык ни күрсә, шуны күреп үсте, ныгыды, ир-егетләр булды. Алар «Бөек Россия» империясенең дәвамчысы булган «Бөек» Советлар Союзында яшәп формалаштылар, СССРның бер сәгать эчендә диярлек таркалып-җимерелеп төшүен күрделәр. Хәзер инде менә ил-халыкны «үзгәртеп кору», «реформа-ислах» шигарьләре белән Россиянең,—димәк, халыкның!—байлыгын талап, шул халыкны тәмам ач-ялангач калдырып бөлгенлеккә төшергән, илне исә, Көнбатыш Европа һәм Америка алдында тезләндереп, хәер сорап кул сузарга мәҗбүр иткән «реформатор-демократларның» гаделсез «кыргый базары» шартларында бөргәләнәләр.

Шуңа күрәдер дә, яшь замандашына эндәшеп, Рашат Низамиев болай яза: «Егерме беренче гасырга керер алдыннан, күпләр белән бергә, тормыш океаны төпкеленнән вакыт сине дә сайлап алган, хәзер инде яшәү рәвеше, кылган гамәлләре белән сезнең буын (Рашатларның үз буыны да, дип өстәр идем.—М. Ш.) вакытны сайлый, кешелек тарихына теркәләчәк көннәрне иҗат итә».

Мөгаен, шулайдыр. Һәм Рашат Низамиев үзе дә без яшәгән гасырның барлык борчу-мәшәкатьләрен, хәзерге катлаулы-болгавыр заманның бар авыр йөген үз җилкәсенә күтәреп барырга дучар ителгән шул буынның бер вәкиледер.

Ә шәхсән Рашат Низамиев иҗаты башлангыч чорыннан ук гаделлеккә, гүзәллеккә, кешенең камиллегенә мәдхия җырлау булды. Һәм шулай булып кала да бирә. Җинелмә аңа, саф-самими, бала җанлы бу романтикка? Әлбәттә, җиңел түгел. Әмма шулай булса да, минем Рашатның борын төшергәнен, төшенкелеккә бирелгәнен күргәнем юк. Ул һаман—терекөмеш! Хәрәкәтчән, житез, эшчән.

Аның «Яшьлеккә хат» (Яшь замандаш белән әңгәмәләр) дигән фәлсәфи-публицистик, үгет-нәсыйхәткә корылган педагогик әсәрендә (1991) бик кызыклы күзәтүләр, уй-фикерләр бар. Менә шунда ул: «Кеше—үзе бер мөстәкыйль дәүләт» дигән девиз-шигарь күтәрә дә, кешегә хас уңай һәм кимчелекле сыйфатларны ике баганага тезеп чыга. Һәр баганада—унбишәр сүз-сыйфат. Уңай сыйфатлардан мин бары тик өчесен генә Рашатның үзенә ярашлы тапмадым. Ягымлы, туры, юмарт—Рашат. Ихлас, гадел, тырыш—Рашат. Ярдәмчел, булдыклы, хисчән—Рашат. Итагатьле, кешелекле, тәвәккәл—Рашат. Тәвәккәл, дигәннән, күптән түгел ул, берниндн күнегүләрсез, кул яссуы белән кирпеч ватарга омтылып, кулын имгәтте һәм шул килеш эшкә йөрде! Менә шулай. Аның бар иҗатына да шул ук сыйфатлар хас.

Ә инде «Яшьлеккә хат» (Яшь замандаш белән әңгәмәләр) әсәренә килгәндә, ул үзенә күрә бер феномен—безнең әдәбиятта әле моңа кадәр күрелмәгән бер күренеш. Әсәр үзе җиде хаттан тора. Һәр хат аерым бер темага багышланган. «Онытма,—ди автор яшь замандашына,—бу хатлар ашыгып укыр өчен түгел!» Беренче хатта сүз кешенең шәхесен калыплаштыру турында барса (аның өчен төп өч шарт: нәселдәнлек, мохит, тәрбия кирәк икән), икенче хатта «үз-үзенне сайлау, язмышын йолдызын билгеләү турында сөйләшик»,—ди Рашат. Сүз уңаенда әйтеп узыйк, «йолдыз» символына без яңадан әйләнеп кайтырбыз әле. Өченче хат яшьлектә иң беренче урында булган мәхәббәт, ярату хисе турында, әлбәттә! Дүртенче хат, мәхәббәттән аерып алып, дуслык турында сөйләшү булып чыккан. Бишенче хатта—яхшылык белән яманлык бәхәсе. Алтынчы хатта автор хакыйкатькә юл эзли һәм шул хакта уйлана, фикер йөртә, нәтиҗәләр ясый. Җиденче, соңгы хат—йомгаклау сүзе. Бу әсәрдәге һәр җөмләне диярлек канатлы, гыйбрәтле сүзләр итеп алырга булыр иде. Менә кайберләре: «Кеше кешегә—табышмак...» «... иң мөһиме—ихласлык», «матурлыкка күз кирәк, дөреслеккә сүз кирәк», «Үзеңдә юк нәрсәне башкаларга биреп булмый» һ. б., һ. б.—кыскасы, һәр бит саен шундый җәүһәрләр очрап кына тора.

Минем үземә калса, бу әсәрне безнең Мәгариф министрлыгы аерым китапчык итеп бастырып, укытучыларга тәрбия сәгатьләре үткәрү өчен ярдәмлек сыйфатында таратыр иде. Шундый хезмәт ул.

Рашат Низамиевнын тетрәндергеч әрнүле «Кызыл кар яугач» исемле повесте, әйтеп үткәнемчә, Әфганстанда барган сугышларда һәлак булган татар егетенең якты истәлегенә багышланган. Повестьның баш герое Шаһинур: «Мин кайчан йолдызларны тотып-тотып карармын икән?»—дип хыяллана. Өлкәннәр аның һәр хыялына: «Кызыл кар яугач...»—дип кенә җавап бирәләр. Күршесе Кирам абыйның: «Без сине кайдан, ничек эзләп табарбыз икән соң?»—дигән соравына да Шаһинур: «Йолдызлар арасыннан»,—дип җавап бирә. Шаһинурның хыяллары тормышка аша—ул очучы була. Һәм, ниһаять, аңлашылмаган Әфган сугышы... Шаһинурның очкычын бәреп төшерәләр. Менә шунда, битен-күзен кан каплаган Шаһинур алдында «кызыл кар ява» ... Цинк табутта авылына кайтарылган егетне җирләгәндә мулла абзый: «Ходай бу егетне сөеп бирде, сөеп алды...»—дип, аның рухына дога укый. Ә Кирам абый исә: «Йолдызлар арасыннан эзләгез мине, дигән иде бит, балакаем! Шулкадәр дә белеп әйткән икән...»—дип яшь коя.

Тарихчылар сүзенә караганда, егерменче гасырның бер генә көне дә җир шарында кайда булса да сугышларсыз үтмәгән икән. Инде кешелек дөньясы канга туйган булырга тиеш, Егерме беренче гасырны сугышларсыз, имин-тыныч яшәп үткәрү турында уйларга тиеш!

Ә йолдызларга килгәндә исә, Рашат Низамиев иҗатының иң төп символ-образларыннан ул. Аның иҗатында йолдызлар образы әсәрдән-әсәргә көчәеп, өзелмәс бер яктылык-нур булып бара. Шул ук «Кызыл кар яугач» повестенда—«Шаһинурның күнелендә мәхәббәт йолдызы кабынган иде: Мөслимә...». Шунда ук: «Ике йөрәк аңлашканда йолдыз атыла икән, бу—гомернең кыскалыгына ишарә, аның кадерен белегез, дигән кисәтү билгесе. «Бозлы миләшләр» («Кар кеше») повесте (1990). Әтисез ятим үскән малай Госман Кар кешене эзләп Арктикага дип юлга чыга. Кар кеше—малайның күңел түрендәге әтисе ул. «Ул бүген хыялына һәм йолдызларга якыная төште шикелле..»—дип яза Рашат.

Һәм, ниһаять килеп, Рашат Низамиевның беренче шигырьләр китабы ук «Йолдыз яңгыры» (1980) дип атала иде. Әйдәгез әле, «йолдыз яңгыры» астында без дә «коенып чыгыйк»—Рашатның шигърият күгенә бераз күз салыйк.

«Яшьлеккә хат» исемле әсәрендә Рашат Низамиев: «Кеше елмаюдан башла-на»,—дип яза, дигән идек. Ул үзе дә һәрвакыт көләч, гел елмаючан икәнен дә искәртеп уздык. Әмма үзенең программ шигырендә үк ул безне кисәтеп куя:

Күзләрем көлеп торса да,
Сүзләрем җитди минем,—ди.

Ә «йолдыз яңгыры» явып тора:

Тукайдан соң
Күпме йолдызлар атылган.
*«Бирче, дөнья!»*

Окоп туфрагына чигелеп,
Күпме йолдыз калды сибелеп.

*«Солдат каешы».*

Җирдә безгә шатлык җитә.
Күкләрдә йолдыз җитә...

*«Безнең гөнаһсыз гомерләр».*

Һаваларда—кеше эзе...
Йолдызлар уйда, сакта...

*«Эзләр».*

Баш очымда һаман шул йолдызлар—
Малай чакнын идиллиясе!
Кулым җитми калган йолдызларга
Килә бары «рәхмәт» диясем.

*«Йолдызлар».*

Салкын кышның зәңгәр йолдызларын
Коя буран!

*«Кышкы сагыну».*

Җитәрдер. Әле болардан тыш та дистәләгән шигырь-хикәяләрдән әллә никадәр йолдызлар «чүпләргә» булыр иде. Начармы бу, әллә яхшы фалмы? Гадәттә безнең тәнкыйть бер үк образ-символларны күп кабатлауны хупламый. Ә ни өчен? Билгесез. Карагыз сез шул ук Есенин шигъриятенә: күпме анда ак каеннар образы! Ә бит аның иҗатын моның өчен берәү дә яманламый, киресенчә, «менә кайда ул Ватан образы!» дип мактап кына яза. Минемчә дә, һәр иҗатчының үз образ-символы булырга тиеш: кемдәдер ул—акбүзат, кемдәдер—таң җилләре, кемдәдер—илаһи күкләр... Ә менә Рашат Низамиевның үз «йолдызы» бар! Һәм мин шунысына да шикләнмим: Гагарин галәмгә менгән чорда ун-унбер яшьлек малайларның кайсысы гына йолдызларга менәргә, космонавт булырга хыялланмады икән?! Рашатның да беркемгә дә сиздермәгән-әйтмәгән хыялы шул булгандыр. Юккамыни базык-тәбәнәгрәк гәүдәле Рашат физик яктан таза, аның мускуллары уйнап тора! Әз күнегүләр ясамагандыр ул моның өчен...

Йолдызлар хакында шуның белән шул.

«Сабантуй»—балалар һәм яшүсмерләр газетасы. Һәм ул бер бик тә кирәкле, изге эш башкарып килә: «Безнең яраткан әдипләребез» дигән баш астында куш бит тотырып теге яки бу әдип турында шактый бай эчтәлекле һәм кызыклы сәхифәләр биреп бара. Мәктәпләр өчен никадәр кыйммәтле хәзинә бит бу!

Күбрәк иҗатын нәкъ менә балалар һәм яшүсмерләргә багышлаган Рашат Низамиевны да шулай ук куш бит тотырып бирү, әлбәттә, изге гамәл. Биредә Татарстанның халык язучылары Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, академик Тәлгат Галиуллин, әдәби тәнкыйтьчеләр Фоат Галимуллин, Салих Маннапов, Мансур Вәлиевләрнең Рашат Низамиев иҗаты турында кыска, әмма бик саллы фикерләре басылган.

Газетта әдипнең кыскача тормыш юлы, басылып чыккан китаплары исемлеге, матур-матур шигырьләре белән бергә ун фоторәсем дә бирелгән. «Сабантуй» газетының 1996 ел, 17 апрель, № 31 саны да, һичшиксез, мәктәп укучылары һәм укытучылар өчен дә зур бүләк ул.

Ә «Мәдәни җомга» атналыгының 1997 ел, 4 июль санында бирелгән шигырьләренә сүз башында Рашат Низамиев бик гыйбрәтле фикерләр әйтә: «Минемчә,—ди ул,—җәмгыятькә тазалык, яхшылык, камиллек эшләргә теләгәндә, бу миссияне президенттан алып урам себерүчеләргә кадәр бергәләп тартып барырга тиешле. Берәүләр—дәүләт урамын, икенчеләре гавам урамын чиста тотканда гына без алга таба барачакбыз. Монда инде бик зур әдәп, әхлак, тәҗрибә, гаделлек сорала. Ходай кушып, безнең моңа көчебез җитсә иде».

Рашат Низамиев үзенең бөтен иҗаты белән «гавам урамын чиста тотарга» тырышты, шундыйлар сафында булды. Аның кайсы гына повесть-хикәяләрен, шигырьләрен, кайнар публицистик мәкалә-чыгышларын алмыйк, без моның шулай

икәненә кат-кат иналырбыз. «Яшел күзле малай» исемле шигырь-балладасында да ул:

Җаны чиста булгангамы,
Дөньялар—гаҗәп якты!—

дип сокланып яза. «Җаны чиста» шагыйрь Рашат Низамиев исә «Татарстан турында моңсу җыр» исемле икенче бер шигырендә, әрнеп, болай дип уфтана:

Бу Рәсәйне бурлак сыман тартып,
Сөйрәп бару—бәхетсезлектер.

Бу инде җитлеккән, зур шагыйрь сүзләре.

Рашат Низамиевның кыска-кыска публицистик чыгышларында да («Сарыкмы, куянмы?», «Солженицынга хат» һ. б.) шул ук ачыну, әрнү, милләт язмышы өчен тирәнтен борчылу ярылып ята. Һәм ул—илле яшьлек ир-егет—шул әрнү-борчылулары белән Егерме беренче гасыр ишеген шакый. Ходай кушып, «гавам урамын чистартырга» түземлеге җитсә иде бу буынның һәм алардан соң килгән буыннарның.

«Алдынгы сафта Рашат Низамиевны күреп, сулыш кинәеп китә... Рашат үткен, әзерлекле публицист. Дөнья агышын, милләт агышын тоя ул һәм илебездәге кискен вакыйгаларга үз мөнәсәбәтен халкыбызга җиткерә бара.» Болары—Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев фикерләре.

Мәкаләбездә йолдызлар хакында шактый сүз булды. «Терекөмеш» Рашат Низамиевның үзен дә без йолдызлар арасында, татар әдәбияты күгендәге йолдызлар арасында күрәбез: ул анда үз төсмерләре, үз нуры белән балкып тора.

Иҗат йолдызларың сүнмәсен, халкыбызга рух биреп озак-озак еллар янып торсын, Рашат!

**Марс ШАБАЕВ**



# Рашат Низамиев

## АЧАМ ЕЛЛАР ДӘФТӘРЕН

### Колын

**Биеп торган нәзек бәкәлләре**
**Кояш нурларында елтырый.**
**Әллә инде кыңгырау чәчәкләре**
**Тоякларга тиеп чылтырый?**

**Офыкларга карап кешни колын,**
**Үзәннәргә көмеш чың ята.**
**Кушыла да курай моңы белән**
**Чал тауларны барып уята.**

Күзли малай колын тыпырдавын:
Киләчәге, өмете—шуңарда.
Чаптарына диган чуклы йөгән
Күптән эленеп тора чоланда!

*1967.*

## Диңгез белән танышу

Инештәге бозлар
Агып китте ерак,—
Диңгездә йөр менә
Адашып һәм елап.

«Монда дәрья, дәрья,
Юктыр иге-чиге.
Инешемнең яры
Иркенрәк иде.

Монда дөнья кысан,
Бозлар олы, эре:
Этә-төртә мине
Йөзеп килгән бере...»

*1972.*

## Вакыт белән бәхәс

Малайлыктан дәшеп, чакырып алдың,
Маңгаема җыерчыклар салдың.
Чәчләремне инде сирәклисең,
Гомер җебен көн дә тетәклисең—
Мин синеке, Вакыт...

Илһамланып якты уйлар корам,
Гасырларны җилгә каршы борам.
Дүрт фасылны меңгә төрләндерәм,
Кысылалар еллар берәм-берәм,—
Син минеке, Вакыт!

*1979.*

## Таш өстендә—наратлар

Саян тавы киртләч-киртләч,
Үрләр—зәңгәр камалыш.
Тып-тын яткан тауларда да
Минут саен яңарыш...

Вакытның авырлыгыннан
Чатнап куя мәгарә.
Һәм кукуруз басуына
Төшә ташлар тәгәрәп.

Самолетның күләгәсе—
Канатлы кош төслерәк:

Кыйгачлый да бәреп керә
Чал наратлар өстенә.

Ташта үскән наратларга
Карап тордым озаклап,—
Тамырлары белән тауны
Куйганнар бит «йозаклап».

Бардыр, Саян, серле капкаң,
Ачылсын ул, ачылсын;
Төптә яткан дастаннарың
Ак җыр булып чәчелсен!

*Тува. 1980.*

## Һәйкәл

*Нәкый ага Исәнбәт белән очрашкач...*

Халыкның бәгырь түреннән
Җыеп сүзне, фикерне,—
Халыкка һәйкәл салды ул
Оста сынчы шикелле.

Зиһен ягын Ходай биргән,
Гыйлем ягын—мәдрәсә.
Берүзендә әллә ничә
Институт ләбаса!

Хәзинә булып тезелгән
Киштә-киштә томнары.
Һай, ашыгып ата да соң
Фани дөнья таңнары!

Нәкый ага күзләрендә
Күрсәк әгәр моңсулык—
Бу бөек бер сызланудыр,
Уйланудыр борчылып:

«Бар куәткә җиктем микән
Гомеремнең көчләрен?
Дөньялыкта ятып кала
Эшләнмәгән эшләрем...»

Халыкның үзеннән җыеп
Җырны, сүзне, фикерне,—
Үзенә дә һәйкәл салды
Оста сынчы шикелле.

*1991.*

## «Тоткын»

Ничәнче көн, ничәнче төн инде
Бәргәләнә җаным, үртәлә—
Үзем теләп, үз кулларым белән
Килеп каптым менә «төрмә»гә!

Чәнечкеле тимерчыбык белән
Чорналмаган юкса көннәрем:
Йөрәкне тик кадап-кадап ала
Роза гөлнең чәнечкеләре...

Бар гаебем шунда булса кирәк:
Сикергәнмен кайнар упкынга,—
Мәхәббәткә дучар ителдем дә
Әвереләдем сәер тоткынга.

Тоткын икән, тоткын язмышыдыр—
Тамчы суга көн дә тилмерәм,

Бер тамчы су белән гомеремне
Озынайтсаң икән, бер генәм!

Сакчылар юк, әмма билгесезлек
Басып тора безнең арада.
Коткар мине сөю төрмәсеннән,
Әсирлектән, зинһар, арала!

Хәер, нигә мине араларга
Тоткынлыктан, мондый газаптан?
Мең кат янгач кына
Үз-үземә
Хөкем чыгарырмын азактан...

*1996.*

## Фатих Кәрим истәлегенә

Берәм-берәм татар егетләрен
Күңелемнән бүген барлыймын.
Беларусьта ятып калган әнә
Композитор Фәрит Яруллин.

Концлагерь тимерчыбыклары
Бар Европа буйлап җәелгән.
Шул чыбыкны җыры белән өзде
Алиш, Курмаш, Муса Җәлилләр.

Шагыйрьләрнең күңел капкасына
Афәт җиле һәрчак бәрелгән!
Рәсәй өчен сугыш утларында
Дөрләп янды Фатих Кәримнәр.

Күпме җирне мәскәүлеләр өчен,
Әй татарым, сугышып алдың син.
Өзелә үзәк: нигә инде хәзер
Үз-үзеңне яклый алмыйсың?

Әй син, халкым,
Шундый егетләрең,
Батырларың була торып та,
Кайчан инде, кайчан үз хакыңны
Даулый белерсең син тарихта?
Тарихта...

*1999.*

## Февраль

Түбәгә җиткерде көртләрне,
Лапаска качырды этләрне.

Инешләр-елгалар боз гына,
Урамда җил-буран сызгыра.

Калтырый сыерчык оясы—
Кар белән тулгандыр дөньясы.

Бакчада шыкырдый саескан,
Көн инде язларга авышкан.

Усал кыш күтәрер чаңгысын,
Песнәкләр җырында—язгы чың!

*1986.*

## Әнкәй гөлләре

*Яңгыр юып киткән тәрәзәгә*
*Шомырт яфраклары ым какты.*
*Тәрәзәне әй ачарга тели*
*Чүлмәктәге гөлләр шулчакны!*

Балачак хатирәсе.

Шыбыр-шыбыр яңгыр тамчылары
Төшә башладымы аз гына.
Тезеп-тезеп куя иде әнкәй
Һәрбер гөлен яңгыр астына.

Тезелешеп гөлләр чыкканнан соң
Ишегалды китә ямьләнеп.
Кул чәбәкләп котлый гөлъяфраклар
Кинәт килгән яңгыр бәйрәмен.

Белгән әнкәй: чыныксыннар диеп
Яңгыр асларына җибәргән.
Шуңа да бит кайчак яшен исе
Аңкый иде безнең гөлләрдән.

Төрле якка атылышып киттек,
Атыныша торгач таганда.
«Хәерле юл, балам!»—дигәннәрең
Истә, әнкәй, истә һаман да.

Кар-бураннар, яңгыр асларында
Без дә байтак йөрдек чыланып.
Башын түгел, ташын әйләндердек
Әлмисактан калган дөньяның.

Битләр пешә иде эсселектән,
Туңган чаклар булды суыктан.
Аягүрә басып кала белдек—
Без чыныккан инде, чыныккан!

Тормыш яңгырлары юды безне
Камчылап та, кайчак назлап та.
Рәхмәт, әнкәй, дучар иткәнсең син
Яшәү дигән татлы газапка.

...Тәрәзәмдә яңгыр. Таң җилләре
Туган яктан сәлам китергән.
Тормыш тагын үзенә дәшә мине,
Без яшәргә дучар ителгән!

*1998.*

## Тәкъдир

Мин китмәкче булам... Тормыш исә
Үҗәтләнеп тота якадан.
Ничәнче кат инде шушы көрәш
Сүнә, туктый, дөрли яңадан!

Сары таңнар чорнап алган чакта
Әвереләм сырхау кешегә.
Ут эчендә әрнеп тибә йөрәк,
Йә суыктан җаным күшегә.

Еш сискәнеп китәм юлыкканда
Агач битле сөмсез бәндәгә.
Кинәт кенә Җирнең киләчәге
Шулар сурәтендә шәйләнә.

Тук чырайлы, шома битле затлар
Бәйрәм итә, көн дә туй ясый.
Ил түрендә мыжгып тора әнә
Мәкер, ялган, иблис оясы.

Мәңгелектән очкын чәчри безгә—
Кыелып кына йолдыз атыла.
Илләр белән илләр бер-беренә
Канлы кылычларын батыра.

«Ахырзаман!» диеп өркетәләр,
Уйный күктә тәкъдир камчысы.
Күңелләрдә—бушлык, битарафлык,
Ахырзаман шулдыр, ахрысы.

Заман йөген кемнәр тартып бара,
Татар йөген кемнәр тартачак?
Туган телне, җирне коткармасак,
Ил корабы төпкә батачак.

Туу белән авыр сәфәрдә без,
Барыр юллар—ташлы, бормалы.
Дөнья буйлап
Үземне дә сөйрәп барам...—
Гап-гади бер татар бурлагы.

Җилкәләрне кисеп керә аркан,
Күкрәкләргә тозлы җил бәрә.
Офыкларда—кара болыт явы...
Ниләр көтә безне иртәгә?

*1999*

# *Яңа исемнәр*

*Беренче җөмләнең, башлап китүнең проза өчен ни дәрәҗәдә мөһим булуы турында инде байтак кына язмаларда басым ясап әйтелде. Чәчмә әдәбият осталары Г. Ибраһимов, Ә. Еники әсәрләреннән китерелгән онытылмас мисаллар барыбызның да хәтерендә... Айгөл Әхмәтгалиева, бәлки, аларны укымагандыр да, ләкин аның нечкә тоемлы иҗатчы күңеле язу эшендәге әнә шул дөрес юлны күреп алган—журналыбызда басыла торган беренче хикәясен ул үзәк өзгеч җырдан башлап китә. Җырның бәгырьне әтә торган сүзләре белән укучы дикъкатен җәлеп итә дә бүгенге авыл тормышының гыйбрәтле күренешләрен нечкә психологик алымнар һәм төгәл тотып алынган детальләр ярдәмендә тасвир кыла башлый. Әйе, яшь язучының теле дә матур, сыгылмалы, образлы—ләкин, шулай да, мине, барыннан да бигрәк, аның дөньяны тою, сизү, күрү тирәнлеге, нечкәлеге сокландырды. Икенче төрле итеп әйтсәк, аның үзенең рухи дөньясының камиллеге, байлыгы. Нәкъ менә шушы эчке хәзинә бит инде каләм иясен гел-гел иҗатка рухландырына, күңелен мәңгелек иҗади ут ялкынында тота. Безнең бик күп яшь язучыларыбызга бүген эчке байлык—рухи байлык—җитми кебек...*

*Айгөлнең бу хикәясенең бетүе дә тетрәндергеч: «Чөнки адәм балаларының берсе дә еламый иде»—дип тәмамлый ул әсәрен.Менә шушылай дип, гаять уйландыргыч хөкем чыгарып саубуллашуда да иҗатчы шәхеснең кемлеге бик яхшы күренә түгелме?!*

*Айгөл 1973 елда Актаныш районының Качкын авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң Казан дәүләт университетының татар теле, әдәбияты, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетына укырга керә. Хезмәт юлының тәүге сукмагы—«Мәгърифәт» газетасы. Яр Чаллыга кайткач, «Нур» газетасына эшкә урнаша. 1995 елдан Яр Чаллы дәүләт педагогия институтының филология факультетында эшли башлый.*

*Шигырьләре, хикәяләре элегрәк «Яшь ленинчы»да, «Ялкын»да басылган.*

Мансур ВӘЛИ

*



## Айгөл Әхмәтгалиева

# СОҢГЫ ӨМЕТ

Баш куям тезләренә лә,
Яшь коям эзләренә...

Карчыкның ишетелер-ишетелмәс кенә моңланып утыруын көтелмәгән чәрелдек тавыш бүлде:

—Әтекәйгенәм, әллә баскычта йоклап утырасың инде, Шәмсенурттәй? Мәрткә китмәгәнсендер бит?

Гомергә чорсыз булды шушы Фәгыйлә, исәнлек-саулык сорашмас, теленә килгән беренче сүзен тәгәрәтеп төшерергә ашыгыр.

—Хәл генә алып утырам ла, Фәгыйлә күрше... Йомышын килендә булса, ул эштән кайтып житмәде бит әле.

Шәмсенур карчык теле-телгә йокмас бу хатынны әлләни өнәп бетерми иде, шуна да сүзне озакка сузарга теләмәде.

—Юк ла, Шәмсенурттәй, бу юлы синең янга керешем ие. Менәтерәк, котылдым теге албастыдан дигән идем—котылырсың, бар! Кабердә ятып та тынгылык күрсәтәсе юк икән. Төн буе төшемә кереп йөдәтә, саташып бетәм, кыйнап ташлагандай уянам иртән... Шулай инде, бәхетеңне бер сыер сөзсә, көтү көткән акчаңны да жыеп ала алмассың, ди минем Нурислам. Кешеләр, хәер бирергә кирәк дигәч, сиңа кергәниием, үзең белгәнчә укыштырып карачәле, котылмам микән шул пәридән!

—Инде гүр иясе булган бианаңны ямьсез сүзләр белән искә алма, килен! Холкы керделе-чыктылы булса да, Фатиха начар кеше түгел иде, Ходай урынын жәннәттән бирсен.

—Китчәле, Шәмсенурттәй, син дә сөйләп торма инде. Аның ишеләр дә жәннәткә үрмәләсә, синең урының кайда булыр микән соң? Гомерең буе намазлык өстеннән төшмәдең. Ә безнеке-е-е...—Фәгыйлә, сөйләмәсәнә дигәндәй, кулын ачу белән читкә селтәп алды. Бианасын искә төшерү аның эчендәге бөтен женнәрен берьюлы кузгата иде, ахрысы. Хатын усалланып, ямьсезләнеп китте.

—Аның кыланмышлары соң... Дояркалар эштән кайтыр вакыт житкәнен көтәр ие дә, ыштан балакларын сызганып, итәген ике якка кыстырып, поф-поф килеп, әй тотыныр ие баскыч юарга! Янәсә, күрегез, киленем идән юарга да ярамый минем... Тфү! Шул баскычның ике сайгагын юешләп куя иде шунда. Өйгә керсән! Аркылысын алып буйга да куймаган була. Ярар, сүләсәң сүз бетмәс инде ул, хәеремне ал да, үзең дога кылырсың, Шәмсенурттәй, яме.

—Ачуланма, Фәгыйлә, булдырып булмас,—диде хатынның такылдавыннан туярга өлгергән Шәмсенур әби,—әллә нишләп бу араларда зиһенем чуалып тора, догаларны да буташтыра башладым. Алай бик теләсәң, әнә Гөлчирә катына барып кара, мәрхүмә бианаңның рухына багышлап дога кылыр.

Әйтерсең, тамагына кылчык кадалды Фәгыйләнең, «ык» дигән аваз чыгарды да, тынсыз калды. Тик аның бу халәте озакка сузылмады, ул гадәтенчә, автоматтан сиптергәндәй, тыкы-тыкы килә башлады.

—Мыскыл итүеңме бу-у?—диде, суза төшеп.—Гөлчирә дә абыстай булсын имеш, акылын аракысына кушып эчеп бетермәгән булса гына инде. Берәр чәкүшкәлек сәдака эләкмәс микән дип, бит сыпырып утырадыр. Әкрен тамганны салып бирсәм, минем Нурисламым үзе дә майтарып ташлый аны.

—Үткән эшкә салават, Гөлчирәне тикшергәнче...—«Үзенә бер карасаң икән син» дип өстәмәкче иде Шәмсенур әби, тыелып калды. Фәгыйлә дә: «Синең белән сөйләнеп торган мин жүләр» дип уйлап куйды да, ничек кергән булса, шулай пырылдап чыгып та китте.

Чынлап та, соңгы вакытларда Шәмсенур карчыкка әлләни булды: сүзгә саранайды, сүлпәнләнде, янагына таянып, көннәр буе тәрәзәгә багып утырырга гадәтләнде. Моңарчы иртәдән кичкә кадәр карчыкның, (үзе үк әйтмешли, әби патшаның) әле бу, әле теге әмере яңгырап торган йортта сәер тынлык урнашты. Болай да колакка каты иде, ишетүе бөтенләй начарайды. Хәер, бер үк соравын кабатлый-кабатлый сабыр савыты тәмам тулган килене артыграк кычкырып жибәрсә:

—Ниемә дип ул хәтле акырасың, саңгырау кеше бармы әллә?—диярге дә күп сорамый үзе. Гомер булмаганны, авыз эченнән жыру көйләп йөри башлады. Ничә карасаң да бер үк сүзләрне кабатлый иде карчык:

Баш куям тезләренә лә,
Яшь коям эзләренә...

Улы Галиулла да, килене Кәшифә дә Шәмсенур әбинең бу кыланышына башта әлләни әһәмият бирмәделәр, ләкин моңа кадәр биш вакыт намазның берсен калдырмаган әниләренең болай жырлап йөрүе сәер, бик сәер иде.

—Әнкәй, алай-болай чирләмисеңдер бит?—дип сорыйсы итте Кәшифә беркөн.

Шул сүзгә балалар кебек үксеп елап җибәрде карчык:

—Әллә нәрсәкәй генә булды шул, килен... Чынлап та, чирләп киттем бугай. Менә, атагыз Сафиулла белән ашлык сугарга барырмын дигән идем, берүзе генә китте, бахырым. Эчләрем өзелә бит шуны кызганып, авыр булыр инде ялгызына.

—Ни сөйлəвең бу, әнкәй? Нинди әтәй, нинди ашлык?

—Соң, атагыз Сафиулланы әйтәм бит. Җитмәсә, җылы оекбашын да алырга оныткан. Булмаса, кичкырын үзем илтеп кайтыйм микән әллә?

Кәшифә, кисеп аударгандай лап итеп урындыкка утырды—Шәмсенур әби акылыннан язган иде.

Тугызынчы дистәне ваклый башласа да, Шәмсенур карчык, килене әйтмешли, җен кебек таза иде әле: хуҗалыктагы бөтен нәрсәгә житешә, су сибә-сибә бакча җиләге үстерә, кош-кортын тәрбияли, ә дигәнче оекбаш-бияләен бәйләп ташлый. Күзе дә яшьләрне көнләштерерлек, кирәгенне дә, кирәкмәгәнен дә, ай, шәп күрә иде! Улы, килене, оныклары күзлек киеп телевизор алдына килеп тезелгәндә, ул, ишек буенда җеп эрләп утырган җиреннән:

—Әй Аллам, бу агач аяклы адәмне кичә дә асып үтергәннәр ие бит, бүген тагын асып маташалар, ни галәмәт,—дип, аһ-ваһ килеп ала.

—Кичәге серияне кабатлап күрсәтәләр, кысылмый гына утыр әле, әнкәй, ишеттермисең...—Әлбәттә, Кәшифәнең теш арасыннан сыгылып чыккан бу сүзләре әбинең колак шәрифләренә барып җитми җитүен, шулай да, киленнең зәһәр карашы бер-ике минутка телне тыярга мәҗбүр итә. Бераздан янә боерулы тавыш ишетелә.

—Галиулла улым, иртәгә бозауларга тал кисеп алып кайтырга кирәк, аскы буа янына төшәрсең, анда яшь таллар күбрәк...

—Алтмыш яшькә таба барам, алты яшьлек урынына да күрмисең, әнкәй.

Ни хикмәт, шушы кырыс, таләпчән карчык кулына Коръән китабы алса, үзгәрә дә куя! Авыз эченнән бисмилласын әйтеп, Коръәннең саргаеп, читләре теткәләнеп беткән битләрен ача да, искиткеч моңлы итеп, көйләп укып җибәрә! Бу минутларда аның еллар шаукымы төсен җуеп бетерә алмаган күзләре дә, тирән җыерчыклардан торган йөзе дә, ияк астыннан бәйләп куйган ап-ак яулыгы да башка һичкемгә күренмәгән, үзләре генә белгән нурда коена кебек.

Әй, гомерләр, диген... Бар иде бит Шәмсенур әбинең дә баскан җирендә ут уйната торган яшь, чая чаклары! Ире Сафиулла да төшеп калганнардан түгел, арыслан йөрәкле иде. Шулай булмаса, күрше авылга утырмага килгән Шәмсенурны көпә-көндез урлап качар идеме?!

Яшәгән кадәресен матур, ләкин аз, һай, аз яшәделәр! Бер-бер артлы уллары Галиулла, кызлары Зәйтүнә туып, гаиләләре түгәрәкләнде дигәндә генә сугыш башланды. «Баш куям тезләренә, яшь коям эзләренә» дип җырлый-җырлый Сафиулла да китте. Басу капкасы янындагы пар наратларга сөялеп озатып калды аны Шәмсенур. Йөрәккәйләре сизенде микән, томырылып-лар карады Сафиулласының киткән юлларына.

Насыйп булмады шул Сафиулласына кайтулар, булмады... Аның турындагы соңгы хәбәр—кара пичәтле кәгазь кисәге генә иде. Түзде Шәмсенур, тешен кысып булса да түзде. Һәр намазында Ходайдан үзенә сабырлык, балаларына иминлек, бәхет сорап ялварды, ахирәттә булса да, ире Сафиулла белән күрештерүне теләде.

Гомер сукмагының ахырына якынлашкан саен Шәмсенур әби үзенең үткәннәрен тагын да ешрак искә төшерә башлады. Аллага шөкер, чиста яшәде. Тәне генә түгел, җаны да, иманы да чиста булды. Тик ни үкенеч, иманның нәрсә икәнен балаларына да, оныкларына да төшендерә алмады. Аларга Аллаң ни дә, муллаң ни! Алларында, әнә, тилебәдәрләре булсын да, яннарында магнитафун дигәннәре үкереп утырсын! Хәтерендә, шулай бервакыт оныгы Гөлия йокларга әбисе янына яткан иде.

Ятсам, йа Алла,  
Торсам, йа Алла.

Бу йокымдин торалмасам,
Бакый иман бир, Алла.

Әбинен ишетелер-ишетелмәс кенә мөнәҗәт көйләп ятуы Гөлиягә кызык тоелды, ахыры, кыз сорыйсы итте:

—Әбекәй, синең жырын бигрәк кызык, әйме? Иман дигәнең нәрсә соң ул?

Шәмсенур карчык берара сүзсез торды. Иман китерер өчен иң элек Алланың барлыгына, берлегенә шиксез ышану, биш вакыт намазны калдырмау кирәген иплэп кенә үзенчә аңлатырга иткән иде, оныгы икенче якка әйләнде дә ятты.

—Әем, муенымнан асам дисәләр дә, төнге йокымны калдырып, дога укып утырасым юк минем!

Шәмсенур әби эндәшмәде. Авыз эченнән генә: «Тәүбә, тәүбә, йа Раббым, үзең ярлыка бу гөнаһлы балаларны» дип теләп алды. Шулай да карчыкның жанын сөендергән берәү—ике өй аша гына яшәүче Гөлчирә бар иде авылда. Бу хатынның язмышын үзенеке белән чагыштырып якын иттеме аны Шәмсенур әби, белмәссең. Югыйсә ике көннең берендә баш төзәтергә аракы теләнеп йөргән хатынны авылда берәү дә яхшы сүз белән телгә алмый иде. Әле кырык яше дә тулмаган, ләкин элекке сылулыгы жуелып, карчыклар кыяфәте кергән, күзләрендә яшәү дәрте калмаган Гөлчирәнең яшьтән үк бәхете булмады. Яратып-сөеп яшәгән беренче ире Хәлил, колхоз печәнен алып кайтканда, агач күпер жимерелеп буага чумды. Исерек булган диделәр дә, шуның белән бетте-китте. Әби патша заманында салынган ул агач күперне кем карарга тиеш булган—анысын тикшереп-нитеп тормадылар.

Шайтан суына якын да килә торган кеше түгел иде Хәлил, нахак гаеп белән кабергә төшерделәр газизен. Икенче ире исә мәрхүмнең капма-каршысы булды, кәеф-сафа ятратты. Шулай инде, иртә унмаган кич унмас, кич унмаган һич унмас! Балалары аякка гына басып килгәндә, авылда яманаты таралган Саимәгә ияреп, чыгып качты ир кисәге. Елап, яше бетте, бәгыре катты Гөлчирәнең. Кемгә алыштырды, хурлыгы ни тора бит! Иренең ниндидер могжиза белән сакланып калган шешәсенә юлыккач, онытылыйм әле бер ичмаса, диде дә... шуннан башланды. Айнырга курыкты. Айныса, аның алдында күзләрен мөлдерәтеп, әниләренең ашарга әзерләвен көтеп утырган ач балаларыннан башка берни дә юк иде. Өмет тә, ышаныч та—барысы сүнгән, жимерелгән... Биреште Гөлчирә, биреште. Сабыр канатлары бик тиз сынды. Дөрес, миенең кайсыдыр бер почмагында «бетәм бит мин болай» дигән сыек кына уй вакыт-вакыт баш калкытып куя иде. Гадәттә, андый чакларда Гөлчирә Шәмсенур әби янына кереп утыра. Жинел иде аңа бу карчык янында. Ни гажәп: үзе үк «исереккә сәлам бирмә, ул бирсә дә, син алма» дип кабатларга яраткан Шәмсенур әби Гөлчирәне читкә этәрмәде. Әллә жанын үтәли күрә идеме ул аның? Кызгана идеме... Аның намаз укыган чагына тап булса, Гөлчирә ишек тупсасына утыра да, тын гына көтә. Нәрсә уйлый ул мондый минутларда, анысын бер Ходай үзе генә белә.

... Өч ел буе күрмәгән хезмәт хакын бүген бирьюлы, житмәсә, акчалата түләячәкләр диюче булса, авыл халкы бу кадәр үк гажәпләнмәс иде. Әмма «Гөлчирә эчүен ташлаган, чәч-маңгаен ак яулык белән каплап, намаз укый башлаган» дигән хәбәрне акыл кабул итә алмады.

Ничек кенә чәйнәмәсеннәр, нәрсәгә генә юрамасыннар, Гөлчирәнең тормышы төбеннән үзгәрде. Йортына жылылык, балаларының йөзенә нур инде.

Беркөнне шулай сөт тапшырган акчасына ни дә булса алып кайтыйм дип кибеткә төшкән иде. Ул кергәндә дүрт-биш хатын сатучы Мәдинәнең авызына карап бакканнар да, шырык-шырык көлешәләр. Тегесе исә телендә сандугач сайрата, кемгәдер акыл өйрәтә иде:

—Нәмәгә аптырап калдың, гөлкәем? Соң аппараты юк дип инде, пычагымамы анысы? Олы кәстрүлең бардыр бит, беразын шуна бушат та, кәстрүл эченә, берәр нәрсәгә бастырып, бәләкәйрәк табак утырт. Олы табакка салкын су салып кәстрүлеңне капла да, эчтәгесенә иң зәһәре жыела инде, малай, шулаймы, Гөлчирә?

Гөлчирә эндәшмәде. Хатыннар янә шаулашып көлештеләр дә, сүзләрен дәвам иттеләр.

—Кичә Нәсимең салам китергән ие, Кадрия. Абау, сүгенеп тә куя инде, малай, ничек колакларын түзә икән синең?

—Әй, исен киткән иске чикмәнгә. Бер көнеккәч, аның фәләненне фәлән итим дигәннәре жаным-бәгърем булып кына ишетелә инде ул.

Янә иһаһайлап көлгән тавыш.

Йа, Раббым, моңарчы берни күрми, берни ишетми яшәлгән икән ләбаса. Күңел күзкәйләремне ачтың, Ходаем, инде моннан соң рәхмәтеңнән ташлама! Әле кайчан гына ул да нәкъ шушы хатыннар кебек иде бит. Күрче, ничек үтенне сытарлык итеп, аты-юлы белән сүгенәләр. Һәрберсенең өендә, җылы урында көмешкәсе утыра инде аларның—кемдә нинди́рәге икәнен әле дә яхшы хәтерли Гөлчирә. Абау, хәзер искә төшерсәң дә җирәнгеч!

Шулчак Мәдинә, нәрсәдер үлчәп маташкан җиреннән, эшеннән бүленми генә Гөлчирәгә эндәште:

—Карале малай, кеше көлдереп, болай кәфенгә төренгән кебек йөрмә инде, зинһар. Бөтенесе бармак төртеп күрсәтә бит үзенә. Синең ишеләр генә тәртипкә сала алса бу дөньяны, без әллә кайчан җәннәттә яшәр идек лә...

—Минем болай яшәвем үзем өчен кирәк, көләсе килгән кеше көлсен. Бер туктар әле. Үзең дөрес әйтәсең, бөтен кеше дә Ходайга иман китерсә, тәртибе, рәте булыр иде дә соң.

—Әзерләп куйганнар ди! Әнә, элек авыл кешесен үрнәк итеп куя торганнар ие. Имеш, әдәпле, ярдәмчел, инсафлы. Хәзер шул «әдәпле» авыл ирләренең яртысы төрмәдә утыра, кайсы урлашып, кайсы кеше үтереп. Хатыннарга кадәр күршесенең казын урлый бит! Яшьләрне кара инде: бар белгәннәре эчү дә сугышу, эчү дә сугышу. Кая барсыннар, колхозда да ни җүнле эше булмасын, эшләгән кешесе еллар буе акча төсе күрмәсен! Җыелып утырырга клубы да юк бит, ичмасам! Гомер булмаганны, авылны уйнашчы хатыннар басты, эте-бете гүләйт итә. Ходай булса, әзрәк тигезләр иде кешеләрне, бу кадәр мыскыл иттермәс иде, Гөлчирәкәем.

Хатыннар да сүзгә кушылдылар.

—Соң, әнә, Шәмсенурттәйне генә карагыз. Бахыр, гомер буе Аллага табынып яшәде, бүген ул акылдан язган карчыкның кемгә кирәге бар инде, җә? Әле беркөн Кәшифә сөйләп тора иде, эштән кайтуыма газ краннарын борып ачып бетергән, тын алмалы түгел иде, ди. Шырпы да сызган булса, өе-ние белән күккә очасы булган, бичара. Төн уртасы дими, торып киенә дә, Сафиулланы каршыларга барам, дип әйтә ди. Беркөн бөтен ярмаларны бергә кушып, болгатып бетергән, утырып еладым ди Кәшифә.

—Безнең бианай: «җәза бирергә теләсә, Ходай кешенең акылын алыр» дип әйтә торган иде,—дип куйды хатыннарның берсе. Гөлчирә:

—Ана түгел, балаларынадыр ул җәза. Ул мескен карчыкка нәрсә, үзенекен эшли бирә, таякның юан башы бүтәннәр җилкәсенә төшә бит, алар җәфалана,— диде дә, аласы әйберен дә алмыйча, кибеттән чыгып китте.

Хатыннарга, әйтерсең, гайбәт сатар өчен яңа җим ташланды: Шәмсенур әбидән башланган сүз йомгагы, әкрен генә сүтелә барып, һәр йортның капкасын кагып, авылның икенче урамына юнәлде.

Шәмсенур әбинең хәле исә бу көннәрдә тагын да начарланды. Тәне тазасау булса да—ул үз гомерендә томауның да нәрсә икәнен белмәде—төннәр буе ыңгырашып чыга башлады:

—Сафиулла, тәнкәйләрең сызланадыр шул, утларда янасыңдыр, сина әйтәм. Хәлләренне дә җиңеләйтә алмаем бит,ниләр кылаем... —Ул инде улы Галиулланы Сафиулласы дип белә иде. Бер төнне, йокысыннан сикереп торды да, улы белән килене яткан бүлмәгә кереп, кычкырып елап җибәрде.

—Яңа хатын алып кайткансың икән, әйтәм, яныма да ятмыйсың,—дип өзгәләнә-өзгәләнә үксергә тотынды.

Галиулла, инде ничәнче мәртәбә:

—Әнкәй, мин бит синең малаең, саташма инде,—дип әйтеп караса да, карчык аны тыңларга да теләмәде.

—Яныма ятмасаң ятма, кырыемда җыруыңны гына җырлап утыр, Сафиулла.

Баш куям тезләренә лә,
Яшь коям эзләренә...

Шулай кабатлый-кабатлый сабыйларча үксеп, йоклап та китте Шәмсенур әби.

Икенче көнне ул йокысыннан басынкыланып уянды. Телендә һаман Сафиулласы иде.

—Йөзкәйләренне бер күрсәм, тынычлап үләр идем, Сафиулла. Бүген төнлә ишек аша гына чакырдын, күрмичә дә калдым үзенне. Урлап качарга килгән булгансындыр инде, әткәй бүлмәмне бикләп куйган шул.

Килене көндез ялга кайтканда, Шәмсенур әби шкафтагы бөтен киемсалымны төенчекләргә төйнәп бетергән, үзе шуларны саклап утыра иде.

—Ярар, инәкәй, мин үзебезгә кайтып китәм инде. Сафиулла чакырды, пар ат җигеп көтеп торам, диде. Сау бул, гаепләп калма.

Кәшифә ана күзенен агын әйләндереп бер карады да, бар икән күрәселәрем дигәндәй, авыр сулап куйды.

—Бишбылтыр сугышта үлгән Сафиулланы сөйләүдән кайчан туктарсын икән, ә?—дия-дия кухня ягына узды. Солдаттагы улы Рафистан хат килгән иде, тынычлап шуны укып алмакчы булды. «Карточкасын да җибәргән булган, улыкаем. Бакчы, наратларга сөялеп төшкән. Ябыгыбрак та киткән шикелле. Әй бала, бала...» Кәшифә, кул аркасы белән дымлы күз төпләрен сөртеп алды. Хатны каткат укып чыкты да, пөхтәләп кенә конвертка салып, өстәл тартмасына тыгып куйды. Аннан сон карчыкны ашатты-эчертте һәм, тагынниләр майтарып куярсын инде, дип сөйләнә-сөйләнә эшкә китте.

Шәмсенур әби исә төенчекләрне бер сүтеп, бер төйнәп арыгач, яна шөгыль эзли башлады. Эзләнә торгач, өстәл тартмасындагы конвертка юлыкты ул. Тартып ала күрмәсеннәр тагы дигәндәй, кабалана-кабалана актарырга тотынды.

—Әстәгъфирулла, Сафиулла, син ләбаса!—Шәмсенур әби калтыранган куллары белән Рафиснын фотосын сыйпый иде. Анын берән-сәрән генә калган керфекләре яшькә чыланды, аякларынын кисәк кенә хәле китте. Карчык, үзүзен белештермичә, идәнгә чүкте.—Йа Раббым, теләкләремне кабул иттең бит, Сафиуллам белән күрештерден. Сафиулла дим, никләр бер авыз сүз дәшмисен, сиңа әйтәм? Үлгән дигән булдылар, ышанмадым. Илле елдан артык көттем бит үзенне, рәхмәт төшкере. Исән икәнсен, жанкаем. Һаман шул наратлар янында көтәсенме, мине? Исендәме, Сафиулла, жырлый-жырлый киткән идең басу капкасы буеннан:

Баш куям тезләренә лә,
Яшь коям эзләренә шул,
Әллә ниләр бирер идем,
«Аh» дигән сүзләренә...

Өзде бит үзәкләремне шул жыруын! Мин дә син киткән якларга карап күз яшьләремне әз түкмәдем. Аллага шөкер, насыйп булгач, күрештек бит менә. Наратлар янында очрашырбыз дисенме, Сафиулла?

Шәмсенур әби карточканы йөзенә якынрак китерде, яшькә чыланган яңакларына терәде.

Сафиулласына коеп куйгандай охшаган оныгынын күзләренә соңгы кабат сөеп-яратып карады да, тын калды. Әбинең йөзеннән ниндидер жинеллек, сөенеч сирпелә иде...

Шәмсенур әбине зиратка алып китәр алдыннан ишегалдына байтак кеше жыелды. Әкрен генә яңгыр тамчылары төшә башлады. Гөнаһлы бәндәләрнең күбәюеннән әрнеп, жир елый идеме, әле күкләр Шәмсенур әбине шулай күз яшьләре түгеп, соңгы юлга озаталар идеме—аңламассын. Чөнки, адәм балаларынын берсе дә еламый иде.

*Рим Идиятуллинга 60 яшь*

# «ТОРМЫШ–ХУШ ИСЛЕ БЕР ЧӘЧКӘ...»

Җирдәгеләргә бер теләк:
Төсләрне вакламагыз,
Безгә дә төшсен нурлары,—
Кояшны капламагыз!

Якташым, безнең күрше авыл—Яна Мортазада миннән бер генә ел элек—1940 елның февралендә туып үскән, егет булгач кына Уфада танышкан, Шигърият дигән тылсымлы көчкә буйсынып, яшьлекнең һәр көнен җыр итеп санаган чорларның, хыялларның шаһиты булган дустым Рим Идиятуллин шигыреннән бу юллар... Уфада узган, бары сокланудан, гаҗәп-ләнүдән генә торган, илаһи бер дөнья кебек тойган ике елымнан (1959-1961) гаҗәеп кызыклы әдәби мохит, кумир-йолдызлар саналган остазлар, шигърият гашыйклары-дуслары турында гел матур хатирәләр генә калган. Сәйфи Кудаш, Мостай Кәримне, Нәҗар Нәҗмине күргән көннәр... Бигрәк тә Әнгам Атнабайга табынган студент яшьләр... Атнабайны якыннан күреп яраттык: ул үзе дә безнең белән күбрәк аралаша иде шул. Вазыйфасы да шундый иде: татарча чыга торган зур абруйлы газетада—«Кызыл таң»да әдәбият-сәнгать бүлеге мөхәррире... җитмәсә, шул гәзит каршында яшь иҗатчылар түгәрәген җитәкли. Башлап язучылар—студентлар, ул чактагы күп «эшче-шагыйрь»ләр, инде азрак каләм чарлаган яшь әдипләр—кыскасы Башкортстан татарларының әдәби штабы кебегрәк иде бу газета һәм Атнабай булмәсе. Һәр укыган шигыре, аны сөйләүдәге тиңсез осталыгы, мыеклы шат йөзе, ирләрчә килешле матурлыгы, мәһабәт озын гәүдәсе һәм кырыслык катыш ягымлылыгы белән әсир иткән яшь «мэтр» (ул чагында утыздан гына узган!) күңелдә шулай саклана. Урыны җәннәттә була күрсен—үзе бер дөнья иде ул безнең өчен! Әйе, нәкъ менә аның сүзләренә йотылып, мөкиббән киткәнбез; остаз белән бәхәсләшү кая! Әмма бер-беребезгә бик каты бәреләбез, аяу белмибез: шигырь, поэма дип тәкъдим ителгән үрнәкләрне—ягъни үзебезне!—тетәбез генә... Бик сирәкләрне Әнгам ага үзе «иләктән аерып», яклап кала. Бер көнне шундый бәхет—ябык кына, акыллы, тыйнак күренгән яшь эшче егет Рим Идиятуллинга, аннары—без фәкыйрегезгә тиде. Рим—яңалыгы, образлы фикерләү сәләте өчен макталды, «әмма форма-калыбын тиешенчә эшләми», диелде. Мине, киресенчә, бик шома, төгәл форма, үлчәү белән хисле язып та, яңалык, фикере азрак, дип «мактадылар»... Ул кичтән—яңа шагыйрь дустымның:



Их, тормышкай! Булсаң икән
Гармундай—суза торган!—

дигән юллары хәтердә. Күректәй сузылып, җай гына бармаса да, тормышта, гел шигырь белән янып яшәлгән гомердә Рим дустым белән кырык ел инде бергә—серләшеп, киңәшләшеп, күп чакта бәхәсләшеп, уртак кумирларны онытмыйча, Казан-Уфаларда аралашып, аерылмыйча яшибез икән ләбаса! Мин Казанга күчеп

киткәндә дә колагымда анын шундый йолдызлы шигырь сурәте янгырый иде:

Үз йолдызымны тапмыйча
Күкләрдән күзем алмам...

Күз яздырмый күзлим күкне
Күзләрем яшькә тулып;
Атылды берсе арадан—
Шигырь юллары булып.

Казанда мин, «жилкәннәрне ефәк жил күтәрде, тын ярларны инде калдырам» дип, романтика шаукымына бирелгәндә, якташым Гафурилы, Бабичлы, Атнабайлы Уфамнан:

Ә мин калам... тәелеп яшьләргә:
һәм исәннәр, һәм үлгәннәр белән
Язган мина монда яшәргә!—

дигән юллары булган «программный» шигыре белән жавап бирде. Ул чакта бу шигырьнен фажигале, әчке агымлы олы мәгънәсен, әлбәттә, анламаганмын әле. Шулай булмыйча! Университетта танышкан яна дуслар—Равилләр, Шамилләр, Хатиплар, Гәрәй, Рөстәмнәр белән биек шигърият түбәләренә карап ашкынган чаклар бит. Кумирлар да инде башка—Туфаннар, Хәкимнәр... олы татар шигыренең үзәге дә монда. Ә читләрдә, илнен төрле почмакларында бөреләнгән талантлар—гөлләр, аларнын язмышы турында Казанда аз уйлыйлар иде ул вакытта. Без, Уфа—Урал татарлары, үзебез дә Казан өчен «башкорт» идек. Әмма без, үҗәтләнеп килеп, Казанны «яуладык», «үзебезгә кайтып», жан теләгәнчә, чын «татар булдык»... Әлеге Әнгам ага Атнабай да безне, Казанга китүче якташларын истә тотып, шулай язган иде бит:

Ник талантлы татар якташларым
Казаннарга китеп торып кала?
...Казаннарда татар булу жиңел,
Уфаларда татар булып кара!

Гомер буе татарча язып, залларны авызына каратып татарча шигырь укыган, татарча сөйләшүе өчен горурланып, хакы барлыгын әйтеп, Башкортстандагы миллионнан артык татар кардәшенең хокукын даулап язган Әнгам аганың иң авырткан ярасы, төзәлмәс жәрәхәте иде бу. Шуңа да ул, Уфада калып, гомере буе үзе кебек үк «Кызыл таң»да эшләгән, татар теле, әдәбиятының шундагы патриоты булган, Тукай, Такташ, Туфаннардан рухи аерылмый яшәгән каләмдәш энесе Рим Идиятуллинга теләктәш, дус булды, анын турында мәкаләләр язды.

Ә бит, әле үсмерчагында ук, Уфа татар мәктәбендә укыганда, очрашуга килгән Хәсән ага Туфан Римгә игътибар итә, шигырьләрендә яна фикри сурәтләр күреп, жылы сүзләр әйтеп канатландыра. Сонрак, 60 елларда Казанда, инде китап кульязмасы белән дә танышкач, ул аны: «Әйбәт бу», «Менә молодец!», «Талантлы шагыйрь бу!» дигән сүзләр белән язып чуарлаган иде... Әйе, Римнен Казанда калырга, 60 елларнын кайнап торган шигъри мохитенә керергә мөмкинлеге бар иде. Равил Фәйзуллин, Ренат Харислар белән уртак тел тапты ул, ирекле шигырь белән дә мавыкты, классик калыпларны да онытмады—эзләнде, күп язды... Сибгат ага Хәким, Илдар Юзеевлар да поэзия секциясендә анын булачак китабын хупладылар, ак юл теләделәр. «Казан утлары»нда ул үзе дә: «Мәхәббәтле Казан! Мәрхәмәтле бул!» дигән дога-сүз белән, зур өметләр баглап, шигырьләрен бастырды. «Беренче карлыгачлар» сериясендә чыккан китапта да анын «оядашлары» Зөлфәт, М. Әгъләм, Р. Закиров, С. Гәрәева, Ә. Рәшит, ә Уфадан—Рәшит Гатауллин, Рәшит Фазлыев, Рәис Рияннар иде... Сонрак Уфадан—Салават Рәхмәтулла, Ренат Хәйри, Марис Нәзиров, Халисә Мөдәррисова, Нәжибә Әминевалар Казан матбугатынын даими авторлары булып китте... Ләкин... 70 елларда «читтәгеләр»гә мөнәсәбәт никтер үзгәрде. «Үз республикаларында үсеннәр», дигән караш урнашты, китап нәшрияты да, көндәлек матбугат та Башкортстан татарларына карата «салкынайды». Бу—нәкъ 80 еллар ахырына кадәр дәвам итте. Күпме язмышлар—талантлар сынды, сүнде бу елларда!

Уфадагылар шул бердәнбер «Кызыл тан»нын «кызыл» чорында да шигырь яктысын сүндерми, шул утка, учакка жыелдылар. Татар язучылары секциясе юк иде—күпләр башкорт әдибе булып, үз теләге белән, намусы кушканча, тугандаш

әдәбиятка талант көчен багышлады. Монда һичнинди гөнаһ күрмим: Уфада калсам, мин дә шулай итәр идем, бәлки... Рим дә «Хәерле иртә» исемле башкортча китап чыгаргач, Роберт Миңнуллин белән икәүләп башкорт газетасына яшь талантны хуплап рецензия дә яздык әле. Мәгълүм ки: соңгы ун ел эчендә хәлләр үзгәрде. Уфада да татарча китаплар чыга. Язучылар берлегендә татар секциясе дә эшли. Татар телле язучылар берлеге дә... «Тулпар» исемле зур тиражлы татарча журнал, «Өмет» исемле газета чыга башлады. Мәйдан киңәйде, яңа сулышлар да ачылды... Казан да Уфа татарларына яңадан йөз белән борылды: берничә шагыйрьне, шул исәптән Римне дә, Татарстан язучылар берлегенә алдык, шигырь бәйләмнәре дә журналыбызда, газеталарда даими басылып килә. Китап чыгару мәсьәләсе генә...

Ә Уфада, 1997 елда, ниһаять, Римнең үзе теләгәнчә, ару ук күләмле, иҗатының төрле чорларын сыйдырган татарча китабы—«Хәерле көн» исемле сайланмасы чыкты. Сүз җаеннан: гомере буе Казанда китап чыгарырга хыялланган Әнгам Атнабай да сөйгән Уфасында китабын татарча чыгаруына сөенеп дөньядан китте. Нажар ага Нәҗми исә Казанда да күренә алган бәхетле иде...

Хуш, Римнең китабына кайтыйк әле. Ул басылып чыкканчы ук, Нажар ага «Кызыл таң»да «Туган җирнең үги балалары» исемле зур, кискен бер мәкалә бастырды. Римнең талантын югары бәяләгән, үз җирендә кояш күрми торган шигъри гөлләр язмышы, татар теле өчен чираттагы әрнүен күрсәткән мәкалә иде ул. Бәхәсләр дә кузгатты аксакал шагыйрьнең сүзләре... Ә Казанда мәгълүмебез Айдар Хәлим, китап белән танышкач, «Тышаулы ат ерак китмәс» исемле эссе-уйлануларын бастырды («Мәдәни җомга», 1998 ел, 10 апрель.). Тел белгече И. Низамов, журналистика факультеты деканы Ф. Әгъзамов та язып чыктылар бу китап турында. Г. Садә дә... «Кызыл таң»га—Роберт Миңнуллин язды. Һәм, ниһаять, Уфада, без искә алган «Тулпар» журналында зур, әтрафлы бер мәкалә (1999 ел, 2 сан) дөнья күрде. Авторы—Казан университеты буенча сабакташыбыз, хәзер Башкорт дәүләт университеты доценты, борынгы әдәбиятыбыз белгече Камил Дәүләтшин. «Талантлы син, Кеше туганым!» дип исемләнгән бу мәкаләдә Рим Идиятуллин иҗатына җентекле анализ ясала, барыннан да бигрәк анын—читтә яшәүче шагыйрьнең шигъри дөньясы татар шигыренең, элгәрләребезнең асыл традицияләренең дәвамы буларак яктыртыла, ышанычлы дәлилләр, мисаллар китерелә. Бу фонда галим—шагыйрьне «эмоциональ поэтик образлылык остасы» итеп күрә; «шигъри сурәт иҗат итүнең төрле принципларын синтезлау талантына ия» дип бәяли. Нажар ага исә Римдә үз җирлегенә—нигез, туфрагына бәйле рәвештә «әрнүле бер моңсулык» күргән иде. Бу хәлне ул Лермонтов, Тукай, Бабич, Туфаннар янәшәлегендә карый—бу үзе үк Римгә олуг бәя иде. Айдар Хәлим дә дустының талантына сокланып яза. Мәкаләләрдә шагыйрьнең иҗат нигезендә Шәрекъ һәм Гареб рухында эзләнүләр ятуы әйтелә. Әйтик, К. Дәүләтшин анарда М. Колыйлардан килгән фәлсәфи дәвамлылыкны күрсәтә. Мисалга, суфый шагыйрьнең:

> Бу адәмне Хак туфракдин төзеде, бел,
> Ут белән суни кушди, һәм тәкый йил.—

кебек юлларын һәм бүгенге Уфа шагыйренең:

> Белмим, кеше нидән яралгандыр?
> Су булса, ул—ташкындыр.
> Ут булса, ул—ялкындыр,
> Җир булса, ул—алтындыр...
> Юктыр, юктыр—
> Кеше—һәм тузан, һәм су, һәм уттыр...

дип тәмамланган шигырен китерә. 60 елларда язылган юллар бу! Әйе, Равил, Ренат, Ш. Анаклар белән бергә, ирекле шигырь өлкәсендә дә нык талпынган еллары бу анын. Шигърияттә янарыш еллары... Табышлар, яңа кыю сурәтләр, ритм иркенлеге Казанда да, Уфада да булган ул елларда. «Кызлар күлә», «Өйрәтү» кебек шигырьләр дә моңа мисал. Ә нигезе—тормыштан, җирдән.

> Тормыш—
> Хуш исле бер чәчкә!
> Яшәүдән туйганнарга

Мин якын да йогынмам.
Бу өч жисем—
Жир, Су, Утым—
Минем терәк баганам.—

ди шагыйрь, үзгәрмәгән матурлык, яшәү кредосын ачыклап. Минемчә, Рим үзе дә, шагыйрь буларак, үз бәясен яхшы белә:

Мин бербөтен. Яманга йә
Яхшыга бүленмәдем.
Сынсам сындым, бөлсәм бөлдем,
Беркемгә бөгелмәдем.

Мәкаләм башындагы дүртъюллыкны истә тотып, Дәрдмәндчә осталыкка дәгъва иткән янә бер парчаны монда мисалга китерәм.

«Нинди гүзәл чәчкә!» Бактым ана
Әллә күпме вакыт тоташтан.
«Нигә әле сула башлады ул?»—
Каплап торам икән кояштан.

Йә, азмыни, шулай көн яктысын күрми сулган, шиңгән чәчәкләребез, талантларыбыз безнең? Чөнки, заман үзгәрешләренә бәйле, соңгы елларда шагыйрь тагын да уйчанрак, моңлырак, димәк, тирәнрәк була бара—гомер тәҗрибәләре дә инде катлаулырак фәлсәфә тудыра:

О, Могҗиза! Торма якында,
Торыр булсаң әгәр якында,
Гайбәт кубар синең хакында:
Кояш булсаң, бирмәс балкырга.
Алтын булсаң, манчыр бакырга,—
Туры килер шуны татырга.

Яки, нәкъ менә яңа гасырга керү алдыннан да җанны борчып торган заман атрибутлары, безнең ил өчен иң характерлы сораулар тудырган авыр коллизияләр тәэсире:

Сорау аттым ана кинәттән:
- Син, Кояшым, нинди милләттән?

Шагыйрьнең миен бораулап торган бу сорау Ал чәчәккә дә бирелә... «Ана хәсрәтенең милләте ни?» дип тә эндәшә ул дөньяга. Ул—ягъни шагыйрь, «Жир өстеннән узып барган мосафир...» Бу, әлбәттә, Дәрдмәндчә уйланулар, бу инде аксакаллар яшенә житеп баручы ир фәлсәфәсе. Конкрет тормыш эпизодлары да, тарих, заман, республика яки шәхси дөнья күренешләре дә читләп узмый аны... Әмма соңгы елларда яшәү, үлем турында, дөньякүләм моң, әрнүләр яктылыгында күренә шагыйрь «мин»е. Югалтулар... Әнисе, улы үлеменә багышланган шигырьләр. Остазлары—Н. Нәҗми, Ә. Атнабайларга мәрсияләр.

Юк, пессимизм, төшенкелек ят аларга. Болар да—ил агаларынча олпат, саллы уй-фикерләр.

Шуны уйлыйм: «Хуш исле бер чәчкә» дигәнебез, мөгаен, шигырьнең үзенә дә карыйдыр. Шигърият гөле уртак дөнья ул. Чын шигырь—кайда да хуш исле, матур, кабатланмас тансык чәчәктер... Гәрчә Уфада яшәүче татар шагыйрьләре, шигырьләре—Казанныкыннан бераз үзгәрәк. Башкорт шигыре тәэсире дә бар анда—инкарь итеп булмый,—фольклоры да йогынты ясаган. Ниндидер бер кырыйдарак торган яшерен чишмә суы кебек сафлык, үзгә бер тәм дә бар анда, кыргый бер ямь дә... Сүзләр дә ятрак тоела кайчакта, эслүбалымнар да. Әмма үзәктә—шул ук татар моңы, татар язмышы. Йә, аны төп татар шигыре юнәлешеннән аерып, «Кояшны каплап» була микән? Кендек каның тамган туган жиреңдә, изге тиягеңдә, «изге кан һәм сөт» калган тәкъдирдә, моң ватаның да калачак бит! Дәрдмәнднең «Сөт калыр, ватан китәр» сүзе никадәр дөрес булса да, Шигърият ватаны—мәңгелек. Халкыбызның үзе, теле кебек үк.

Алтмышта да, аннан аргы елларда да бергә булыйк, шул Шигырь илендә калыйк, дустым!

**Рәлиф ГАТАШ**

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Юныс Сафиуллин**

# СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕБЕЗ НИНДИ?

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ XIII КОРЫЛТАЕНДА ЯСАЛГАН ЧЫГЫШ

Татар драматургиясенә багышланган бу чыгышымны шуны әйтеп башларга тиеш табам, мин монда кемне дә булса мактарга да, хурларга да җыенмыйм. Андый хокук бирелә калса да шундук баш тартыр идем. Бу коллык психологиясеннән дә килми, курку-шикләнүләрдән дә түгел. Татарның барлы-юклы сигез театрына (инде бөтенләй күзне йомып санасаң—ун театр) драматургиябезнең 79 каләм тибрәтүчесе хакында гап-гади сүз әйтер өчен дә калын бер китап язу кирәк. Дөнья күләмендә дә ул шулай хәл ителә. Татарның театр сәнгатендә ирешкәннәрен дә мин дөнья тудырган мәдәният һәм сәнгатьнең бер өлеше дип карыйм. Шуңа шәхси тойгыларына таянып сүз әйтергә маташучылар, бәя бирүчеләр, катгый хөкемнәре белән берәүләрне җиргә егып, икенче берәүләрне һәйкәл итеп күтәрүчеләр күңелдә ризасызлык тудыра, чөнки бу «революционерлар» да элеккеләре кебек үк үзләре теттереп сүккән «төркемчелек», «әшнәчелек» тарафдарларыннан бик ерак китмәсләр шикелле.

Татарның сигез-ун театры бар дидек, әгәр анда елына уртача алганда ике өр-яңа әсәр дөнья күрә икән, димәк 79 драматургның нибары 20 яңа әсәре генә тамашачыга барып ирешәчәк. Биш елга бу 100 әсәр булыр иде... Мисал өчен Камал театрында ике корылтай арасында (5 ел эчендә) 7 татар драматургының нибары 18 яңа әсәре дөнья күрде. Башка театрларда исә яңа спектакльләр бездән бик күпкә азрак куелды.

Сәхнә әсәре хакында сөйләшкәндә шундый бер фикер белән очрашасың: «Пьеса яздым, театрга алмадылар, бастырам... үтәр вакыт һәм ул әле куелачак. Киләчәк буыннар шаккатачак!..» Бу бик беркатлы фикер. Драматургның иң зур фаҗигасе дә, иң зур шатлыгы да шундадыр: үз чорында сәхнә тота алган, сәхнә дигән могҗиза аша узып тамашачыларның җан җылысын үзенә туплаган бәхетле әсәрләр генә, анда да әле аларның кайберләре генә, киләчәктә дә ялтырап алырга мөмкин. Инде вакытында андый бәхетне күрмәгәннәренә, киләчәктә дә ул бәхет насыйп булмастыр. Әнә, Оноре де Бальзак тоташ ике ел буе «Кромвель» дигән трагедияне язган. Ике еллык алтын вакытын бары шушы трагедиясенә багышлаган, әмма Бальзак «Кромвель»енең бүгенге көнгәчә сәхнә күрә алганы юк. Тагын шунысы бар, драматургия белән шөгыльләнүче язучы сине очрата да: «Унбиш пьеса яздым, нибары берсе сәхнә күрде»—ди. Шигырьләрем барсы да басылып килә, хикәя-повестьләрем да дөнья күрә, сәхнә әсәрләрем генә беркемгә дә кирәкми»,—ди. Чыннан да, кызык хәл,

ләкин минем әле бер генә прозаиктан да «дөньяга чыкмаган унбиш повестем бар» дигән сүз ишеткәнем булмады.

Татарның бүгенге сәхнәгә хезмәт итүче 79 драматургы бар, дип әйттем. Бу, әлбәттә, берникадәр бәхәсле сан. Мәсәлән Марсель абый Сәлимжановка «татарның 79 драматургы бар...» дип әйтүем була, ул шундук кычкырып көлә башлый. Бередә дә көлүчеләр булыр. Шуңа мин ул санны берникадәр «сүтебрәк» бирәм. Сүзне дә ерактан башлыйм. Безнең театр 93 ел яшәп килә. Татар пьесасына 102 яшь. Габдрахман Ильясиның беренче булып язылган пьесасы безнең сәхнәдә беркайчан да куелмаган. Шушы көнгәчә 104 татар драматургының 321 яңа пьесасы безнең театр сәхнәсенә күтәрелгән. Димәк Г. Камал театрында 93 ел буе куелган 760 әсәрнең 321 генә (димәк, яртысыннан да азрагы)—104 татар драматургы тарафыннан язылган өр-яңа пьесалар. Бүгенгесе көндә әлеге 104 драматургтан 84 инде мәрхүмнәр... Менә хәзер инде алдарак әйтелгән 79 драматург турында сөйләшүгә күчәбез. Әйе, бүген театрларга пьесалар язучы 79 драматургның 20 се—безнең академия театрында пьеса куйдырган язучылар. 38 е (алар арасында да бик кызыклы драматурглар бар) әлегә милләтебезнең төп сәхнәсендә күренмәгән, әмма башка театрларда уңыш казана килгән спектакльләрнең пьеса авторлары. Калганнарын исә 21 кеше дип алыйк, ә чынлыкта алар күбрәк...

Академия театрының 20 драматургы дип кемнәрне күздә тоттым... Шәриф Хөсәенов, Аяз Гыйләжев, Туфан Миңнуллин, Илдар Юзеев, Әхсән Баян, Нурихан Фәттах, Батулла... хәер санап тормасак та була—аларны яхшы беләләр. Әйтергә теләгәнем шул: Туфан Миңнуллин бездә 26 әсәр куйдырган. Бу—кызыклы рекорд. Татар театры тарихында күп әсәр куйдырган авторлар берничә генә, әйтик Кәрим Тинчурин—20 әсәр, Нәкый Исәнбәт—18, Тажи Гыйззәт—16, Г. Камал белән Хәй Вахит—13 әрне, Гаяз Исхакый—9 ны. Ә Туфан Миңнуллинның бер безнең театрда гына да 26 әсәре алкышланды. Кабатлыйм—бу бик зур күрсәткеч. Академия театрының 20 драматургы дип аталган драматургларыбыздан тагын Аяз абый Гыйләжевнең генә бездә 10 әсәре дөнья күрде. Калганнары болардан бик күпкә азрак куйдыра алды. Бу элек тә шулай булган. Камал театрында 104 драматургтан 52 сенең берәр генә әсәр белән калуы әнә шул хакта сөйли. Әмма бу бер генә әсәр куйдырган драматургларыбызны кимсетү булып аңлашылмасын иде. Бер генә әсәре белән дә классик булып танылучылар бар. Шундыйлардан «Шәмсекамәр», «Кол Гали» авторларын атап китәргә була. Шул ук вакытта бер мөһим нәрсәне кабат ассызыклап әйтәм: ике корылтай арасындагы 5 сезонда Г. Камал театрында 18 яңа әсәр куелган, һәм аларны нибары 7 автор иҗат иткән. Туфан Миңнуллин 5 пьеса, Зөлфәт Хәким 4, Аманулла, Хәлим Җәләй 3 әр, Рәшидә Җиһаншина 2, Гафур Каюм белән мин берәр. Ә калган драматургларыбыз нишли? Нурихан аганың бездә 25 ел буе куелганы юк. Гариф Ахуновның—26, Рөстәм Мингалимов—18, Илдар Юзеев—16, Ризван Хәмид—14, Аяз абый Гыйләжев белән Батулла да—10, Шәриф Хөсәенов белән Мансур Гыйләжевлар җидешәр ел куелганнары юк. Мин бик еш кына әнә шул хакта уйланам. Театрның һәм драматургларның да бу уртак житешсезлеген үз өстемә генә аласы килми. Мин режиссер да, директор да, хәтта директор урынбасары да түгел. Ләкин сүз уңаенда әйтим: безнең театр югарылыгындагы башка театрларда әдәби бүлек мөдирләре директор урынбасарлары булып бетте. Мин аларга «Нигә кирәк соң ул сезгә?» дигәч, «Драматургларга пьеса язарга заказ биргәндә кирәк була» диделәр. Аларның драматург белән килешү төзү хокуклары бар икән. Андый кешенең сүзе эш белән дә ныгытыла, диләр. Һәм шундук исемә Разил Вәлиев, Марсель Галиев, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт Маликов, Ркаил Зәйдулла һәм башка талантларыбызга пьеса язарга заказ биреп йөргән чакларым искә килеп төште. Һәм алар яздылар да. Кулларында берниндн килешү фәләннәре булмаса да язды алар... Әле ярый Разил Вәлиев белән Марсель Галиевларның эшләгән эшләре әрәмгә китмәде. Бездә куелмасалар да башка театрларда гөрләп бардылар, театр сөючеләрнең зәвыкларын төрләндерделәр.

Шунсы кызык: элеккерәк елларда, ягъни без яшь чакларда, милләтнең баш сәхнәсендә әсәреңне куйдыру докторлыкны яклау кебек үк бик авыр

нәрсә була иде. Ә хәзер әнә кайбер яшьләргә гаять зур ташламалар ясала. Театр бер ара пьесаларны акча түләп яздыра башлаган иде. Театрнын үзендә үк язылды алар. Әйе, яшь драматург кирәк булган өчен генә кайберәүләргә ишекләребез түбәнәчә каерып ачылды. Чөнки яшьлек дөньяны янартырга килә дип ышанабыз. Әмма яшьләр арасында да янартуны камилләшү дип түгел, ә киресенчә, булган ишек урынына тәрәзә, тәрәзә урынына исә ишек ясау дип кенә анлаучылары да бар. Бу очракта ничек инде Америка тамашачыларын үзенең яңа әсәрләре белән сокландырган 90 яшьлек Артур Миллерны искә төшермисең. Ә драматургиягә камилләшү аеруча зарур. Ул элек-электән шул юл белән генә үсә-үзгәрә килгән. Дөнья драматургиясенең иң камил әсәрләреннән саналган «Гамлет», «Отелло», «Король Лир», «Ромео һәм Джульетта» кебек әсәрләрне иҗат иткән һәм үзе дә драматургларның дөньякүләм юлбашчысы дип танылган Шекспирга чаклы да бүтән «Гамлет», «Ромео һәм Джульетта»лар язылган булган. Алар төрле театрларда уйналганнар. Аларның яратып караучылары да, ошатмаучылар да булган. Бу әсәрләрдән кайберләренең авторлары да билгеле: Джиральди Чинтио, Томас Кид, Банделло, Артур Бруклар... Һәм менә сәхнәне яхшы аңлавы өстенә тирән белемгә дә ия, атаклы поэмалары һәм сонетлары белән дә киң танылган шагыйрь һәм артист Уильям Шекспир мәйданга чыга. Ул әлеге искергән, тапталган сюжетларга таянып үзенең даһи әсәрләрен иҗат итә.

Без менә бүген репертуарыбызны озак еллар буе бизәп килгән бик күп классик әсәрләрне куя алмый башладык. Аларда йә динне, йә Алланы, йә байларны сүгәләр, кирәкме-юкмы бертуктаусыз коммунистлар белән урысларны теттереп мактыйлар, кыскасы, бу классик сюжетларга да Шекспир тәҗрибәсен үзләштергән драматурглар кирәкмиме икән?.. Миңа кайчак «Сюжет нәрсәгә инде ул, әнә урысның Коляда кебек драматурглары бернинди сюжетларсыз да яза башладылар бит» диләр. Чыннан да, бу күренешне рус драматургиясендә генә түгел, Европа һәм Азия илләрендәге халыкларда да очратып була. Ансы да кирәктер. Шәп характерлар иҗат итә алган драматург шулай ук зур эш эшли. Әмма театрларда меңләгән еллар яшәү дәверендә чарланган сюжетны ансат кына сызып ташлау кирәкме икән? Театрларда элегерәк Мольер, Шекспир, Гольдони, Берднард Шоу, Островский кебек драматурглар беренче урында торганда бу хакта уйларга да кыймаганнар. Ә инде драматург урынын театрда режиссер яулап алгач һәм ул әкрен генә беренче кеше булу белән генә канәгатьләнмичә, иң төп кеше дәрәҗәсенә үк күтәрелә башлагач, театрда драматургка яшәүләре катлаулана башлый. Бүген инде әнә пьесадан башка гына спектакль иҗат итү, драматургтан тулаем котылу омтылышлары да көчәеп килә. Бу тенденция кая алып барып житкерер—билгесез. Мин үземнең инануым буенча шуны әйтәм: хәтта даһи режиссер да үзенең таң калырлык итеп куелган мизансценалары, аң төпкеленә акыл ярдәменнән башка да үтеп керә ала торган музыка, күзнең явын ала торган декорация, даһи артистлары белән дә, барыбер драматургны алыштыра алмый. Драматург һаман да театрда беренче кеше булып калырга тиеш! Драматург тормышны хәрәкәткә китерүче төп кануннарны белү белән берлектә, драматургиянең меңнәрчә еллар буена килгән төп серләрен дә үзләштерергә тиеш. Бусы—бик авыр хезмәт. Әмма башка юл юк.

Шигырь яки проза әсәре язучы, көй чыгаручы, яки рәсем ясаучы художниклар шуны яхшы аңлый: чынбарлыкны инләп бетерү авыр. Инләгән кадәрен дә икенче кешеләр белән уртаклашу, аларда да фикер тудыру—шулай ук бик авыр. Ә драматургка бу тагын да кыенрак. Чөнки ул берьюлы мен кеше белән сөйләшергә тиеш.

Ерактан күренми торган нәрсәне күрер өчен бинокль, телескоп, ә якыннан да күренми торган бик кечкенә нәрсәләрне күрергә микроскоп уйлап тапканнар. Драма әсәрендә сюжет төзү дә—шундыйрак бер зарурлык. Билгеле, теория өйрәнеп кенә язып булмый. Әмма бер урында таптанмыйк, бер кат табылганны сыер кебек мең кат күшәүдән котылыйк һәм бер-берсенә бер тамчы су кебек охшаш әсәрләр язудан сакланыйк дисәк, камилләшүгә илтә торган драматургия теориясен дә өйрәник. Бу сүзләр, әлбәттә, асылда яшь даһиларыбызга гына

кагыла. Чөнки аларга, карт даһилардан аермалы буларак, әле тартасы да тартасы!

Сәхнәне бик кыю рәвештә үз кулларына ала барган яшь драматургларыбыз—яшьләре белән дә асылда ять-яшьләр. Драматург 35 яшендә генә өлгереп житә дигән сүздә хаклык, әлбәттә, зур. 8 яшендә үк искиткеч музыка ижат итеп композитор исеме алган, 15 яшендә үк чын шагыйрь булып житешкән, Надя Рушева шикелле бик яшьли бөек рәссам булып танылган яшүсмерләр бар. Прозада да андый талантлар очрый. Ә менә драматургиядә андый яшүсмерләр юк. Чөнки драматургия шәхестән интуиция белән бергә бик югары акыл эшчәнлеген, тормыш тәжрибәсен дә таләп итә.

Мин драматургияга гашыйк булган егетләребез белән бик горурланам. Кемнәр соң алар?.. Академия театры репертуарына сиксәненче еллар ахырында ук килеп кереп «Бичура»сы белән жиңү яулаган Мансур Гыйләжев... «Мирас» кебек гаять милли рухлы, камил әсәр ижат иткән Гафур Каюм... Әсәрләрен Академия сәхнәсендә куйдырмаса да калган барлык театрлар белән дә бик тыгыз элемтәдә ижат иткән Данил Салихов... «Сөйгәнен су төбеннән дә эзләп таба ала торган», үзен Туфан Миннуллин янына ук куеп сөйләшүче, шунардан да кимгә риза булмаучы Зөлфәт Хәким... Зөлфәтнен үкчәсенә үк басып килүче артист, режиссер, драматург Аманулла... Бик үзенчәлекле талант иясе Хәбир Ибраһим, Шамил Фәрхетдин, Рәдиф Сәгъди, Фәнәвил Галиев, Ләбиб Лерон... Менә боларның һәммәсе—соңгы ун елда иң күп ижат иткән, аякларында нык басып торган бик өметле киләчәгебез.

Драматургларыбыз бер-берләренә охшамаганнар. Кайберләре күбрәк комедия язарга, кайберләре психологик драма, яки башка жанрда ижат итәргә ярата. Һәм, әлбәттә, һәркайсы үзен хаклы, иң дөрес юлда дип уйлый. Кайчак бәхәсләр дә килеп чыккалый. Алар нинди генә сәбәпләр аркасында килеп чыкмасын, соңгы инстанция итеп тамашачы галижанәбләре күз алдында тотыла. Үзләренен таяну нокталары булган тамашачы турында драматургларның кайберләре: тамашачы комедия ярата, тик тамашачыны елатуга караганда көлдерүе авыррак диләр; икенче берәүләр: юк, тамашачы драма ярата, тамашачыны елатуы авыррак дип каршы төшәләр; өченче берәүләр: көлдерәсе авырдыр, елатуы да жинел түгелдер, ә менә күз яшьләре аша көлдерә белү бу инде драматургтан иң-иң зур осталыкны сорый,—дип куялар. Боларга дүртенчеләре кушыла: күп көлдердек, күп елаттык—инде халыкны уйлый белергә дә өйрәтәсе иде, диләр. Әгәр мина алар белән бәхәскә керергә туры килсә, мин берни дә әйтмәс идем. Чөнки алар үз жаннары кушканны язалар. Әсәр ата-анасына охшап туган бала кебек, язучының үзенә охшый. Әйе безгә, татар драматургларына, үзебез булып калу хәерле, тик ижатыбызда осталыгыбызны арттырырга һәм гел камилләштерергә барырга тиешбез. Ә инде: «Шундый чор килде, халык театрга кәмит карарга гына йөри»—дип үз-үзебезне алдап ятсак, тамашачыны беркайчан да үз артыбыздан ияртә алмабыз. Театр яшәгән елларда да безнең чордашларыбыз кебек үк гади кешеләр яшәгән. Тарихка багып, андагы кешеләрне замандашларыбыз белән чагыштырып карыйк. Халык өчен гомерен дә жәлләмәүче Сөембикә, Идегәй, Батырша, Сахаров, Мирзаянов кебекләр беркайчан да күп булмаганнар. Нәкъ бүгенге күк, көчкә-көчкә көннекөнгә ялгап, өсте бөтен, тамагы тук булса, шуны да жәннәт дип уйлаган кардәшләребез иң зур күпчелекне тәшкил иткән. Яшәү кайчан да авыр булганга, «жанынның ваклыгын сылтама заманга» ди бит шагыйрьләр дә. Драматургияне үстерер өчен бүген дә шартлар бар. Бары тик театр буфетында шүрәле шикелле кытыклау сәләтенә ия 100 грамны яка астына төшереп, янындагы кызның колагына пышылдаган сүзләреннән үзе үк кытыкланып көлеп утырган тамашачыларга гына йөз тотмаска кирәк.

Кайбер ижатчылар телендә «драматургия—әдәбият һәм сәнгатьнең тажы» дигән гыйбарә бар. Гадел бәяме бу? Сынлы сәнгатьтә, музыкада, яисә шигърияттә яна алым белән, өр-яңа юнәлештә ижат итүчегә, уңышка ирешү өчен, аны аңлый торган тар гына даирә дә житә. Әлеге даирә кешеләре арасындагы белгечләр һәм акчалата ярдәм итеп торучы меценатлар ярдәмендә шагыйрь, композитор, рәссам, прозаиклар китап та чыгара алалар, рәсем дә

ясыйлар, музыкасын да язалар. Ә театр сәнгате тумышы белән үк зур аудиторияләр өчен билгеләнгән. Аны яшәтү өчен уен кораллары, карандаш, буяу, пумала һәм ак кәгазь генә житми. Драматургка янача иҗат итә ала торган артистлар, драматург фикерен аңлаучы режиссер, музыкантлар, рәссамнар, кием цехлары, яктырту аппаратлары—бер сүз белән әйткәндә, көн дә туптулы заллар җыя ала алган «галиҗанәб театр» үзе кирәк. Әнә шуңа да ул үзенең тарихи үсешендә Сабан туе рәвешендәге уртак мәйданга көрәш батырлары кебек иң ахырда гына чыгып баса. Тарихка Яңарыш эпохасы дип кереп калган Ренессанс чорында да шулай бирелгән. Ренессанс чорының шигърияте, архитектурасы, сынлы сәнгате һәм скульптурасы белән тигез рәвештә, аларга тиң булып, янәшәләрендә үсеп бара алмаган драматургия... Ә алардан өч гасырга соңрак калып кына өлгергән.. Европада шигърият җиңү арты җиңү яулаганда Дантеның «Илаһи комедиясе», Петрарканың сонетлары, Боккачының «Декамерон»ы, инглизләрнең «Кентербери хикәяләре», французларның «Олы мираснамә»ләре дөнья күргән... Ә шул чакта, кайда гына карама, урам сәхнәләре Инҗилдән алынган иң беркатлы сюжетлар белән генә канәгатьләнгән. Халыкны урта гасырлардан мирас булып килгән артка тибеп көлдерә торган иң тупас фарс яки мистерияләр белән сыйлаган. Шигърият гуманизмның формулаларын әйтеп, сынлы сәнгать аларны сынландырып биргәндә, театрлар исә «бөек фикерләр һәм тойгылар кешегә фани дөнья эшләреннән арынып, бары тик теге дөнья турында уйлаганда гына килә» дип ышандырганнар. Алар җирдәге хәлләрне карикатура итеп кенә тасвирлаганнар. Урта гасырдан ук калып килгән эпос, лирика, сынлы сәнгать, музыка кешеләрнең йөрәгендә һәм аңнарында билгеле бер үзгәрешләр ясагач кына театр төп сүзне әйтергә алына соң. Ни өчен шулай? Чөнки ул үзен тиңдәшсез көч итә торган массалар, ягъни, күпчелек белән эш итә. Бик демократик рухлы булуы һәм күп санлы тамашачылар белән эш итә алуы аркасында ул үзенең тамашачылары зур фикерләр өчен өлгереп җиткәнен көтәргә мәҗбүр булган. Менә шунда гына Ренессанс чорының иң гүзәл, иң фәлсәфи трагедиясе «Гамлет» туа алган. Бу образны Шекспирга чаклы 100 ел элек Микеланджело үзенең Давидында гәүдәләндерә. 50 ел үткәч аны Томас Кид бик примитив рәвештә сәхнәгә чыгара. Бары шушы юлны үткәч кенә «Гамлет» туа. Әйе, драма бик кыска вакыт эчендә, үзенә бөтен тәҗрибәне үзләштерә дә, моңарчы булган примитив әйберләренә алмашка буй җиткесез «Король Лир» белән «Овечий источник» шикелле әсәрләр тудыра. Ренессанс драмасында чынбарлыкның бөтен зурлыгы, кешеләрнең иң катлаулы эчке тетрәнешләре дә чагыла.

Драматургиянең нинди көчкә ия булуын корольләр, патшалар да яхшы белгән. Драма әсәрләре турыдан-туры алар цензурасы астында булган. Мольер һәм король Людовик мөнәсәбәтләрен генә алыйк. Һәм Елизавета, әби патша чорларын... Пушкинның «Борис Годунов»ын Николай I үзе төзәтергә омтыла. «Онегин» поэмасын да, проза әсәрләрен дә түгел, ә трагедиясен! Россиядә һәм Европада да шундый ук йөзләгән очракны әйтергә булыр иде. Хакимият башындагыларны драманың халыкка булган тәэсире һәрчак куркыта. Виктор Гюгоның атаклы манифестында да бу турыда әйтелә: «Драма үзенә бөтен шигъриятне тулаем сыйдырып кына калмый, ул аны иң бөек ноктасына күтәрә... чөнки, шигърият үзенә драманың орлыгын гына сыйдыра ала...»—ди. Безнең совет чорында драматургиягә карата йөзләрчә карарлар бер-бер артлы чыгып кына торган. Аеруча Сталин драматургиянең халыкка булган тәэсир көчен нык аңлый. Ул драматурглар һәм театр белән тыгыз бәйләнештә була. Җене сөймәгән совет интеллигенциясенең «череклеген» халыкка аңлату бурычын да ул драматургларга тапшыра. Константин Симоновка «шундый пьеса яз» дип шәхсән үзе куша. Игътибар итегез: күренекле шагыйрь һәм прозаик та булган бу язучыга шигырь дә, поэма да, повесть та, роман да язарга заказ бирми, ә пьеса язуын сорый. Һәм шундый ук пьесаларны Штейн белән Лавреневлардан да яздырта. Әйе, партия җитәкчеләренең беркайчан да тематик шигырь, проза язарга заказ биргәннәре булмаган, алар һәрчак пьеса сораган. Суслов заказлар биргәндә һәрчак үзе драматурглар белән шәхсән очрашып сөйләшкән. Пьеса мөһим политик акцияне үткәргәнгә аңа гонорарны да күтәргәннәр.

Инде үзебезгә әйләнеп кайтыйк. Шушы көннәрдә без Төркиядән шатлыклы хәбәр алдык. Европаның Истанбулдагы Лион клубы бүлеге Төрки дөньядан килгән барлык театрларның спектакльләрен карагач һәм шулай ук Төркиядәге барлык театрларның спектакльләрен дә искә алып, иң яхшы куелыш дип Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»ен атаган. Шул хакта беркетмәсен дә җибәргәннәр. Марсель Сәлимҗановка акалтын планшетлар да тапшырачаклар. Бу—татар драматургиясенең дә зур җиңүе. Моннан 23 ел элек язылган әсәребез бит ул... әнә нинди югары бәя алды! Шундый әсәр язып та Туфан абый, безнең бәхетебезгәдер инде, һич тынычлана алмый. Мәдәният министрлыгы оештырган пьесалар бәйгесендә яңа гына язылган «Шәҗәрә» һәм «Бик бүлтәймә, бультерьер!» дигән пьесалары белән ул тагын иң алдынгы урыннарны яулап алды. Аның «Шәҗәрә»сен безнең сәхнәдә күргән кешеләргә инде артык сүз кирәкмәс. Зәки ага әйтмешли: «Афәрин, Туфан!» Туфан абый ике корылтай арасында җиде өр-яңа әсәр куйдырды. Мин Туфан абыйның ни өчен тынычлана алмавының серен беләм, чөнки аның артыннан талантлы алмаш килә. Дөрес, Мансур Гыйләҗев соңгы биш елда бездә әсәр куйдырмады. Бизнеска тартылды. Шулай да, барыбер иҗат уты акрын гына көйри. Аның «Алла каргаган йорты»н «Современная драматургия» журналы бастырды. Әлмәттә сәхнәләштергән бу әсәр ул театрга җиңү китерде. Тагын бер әсәре Чаллы театрында, тагы ике әсәре курчак театрында дөнья күрде. Гафур Каюм да бездә «Сарык-арыслан»ын гына куйдырды. Аның күпчелек әсәрләре «Нур» , Туймазы, Минзәлә, Түбән Кама, Әлмәт театрларында бара. Мәскәүдә режиссерлык курсларын тәмамлаган Гафур Каюм соңгы әсәрен инде режиссер буларак та дөньяга чыгарды. Режиссер булып алгач ул мона каләр беркайда да куйдыра алмаган 5 әсәренә дә тормыш бүләк итә алыр дип тә ышанасы килә. Данил Салихов безгә әйберләрен бирми, ул аларны башка театрларга барып үзе куя. Ике корылтай арасында аның 5 яңа әсәре сәхнәгә менде... Яшьләр арасында иң күп әсәр куйдырган драматург Зөлфәт Хәким бугай. Аның барсы 7 әсәре куелган. Зөлфәтнең тагы шундый өстенлеге бар: аның күпчелек әсәрләре милләтебезнең төп сәхнәсендәге баш режиссер Марсель Сәлимҗанов тарафыннан сәхнәләштерелде. Шуңа күрә яңгырашлары ук икенче! Кайберәүләр «нинди аерма инде» дигән булалар. Әмма аерма зур. Ул бит шигырь генә район газетасында басылса да, «Казан утлары»нда чыкса да—барыбер шул ук шигырь булып кала. Зөлфәтнең башка театрда үзе куйган «Кишер басуы»н гына алыйк—бу инде карикатура. Шушындый ук фикерне минем Аяз абый кебек тәҗрибәле драматурглардан да ишеткәнем бар: «Шулай килеп чыкты, фәлән театрның спектакленә соңга калып бару сәбәпле авторының кемлеген белмәдек, карап кына булмый, драматургиядән хәбәрдарлыгы чамалы кеше язган икән дип торабыз, ә ул... фәлән икән.»

Артист, режиссер һәм драматург Аманулла 6 әсәр иҗат итте. Аның спектакльләре буш залларга уйналмый. Безнең театрда үзе үк куйган «Әле кичә генә яз иде» әсәре котмәгәндә яшь җилкенчәкләрнең иң яратып карый торган спектакленә әверелде. Шушы биш елда Тинчурин театры артисты Шамил Фәрхетдиннең дә 5 спектакле дөнья күрде. Аның әсәрләренең дә күбесе—үз режиссурасында. Шул ук театрның Рәдиф Сәгъди атлы ир-егете дә Тинчурин театрында өч әсәр куйдырды. Шуны да әйтим: бу егетнең куйдырмаган әсәрләре дә байтак. Журналистикадан килгән драматург Хәбир Ибраһимның да тотымы мулдан—куйдырган сәхнә әсәрләре бишәү. Яшьләр театры артисты Фәнәвил Галиев та әсәрләрен үзе сәхнәләштерә. Ул биш елга өч спектакль бүләк итте. Ләбиб Леронның 2 әсәре сәхнәләштерелде. Бу яшьләр янына Рафис Корбановны да кушарга буладыр. Чөнки ул—Курчак театрында иң күп спектакль куйдырган автор. Иң соңгы әсәре Яшьләр театрында бара. Кабат игътибар итсәгез иде: күпчелек яшь драматурглар—үз әсәрләренең режиссерлары да. Режиссурага аларның бу хезмәтләре файда китерерме—билгесез, әмма дә ләкин татар драматургиясен үз кулларына алачак егетләрнең үз көчләрен режиссер буларак та сынап караулары бу егетләргә һәм драматургиябезгә билгеле бер тәҗрибә алып киләчәк.

Ун елда ун драматургның үсүе аз түгел, дибез. Чөнки безнең бит әле

сәхнәдән вакытлыча гына читләшеп торган Аяз Гыйләжев, Нурихан Фәттах кебек осталарыбыз да бар. Алар «Йәгез, бер дога!» кебек шәп романнарыннан, кызыклы киносценариеләреннән, фән кешеләрен дә көнләштерерлек мөһим ачышка ия хезмәтләреннән соң һичшиксез театрны сагынырлар төсле. Әнә, Илдар Юзеев дүрт әсәр язып өлгертте. Аларның беренчесе—«Ак калфакны төшердем кулдан» драмасы Башкорт академия театрында зур уңыш казанды, «Хуш, Хәйбүш!» Яшьләр театры сәхнәсен бизәде. «Моңлы бала түгел идем» музыкаль комедиясе белән «Эзләдем, таптым, югалттым» драмасын да тиздән сәхнәдә күрербез. Разил Вәлиевнең да әлегә куелмаган өч әсәре бар. Ризван Хәмид, Фәнис Яруллин, Фоат Садриевлар да гаять актив иҗат итәләр. Фәнис Яруллин дүрт театрда 5, Фоат ике театрда 4, Ризван өч театрда өч өр яңа әсәрен куйдырды. Гөлшат Зәйнашева Тинчурин театры белән бик матур иҗатташлык итә. Ул яшьләрдән һич калышмыйча «Гайфи бабай, өйлән давай», «Җаным җәл түгел сиңа» дигән халык ябырылып карый торган әсәрләрен куйдырды. Артист буларак киң танылу аркасында гына язучылыгы арттарак кала килгән Хәлим Җәләй—ике китап авторы булды, шушы ике корылтай арасында 5 әсәр куйдырды. Өчесен бездә, икесен башка театрларда кабатлап куйдылар. Монда аңа балалар дөньясын яхшы белүе, яратуы да ярдәм итә. Балалар аның һәр пьесасын көтеп алалар. Шуңа ул ял да итәргә теләми, инде әнә, яналарын төгәлләп килә. Безнең Рәшидә апа Җиһаншина шулай ук драматургияга ихлас хезмәт итәргә тырыша. Өч өр-яңа пьеса язып, икесен Академиядә, берсен Минзәләдә куйдырды. Зөлфәт Маликов безгә тәрҗемәләр белән генә килә. Асылда пьесаларын Курчак театры өчен яза. Мин аларны һәм шулай ук анда куелган башка драматургларыбызның әсәрләрен барып карыйм да, «әле ярый бу дөньяда бер безнең театр гына түгел» дип кайтам. Танылган драматургларыбыздан Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхимнәр дә театрларда икешәр әсәр куйдырдылар. Талантлы прозаик Мәдинә Маликова Әлмәт театры тамашачыларын «Синең өчен үләрмен» драмасы һәм дә «Ач, Сәкинә, Әмрикәне!» комедияләре белән куандырды. Мин үзем ике корылтай арасында «Идегәй» белән «Йөзек һәм хәнҗәр» трагедияләремне куйдырырга өлгердем. «Сукбай артистлар» комедиясен миннән яздырткан Дамир Сиражиев бик вакытсыз арабыздан китеп барды. Драматурглар өчен бу төзәтеп булмаслык яра, авыр югалту. Калган драматургларыбыз Эсфир («Типтерик әле!»), Әнәс Хәсәнов «(«Әти диясе килә»), Харис Төхфәтулла («Сакла сөюне!..»), Исламия Мәхмүтова («Син бит минем бер генәм!»), Альберт Гаделшин («Айсылу»), Нәзифә Кәримова («Үп мине, Зәйтүнә!»), Әхмәт Гадел, Фәрит Яхин, Сәрия Вильдановалар шактый яңа әсәрләр иҗат иткән булсалар да, ике корылтай арасында берәр генә әсәр белән күренделәр.

Чыгышымдагы соңгы сүз итеп тә шуны әйтәм: 79 драматургы булган безнең драматургия өчен әле генә санап киткән 32 драматургның 95 спектакле 5 елга бик аз инде бу! Ләкин безгә әле сан хакында гына түгел, ә сыйфаты хакында да бергәләп уйлашасы бар. Тагын 5 ел узганны көтеп тормыйча гына...

*Милләттәшләребез чит илләрдә*

# ДӘҮЛӘТЛЕ НАДИР ДӘҮЛӘТ

Профессор Надир бәй белән мин беренче тапкыр 1990 елда Чулманкалада (Түбән Кама) очраштым. Ул Америка профессоры Рифат Таби белән шул якларга килеп чыккан иде. Житди оешмаларның житди чикләүләре булган заманда Разил Вәли аларны ничек итеп туган ягына алып кайткандыр? Бу эшнең кыенлыкларын Разил үзе генә беләдер. Ике олы илнең ике олы профессоры бик шаян-шат күнелле кешеләр булып чыкты. Әллә алар Төркия белән АКШта сирәк күләме, әллә ул илләрдә Разил Вәли кебек мәзәк сөйләүчеләргә кытлыкмы, белмим, әмма бу ике жегетнең рәхәтләнеп-иркенләп көлүләре бөтен мәжлескә йога: табын янындагылар таралып, кайгысыз күңел ача. Мин дә аларга сокланып багам. Горбәттә дә саф килеш сакланган Ана телебезне тынлап ләззәтләнәм. Аларның сөйләмендә бер генә урыс сүзе дә ишетелми. Телләре тәмле, бай һәм тирән мәгънәгә ия, дип сокланам. Без бу ике дус белән Төркиядә дә, Америкада да берничә тапкыр күрештек. Алар һаман шулай көр күңелле булып кала бирәләр, шөкер.

Ләкин Надир бәй көлүдән туктаган арада кинәт житдиләнә, аның аксыл йөзендә, күз карашында моңсулык пәйда була. Аның куллары үзе дә сизмәстән тәмәкегә үрелә, Надир бәй бик еш тәмәке тарта. Мина ул башта бераз чирләп торадыр сыман тоелган иде. Әмма еллар аша янадан-яна күрешүләрдә дә аны шушы ук халәттә күргәч, башыма уй йөгерде, Надир Дәүләтнең күңеле беркайчан да бетми торган сагыш белән тулган. Ул үзе сау-сәламәт, ләкин кара язмыш аның йөрәк тибешенә жирсү хисләре салган. Моның шулай икәнен Надир бәй Дәүләтнең тормышын якыннан белгәч кенә аңлап була. Аның узган юлы—трагик поэма, кызганыч сюжетлы фильм, жыламыйча укып булмый торган кыйсса.

Коммунизм аждаһасыннан качып, Кытай Маньчжуриясенә барып, тыныч куыш тапкан татар зыялысы Ибраһим Дәүләт-Килденең бәхетле гаиләсендә 1944 елда Надир исемле ир бала дөньяга килә. Бер яше тулар-тулмас вакытта совет гаскәрләре Маньчжуриягә бәреп керә, атасы Ибраһим абзый белән анасы Рокыя ханымны кулга алалар, Себергә алып китеп, зинданга ябалар. Бер яшьлек сабый Надирны күршеләре яшереп алып кала. Кара ятим Надирны миһербанлы Әхтәм абзый Ильясов белән Гайнижамал ханым уллыкка ала. Надир үзенең ата-анасын күрми-белми үсә. Әхтәм абзый белән Гайнижамал Надир үсеп балигъ булгач кына серне ача. Шулай итеп, Надир үзенең Ильясов түгеллеген, бәлки Дәүләт-Килде атлы морзалар токымыннан икәнлеген белә. Үз балалары итеп, сөеп үстергән, ана белем биргән кешеләрнең үзеннең ата-анан түгел икәнлеге Надирны бер тетрәндерсә, аларга соклануны, рәхмәтле итсә, икенче яктан, үз атасының Совет зинданында жәзалап үтерелүе һәм йөкле килеш кулга алынып, озак еллар Совет сөргенендә жәберләнүче анасы, төрмәдә туган нәни сеңлесенең тартып алынып ятимнәр йортына тапшырылуы хакында ишеткәч, Надир бәй икенче тетрәнү кичерә. Гаепсезгә жәзаланганнар, аларны жәзалаучылар турында уйлый-уйлый, зинданнан исән чыккан анасы, сеңлесе белән очраша алмаулары турында уйлый-уйлый Надир Дәүләтнең күңелендә ризасызлык, кемгәдер нәфрәт юшкыны урнаша, йөзенә сары сагыш булып сирпелә.

Алар очраштылар. Бертуган абый, бертуган сеңлесе, ниһаять, олыгаеп барганда Казанда очраштылар. Бу очрашуны ничек сурәтләргә соң? Язып булмый, аңлатып булмый моңдый халәтне. Бер ата, бер ана балалары булса да, икесе ике мохиттә тәрбия алган, берсе татарча да, инглизчә дә, төрекчә дә белми торган, йолаларсыз үскән хатын, икенчесе—сөйләшерлек урысчасы булмаган, әмма дөньяның иң олы телләрен, Ана телен мөкәммәл белгән профессор. Алар икесе ике милләт кешеләре кебек иде. Аларның сөйләшергә уртак теле юк. Күз карашлары тулы сагыш, ни өчендер, кемгәдер, адресы булмаган рәнжеш мохитында утыруы башка кешегә дә читен иде. Бичара хатын туганда

ук хокуксыз булып туган икэн, картаеп барганда да уртача гына булса да фатир алалмаган, боек, сагышлы, ятакханэдэ кара ятим булып яшэп ятучы япа-ялгыз ханымга карап, абыйсы Надирнын бэгыре киселмэгэндер дип кем эйтэ ала? Телгэлэнгэн бэгырьнен эчесе чырайга чыкмый, кая чыксын сон?

—Алар тугел, мин уксеп жыладым, - диде Разил Вэли абыйлы-сенелле туганнарнын беренче очрашуыннан сон.

... Яхшы ата, яхшы аналарнын
Яман тугел баласы идек.
Яманлыкнын кузенэ баса-баса
Тантанага барасы идек.

Кемгэ тидек?
Кемне рэнжеттек сон?
Кем сон безне шулай каргады?
Сак белэн Сок кебек монаябыз,
Арабызда - Урал таулары...



*I Бөтендөнья Татар Конгрессында катнашучылардан бер төркем сулдан уңга: Фәрит Иделле(Германия), Надир Дәүләт (Төркия), Ислам Әхмәтҗанов (Татарстан), Равил Селихмәт(АКШ), Али Акыш (Германия), Илсөяр Хәйруллина (Татарстан), Ренат Харис (Татарстан),Флүс Латыйфи (Татарстан),Мостафа Өнәр (Төркия). 18 июнь, 1992 ел.*

Казанга килгэн саен Надир бэй сенлесе янында була. Ташламый ул сенлесен. Тел бер булмаса да, кан бер. Халык депутаты, шагыйрь Разил Вэли белэн икесе йөри-йөри Надир Дәүләтнен сенлесенэ фатир алып бирүгэ ирештелэр. Төркиягэ барган кешелэр артыннан Надир Дәүләт һәрвакыт сенлесенэ кучтэнэч жибэрэ. Ата-ананын рухы разыйдыр, мөгаен. Ике бертуган, ниһаять, очрашты, алар бер-берсен тапты, алар бер-берсенэ ярдэмле, дип сөенэ торганнардыр.

Үги эти-энисе Надирга яхшы тэрбия, югары белем биреп, кеше итте. Инде алар да гүр иясе булды. Урыннары жэннэттэ булсын. Надир Кытайда, Төркиядэ, Алманиядэ, Америкада алган белемен татар халкына хезмэт итүдэ файдалана. Ул язган фэнни-гыйльми китапларнын барысы да, дип эйтерлек татар халкына, анын тарихына, эдэбиятына, атаклы шэхеслэренэ багышланган. Надир бэйнен төрек, инглиз, татар һэм урыс теллэрендэ басылган йөз иллелэп мэкалэсе һэм берничэ китабы шулар хисабыннан.

*Rusya Türklerinin Milli Mücedele Tarihi. Ankara, 1985.*
*Ismail Bey Gaspirali. Ankara, 1988.*
*Cagdas Türk dünyasi. Istandul, 1989.*
*Хәзерге чор төркиләренен халыкара алифба симпозиумы. Истанбул, 1989.*
*Чагдаш төркиләр. Истанбул, 1993.*
*Исмәгыйл бәй Гаспралы. Икенче басма, Казан, 1996.*

*Идел-Урал экспедиционы: Татарлар-Башкортлар-Чувашлар. Анкара, 1997.*
*Русия төрекләренең милли мужадәлә тарихы. Икенче басма, Анкара, 1998.*
*Ефәк юлы экспедициясе альбомы. Анкара, 1997.*
*1917 ел революциясе һәм Төрек-Татар Милләт Мәжлесе. Анкара.*

Әле күптән түгел генә Казанда «Милли китап» нәшриятында басылып чыккан «Русия төркиләренең милли көрәш тарихы (1905-1917)» дигән китап Надир Дәүләтнең ин әһәмиятле хезмәтләреннән берсе. Бу китап Төркиядә 1985, 1998 елларда басылып чыккан иде. һәм, ниһаять, ул Ана телебездә дә пәйда булды. Хөрмәтле профессорыбыз китапка багышлама да язган: «Бу хезмәтне Төркия белән Татарстан арасында фәнни һәм мәдәни күпер салынуга бик зур өлеш керткән, шушы юнәлештәге эшчәнлегемдә мина һәрдаим ярдәм кулын сузган, татарларның чын мәгънәсендә горурлана алырлык күренекле шәхесе Разил әфәнде Вәлиевкә».

Халкыбызның шушы чордагы көрәше турында аз язылмаган. Татар галимнәре бу чорны яхшы белә. Әмма Надир Дәүләт китабы шушы мәүзугъка багышлап, ватаныбызда чыгарылган хезмәтләрдән аерыла. Татарстан галимнәре нигездә ике телле архив материаллары белән генә эш йөртә ала: урысча һәм татарча. Татар галимнәре каршындагы икенче бер кыенлык, мона кадәр татарларга чит илләрдәге материаллар белән танышу чикләнгән иде. Өченчедән, галимнәребез гасыр башыннан алып унжиденче елларга чаклы булган көрәшне тар мәйданда, татар мәйданында гына тикшерәләр иде.

Шулай итеп, Надир Дәүләтнең татар телендәге бу китабы өч ягы белән отышлы һәм әһәмиятле. Надир Дәүләт милли азатлык өчен көрәш тарихын бер татарларга гына кайтарып калдырмый, бәлки Русиядәге бөтен төрки халыклар турында да яза: азәриләр, Кырым татарлары, казакълар, үзбәкләр, башкортларның да милли азатлык өчен көрәшкә керткән өлешләре турында әһәмиятле материаллар бирә. Надир Дәүләт Татарстан, Мәскәү архивларыннан тыш Төркия, Алмания һәм башка илләрдәге архивлар белән дә эш итә, һәр материалны ул оригиналь текстта тикшерә, нәтижә ясый. Шуна күрә, анын бу олуг хезмәте өстәмә материалларга бай.

Хөрмәтле галим, профессор, Төркиянең Мәрмәрә университеты житәкчесе Надир бәй Дәүләт үзенең чын ватаны, чын дәүләте дип Татарстанны саный һәм татар халкының тарихы-әдәбиятына бәйле жыеннарда бик теләп, актив рәвештә катнаша, әйтергә кирәк, бу жыеннарда анын чыгышларын тын алмыйча, йотлыгып тынлыйлар, чөнки Надир бәй буш сүз сөйләми, житди мәсьәләләр күтәрә, милли хәрәкәттәге, тарих гыйлемендәге тайпылышлар ана читтән яхшырак күренә булса кирәк.

Анын күп санлы мәкаләләре татар матбугатында еш басыла килә. Без дә Надир Дәүләтне ватандашыбыз, үз галимебез дип хисаплыйбыз.

**Рабит БАТУЛЛА.**
*8 декабрь, 1999 ел.*

## Надир Дәүләт

# ШАГЫЙРЬ ШАҺВӘЛИ КЕЛӘҮЛИ ИЖАТЫ*

Чит илләрдә яшәүче татарларның саны күп булса ун меннән дә артмый торгандыр. Алар, нигездә, Төркия, АКШ, Финляндия, Австралия, Япония, Германия кебек илләргә таралган. Төгәл саннарын билгеләү мөмкинлеге булмаса да, кайбер фаразлар ясарга була. Төркиядә ике-өч мен татар булса, АКШта алар кимрәк— мен тирәсендә. Финляндиядә дә шул чама. Австралиядә 200-300 тирәсе. Япония белән Германиядә исә

* Язмада автор стилистикасы сакланды.

50 дән дә артмый торгандыр. Табигый, аларны татар һәм башкорт дип аерсагыз, шиксез, башкортлар 10 процентны да тәшкил итми торганнардыр. Ләкин чит илләрдә яшәүчеләр мондый аеруны кирәк тапмаганнар. Шул сәбәпле дә алар төзегән оешмаларнын исемнәрендә Урта Азия җөмһүриятләрендәге кебек татар-башкорт яки аерым татар һәм башкорт исемнәренә очрамыйсыз. Алар «Төрек-татар», «Идел-Урал», «Казан төркиләре», «Ислам» кебек исемнәр алганнар.

Татар-башкортлар, гомумән алганда, 19 белән 20 йөз башында төрле сәбәпләрдән чит илләргә тарала башлаганнар. Нинди сәбәпләр соң болар? 19 йөз азагында патша хакимияте безне урыслаштырачак дип курку, сонрак революция дулкыннарына эләгү, икенче бөтендөнья сугышы чорында исә Германнарга әсирлеккә төшеп, сугыштан сон Советларга кире тапшырылудан котылып калу һ. б.

Инде мондый язмышка дучар булганнар бер урында укмашып, саннары 50-60 тан ашкач, алар дини һәм милли ихтыяжларын канәгатьләндерү өчен җәмгыятьләр төзи башлаганнар. Кытай, Япония, Төркия, АКШ, Финляндия һәм хәтта Германиядә дә төрле дини-милли оешмалар барлыкка килгән. Бу оешмаларнын төп максаты берьяктан җомга көннәре белән Рамазан аенда тәрәвих, җеназа намазлары уку, туган балаларга исем кушу, никах кылу кебек дини гыйбадәтләрне, йолаларны тиешенчә үтәү, икенче яктан балаларга туган телне укыту, ягъни милли-мәдәни азыктан мәхрүм калмау була. Әлеге оешмаларнын көче житкәннәре оешма бинасы, мәчет һәм мәктәпләр салган, китап-журналлар баскан, театр уеннары куйган, милли җыр-бию кичәләре оештырган.

**Кытайдагы оешмалар**

*Харбин Төрек-Татарлар Дини вә Милли Җәмгыяте (1904-1945)*
*Хайлар Төрек-Татарлар Дини вә Милли Җәмгыяте (1906-1955)*
*Пограничный (Дун-нин) Төрек-Татарлар Җәмгыяте (1920-1935)*
*Мукден Төрек-Татарлар Дини вә Милли Җәмгыяте (1923-1945)*
*Шанхай Төрек-Татарлар Милли Дини Оешмасы (1925-1945)*
*Тензин Оешмасы (1930-1945)*
*Чән-Чун ( Чан-Чун)*
*Оешмасы (1932-1945)*
*Һун-һуй Ди Оешмасы (1943-1945)*
*Ил Дуга Авылы Оешмасы*

**Японияддәге оешмалар**

*Токио оешмасы*
*Кобе оешмасы*
*Нагоя оешмасы*
*Япония Төрек Җәмгыяте*

**АКШтагы оешмалар**

*Американ Ислам оешмасы. Нью-Йорк штаты, Нью-Йорк шәһәре (1923)*
*(Американ Төрек-татар Оешмасы. Дини һәм мәдәни оешма) Сан Франциско/ Берлингейм*

**Финляндиядәге оешмалар**

*Финляндия Җәмаати Исламия. Хельсинки (1925)*
*Финляндия Төркиләре Берлеге. Хельсинки (1935)*
*Тампере Җәмаати Исламия. Тампере (1943)*

**Төркиядәге оешмалар**

*Идел-Урал төркиләре мәдәният һәм социаль ярдәм оешмасы. Истанбул (1955-1980)*
*Сөембикә мәдәният оешмасы. Истанбул (1957-1964)*
*Тукай яшьләр түгәрәге. Истанбул (1963-1967)*
*Казан төркиләре мәдәният һәм ярдәмләшү оешмасы. Истанбул, (1967-1980)*
*Казан мәдәният һәм ярдәмләшү оешмасы. Анкара (1967)*
*Идел-Урал төркиләре мәдәният һәм ярдәмләшү оешмасы. Истанбул, (1993)*
*Казан Мәдәният оешмасы. Искешәһәр (1993)*

Югарыдан күренгәнчә, чит илләрдә төзелгән оешмаларның берсе дә татар яки башкорт исемен алмаган. Моны да татар-башкортларны бер-береннән аеру нияте булмаган дип бәяләргә була. Асылда төрки халыклар арасында татарлар белән башкортлар кебек бер-беренә тел, гореф-гадәт, территория, тарих һәм башкалар ягыннан шулхәтле якын булган ике халык юк кебек. Кыскасы, чит илләргә китәргә мәҗбүр булган татар-башкортлар бер үк язмышны уртаклаштылар, бер үк мәчеткә йөрделәр, бер үк мәктәптә укыдылар, бер үк оешмаларда күңел ачтылар, монландылар. Шул сәбәпле аларда, һәм бигрәк тә, аларның балаларында бернинди дә аерма калмады.

Югарыда бирелгән мәгълүматлардан күренгәнчә, татар-башкортлар беренче буларак күпләп Кытай, Япония һәм аз санда Кореяга урнашканнар иде.

19 йөз азагына таба Россия белән Кытай арасында төзелгән килешү нигезендә Себердән Маньчжурияга таба узачак тимер юлы төзелә башлады. Шушы төзү эшләрен күзәтеп бару өчен билгеләнгән үзәк исә, Кытай кул астындагы иске Монголиядәге Харбин шәһәре булды. Инженерлар, администраторлар, төзү эшчеләре һәм алар белән бергәләп вак сәүдәгәрләр дә Кытайга агыла башлады. Болар арасында руслар, әрмәннәр, яһүдләр һәм татар-башкортлар да бар иде. Вакыт үтү белән аларның бер өлеше гаиләләрен үз яннарына алдыртты. Боларга аклар сафында кызылларга каршы көрәшеп Кытайга хәтле чигенгән татар-башкорт офицер һәм солдатлары—революция кануныннан котылу өчен качучылар кушылды. Шулай итеп, Маньчжурия, Кытай һәм бирелән Япониягә күчкән татар-башкортларның саны 10-15 ел эчендә байтак үсте, аларның саны 10 меңгә житте. Тик бер Хайларда гына да әлеге сан 1000-1200 чамасын тәшкил итте. Хайлар мәктәбенә йөргән балалар саны 80-100 тирәсенә иреште. Хайлардагы ике мөселман зиратында 600-700 мәет ята иде. 1930 елда Харбиндагы дини-милли оешмадагы әгъзалар саны 1000 чамасы кешене тәшкил итте.

Мукден шәһәре исә чит илләрдә яшәгән татар-башкортларга таралучы, 1937-1945 елларда әтием Ибраһим һәм әнием Рокыя Дәүләт-Килдиләр тарафыннан чыгарылган «Милли байрак» газетасы белән дикъкатьне җәлеп итте. «Милли байрак» газетасы һәвәскәр, хәтта профессиональ драматург, язучы һәм шагыйрьләрнең дә барлыкка килүенә юл ачты.

Менә шундыйлар арасында Шаһвәли Риян улы Келәүли үзенчәлекле урын били. Аның тормыш юлы татар-башкорт халкының авыр язмышына яхшы үрнәк булып тора. Аның тормышы турында кулыбызда «Ачы язмыш» һәм «Тәрҗемәи әхвәлем вә хатирәләрем» исемле ике шигъри әсәре бар. Шаһвәли 1900 елда Зирекле белән Авыргазы исемле ике кечкенә елгасы һәм Канбулат исемле күле булган Габдуссәләм авылында туа. Анасы бер мулла кызы, атасы исә хәзрәт янында укыган, ләкин дин юлыннан китмичә вак сәүдә һәм игенчелек белән мәшгуль булган Риян әфәнде. Шаһвәлинең Сатыйга исемле апасы, Мохтар һәм Гыйрфан исемле абзыйлары да була. Шаһвәли авылдагы ысулы кадим мәктәбендә укый, хәлфәдән үзенә күп чыбык эләгә. Алты-җиде яшьләрендә әнисе үлеп куя, ятим кала. Атасының эшләре дә начарайгач Петропавловскийдагы (Кызыл Яр) абзые Мохтарның чакыруы буенча өчәү—атасы, абзые Гыйрфан һәм Шаһвәли Себергә китәләр. Монда инде ул шәһәр тормышын күрә, ысулы кадим мәктәбендә укый, күзе ачыла башлый. Ләкин язмыш анарга рәхәт сулыш алырга мөмкинлек бирми. 1911 елда атасы хасталангач кабат авылга кире кайталар һәм атасы Риян 52 яшьтә вафат була. Шулай итеп Шаһвәли атасыз-анасыз кала. Мескен Шаһвәлине тәрбияләргә кем дә калмагач, анасының бертуган абзые, Кәлҗир авылының карт мәзине аны янына алдыра. Тормыш авыр булса да Шаһвәли биредәге рус мәктәбендә укып белемен арттыра. 1913 елда бик яраткан апасы Сатыйганың вафат хәбәрен алу аның яшь күңелендә зур җәрәхәт тудыра. 14 яшь тулганда ана кечкенә бер сәүдә үзәге булган, Дим суы буена урнашкан Дәүләкәндә эш табыла. Бер кибеттә приказчик булып чәй, шикәр, мамык һәм башка товарлар сатарга өйрәнә. Дәүләкән аның тормышында башка бер борылыш ноктасы була. Чөнки ул биредә чакта беренче дөнья сугышы кабынып китә, абзыйларын хәрби хезмәткә алалар. Икенчедән, Дәүләкәндә мәдәни тормыш җанлана башлый, яшьләр мөселман халкын уяту өчен милли кичәләр оештыра, аена бер мәртәбә театр куя башлыйлар, бер көтепханә ачуга ирешәләр. Шаһвәли дә шушы актив яшьләр сафында алдынгы урын били. Ләкин язмыш монда да якасыннан тота аның—1916 елда Мохтар абзыйсының сугыш кырында һәлак булу хәбәре килә. Озакламый Гыйрфан абзые дүрт кабыргасын югалткан имгәк рәвештә фронттан кире кайта. Аны

тәрбияләү вазифасы да Шаһвәлинең жилкәсенә төшә. Абыйсына ул үзе эшләгән кибеттә аз гына хезмәт хакына булса да, бер гарип башкара алырлык эш таба. Әмма Шаһвәлигә янә тынычлык насыйп булмый, чөнки бу юлы революция кабынып китә, ватандашлар сугышы чыга. 1918 елда аны хәрби хезмәткә тарталар. Бу ачы борылышның аның хәтерендә нинди тәэсир калдырганын үзе язып калдырган юллардан яхшы аңларга мөмкин.

Каһәр суксын фикер биргән галимне,
Сугышырга котырткан бар залимне.
Шулар изде минем яшьлек чагымны.
Алар ала язды минем жанымны.

Сугышка сөрелде ифрат күп инсан,
Бере кызыл, бере ак төскә кергән.
Кирәкмәгән гамәлгә, әһли шайтан
Өчен бирде ничә йөз мең кеше жан.

Идел-Урал бу ихтилал чагында,
Янып көйде әжәлнең кочагында.
Газиз туган илнең һәрбер ягында
Таланды, туналды халкыбыз тагын да.

* * *

Куылды бар халык бездән сугышка,
Яше, карты канлы, явыз буышка.
Куылды һәр ике якка бүлешкә,
Алар өчен, имеш, әйдә сугышка.

Кара бәхет милләтемә кадалган,
Йөз елларга ирексезлектә калган,
Сарык кебек сөрелде, чөнки мәхкүм,
Илем әсир, халкым кол, барысы мәзлүм.

Ике аеры әмәл, һәм канлы гая
Өчен халкым шаһит булды, бичара.
Белә алмый турылык кем ягында,
Без кан костык кызыл һәм ак сафында.

Унсигез яшь тулмас борын хәрби хезмәткә алынган Шаһвәлине аклар армиясендә кавалерист итеп куялар. Кызыллар каршында чигенгән аклар сафында өч ел чамасы сугыш кырларында дошманның угыннан, артиллерия снарядларыннан, ун меңләгән гаскәрнең дошман угыннан исән котылса да, чак кына ачлыктан һәм тифтан үлми кала ул. Хабаровскида аягын жәрәхәтли. Ул чакта әле Японнар кул астында булган Кореяның бер шәһәрендә япон шәфкать туташлары аны ике ай буе бик яхшы дәвалыйлар һәм ул исән кала. Шаһвәли Келәүлинең Байкалны үткәндә алган тәэсирләре аның «Байкал жыры» исемле әсәрендә чагылыш таба һәм бу аның көчле ижатларыннан исәпләнә. Әлеге шигыренә үзе үк көй дә яза һәм бу жыр Кытайдагы татарлар арасында озак еллар яратылып жырлана.

## Байкал күле

Егерменче ел башында
Киттек тезелеп гаскәр сафында,
Гаскәр сафында.
Төрек татар халкының без
Мәхкүм яшьләр ягында.
Байкал буенда.
Байкал буенда,
Кылыч билемдә, мылтык кулымда.

Байкал өсте бозлы ялан,
Күренми һич аргы яр чите.
Аргы яр чите.
Тик күренгән кебек шунда
Ерак күкшел, биек тау бите.
Байкал буенда.
Байкал буенда,
Кылыч билемдә, мылтык кулымда.

Байкал аша атлы гаскәр
Чыктык бер-бер артлы тезелеп,
Артлы тезелеп.
Шаулый, үкерә Байкал асты,

Ярылып китә бозлар өзелеп.
Байкал буенда.
Байкал буенда,
Кылыч билемдә, мылтык кулымда.

Салкын искән җил куәте
Чеметә битне ачы сиздереп,
Ачы сиздереп.
Ирексез без гаскәрләрне
Язмыш йортә
Байкал гиздереп.
Байкал буенда.
Байкал буенда,
Кылыч билемдә, мылтык кулымда.

Җәелеп яткан боз сахрасы
Иске данлыкларны уята,
...ларны уята.
Ничек әүвәлге бабайлар
Дәүләт корган
Байкал буйлата.
Байкал буенда.
Байкал буенда,
Кылыч билемдә, мылтык кулымда.

Элек заман изге Байкал
Күле булган ханнар кулында,
Ханнар кулында.
Югалган шул зур байлыкны
Күреп уздык Байкал буенда,
Байкал буенда.
Байкал буенда,
Кылыч билемдә, мылтык кулымда.

Шул ханнарнын күле Байкал
Буйларында без күп тормадык,
Без күп тормадык.
Тик калсын дип бездән ядкарь
Шушы көйгә моңлап җырладык.
Байкал буенда.
Байкал буенда,
Кылыч билемдә, мылтык кулымда.

*(Шанхай, 1930)*

Җинелгән армиянен хуҗасыз калган яралы солдатын кытайлар миһербанлык күрсәтеп, башка качаклар белән беррәттән, үз илләренә сыенырга рөхсәт итәләр. Шулай итеп Шанхайда Шаһвәлинен тормышында яна эпизод башлана. Ул үзе кебек исән-сау котылган Вәли һәм Гали исемле ике дустынын буйдаклар йортына урнаша. Эшсезлек, һөнәрсезлек аны асламчы булырга, ягъни җилкәсенә әйберләр салып урам буйлап, йорт борынча сатып йөрергә өйрәтә. Анын «Асламчылар» (Шанхай, 1937) исемле бер пәрдәлек комедиясе дә менә шушы чорнын мирасы.

1925 елда Шанхайдагы мөселманнарнын саны 50-60 тирәсенә җиткәч, мулла Мәдьяр Шәмгуни җитәкчелегендә дини-милли җәмгыять төзелә. Шушы чорда Шаһвәлинен әдәби эшчәнлеге башлана—25 яшькә җиткән шагыйребез иҗат итә башлый. Бер үк вакытта җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. 1934—1940 елларда Шанхай төрек-татар оешмасында секретарьлык вазифасын да үти. Шул арада бер ел Мукденгә барып, «Милли Байрак» газетасында эшли, сонрак та газета белән тыгыз бәйләнештә тора, анын биредә төрле шигырьләре басыла. «Асламчылар» кебек комедияләре Шанхайда сәхнәгә куела. Ул шушы еннарда драматург, режиссер һәм уенчы буларак та вазифа күрә.

Шул арада анын башына тагын бер һәлакәт килә—1935 елда өйләнгән хатыны Разия Агафур ике елдан сон вафат була. Ул бирешмәскә тырыша, бер ун елдан сон, 1948 елда, бу юлы Гайсә Фәтхулла исемле хатын белән тормыш кора.

1943 елда Совет армиясе Маньчжурияне басып алгач, яшәү кыенлаша—барча чит халыклар кебек татар-башкортлар да Маонын руслар ярдәмендә хакимияткә килүен күреп, үзләренә тормыш калмаячагын анлап, Кытайдан күчеп китү юлларын эзли башлыйлар. 1945 елда Маньчжурияне басып алган Совет солдатларынын «Милли Байрак» газетасын ябулары, анын хезмәткәрләрен һәм юлбашчыларын кулга алып, аларнын эзсез югалулары да коммунист режимынын ниләр башкарачагына яхшы ишарә була. Күпчелек халык «Кара тәре» оешмасынын ярдәме белән Төркиягә күчәргә җыена. Шулай итеп Шаһвәли дә хәләл җефете белән 1949 елнын 28 ноябрендә Истанбулга килеп төшә.

50 яшенә җиткән Шаһвәлине монда да җиңеллек көтми. Акчасыз, һөнәрсез Шаһвәли Келәүли кулыннан килгән бер генә эше—асламчылыкны Истанбулда да дәвам иттерә. Шушы кыенлыклар 1951 елда аны кабат буйдаклыкка этәрә. Истанбулнын Мәчидиякөй дип аталган, бары тик ярлылар гына яши торган районында, бер чокырга урнашкан өйнен подвалында үзе кебек 3 агай-эне белән яшәргә мәҗбүр була. 1966 елда, сәламәтлеге җитди рәвештә какшагач, татарларнын алдынгы шәхесләренен булышлыгы белән гарип, карт һәм кеме дә булмаганнарны кабул итә торган Дарүлгачәзә исемле картлар йортына урнаштырыла. 1970 елнын 21 апрелендә шунда вафат була һәм Ферикөй районындагы зиратка күмелә.

Шаһвәли Келәүли исән чагында, тормышның барлык авырлыкларына карамастан, үз халкыннан кулмый, аларның кичәләрендә шигырьләре белән катнаша. Хәтта аның «Асламчылар» исемле комедиясе 1967 елда Тукай яшьләр түгәрәге тарафыннан сәхнәгә дә куела. Ул 1969 елның азакларына хәтле, үлеменә 4 ай калганчы, ягъни кулы каләм тота алмаслык дәрәҗәгә килгәнче иҗат эшеннән ваз кичми. Соңгы елларында күпчелеге Шанхайда язылган 66 шигырен һәм 1925 елда Шанхайда иҗат ителгән «Ачы язмыш» исемле поэмасын нәшриятка әзерләгән булса да, бастыру мөмкинлеген таба алмый. Тик үзе вафат булганнан соң гына «Казан» журналы аның 7 шигырен төрекчәгә тәрҗемәләре белән басып чыгара. Кулыбызда аның басылмаган «Биш тәкә» исемле бер комедиясе, 1966-1969 елларда иҗат ителгән 56 шигыре бар.

Шаһвәли Келәүли шигырьләренең күпчелеге ил, илгә хәсрәт, тормыш турында. Тормышының соңгы елларында аны илдән килгән хәбәрләр борчый башлаган. Илдәге татарлар белән башкортлар арасында низаг бар дигән сүзләр йөрәгенә хәнҗәр кебек кадалгач 19 куплеттан торган озын бер шигырь яза ул. Аның фикерләре асылда чит илдә яшәүче милләттәшләрнең карашларын да чагылдыра дип әйтергә була. Шигырь бигрәк тә нәкъ менә шул ягы белән көчле, мәрхүм Шаһвәли Келәүлинең васыяте кебек тоела ул.

## Аерылмак юк, берлек бар

*Бик кыйммәтле вә мөхтәрәм башкорт кардәшемә*

Бик еракта, алдыбызда, ялтырыйдыр бер маяк,
Берләшербез— бу маякка туп-туры киттек карап.
Милли берлек кыйбласыдыр, алдыбызда ул маяк,
Тарта безне ул үзенә һәм юл ача ялтырап.

Без утырдык бер көймәгә, тупланып биш кабилә,
Башкорт, мишәр, типтәр, алатлар һәм дә үз нугай илә.
Асылыбыз төрек-татардыр, тел вә каныбыз илә,
Максатыбыз, милли бер байрак ташу, берлек илә.

Капитаны башкорт затыннан, без кабул иттек аны,
Бездән кабиләчелек юк, бар бөтенлек иманы.
Эстәсә ул, киләчәктә булсын илнең солтаны,
Булмасын тик, милли берлекнең, кара бер дошманы.

Аера алмас безне башка төрле куәт, гайә,
Чөнки без, бергә яшәгән барчабыз бер нык кыя.
Күптән инде, милли берлеккә салынган бу мая,
Бу мая безләргә биргән мәңге сүнмәслек гайә.

Бик еракта булса да ул, безгә якты нур бирә,
Әкрен-әкрен көн саен ул яктырып якын килә.
Без юнәлдек бу мөкатдәс кыйблага берлек илә,
Каршы килгән барча куәтләрне бу берлек җиңә.

Һәм мохаккак без җиңәрбез, ул маякка син инан,
Чөнки берлек безне йөртә һәм куәтле, саф иман.
Безнең илдән китсен артык, безгә кирәкми Иван,
Һәр Иваннан күптән инде һәр татар күптән туйган.

Безне аерырга теләгән чыкса әгәр бер кеше,
Бер җирәнгеч бит булып калыр тарихта һәр эше.
Пычратып беткән тарихны, бел, ул хаиннәрнең эше,
Бозма эшне, бит төшәр сина халыкның каргышы.

Аерылу димәк, урысның балтасына сап булу,
Һәм тегермәнен урысның тарттырырга су ташу.
Башка милләткә булып кол, үз юлыннан адашу,
Барлыгыннан, кыйммәтеннән, үзлегеннән качу.

Йөрмә әле син әфәндем кәкре-бөкре юл табып

Аерылсан, син, көчексен, бит урыс йотар кабып.
Әйдә, утыр шул көймәгә, йөрмә син башны ватып,
Телдә, эштә, һәм фикердә берләшик без жан атып.

Ялварып мин сезгә әйтәм, берләшик без һәммәбез,
Бар кабилә бергә булсын, булмасын һич сез вә без.
Һәм Иделнен, һәм Уралнын буйларында барчабыз,
Ашказарны бергә жырлап, бергә эчәрбез кымыз.

Кардәшем башкорт әфәнде, бәлки ялгышам үзем,
Итмәсән кабул әгәр дә шунда калсын бу сүзем.
Илнен исеме булмаганга, төн буе ачык күзем,
Байрагы да юк бу илнен, тәнре, бир безгә түзем.

Куп төшендем бу фикерне, сезгә сөйләп узуым,
Жан йөрәктән халкыбызга дәртләнеп бер юл сузыйм.
Татарстан, Башкортстан—бу исемнәрне бозыйм,
Чөнки берлек кабул итмәс, яна бер исем сызыйм.

Бик матур иде ул, «Идел-Урал» сүзләре,
Һәм лаек безнен ватанга жанлы иде үзләре.
Бер кыйсым халыкнын әнә каршы килгәч эзләре,
Бик бозылды, нишлисен бит, кунел йөзләре.

Ул югалмас, калсын инде, жанланып артта шулай,
Эстәсәләр тергезергә янадан ул бик кулай.
Арабызда юк шул абзый, ул батыр мәшһүр Юлай,
Кипми ник шөбһә тире бу жәпһәдән юк һәм Тукай.

Мин үземчә тәклиф итәм, илгә яна бер исем,
Һәр ике яктан мәкъбул, бар татар-башкорт сөйсен.
Калкынып чыгыйк жиһанга, бу исемгә баш исен,
Бу матур ил, ин ниһаять, бер матур кием кисен.

«Тат», ди бездән, «Баши» сездән, я хәрефен беркетеп
«Татбашия» дип куйсак без һәр ике якка итеп.
Хан вә солтанлык кирәкми, калсын артта ул бетеп,
«Татбашия» бу ватанны яшәтер алга илтеп.

Һәр ике тарафтан алган, бу өчәр хәреф үзе,
«Татбашия» дип жиһанда яктырып торсын йөзе.
Бер булып берлек эчендә бу исем берлек күзе—
Безне күрсен, бер фикердә яшәсен берлек үзе.

Кычкырып мин халкыбызга бар бөтен тавышым илә,
Бергә көймәдә, сезгә таба «Татбашия»ле килә.
Бар кабиләне тоягән бер фикер берлек илә,
«Татбашия»ле булырга сезгә дә өмет бирә.

«Татбашия», «Татбашия», син матур «Татбашия»
Сине тәбрик итә милләт, сина таба баш ия.
Чын йөрәктән, һәм кунелдән сине бар халык сөя,
Яшәсен безнен ватанда бу исем—«Татбашия».
Бик кыйммәтле вә мөхтәрәм башкорт кардәшемә

*Истанбул, 12.01.1968.*

*Сәнгать*

# ИЛҺАМ ШӘҖӘРӘСЕ

***Узар заманнар, Илһам Шакировны планетаның иң атаклы җырчылары белән янәшә куярлар.***

Гариф Ахунов,
Татарстанның халык язучысы.

## Илһам...

Бөтен татар дөньясының горурлыгына әверелгән бу исемне һәр тарафта яратып телгә алалар. Җырчы Илһам Шакиров турында күп язылган, кинолар төшерелгән, шигырьләр иҗат ителгән, җырлар чыгарылган... Халкыбызның моң иясе булып танылган Илһам Шакиров үзе исән чакта ук рухи асылыбызны чагылдыручы зат булды, җыр дөньясының олпат улы була белде.



Бүген дә аңа булган илаһи мәхәббәт һәр татар күңелендә үсә бара. Халкыбыз үзенең Илһамыннан илһамланып яши, тулы мөстәкыйльлеккә юл яра.

Ходай биргән сәләте янында тагын 99 процентка торышлы тырышлыгы булганга без хәзерге Илһамны беләбез. Аның тору урыны да, яшәү урыны да татар тамашачысы белән тулы залларның сәхнәсе булды.

Халык аны зурлады, әмма ул эреләнмәде, тәкәбберләнмәде, масаймады, байлык артыннан кумады, сарайлар салмады. Аның алтын сарайлары—халык күңелендә.

Илһам Шакиров татар жырындагы илһамлык серенә теләсә кемгә караганда да тирәнрәк төшенде. Шуна да бит ана бөтен татар дөньясы табынды һәм хәзер дә табына.

Сер түгел: Илһам Шакиров исемен ишетүгә күнелләр канат кагына, тормышлар акланып, пакъләнеп, сафланып киткәндәй була. Мондый халәт бары яхшылыкка, изгелеккә илтә.

1970 елларда инде танылган жырчы буларак, ул туган ягына—Сарманга концерт белән кайтты. Залда, кем әйтмешли, алма төшәр, энә төртер урын юк иде. Шул концерт барышында туган хисләрне шигырьгә салып ана житкердек. Архивымнан табып, шул шигырьне укып чыккач, анын хәзер дә искермәгәнен белдем.

Әйе, ул барыбызны да әсир итте, анын жырлавын халык, бөтен жаны, бөтен йөрәге белән көтте. Ә ул, бәгырьләрне телә-телә, халкы өчен жырлады да жырлады.

Жырчының нәсел-нәсәбе, шәжәрәсе белән кызыксынучылар күп. Әнә шул ихтыяжны канәгатьләндерү йөзеннән Илһам Шакировның ата-бабалары эзеннән анын туган якларына сәяхәткә чакырабыз, мон иясенен шәжәрәсе белән таныштырабыз.

Жырчыны халык улы буларак ныграк анлау өчен дә кирәк бу.

## Олы юлның кече авылы

Сарман—Азнакай, Сарман—Әлмәт, Сарман—Чаллы юллары өстендә утырган авылларның барсы да диярлек мәдәни һәм әдәби күгебездә йолдыз булып балкыган шәхесләрне үстергән.

Иске Минзәләбашта, ягъни, борынгы Бикбулат авылында фантаст язучы Адлер Тимергалин туган, күрше Дүсем авылы язучы, шагыйрь Фәрит Яхинны, галим Гамиржан Дәүләтшинны биргән. Казна урманы астына, Камышлы елгасы буена утырган Күтәмәле авылында Диләрә Зөбәерова канат жилпегән. Аннан төньяктарак утырган Кәшербаш (аны рәсми кәгазьләрдә Урта Кәшер дип язалар) авылы—язучы Рафис Гыйззәтуллинның туган авылы. Иске Кәшер исә патриот шагыйрь Муса Жәлилнен әсирлектәге көрәштәше Зиннәт Хәсәнов Ватаны буларак билгеле. Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшиннын ата-бабалары шушы авылда туып үскәннәр.

Фәкыйрегез туган Яхшыбай авылында Коръән Шәрифне татарчага әйләндерүче Шиһаб Мәржани шәкерте Шәйхелислам Хәмиди яшәгән. 1905 елларда бирелә язучы Фатих Сәйфи-Казанлы мөгаллимлек иткән.

Сарманга терәлеп кенә торган Мортыштамак авылында халык язучысы Аяз Гыйләжевнын әтисе Мирсәет хәлфә дөньяга килгән. Бирелә татар хатын-кызларыннан беренче роман язучы Мәдинә Маликова туган.

Сарманда Хәниф Хәйруллин туып, шунда гомер итеп, бакый дөньяга күчте. Бирелә Зөһрә Шәрифуллина зур сәхнәгә юл алды.

Сарманнан 5-6 чакрым гына читтә утырган Каташ Каран авылында нечкә күнелле лирик шагыйребез Нияз Акмалов туып үскән. Ә инде күршедәге Янурыс авылы язучы Марсель Зариповны дөньяга китергән, Нөркәй авылы исә язучылар Сөббух Рәфыйков, Саимә Ибраһимова, Изаил Зарипов белән горурлана ала.

Тау астындагы Шыгай авылы тарихында шагыйрь Гали Чокрый эз калдырган.

Аннан сон, Сарман—Чаллы юлынын уң ягында Таулык авылы. Бу Илһам Шакировнын ата-бабалары яшәгән авыл. Хәер, әтисе Гыйльметдин абзый да шушы авылда туып үскән, шушында «башлы-күзле» булган. Илһамнын апалары да шушы авылда туган.

1927 елда Гыйльметдин абзый башка авылдашлары белән бергә Яңа Бүләк авылына күчеп утыра. Бик тә бәрәкәтле урын була бу. Менә шушы авылда Илһам Шакиров туган. Сүз дә юк, күрше авыллар да мактанырлык кешеләре белән горурлана алалар. Иске Теләнче авылында—Гөлшат Зәйнашева туган, кечкенә генә Салих-Тукай авылында жырчы Зөһрә Сәхабиева туып үскән.

Бу авыллар арасында Илһам Шакировка бәйле булган Таулык һәм Иске Теләнче авыллары тарихына тукталып китик.

## Таулык авылы

Авыл турында беренче урыс мәгълүматлары 1761—1767 елларда Рәсәйдә үткән III ревизия (жан исәбен алу) документларында бар. Бу чорда авылда 94 ир-ат заты яшәгән. Аларның 39 ы «ясаклы татар» дип язылган. Димәк, алар хөкүмәткә ясак түләүчеләр булганнар. 55 ир-ат «йомышлы татар» булган. Болары инде чукынырга теләмәгән, шуңа элекке жирләреннән куылган яки көчеп китәргә дучар ителгән татар морзалары һәм аларның балалары була.




*Илһам Шакировның туграсы.*

Егерме елдан соң да, ягъни IV ревизия (1781—1782) вакытында да, авыл халкы бер дәрәжәдә калган, бары тик бер ясаклы татар ким күренә.

Бу хактагы мәгълүматларны миңа тарихчы, замандашыбыз Дамир Исхаков бирде.

1816 елда үткәрелгән VII ревизия материалларыннан күренгәнчә, авыл бу вакытта 34 хужалыктан торган, анда барысы 115 ир-ат яшәгән.

16 хужалыкта 51 ясаклы татар, 18 хужалыкта 64 йомышлы татар гомер иткән. Хатын-кызлар санын да ир-атлар саны кадәр булгандыр дисәк, 1816 елда бу авылда 230 лап кеше яшәгән дип гоманлый алабыз. Авыл Таулык инеше буена урнашкан, дип язылган. Шулай итеп, инеш исеме авыл исеме булып киткәндер дип тә уйларга мөмкин. Бу чорда авылда уртача гына зурлыктагы мәчет тә эшләгән.

Таулык авылы иң башта Байлар волостена караган, әмма соңрак Сарайлымин волосте белән бәхәсле жирләрдә кала. Сарайлымин ыруының Байлар ыруыннан аерылып чыкканлыгы мәгълүм. Жирләрнең кемнеке икәнлеген ачыклау зарурлыгы туган заманда Минзәлә елгасы бассейны буйлап—26, Игәнә елгасы бассейны буйлап 22 авыл әнә шул ике ыру волостеның бәхәсле жирендә булып чыга. Күршедәге Шыгай, Казаклар, Теләнче Тамак, иске Теләнче, Иске Дөреш, Таулы Дөреш, Хужи, Югары һәм Түбән Чыршылылар, Ләке авыллары да нәкъ шундый хәлдә була. Бу хакта Оренбург өлкә Дәүләт архивындагы (6 ф., 3 тасв. 2353 эш, 61 б.) материаллар бик ачык сөйли.

Ыру буенча булган волостьлар бетерелеп, аерым территорияләр буенча волостьлар төзелгәч, Таулык авылы Янурыс волостена карый. Бераздан волость үзәге Шыгай авылына күчерелә. Әмма волость житәкчеләрен урыслардан гына куйганлыктан, шыгайлылар волость үзәген Языкау (Языково) дигән урыс авылына күчерүгә ирешәләр.

1917 елгы Октябрь революциясенә кадәр Таулык авылы Уфа губернасы Минзәлә өязе Языкау волостена карый.

Бу вакытта инде биредәге халык ясаклы һәм йомышлы татарларга бүленеп йөртелмәгән. Русиядә крепостное право бетерелгәч, мондагы кешеләр дәүләт крәстиляннары булып исәпләнә башлыйлар.

1901 елда авылда 414 ир-ат, 372 хатын-кыз яшәгән.

XX гасыр башында Таулыкта 800 ләп кеше яши.

1917 елгы революциядән соң авыл башта Минзәлә кантонына, аннан, Чаллы кантоны төзелгәч, Чаллы кантонына карый.

1930 елның 10 сентябрендә Чаллы кантоны урынына районнар төзелгәч, Таулык авыл Советы (бу авыл Советына Казаклар авылы да кергән) Сарман районына керә. Бу чакта Таулыкта 460, Казакларда 740 кеше яшәгән. 1930 елда авылда колхоз төзелә, аңа «Сигнал» дигән исем кушалар.

1954 елда колхозларны эреләндерү башлангач, Казаклар авылында оешкан колхоз белән кушылалар, ә инде 1960 елларда «Мәгариф» (Теләнче Тамак) белән берләшәләр. Хәзерге көндә Таулык үзәге Казаклар авылында булган «Маяк» хуҗалыгына карый. 1935 елда Ворошилов районы (1957—1959 елларда Яңа юл районы) төзелгәч, Таулык авылы шушы районга күчә.

1959 елларда районнар эреләндерелгәч, Таулык янадан Сарман районына бирелә һәм яңа Тукай районы оешканчы ул Сарман районында кала.

1998 ел башына Таулыкта 50 хуҗалык исәпләнә, халкы 130 кеше.

Җырчы Илһам Шакировның нәсел тамырлары менә шушы Таулыкта. Авыл зиратында аның бабасы, бабасының ата-бабалары бакый йокыга талганнар. Зират уртасындагы иң озын чыршы Илһамның бабасы Шакирның атасы Габделнасыйр Габделхалыйк углыныкы.

Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовның әби-бабалары да шушы авылдан булган. Таулыктан берничә гаилә икенче урынга күчеп китәләр. Алар тәмле сулы чишмәләр типкән җиргә барып төпләнәләр. Авыл Бишсубаш (ягъни биш су башы булган авыл) дип аталган. Бу авылны урыслар Верхнее Бишево, Пуст Ашит (Пусташит) дип йөртәләр. Авылның Бистебаш (Бистубаш) дигән исеме дә бар. Монысы инде Бишсубаш дигәннән үзгәртелгән варианты гына. Таулык белән Бишсубаш арасында якынлык җепләре озак өзелми. Икесе дә Бөре—Мамадыш тракты кырында гына. Бу трактны Казан—Уфа (Уфа—Казан) юлы дип тә йөрткәннәр. Гомумән, бу юл Рәсәй белән Себерне тоташтырып торган.

1894 елның 1 декабрендә (искечә) Таулыкның ясаклы Фәйзулла Фәтхулла улының 22 яшьлек кызы Бибихәдичә менә шул Бишсубаш авылының билетлы солдаты Әгъләметдин Фәйруша улына кияүгә чыга. Кияүгә 24 яшь була. Менә шуларның оныгы шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов була да инде. Бибихәдичә әби оныгы Мөдәррискә бишек җырлары җырлаган, аны тирбәтеп үстергән.

Хәдичә әбинең 102 яшькә җитеп вафат булуын сөйләде Мөдәррис Әгъләмов. Ә менә Әгъләметдиннең гомере кыска булган. Ул нибары 54 яшендә фани дөньядан күчкән.

Таулык тарихы белән Мөдәррис Әгъләмов та кызыксына икән. Аңа Афзалетдин исемле бер аксакал кешеләрнең Таулык авылына хәзерге Оренбург белән Казакъстан чигендәге Кырмалы тау дигән җирдән күчеп килүләрен сөйләгән.

Әйе, Таулык авылының серләр тулы озын тарихы бар. Биредә Илһам шәҗәрәсен өйрәнеп йөргәндә күңелдә бу авылга багышлап җыр туды.

## Кош теледәй кәгазь серләре

Кайчандыр ата-бабаларыбыз йөрткән, әмма хәзерге заманда кулланылышта сирәк булган исемнәрне ишетсәм, йә иске китап битләрендәге язмалардан укысам, йә төрле җиргә сибелгән шәҗәрәләрдән тапсам, аларны күен дәфтәремә язып куя торган гадәтем бар. Мәсәлән, Йөзкәй, Йөзмән, Каракай, Карашай, Бөдәил, Ханкирмән, Йортый, Йортбагыш, Ишали, Акмәмәт, Юлдаш, Акбарс, Байчура, Бикчура, Тукбирде, Иштирәк, Куштирәк, Хорамша, Әрдуан, Уразай, Уразмән, Туктар, Ишмәт, Туйчы, Ирназар, Таймас, Яхшыкол, Якшәмбәт кебек бүген дә матур аһәңле исемнәрне теркәгәнмен. Тора-бара үзем күреп белгән байтак замандашларымның ерак ата-бабалары арасында да шундый исемнәр йөртүчеләрне белеп, нәни генә «ачышлар» ясаганым булды.

Теләнче Тамак авылында табылган бер иске китап эченнән чыккан кәгазь битендә миңа ике шәҗәрә очрады. Аның берсе Таулык авылында муллалык

иткән Сәлахетдин хәзрәтнеке иде. Икенче шәҗәрә Мөхәммәтсадыйк-Габделнасыйр-Габделхалыйк-Габделгазиз-Габдулла-Ишкилде-Үтәгән-Алпар дигән исемнәр тезмәсеннән гыйбарәт булып, шулай ук кызыксындыру тудырды.

Сәлахетдин мулла эзенә тиз төштем. Аның турында заманында тарихчы Морад Рәмзи дә язып калдырган. Ул 1847 елның 19 июнендә (искечә) ахун Сәхабетдин Габтукаев гаиләсендә туган. Заманында Шиһаб Мәрҗани мәдрәсәсендә укыган һәм аны 1879 елда тәмамлап, бу зат Таулыкта имам-хатип булып эшли башлый. Сәлахетдиннең бабасы Зәйнетдин хәзрәт тә башта Таулык авылына имам-хатип булып килгән була. Әмма ул Нөркәй авылына күчеп китә. Соңыннан Иске Әл-мәт авылында имам-хатип вә мөдәррис була. Морад Рәмзи дә, галим Ризаэтдин Фәхретдинов та аның Иске Әлмәт авылында имамлык итүе турында язалар.

Әмма Зәйнетдин хәзрәт тә, аның балалары да, оныклары да, җир өлешләре Нөркәйдә булганлыктан, үзләрен Нөркәйнеке дип исәпләгәннәр һәм ән-Нөркәви дигән тәхаллүс йөрткәннәр. Зәйнетдин хәзрәтнең Сәхабетдин һәм Хөснетдин исемле уллары атаклы Кышкар мәдрәсәсендә гыйлем эстәгәннәр. Сәхабетдин Мортышбаш авылында да мулла булып торган.

Зәйнетдин хәзрәт 1860 елның 9 маенда (искечә) 65 яшендә Иске Әлмәт авылында вафат була. Аның эшен улы Хөснетдин дәвам итә. Хөснетдинның Габдрахман исемле улы шул ук Иске Әлмәт авылының мулласы була, ә Мирсәет исемле улы икенче төп Ватаннары булган Нөркәйдә яши.

Габдрахманның Рәкыя исемле кызы—язучылар Марсель һәм Изаил Зариповларның әнисе. Кабере кечкенә генә Күктау авылы зиратында.

Мирсәет исә 1905 елда Нөркәйдән күчеп, Күктәкә авылы кырына килеп яна авылга нигез сала. Бу авылны башта Яңа Нөркәй дип йөртәләр, әмма халык арасында ул Мирсәет авылы дип атала. Тора-бара әлеге ике авыл бергә рәсми рәвештә Күктәк Мирсәет дип йөртелә башлый. Бу авыл Илһам Шакировның туган авылы Яңа Бүләк белән янәшәдә генә, аралары ике чакрым гына.

Мөгаен, һәр шәҗәрә үзенчә кызыклы. Тикшерә торгач, әлеге Габтукаевлар нәселенең төп бабасы Габтукай Урманкаевның хәзерге Балтач ягындагы Салавуч авылыннан, чукындырудан качып, 1690 елларда Стәрлебаш авылына барып урнашканлыгы ачыкланды. Кайсыларыдыр Әгерже ягындагы Салагышта калганнар. Еллар үткәч, бу токым кешеләре дә Стәрлебашка килеп тупланәләр. Алар анда мәдрәсә салалар. Анда бөтен Рәсәй мөселманнарының балалары укый. Шагыйрьләрдән Акмулла шунда белем алган. Шәмсетдин Зәки һәм Гали Чокрыйлар шунда укытканнар (1825—1865).

Теләнче Тамак авылында табылган бер иске китап битендә теркәлгән ике шәҗәрәнең берсе әнә шундый серләр ачты. Бу шәҗәрәне дәвам итүчеләр хәзер инде Алабуга, Түбән Кама, Әлмәт, Зәй, Чаллы шәһәрләрендә яшиләр. Таулыкта исә Сәлахетдин мулланың оныгы Фәйзрахман (1915 елда туган) абзый гына бар.

Икенче шәҗәрәнең серен озак ача алмадым. Шулай да андагы исемнәр гел күңелдә йөрде. Мөхәммәтсадыйк-Габделнасыйр-Габделхалыйк-Габделгазиз-Габдулла-Ишкилде-Үтәгән-Алпар... Теләнче Тамак авылында аерым-аерым Садыйклар, Насыйрлар, Халыйклар нәселләрен тапсам да, алар бу шәҗәрәнекеләр булмады. Ә инде Ишкилде, Үтәгән, Алпар исемле кешеләрне белүчеләр яки ишетүчеләр бөтенләй очрамады.

Шулай да күрше Шыгай авылында Казан сәүдәгәрләре Үтәгәневләрнең кемедер төпләнеп калуын белдем. Монда Үтәгәнев фамилиясен йөртүчеләр элек күп булган. Әмма бу да исеме исемгә туры килү генә булды. Ә менә шул ук Шыгай авылы җирендә ике тау арасы Ишкилде исемен йөртә. Авыл халкының сөйләвенә караганда, урыс хөкүмәтенең чукындырып йөрүче миссионерлары килгәч, авыл кешеләре шул тау арасына качканнар. Ә инде шул урынга тагын кемдер килеп чыкса:

—Әссәләмүгаләйкүм!—дип сәлам биргән һәм әлеге качакларга кушылган.

—Иш килде, иш килде!—дип тегеләр арасында яңа килгән кеше турында бер-берсенә хәбәр таралган.

Бу риваять күпме дәрәҗәдә дөрескә чыгадыр, әйтә алмыйм, тик «иш килде» дигәнен Ишкилде дигән кеше исеме итеп кабул итәсе килде. Бик күп бит

ул аерым кеше исеме белән аталган тау, чокыр, алан, урман, чишмә исемнәре!

Ниһаять, туган авылында, ягъни Яна Бүләктә җырчыбыз Илһам Шакиров музее ачылачак дигән хәбәр таралды. Тукай районы житәкчелеге шундый карар кабул иткән. Хакимият житәкчесе урынбасары Фәһимә ханым Гыйниятуллина белән сөйләшеп утырганда, Илһам Шакировның шәҗәрәсе хакында да сүз чыкты. Мин бу мәсьәләне хәл итәргә алындым.

Җырчының Яна Бүләк авылында яшәүче абыйсы Кыям Шакиров, Теләнче Тамакта яшәүче апасы Гөлсем апа белән очраштым. Алар әтиләре Гыйльметдин абзыйның Яна Бүләккә Таулыктан күчеп килүен, бабалары Шакир исемле, Шакирның атасы Насыйр, Насыйрның атасы Халыйк исемле булуын әйттеләр. Мин бу исемнәрне Таулык зиратындагы кабер ташларыннан да укып таптым. Кыям Шакиров бабасы Шакирның каберен чардуган белән әйләндереп алган.

Насыйр, Халыйк дигәннәре теге Теләнче Тамак авылында табылган бер иске китап битенә теркәлгән икенче шәҗәрәдәге Габделнасыйр, Габделхалыйк булуы мөмкин дигән бер уй баштан йөгереп узды. Ни дисәң дә, беренче шәҗәрә шул Таулык авылында 35 ел мулла булып торган Сәлахетдин хәзрәтнеке булгач, икенче шәҗәрә дә шул Таулык авылы кешесенеке булуы мөмкин иде.



*Илһам Шакировның шәҗәрәсе.*
*Төзүчесе—Дамир Гарифуллин.*

Илһамның бабасы «коры» Шакир гына түгел, Мөхәммәтшакир исемле булган икән. Метрикә дәфтәрләрендә нәкъ шулай язылган. Аның бертуганы Мөхәммәтсадыйк булган. Мөхәммәтсадыйкны ачыклагач, бөтен шик-шөбһәләр бетеп, эчкә «жан керде».

Архив кәгазьләре, метрикә дәфтәрләре актарып, минем куен дәфтәремдәге икенче шәҗәрәне дә шактый ачыкларга мөмкин булды.

Мөхәммәтсадыйк-Габделнасыйр-Габделхалыйк-Габделгазиз-Габдулла... Шәҗәрәдәге менә шушы биш бабаның исемнәрен таптым. Ә инде Ишкилде-Үтәгән-Алпар исемнәрен ачыклау мөмкинлеге юк, чөнки алар яшәгән чор документлары беркайда да сакланмаган да, теркәлмәгән дә.

Мөхәммәтсадыйк белән Илһамның бабасы Мөхәммәтшакирның бертуган булуын язган идек инде. Мөхәммәтшакир дәүләт крәстияны (гарәп хәрефләре белән урысчалатып «государственный крестьянин» дип язылган) булса, Мөхәммәтсадыйк отставкадагы солдат («отставной солдат») дип теркәлгән. Солдатта хезмәт иткән кеше буларак, ул урысчаны да әйбәт сукалагандыр, китап та яратучы булгандыр. Андый кеше үзенең шәҗәрәсе белән дә кызыксынмыйча калмагандыр. Бәлкем ана ата-бабалар исемлеге нәселдән-нәселгә күчеп килеп житкәндер. Хәзер инде бу хакта төгәл генә әйтеп тә булмый. Шулай да теге бер иске китап битендә очраган икенче шәҗәрәдәге 8 исемнең 5 се бүгенгәчә сакланган документларда очрагач, без инде әлеге шәҗәрәне Илһам Шакиров шәҗәрәсе дип шикләнмичә әйтә алабыз. Шулай итеп, җырчыбызның нәсел язуын Габдулладан түгел, ә бәлки Алпардан башлап китү дөрес булыр.

## Алпар...

Әйе, элекке заманнарда татарда андый исем булган. Башта кушамат буларак таралгандыр. Олы гәүдәле, баһадир кешене Алып гәүдәле, алып ир дигәннәр. Алып ирдән Алпар исеме барлыкка килгән. Алпавыт (җир-су хуҗасы) дигәндә дә шул ук тамыр сакланган.

Күп кенә урыннарда кечкенәрәк таулардан гыйбарәт өемнәрне «Алып чабата каккан җир» диләр. Ә Альп тауларының исеме дә шул ук Алыптан түгел микән?

Хәер, болары уйга бирелеп, хыял артыннан иярүдән генә әйтелә.

Һавадан җиргә төшсәк, балаларының, оныкларының нәсел-нәсәбе Таулыкта гомер иткән Алпар картның 10 нчы буыны Илһам Шакиров икәнне күрәбез. Бу унынчы буын инде Яңа Бүләк авылында туган.

Кеше күнеле кызык бит ул. Менә шушы юлларны язып утырганда ук инде Илһам Шакиров җыр дөньясының Алпары булып күз алдына баса. Элекке Алыплар, чабатасын кагып-кагып, истәлеккә калкулыклар калдырган булсалар, Илһам-Алып йөрәкләребезгә җырын индереп, гомерлек истәлекләр бирә. Шуңа күрә меңләгән-меңләгән кешеләр җырчының даһилыгын таныйлар һәм аңа тирән хөрмәт белән баш ияләр. Ихластан аны сәхнәләрдә көчле алкышларга, хуш исле чәчәкләргә күмәләр.

## Җырчының бабасы

Аны Шакир дип кенә йөрсәләр дә, мулла кушкан исеме, әйткәнебезчә, Мөхәммәтшакир булган. Атасы Габделнасыйр 1882 елда 82 яшендә дөнья куя. Аның әтисе Габделхалыйк бабай, мөгаен, йөз яшьнең теге ягына чыгып вафат булгандыр. Ул 1893 елның 16 ноябрендә (искечә) гүр иясе була. Метрикә дәфтәрләрендә аның яше 95 дип күрсәтелә. Габделнасыйрның һәм Габделхалыйкның үлү елларында күрсәтелгән яшьләре белән аларның туган елларын табуда аңлашылмау килеп чыга. Күрәсең, йә Габделнасыйрның яше арттырып язылган, йә Габделхалыйкның яше ким күрсәтелгән. Монда икенең берсе, башкача була алмый.

Мөхәммәтшакир бабайның каберендәге кабер ташында Шакир Насыйр углы диеп кенә язылган. Аны, күрәсең, Мөхәммәтшакир абзый үзе исән чакта ясап һәм язып куйган. Соңыннан кабер ташын илтеп куючылар да аның ничә яшьтә һәм кайчан вафат булуын ташка чокып тормаганнар, кабер ташын, элек ничек ясап һәм язып куелган булса, зиратка шулай илтеп утыртканнар.

Зиратта Шакирның атасы Габделнасыйр Габделхалыйк углының кабер ташы булуын искә алган идек инде. Анда «Габделнасыйр Габделхалыйк углы» дигән сүзләрдән соң буш урын калдырган да, аннан соң «яшендә вафат» диелгән. Габделнасыйр бабай да кабер ташын үзе ясап һәм язып куйган, димәк. Ә вафатыннан соң аның да яшен һәм кайчан үлүен язып тормаганнар, шулай итеп, аларны язасы урын хәзер дә буш тора.

Мөхәммәтшакирның йорты олы юлның күпер төбендә булган. Шуңа аны «Күпер Төбе Шакир» дип йөрткәннәр. Бу вакытта авылда 5 Шакир булган. Шуңа күрә һәрберсенә кушамат тагылган. Күпер Төбе Шакирны әле тагын «күке» дигән кушамат белән дә атаганнар. Кайберәүләр моны Мөхәммәтшакирның күкеле сәгатьләр төзәтүгә маһирлыгыннан чыгып аңлаталар. Аның өендә ел әйләнәсендә күке тавышы тынмаган, диләр. Бу уңайдан язучы Хәйдәр Гайнетдинов (Шакир бабайның оныгы Гыйльмисафа апаның улы) әнисеннән ишеткән бер истәлекне язып чыкты.

«Шакир абый кечкенә чагында урамда уйнап йөри икән. Күршедәге сырхау апаның басу капкасыннан чыгып баруын күреп, кая юл тотуын сораган. «Урманга, бәбкәем,—дигән апа.—Туйдым бу сырхаудан... Күкедән сорыйм әле, күпме гомерем калган икән... Ичмасам, үлемемә әзер торыр идем...» Киткән сырхау апа урманга. Аның артыннан Шакир да киткән. Урманга барып җиткәч, апа күкедән (ничә ел

яшисе барын—Д. Г.) сораган. Күке булып Шакир сиксән мәртәбә җавап биргән. Шуннан соң теге сырхау апа, таягын ташлап, авылга йөгереп диярлек кайткан. Сихәтләнеп, озак яшәгән, имеш.»

Күпер төбендә генә булгач, Габделнасыйр бабайның да, Мөхәммәтшакир бабайның да өеннән юлчылар өзелмәгән. Элекке заманнарда Бөре—Мамадыш тракты (Уфа—Казан юлы) Бөре—Минзәлә арасындагы почта юлы белән килеп, хәзерге Минзәлә районындагы Матвеевка авылыннан Кама ягына борылган. Ул Останково, Иске Теләнче авыллары аша узып, Түбән Биш—Токмак—Пальчиково авылларын узып, Соколкага килгән һәм Кама буйлап Мамадышка барган. Таулык та менә шул олы юл кырында гына булган.

Әлбәттә, башта бу юлның әһәмияте зур булган. Уфа—Бөре ягыннан Казан тарафына, Рәсәй өлкәләренә җәнлек тиреләре, күн, киез әйберләре, терлек ташыганнар. Казан ягыннан исә металл әйберләр, тукымалар, каләм-кәгазь һәм башка кирәк-ярак агылган.

Агыйдел белән Камада пароходлар йөри башлагач, бу юлның әһәмияте кими. Уфа белән Казан арасында кешеләр өчен дә, йөк ташу өчен дә пароходлар йөреп торганда әлеге олы юл бушап кала, күперләр әкренләп ташландык хәлгә килә, ташларын кирәк-яракка: өй нигезләренә, кабер ташларына сүтеп бетерәләр. Шакир бабайның кабер ташы да әнә шундый таштан ясалган.

Шакир бабай сәгать төзәтүче оста булган. Шуңа күрә, сәгать ватылдымы, аңа килә торган булганнар. Якын-тирәдә андый осталар икәү генә булган. Берсе Иске Дөреш авылы мулласы—Гәрәй, икенчесе—Шакир; Шакир өендә сәгатьләр күп булган. Суга торган һәм күкеле сәгатьләр тавышы өйдә тынып тормаган. Теләнче Тамактагы атаклы Хәлфиннәр урыс чиркәве кебек суга торган бик зур бер сәгатьне Шакирга китереп, татарча моң чыгарып суга торган сәгать көйләткәннәр дигән сүз йөри халыкта.

Буш вакытларында Шакир иске сәгать механизмнарыннан үзйөрешле арбалар да ясаган. Бу шөгылен ул кабер кырына аяк басканчы ташламаган. Нөркәй, Теләнче Тамак базарларында үзе ясаган әнә шундый үзйөрешле арбаларны сатып тамак туйдырырлык акча тапкан. Бер үк вакытта ул Совет чорындагы авыл мөәзине дә, мулласы да булган. Ураза айларында капка түпләренләге үргә, яки кар өеменә менеп, бөтен авылга ишетелерлек итеп азан әйткән...

Шакир бабай әтисе һәм бабасы кебек озын гомер кичерә. Бик картаеп, колагы катыланып, күзләре күрмәс булып, ап-ак сакаллы бабайга әверелеп, Хөснетдин исемле улының хатыны Гыйльмисафа тәрбиясендә яши һәм аңа хәер-фатихасын калдырып, 1943 елның 9 июлендә 94 яшендә фани йортыбыздан бакый дөньяга күчкән. Гыйльмисафаны Шакир бабай бик тә хөрмәт иткән һәм якын күргән. Гыйльметдин исемле улының кызына да аның исемен бирдерткән.

## Яңа Бүләк авылы

Дөньяга Илһам Шакировны бүләк иткән авыл әнә шулай атала. Ул борынгы авыл түгел. Аңа нибары XX гасырда гына, төгәл әйтсәк, 1927—1928 елларда гына нигез салына. Килеп утыручыларның барсы да диярлек Таулык авылыныкылар, дөрес, алар янына Бистебаш авылыннан да берничә кеше килеп тупләнә.

Башта хәзерге Урманчы авылы урынында, салкын чишмә буенда авыл корырга уйлыйлар. Әмма тора-бара хәзерге, ике ягыннан да су агып торган матур гына аланлы урынны сайлыйлар. Шулай итеп, элекке бояр Ушков җирендә яңа авыл барлыкка килә.

Җырчының әтисе Гыйльметдин абзый әлеге авылны нигезләгән авылдашларының үтенүе буенча бу авылга 1927 елның ахырында гаиләсе белән күченеп килә. Әтисе Шакир бабай үзенең шәхси алачыгының яртысын сүтеп алып китәргә рөхсәт бирә. Гыйльметдин тыкрык кырына килеп утыра һәм йорт җиткерә, бакча артына үз алачыгын кора. Ул тәгәрмәч ясарга, урак тешәргә, чиләк-комган-чүмеч ясарга, самавыр, йозак төзәтергә, савытларга тотка куярга бик оста

була. Әле тагын тегермән дә тарттыра белә. Кыскасы, яна авыл өчен бик тә кирәкле кеше була Гыйльметдин абзый. Авыл төзек булып, матур гына үсә бара. Үзенә житәрлек иген басулары, куе гына урманнары, челтерәп аккан чишмәләре һәр тарафка хозурлык бирә. Зәңгәр күкләрендә тургайлар, әрәмәлекләрендә сандугачлар сайрап монсызларга моң бирә, моңлыларны жыр суздырта.

Совет хөкүмәтенең авыл хужалыгы өлкәсендә алып барылган бөтен үзгәртүләрен яңабүләклеләр дә үзләрендә татыйлар.

1928 елның 28 апрелендә Чаллы кантоныннан Зәки Госманов дигән берәү колхоз оештыруда «крестьяннарга ярдәмгә» килә. Беренчеләрдән булып 5 хужалык колхозга керә. Аңа «Өмет» дигән исем бирәләр. 1929—1930 елларда авылның күпчелек хужалыгы колхозга кереп бетә. Күмәкләшкән хужалыклар саны 24 кә житә. Бу өлкәдәге житезлекне өстәгеләр дә күреп алалар. Колхозга бүләк итеп сабан, чәчкеч, ургыч, ат белән ашлык суктыру машинасы бирелә. Шушы «бүләкләр» хөрмәтенә колхозың исемен «Яңа Бүләк» дип алыштыралар. Менә шушы исем авыл исеме булып та китә.

Колхоз рәисе итеп Зәки Зариповны сайлыйлар. Бу чорда авыл Советы рәисе булып Әюп Гайсә улы Гайсин эшли. Колхозның иң алдынгылары— Гыйльметдин Шакиров, Зифа Абдуллина, Заһидулла Шәриповлар Чаллыга алдынгылар жыелышына баралар, анда республика житәкчеләре белән очрашалар.

Әлбәттә, тормыш бер урында тормый. Авылдагы һәр үзгәрешне, һәр яналыкны социализм һәм коммунизм идеяләре яктылыгында хуплыйлар, зурлыйлар, бәйрәм һәм тантаналар белән билгеләп үтәләр.

1930 елда ике агач өйне берләштереп салалар да башлангыч мәктәп ачып жибәрәләр. Беренче укытучы булып Гариф Ильясов, аннан соң Нурбисәлимә Таһирова, Кәшфетдин Госманов, Мәрзия Суфиянова, Солтангали Мирсәетов, Әсма Зыятдинова, Хәйбри Зыятдиновлар эшли.

Заманында мәчет өчен буралган бураны клуб һәм колхоз идарәсе өчен бина итеп күтәрәләр. Анын бер башына клуб урнаша, икенче башында колхоз идарәсе була.

Алга китеп шунысын да әйтик, 1935 елның март аенда Яна Бүләк авылы Сарман районыннан яңа оешкан Ворошилов районына күчә. Чирек гасыр узуга бу район бетерелә һәм авыл янадан Сарман районына бирелә. Тукай районы оешкач, Яна Бүләк авылы әнә шул район составында кала. Шәхес культы чорында ил өстен томалаган кара болытлар Яңа Бүләкне дә читләп үтми. Ун еллык та тарихы булмаган Яңа Бүләк авылында да халык дошманнарын, кулакларны эзләү башлана. «Шундыйларның берсе» авыл тимерчесе, Илһам Шакировның әтисе Гыйльметдин Шакиров кулга алына һәм төрмәгә озатыла...

Бәла ялгыз йөрми, диләр. Озак та тормый Бөек Ватан сугышы башлана. Авылның өрлектәй 44 ир-егете немец фашистларына каршы яуга китә. Аларның үзләре нигезләгән, яки үскән авылы Яңа Бүләк карт-корылар, хатын-кызлар һәм бала-чагалар кулына кала. Сугышка китүчеләрнең 25 янадан әйләнеп кайтмый, канлы көрәштә һәлак була.

Сугыштан сонгы авыр еллар да артта калалар. Ачлы-туклы халык бәхетле тормыш өмете белән алны-ялны белми эшли. 1950 еллардан соң авылда әллә күпме шатлыклы үзгәрешләр була. 1950 елда дәүләт исәбендәге клуб ачыла, беренче мәртәбә кино күрсәтелә башлый. Аннан соң 1952 елда китапханә ачыла. Бу чорда элек берәр авылдан торган колхозларны эреләндерү башлана. Яңа Бүләк әнә шундый «эре хужалык»ның үзәге булып кала. Бу хужалыкка «Яңа адым» (Иске Теләнче авылы), «Агроном» (Бай Бүләк авылы), «Урожай» (Мирсәет авылы) һәм «Игенче» (Яңа Бүләк авылы) колхозлары берләшә. Әле бервакыт «Самолет» (Шыгай авылы) колхозы да шушы хужалыкка бирелә. Әмма бу Шыгай авылы бернichә елдан соң үзәге Азалакта булган «1 Май» колхозына күчә.

Яна Бүләк авылы «Игенче» колхозының үзәге булып кала. Колхоз составында булган авыллар зур түгел. 1981 ел башына, мәсәлән, Яңа Бүләктә 68 хужалык, 247 кеше; Иске Теләнчедә 47 хужалык, 191 кеше; Күктәк Мирсәеттә 52 хужалык, 200 кеше; Бай Бүләктә 37 хужалык, 143 кеше; Урманчыда 5 хужалык, 16 кеше булган. Ягъни, Яңа Бүләк авыл Советы буенча 209 хужалык исәпләнгән, аларда 797 кеше яшәгән. Колхозның бөтен жир мәйданы 2959 гектар тәшкил итә.

Сөрүлек җирләре 2410 гектар мәйданны алып тора, ягъни бөтен җирнең 88 процентын биләп тора. 1957 елдан колхоз рәисе булып Шамил Гыйлаж улы Гыймадиев эшли. Бу чорда колхоз зур уңышларга ирешә.

Биредә авылдашлары Илһам Шакиров музее төзү һәм аны ачу да авыл тарихының җуелмас сәхифәсе булыр.

## Җырчының әтисе һәм әнисе

1993 елның урталарында журналист Резидә Әхтәмованың Илһам Шакиров белән әңгәмәсе «Юлдаш» газетасында басылып чыкты.

Анда җырчы болай ди:

—Мин әткәйне белмим. Аны 1937 елда Сталинның бик котырган чагында алып китәләр...

Ә инде: «Әткәегезне ни өчен кулга алдылар?»—дигән сорауга Илһам Шакиров:

—Беркем дә белми. Ул авылның тимерчесе булган,—ди.

Әйе, Илһамның, мин әткәйне белмим, дию бик тә дөрес. Әтисен кулга алганда ана бит әле ике яшь ярым гына узып барган. Илһам әтисеннән 935 көнлек бала булып кала.

Әмма тормышта ана әтисен гел искәртеп торгалыйлар.

«Әтиең артыннан китәсең киләме?—дип яныйлар иде»,—ди Илһам бер әңгәмәсендә («Мәгърифәт» гәзитәсе, 1995, 11 февраль, № 6 (164). Дилбәр Исламова белән әңгәмә).

Менә Илһамның җавапларыннан тагын берсе: «Унынчы сыйныфны бетереп, музыка училищесына укырга кереп кайтышлый, военкоматка учеттан төшәргә кергән идем. Шунда утыручы бер карагруһ урыс: «Бүген үк армиягә китәсең, никаких уку!»—дип җикерде. Бер-ике каршы сүз әйтеп маташкан идем, җавабы шул ук булды: «За отцом хочешь идти что ли?»

Әлбәттә, Илһам Шакиров әтисенең ни өчен кулга алынуын һәм ни өчен төрмәгә ябылуын белмәгән. Бу хакта имеш-мимешләр генә йөргән, алар арасында иң авыры—«халык дошманы» дигәне. Ул заманда мондый гаепләнүне шик астына да алырга ярамаган. Хәтта күршеләре дә «кара инде, ул бит халык дошманы булган икән» дип кенә фикер йөрткәннәр һәм шуңа ышанырга тиеш булганнар.

Илһамның әтисе Гыйльметдин Шакировның КГБ архивында саклана торган «дело»сы белән танышкач, аның бер гаепсезгә хөкем ителгәнен тоясың.

Биредәге язмалар—кеше язмышы белән бик тә җинел уйнауның ачык мисаллары. Гаепләнүченең исем-фамилиясе Шакиров Гыйльми дип кенә язылган. Әле Гыйльмине дә йә Гыйльмай, йә Гыйльман дип тутырган урыннар бар. Югары Чыршылы авыл Советыннан бирелгән характеристикада гына һәм тагын бер кәгазьдә генә ул Гыйльметдин диелә. Ник бер җирдә әтисенең исеме язылсын!

Гыйльметдин абзый өендә 1937 елның 8 октябрендә тентү үткәрәләр һәм шул ук көнне аны кулга алалар. Архивтагы «дело»да тентү беркетмәсе сакланган. Тентүне НКВДның элекке Ворошилов районы бүлеге хезмәткәре Н. Биктимеров махсус бирелгән 22 санлы ордер нигезендә үткәрә, тентү вакытында Югары Чыршылы авыл Советы әгъзалары Гариф Шакиров белән Әюп Гайсин катнаша.

«Дело»да 1937 елның 9 октябрендә Теләнче Тамакта үткәрелгән беренче сорау алу беркетмәсе дә бар. Аны НКВДның Ворошилов район бүлеге оперуполномоченные урынбасары Б. Рәҗәпов алып барган. Гаепләнүченең 7 кешедән торган гаилә составы түбәндәгечә язылган.

Хатыны Нуриәсма—45 яшьтә;
улы Имаметдин—22;
кызы Сафа—18 (монысының тулы исеме Гыйльмисафа);
кызы Гөлсем—13;
кызы Зәйнәп—7;
улы Кыям—5;
улы Илһам—3 яшьтә.

Бу сорау алу барышында Гыйльметдин абзыйга нибары өч сорау бирелгән. Беркетмәдә аларга бирелгән җаваплар да теркәлгән.

**Беренче сорау:** Хөкем органнарына (беркетмәдә «следствию» диелгән) үзенең социаль-милек хәлегез һәм чыгышыгыз турында сөйләгез.

**Җавап:** Мин урта хәлле крестьян улы. Хуҗалыгыбызда 2 өй, 1 икмәк амбары, 3 ат, 2-3 сыер һәм 10 баш вак терлегебез булды.

Мин 1926 елда әтидән башка чыктым. Минем хуҗалыкта 1 өй, 1 икмәк амбары, 2 ат, 2 сыер, 5-6 вак терлек иде.

Тимерче булып эшлим. Үземнең алачыгым бар иде, сезон вакытында 2-3 кеше яллый идем.

1930 елда колхозга кердем, бөтен инвентарьләрне һәм инструментларны колхозга кумәкләштердем.

**Икенче сорау:** Хөкем органнарына үзегезнең советка каршы алып барган бөтен эшчәнлегегез турында сөйләгез.

**Җавап:** Юк, мин беркайчан да контрреволюцион агитация алып бармадым.

**Өченче сорау:** Сезгә РСФСР Җинаять кодексының 58—10 маддәсе буенча билгеләнгән гаепләү буенча үзегезне гаепле саныйсызмы?

**Җавап:** Юк, санамыйм.

Әлеге беркетмәгә Гыйльметдин абзый латин хәрефләре белән «Sakirov» дип үзенең имзасын куйган.

Әйе, беренче сорау алу вакытында Гыйльметдин Шакиров үзен гаепсез дип саный. Мөгаен, аннан соңгы сорау алуларда да ул үзенә ташланган гаепләрне танымагандыр. «Дело»дагы икенче сорау алу беркетмәсе 1937 елның 3 декабрендә шулай ук Теләнче Тамакта тутырылган. Димәк, ике айга якын ул әле Теләнче Тамакта тотылган; күрәсең, төрле җәберләүләр һәм җәзалаулар аның да ихтыярын сындырган, тоткынлыкта тоту шартлары сәламәтлеген тагын да какшаткан.



*Илһам Шакировның әтисе*

1937 елның 3 декабрендә булган сорау алу вакытында ул үзенә ташланган гаепләрне өлешчә таный төшә, бик җитди чирле булганлыктан, күрәсең, ул гаепләргә кул селти. Аның чирле булуы хакында шул ук 3 декабрьдә Теләнче Тамак врачлык амбулаториясеннән кош теледәй кәгазьгә язылган бер белешмә бик ачык сөйли. Сорау алу алдыннан амбулатория белгечен, мөгаен, НКВДга чакыртып, тоткынның сәламәтлеген тикшерткәннәрдер. Белгеч биргән белешмәдә тоткынның каралу вакытында хроник бронхиттан, миокардтан һәм икенче дәрәҗә трахомадан җәфалануы әйтелгән.

Гыйльметдин Шакировны нәрсәдә гаепләгәннәр соң? Моны 1938 елның 8 июнендә Минзәлә шәһәрендә булган Татарстан АССР Верховный судының махсус коллегиясе сессиясенең ябык хөкем утырышында чыгарылган хөкем карарыннан ачык белергә мөмкин.

Гаепләнүче Гыйльми Шакиров совет властена дошманнарча карап, янәсе, эзлекле рәвештә контрреволюцион, советка, колхозга каршы, троцкийчыларны яклап, агитация алып барган. Мәсәлән, 1937 елның февраль аенда, аннан соң шул ук елның февраль аенда колхозчыларның клубта узган җыелышында ул әнә шундый агитация ясаган. Кыр эшләре чорына техниканы ватык калдырып ремонтлаган, ягъни корткычлык эшләгән.

Әлбәттә, бу «җинаять»ләрне ул кире каккан. Әмма суд шаһитлар авызыннан әлеге җинаятьләрне раслата. Шулай итеп, Гыйльметдин Шакиров 8 елга төрмәгә ябыла һәм әле тагын 3 елга сайлау хокукыннан мәхрүм ителә. Әлбәттә, Гыйльметдин Шакиров РСФСР Верховный судына кассация шикаяте яза. Әмма РСФСР Верховный судының махсус коллегиясенең 1938 елның 8 июлендә булган утырышында хөкем карары үз көчендә калдырыла, ә кассация шикаяте канәгатьләндерелми.

Инде Гыйльметдин Шакировның Совет властена, колхозга каршы алып

барган «җинаять»ләрен ача төшик. Гаепләнүченең эш кәгазьләреннән күренгәнчә, 1937 елның июнь аенда колхозчыларның гомуми җыелышында ул СССР оборонасы заемына язылмаска өндәгән. Ул бу гаепкә аңлатма төсендә 1937 елның 3 декабрендә үткәрелгән сорау алу вакытында болай дип җавап бирә: «Оборона заемын сатып алмаска кирәк, без узган елларда колхозга ел буе эшләп тә хезмәт көненә бернәрсә дә алмадык, дәүләт әнә шул хезмәт көннәрен заем урынына алсын...»

Икенче зур җинаяте шуннан гыйбарәт, янәсе ул 1937 елның сентябрь аенда колхозчыларның гомуми җыелышында советка каршы агитация алып бара һәм совет дәүләтенә яла яга. Шул ук сорау алу вакытында ул бу гаепләүгә дә җавап бирә: «Узган елларда бөтен ашлыкны дәүләткә сатып колхозчылар ачыктылар, быел икмәк сатмаска кирәк...»

Троцкийчыларны яклавы мәсьәләсен ул болай аңлата: «Мин күп кенә колхозчылар җыелган җирдә, 1937 елның язында, февраль аенда, троцкийчыларны юкка гына аталар, алар бит крәстияннар файдасы өчен көрәштеләр. Троцкий хуҗалык хәлен ныгыту һәм иркле сәүдә ачу өчен көрәште, дип әйттем.»

Татарстан АССР НКВДсының Ворошилов район бүлегеннән бирелгән белешмәдә Гыйльметдин Шакировның дошман элементлар, аерым алганда, Чаллы шәһәрендә яшәүче эре кулак Нәҗип Якупов һәм Чураш авылы кулагы Фәхриев белән элемтәдә булуы, Югары Чыршылы авыл Советыннан бирелгән характеристикада аның тагын НКВД органнары тарафыннан Мәрәс авылыннан сөргенгә сөрелгән җизнәсе белән дә тыгыз элемтәдә торуы әйтелгән.



*Илһам Шакировның әнисе*

Сүз дә юк, мондый гаепләүләр ул чагында кемнең дә башына җитәрлек булган.

Сталинның шәхес культын гаепләп, ГУЛАГларга озатылганнарны аклау башлангач, Гыйльметдин Шакировның улы Кыям Шакиров тиешле органнар алдында әтисен аклау буенча эш кузгата.

Ниһаять, РСФСР Верховный суды Президиумы 1972 елның 22 ноябрендә Гыйльметдин Шакировка 1938 елның 8 июнендә чыгарылган хөкем карарын юкка чыгара, аның хәрәкәтләрендә җинаять составы булмаганлыктан, җинаять эшен туктата һәм, шулай итеп, җырчының әтисе аклана.

Шулай да моңа кадәр 1938 елда шаһит булган кешеләрдән тагын бер мәртәбә сорау алу була. Әмма бу вакытка аларның күбесе—Гариф Шакиров (1890 елда туган), Зариф Шакиров (1905), Ислам Хәйруллин (1890), Фәйзулла Гайфуллин, Сөләйман Мирсәетов, Афзалетдин Сиражетдинов, Фәсхетдин Сәгытдинов вафат булалар инде. Ул чактагы колхоз рәисе Хатыйп Салихов исә Ватан сугышы кырларында хәбәрсез югала.

Шулай да 1972 елның 6 сентябрендә Гыйльметдин Шакиров эше буенча Габдулла Зәйнуллин, Сәгыйдулла Төхфәтуллин, Әюп Гайсин, Заһидулла Шәриповлардан янадан сорау алу үткәрелә. Алар Гыйльметдин Шакировның үз күче белән көн күрүче тырыш, үз сүзен курыкмый әйтүче кеше икәнлеген тагын бер мәртәбә раслыйлар.

Гыйльметдин Шакировның өендә тентү ясап, аны кулга алганда авыл Советы әгъзасы буларак катнашкан Әюп Гайсин теге чакта НКВД хезмәткәренең Гыйльметдин Шакиров өеннән винтовка эзләвен әйтә, әмма юк әйберне ул да таба алмаган.

Гыйльметдин Шакиров, ата-бабаларының гомер уртасы гына узып барганда, 1940 елның 4 мартында 5 нче хезмәт белән төзәтү колониясендә (ИТК-5) 50 яше туларга ике ай кала якты дөньядан китеп бара. Алты баланы үстерү Нуриәсма өстенә кала. Әлбәттә, ишле гаиләне туйдыру, балаларның өстен бөтен тоту җиңел булмагандыр. Бөтен җанын моң баскан бу әбине күреп сөйләшкәнем дә булды. Ул гомеренең соңгы елларын кичерә иде инде. Балаларының тормышы бөтен булуга, оныкларының сау-сәламәт үсүенә ихлас шөкер булуын әйтте. Әллә нинди озын көйләрне сүзсез генә, аларга ифрат матур борылышлар биреп

шыңшуында шатлыкка карый сагыш күбрәк иде бугай. Шул сагышлы моң татар язмышының агышы булып тирә-юньнәрне дә тетрәндереп сискәндергәндер, мөгаен. Нуриәсма апаның барлык балаларында да, оныкларында да бу җәһәттән табигать биргән илаһилык бар, минемчә. Улы Кыямның сәхнәләрне тоткан чагы күп булды. Әмма ана янындагы моң күбрәк төпчек улы Илһамга бирелгән икән. Моңа инде бөтен татар дөньясы шаһит.

Гыйльметдин абзый да чаң-чоң тимер сукканда җырлар көйләгән, диләр. Заманында Таулык авылы мулласы Сәлахетдин хәзрәт турында кызыксынып истәлекләр җыеп йөргәндә, авыл картларыннан Гыйльметдин абзыйның менә мондый бер җырын язып алган идем:

Ак күлмәгең аклырак,
Күк күлмәгең затлырак.
Авызын үпсән—телен бирә,
Теле балдан татлырак.

Мин бу хакта Нуриәсма апага да әйткәнем булды:

—Апа, бу җыр синең хакта булгандыр инде, әйеме?

—Яшь чагымда, Аллага шөкер, ак күлмәгем дә, күк күлмәгем дә бар иде,— дип әйткән иде Нуриәсма апа, рәхәтләнеп бер елмая-елмая.

Әмма әнә шундый елмаюында да сагыш сизелә иде аның. Тормыш каккан, язмыш утка-суга аткан гадәти татар хатыны иде ул. Ул да бик күп замандашлары кебек күпне күргән, күпне кичергән. Баш баласы Имаметдин Бөек Ватан сугышында катнаша, Ленинград блокадасы мәхшәрләрен үз җилкәсендә татый. 1943 елның февралендә яу кырында һәлак була. Калган балаларына да 1418 тәүлеккә сузылган сугышның бөтен авырлыгы төшә. Өч кызына да ат белән дә, үгез белән дә эшләргә туры килә. Гыйльмисафа (1919—1995) Дүртмунча авылына Гайфетдин Гайнетдиновка кияүгә чыга, җиденче дистәне ваклап барганда дөнья куя. Гыйльмисафаның Хәйдәр исемле улы каләм иясе булды. Ул шигырьләр дә, хикәяләр дә яза. Аның әсәрләре буенча шактый гына санда телевизион тапшырулар барды һәм бара. Гыйльметдин белән Нуриәсманың Зәйнәп (1929 елда туган) исемле кызлары да шул Дүртмунча авылына килен булып төшә. Гөлсем (1925 елда туган) исемле уртанчы кызлары Теләнче Тамак авылының Касыйм Суфиянов дигән егете белән тормыш корып җибәрә. Уртанчы малайлары Кыям (1932 елда туган) Яңа Буләк авылында яши. Шәрләрәмә авылы кызы Рәзинә (1935) белән бер кыз, өч малай үстереп, әтисе төзешкән авылда Алпар карт шәҗәрәсен дәвам итәләр.

Нуриәсма апа 1981 елның 29 октябрендә вафат була. Хәзер инде эфирда аның истәлегенә «Нуриәсма» дигән җыр гына яңгырый. Сүзләрен күренекле публицист, күп кенә җырлар авторы Мидхәт Миңшин язган. Көе—танылган композитор Ганс Сәйфуллинныкы. Халкыбызга Илһамны биргән ананы җырда мәңгеләштереп әлеге мөхтәрәм затлар изге эш кылганнар, билгеле.

Җилләр дә исте каршыга,
Уйнады бураннары.
Ни күрсә дә, Нуриәсма
Яманга юрамады,
Яманга юрамады.
Өметләр белән яшәде:
«Якты көн алда әле,
Якты көн алда әле...»

**Дамир ГАРИФУЛЛИН**

*

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Рецензияләр конкурсы*

## БӘХЕТЛЕ МЕСКЕНЛЕК

Айдар Хәлим үзенең «Казан утлары»нда (1999 ел, 3 сан) басылган әсәрен «кечкенә роман» дип билгеләгән. Роман, чыннан да, үтә кыска, уртача күләмле хикәягә тин дияргә була. Әсәрнең эчтәлегенә килгәндә, утыз сигез журнал битенә татар халкының язмышы тулысынча сыеп беткән дисәк, бер дә арттыру булмас шикелле. Дөрес, Көнбатыш әдәбиятларында мондый кыскалык инде күптән очраштыргалый. Сугыштан соң, укучының вакыты тар булуны искә алып һәм әдәбиятта публицистика белән телевидениеның «теше үтмәслек» рухи-әхлакый мәсьәләләр генә сайланганлыктан, әдәби текстның күләме кечерәйде. Татар әдәбиятында исә кыска язарга өйрәнү мәсьәләсе әле һаман көн тәртибендә кала килә.

«Татар вакыты» романында персонажлар саны да шактый әз. Әсәрнең үзәк герое Мотаһар Чанборисовтан тыш һәр персонаж диярлек шушы бәндәнең язмышын тулыландыру, тирәнәйтү, аның тәкъдирен яшәешкә ныграк бәйләү өчен сурәтләнгәннәр.

Кайсы яктан алып карасаң да, әсәр гаҗәеп уңышлы чыккан! Ләкин роман авторы мактауга мохтаҗ түгел. Гомумән, минемчә, мактау әдәбият өлкәсендә язучының абруен төшерүдән тыш берни дә бирми. Ә «Татар вакыты» исә—әдәбиятыбыз тарихына кереп калырлык, әдәби вакыйга булырлык әсәр.

Мотаһар—сугыш инвалиды. «Ватан сугышы» дип аталган гарасат аның теш казнасын умырып ташлаган, ә инде тынычлык елларындагы социалистик хезмәт мескеннең күзен сукырайткан. Зәвыклы укучы әсәрне укып чыккач тоя, аңлый: геройның гарипләге даими сугыш белән шөгыльләнеп, сугыш өчен яшәгән империя шартларында табигый хәл.

Бусы әле роман эчтәлегенең өске катламы гына. Мотаһар Чанборисовның язмышы, аның сукырлыгы, талымсызлыгы, тормышның иң каһәрле шартларында да канәгать яшәве татарның менталитетына тәңгәл килә. Символ буларак, Мотаһарның татар халкын хәтерләтүе бәхәссез. Бу сурәттә милләтнең бүгенге сыйфатына, аның тарихи язмышына тиң тетрәндергеч хакыйкать чагыла...

Чыннан да, милләт буларак, без гарип түгелмени? Милли йолалар, гореф-гадәтләр югалган. Безне динсез калдырганнар. Телебезнең калган өлеше шундый ярлы, сай, күп очракта күңел кичерешләре катлаулылыгын аңлатуы да бик авыр. Ә чынбарлыкны, менә-менә өстебезгә ишелеп төшәргә торган инкыйразны күрүгә килгәндә—без сукыр. Җитмеш ел совет чынбарлыгында яшәтеп безне күңел күзе белән күрүдән биздергәннәр. Маңгай күзе дә милләткә, җәмгыятькә куркыныч алып килгәнне түгел, бары тик тар бер кисәкне генә күрүгә көйләнеп беткән. Безнең күз дә, колак та, баш миебез дә үзебездә түгел—хакимият кулында. Нәрсә биреп, нинди юл белән алганнар соң безнең шушы кешелек дәрәҗәсен исбатлый торган иң асыл, иң зарур сыйфатларыбызны? Айдар Хәлимнең романы нәкъ шушы сорауларга җавап бирә. Фикерле, дәлилле һәм дөньяны тирән аңлый торган кешене канәгатьләндерерлек җавап бу. Ләкин шушы куркыныч хакыйкатьне аңлый алырлык укучы калдымы соң татарда? Калган булса, күпме алар? Кемнәр, нинди кешеләр алар?

* * *

Әдипнең төп хезмәте нидән гыйбарәт? Язган әсәрендә чынбарлыкны мөмкин булган дәрәҗәдә төгәл, жете сүрәтле итеп, дөрес һәм тирәнтен чагылдыруда. Юк, графоманнардагыча, казылык тутырган шикелле тормыш детальләрен әсәргә төеп тутыру ярдәмендә эшләнми бу. Әдип укучының мәрткә китә башлаган иманын уятып, аны битарафлыктан сөйрәп чыгара алырлык кайнар тәэсирле сүз тылсымы тудыра алу белән үзенең вазифасын раслый булса кирәк. Ләкин бусы—аерым бер тема. Бу мәсьәләгә кагылуымның сәбәбе исә «Татар вакыты»нда шушы эшнең моңа кадәр татар әдәбиятында күрелмәгән дәрәҗәдә башкарылуын әйтер өчен генә. Чыннан да, Айдар Хәлимнең уңышы—татар әдәбиятының уңышы бит. Без, әдипләр, бу әсәр белән горурланырга хаклы.

«Һәйбәт кешеләр иде, мәрхүмкәйләр...»—дип башланып китә роман. Аңлаган укучы өчен мөһим реплика бу. Романның калган өлешендә автор шул «Һәйбәт кешеләр»нең коммунистлар икәнлеген язганнан соң, алар калдырган мирасны барлый башлый. Чиктән тыш җаваплы, авыр, катлаулы вазифа. Бүгенге болгавыр чорда, социализмнан кире капитализмга кайту чорында—бөлгенлек һәм гаделсезлек чорында—коммунистлар хакимияте заманын без бөек төзелешләр һәм галәмгә очу, социалистик ярыш, «бөек» ватан (!) сугышында җинеп чыгу рәвешендә күрергә өйрәнгәнбез. «Артта калган, надан, кара халыкны социализм чорында белемле, культуралы иттек, бәхеткә ирештердек!» дип баш миебезгә чүкеп торды агитпропта. Моңа ышанмаска тырышып, карышып карасак та ялгыз шәхес системага, хакимияткә каршы тора алмаганлыктан, без пропагандага тәмам инанып беткәнлегебезне сизми дә калдык. Башка илләрдәге шартлар белән чагыштырып карау мөмкинлеге дә юк иде совет чорында. Ләкин, тулаем алганда, ул чакта бүгенге көн дәрәҗәсендәге хәерчелек тә, халык мөлкәтен талап миллиардлар туплаучылар да юк иде. Гадиләштереп әйткәндә, патша заманындагы байлык белән шул чорның хәерчелеген бергә кушып тигезләгәч, социализм чорында авыр булса да түзәрлек дәрәҗәдә мохтаҗлык барлыкка килде. Тоташ милексезлек... Тоташ ялланып эшләү... Хакимият, гади халык турында кайгырткан булып, күз буйый. Хезмәт ияләре тырышып эшләгән булып хакимият каршында юхалана. Күпчелекнең кесәсендә, белемгә кысыр булса да, мөһер сугылган диплом. Белемсез булсалар да фәнни дәрәҗәгә ия надан галимнәр... Патша заманындагы лашманчылыкны татар халык иҗаты каргап каһәрләсә, совет чоры лашманчылыгын әдипләребез күкләргә чөеп мактадылар. Айдар Хәлимнең «Татар вакыты»нда безнең әнә шул иллюзияләребезнең сабын куыгы шикелле шартлап ярылуы баш каһарман язмышы аша күрсәтелгән.

* * *

Романның сюжетына тукталыйк. Әсәр иртәнге сәгать тугызлар тирәсендә башлана һәм кичке дүрттән соң (чөнки кышкы көн ифрат кыска) караңгы иңеп килгәндә тәмамлана. Коммунистларның «Һәйбәт кеше» булулары турында Мотаһар карт улы Мөдәррискә иртәнге чәй вакытында белгертсә, кичке эңгер иңеп, шәһәр карангылыкка кереп югала башлаганда әсәр тәмамлана. Шушы кыска вакыт эчендә бер гаилә язмышы аша сурәтләнгән каһәрле татар тәкъдире тулаем диярлек сурәтләнеп бетә.

Миңа иң зур куаныч китергәне—әсәрдәге образлар астында яткан тирән философия. Нинди философия соң бу? Совет чорында безгә көчләп кертелгән диалектик һәм тарихи материализммы? Түгел. Айдар Хәлимнең бу әсәре кайсы ягы беләндер Жан Поль Сартрның «Косасы килү» (урыс тәрҗемәсендә «Тошнота») повестын хәтерләтә. Дөрес, «Татар вакыты»нда Сартр әсәрләрендәге кискенлек йомшартылган, татарга хас моңсулык, тыйнаклык кертелгән, әмма әсәрнең нигезендә экзистенциальлык ятуы бәхәссез. Бик тә тырыш, тормышка теше-тырнагы белән ябышып яшәгән Мотаһар белән анын хәләленнән туган балалар нигә шундыйлар? Мотаһарның оныгы Вадимда татарлык кына түгел, адәм баласына хас бүтән сыйфатлар да кая китеп беткәннәр соң? Мотаһарның килене Зөмәрә татар дөньясыннан күптән ваз кичүенә карамастан, нишләп әле татар лицеендә сәнгать фәнен укыта? Сәнгать дөньясында йөзгән хатын нигә шулай шапшак, мәнсез, дорфа? Әсәр персонажлары бер-берсен берничек тә аңлый алмыйлар һәм үзара дөм битарафлар. Бу—әсәрнең төп проблемасы.

Адәм баласы бүгенгелектән бәхет таба алмаган очракта бәхет эзләвен киләчәк

хыялларына күчерә, киләчәктән өметләре өзелгән очракта да төшенкелеккә бирелмичә, үзенең артта калган бәхетле көннәренә күчеп яши башлый. Вакытка сыйган вакыйга кичерешләре дә экзистенциаль философия үлчәве белән үлчәгәндә шактый үзгә. Мәсәлән, картларның бер ай татыган хатирәләрен балалар бер көн эчендә колачлый алганнары мәгълүм. Айдарның әсәрендә вакытка кагылышлы тагын бер ачыш ясалган: колониаль режим бездән, татардан, вакытыбызны да алып, үз вакытын—Мәскәү вакытын таккан икән. Юк, бу Спас манарасындагы сәгать сугуына көйләнеп яшәү белән генә чикләнми икән. Асылда, без, татарлар, нәкъ урыслар шикелле, тоталитар хакимият кушканча, кулдагы, бүгенлелектән ваз кичеп, һавадагы киләчәкнең буш вәгъсенә инанып яшәргә мәҗбүр ителгәнбез икән. Романда шушы проблемалар гаҗәп тәэсирле һәм төгәл куелганнар.

Бер генә эпизодка күз сирпеп үтик. Мотаһарның оныгы Вадим мәктәптән кайту белән Җанбарысларның берничә буынына хезмәт иткән гаилә реликвиясе саналган күкеле сәгатьне туктатып, телевизорны кабызып җибәрә. Сәгать—гаилә мирасы, вакытны мөстәкыйль исәпләп семья әгъзаларына белгертеп торучы бер символ. Сәгать Мәскәүгә буйсынмый. Телевизор исә тулысынча Мәскәү сәясәтен, адәм баласын агулый торган ялган, ясалма тормыш бирә. Ул кешене чынбарлыктан суырып алып, үз мохитында, үзе боерганча яшәргә мәҗбүр итә. Ниһаять, ул сәгатьне талап алып китәләр һәм, әсәрдә бу турыда сүз кузгатылмаган булса да, татар вакытын саклаучы символның язмышы аңлаешлы: аны сатачаклар. Мотаһар картның үлүе дә безнең милли проблемаларга кагылышлы күп нәрсәне ачыклый. Чынбарлыкта Мотаһар ишеләргә реаль яшәү генә түгел, виртуаль яшәүгә дә урын калмаган икән. Андыйлар тормыш аренасына килгән вадимнар, зөмәрәләргә урын чистартырга тиешләр икән.

Шушы утыз сигез битлек бәләкәй генә романга Айдар Хәлим татарның Евразия киңлекләрен иңләп, дөньяны дер селкетеп яшәгән җанбарыслык чорларын, аннары мөстәкыйльлекне югалткач, сәүдәгәрлеккә ябышып карау, коммунизм байрагы астында инкыйразга юлыгу һәм бүгенге көндәге Вадим дәрәҗәсенә житеп мутантлашу күренешләрен сыйдыра алган.

* * *

Романда татар язмышы гаилә тормышы аша сурәтләнә, дидек. Татар әдәбияты өчен чиктән тыш мөһим, хәлиткеч тема бу. Ни өчен? Чөнки җәмгыятьтә татарга урын юк диярлек. Дөресен әйткәндә, татарның җәмгыяте дә юк дәрәҗәдә. Җәмгыять аренасына керү белән без урыс чанасына утырып, урыс җырын җырларга тиешбез. Башкача булса безне тибеп озатырлар дип куркабыз без. Инглизләрдәге фикердәшлек, уртак мавыгу, сердәшлек мәктәбе—«инглиз клублары» да юк бездә. Яһүдләрдәге һәм әрмәннәрдәге шикелле, кешегә кыйбла табарга ярдәм иткән, яшәү проблемаларын күмәк чишәргә чиктән тыш кулай общиналарыбыз да юк. Адашканга юл күрсәтеп, бәхетсезлеккә юлыкканнарга ярдәм кулы сузарга әзер торган андый татар общинасын оештыру бәлки мөмкин дә түгелдер, чөнки бергә җыелган татарлар арасында ким дигәндә 10-15 проценты рәсми шымчы һәм шулар өстәвенә сатылырга әзер торучылар, шул юл белән тамак туйдырырга уйлаучылар даими була. Милләтнең оешуына каршы торган көчләр моның белән генә дә бетми әле. Мәсәлән, урысларны җәмгыятьтә дә, хезмәттә дә озын-озак гасырларга сузылган, яулап алу процессында барлыкка килгән казарма бердәмлеге, ушкуйниклык тәвәккәллеге берләштерә. Ә безгә бүгенге көндә тик бер генә оешу мөмкинлеге рөхсәт ителгән: империянең яулап алу байрагы астында һәм лашманчылык кысасында. Дөрес, Татарстан Язучылар берлегенең соңгы корылтае, анда дистә еллар буена әдәбиятның җелеген суыручыларны бәреп төшерү милли аңның уяна башлавын раслады. Ләкин бу әле мескенлек диңгезендәге бер генә тамчы рухи батырлык...

Николай Трубецкой татарны «блуждающий атом», дип юкка гына атамаган. Колониаль богауга юлыккан, керәш дәверендә батырларын югалтып бетергән, ирек төмен оныткан һәр милләткә диярлек хас сыйфат бу. Ә бергә җыелып, милли проблемаларны чишә башлау белән татарның колагына бер аваз ишетелә: «Өлкән абзыкайлар хупларлармы сезнең бу гамәлегезне? Әллә бәрәңге бәхетеннән дә колак кагасың киләме?..» Кешенең аң базында сөрән салып ятучы шомлы аваз бу. Шушы авазны ишетү белән үзебез дә сизмичә, ирексездән, тизрәк шаһгалиләргә барып сырышабыз без...

Айдар Хәлимнең соңгы елларда язылган әсәрләренең барысы да диярлек гаилә тормышын, шул тормышта туган проблемаларны ачыклауга багышланганнар. Ни өчен? Кызганычка каршы, татар кешесе бер урында, бары тик бер генә урында җанына рәхәтлек, күңеленә яшәү дәрте таба ала. Бу урын—гаилә. Татарда гомумкешелек сыйфатлары, мең еллар буена бөртекләп сайланган иң кыйммәтле хәзинәбез—гореф-гадәтләр бары тик гаиләдә генә саклана алган. Гаиләдән чыгып, шәһәрнең урамтыкрыкларына керү белән без әнә шул ата-баба хәзинәсеннән колак кага башлыйбыз. Карьера дигән баскычтан югарыга күтәрелгән саен аяусызрак кырыла, югала, исраф була ул сыйфатлар. Империя казармасының аяусыз шарты бу... Империя исән чакта биш гасыр камилләшкән аяусыз канунны бернинди көч, бернинди дәрман да үзгәртә алмаячак. «Империя исән чакта татар кешесенә бәхетле яшәү турында өметләнү—алсу томаннан тукылган иллюзия генә ул» дигән фикер Айдар Хәлимнең «Өч аяклы ат», «Сандугачым-карлыгачым», «Кыйбла», «Әңгер», «Авылдаш» исемле элегрәк басылган әсәрләрендә җәйрәп ята. Китап укуны онытмаган бәндә (ә бит без озак гасырлар китап белән юанып яшәгән милләт) һичшиксез бу мәгънәне аңлаячак.

Күңелгә кызык бер фикер килә.

Әгәр мин шушы әсәрләрнең авторы булсам, Оноре де Бальзак тәҗрибәсенә таянып, әлеге китапларны «Татар гаиләсенең таркалу фаҗигасы» исеме белән бергә берләштерер идем. Гаилә тарихы аша милләт тарихын аңлау дәрәҗәсенә ирешер иде бу очракта укучы.

* * *

«Татар вакыты»нда күтәрелгән проблемалар шактый күп. Аларның барысын да анализлый башласам, язмам диссертациягә әверелер дип куркам. Диссертацияне исә, сез беләсез, укымыйлар. Ләкин, әлеге проблемалардан тыш безнең әдәбият өчен яңалык булырлык манзаралар да күп әсәрдә. Шулар арасыннан берсе—кибеттә балык уылдыгы кузгаткан җәнҗал. Казан дәрәҗәсендәге мәдәният үзәгендә яшәгән татарлар да икраның үз телләрендә ничек аталганын белмиләр икән. Чыннан да бит, уылдык—түрәләр ризыгы, аны татар түрәләре үзләреннән өстәрәк утыручы урыс түрәләре белән мәҗлестә очрашканда гына ашыйлар. Шуңа күрә дә гади халык аның нәрсә икәнлеген белә алмый. Аннары, кызы Фәрдүнәгә әллә нинди зур пенсия акчасы алучы булып тоелган Мотаһар картның бу ризыкны бөтенләй татып та караганы юк икән әле. Менә шушы, беренче карауга пүчтәк кенә тоелган күренеш татар халкының нинди шартларда яшәгәнлеген ачык күрсәтә.

Проблемаларның һәрберсенә тукталып торудан баш тартсам да, шулар арасында миңа чиктән тыш кызыклы тоелган берсенә игътибар итми мөмкин түгел. Бу проблема—татар кешесенең язмышында орден-медаль мәсьәләсе. Әйе, бүләк алу белән мавыгу хан заманында ук халкыбызга санап бетергесез фаҗигалар тудырган. Чөнки бүләк белән ришвәт арасындагы аерманы, бүләкнең мактаулы билге булудан туктап, сатылу дәрәҗәсенә күчү чиген кем билгели ала? «Татар вакыты»нда бу нечкә мәсьәлә искиткеч оста кулланылган. Мотаһар карт үзенең гариплегенә, якты дөньяны күрүдән мәхрүм калуына һәм дөм ялгызлыкта яшәвенә карамастан, үзен шактый бәхетле тоя. Аның бәхетенең бер өлеше—пенсиясе печтек кенә булса да бүгенге бөлгенлектә, хәерчелек фонында зур булып тоелуы. Шушы томана канәгатьлек мескен картны саклау кассасына салган акчаларының девальвация нәтиҗәсендә туктаусыз кимеп торуын сиземләүдән дә коткара. Ә инде шушы бәхетле мескенлекнең төп сәбәбенә килгәндә, бу—картның ватан сугышына катнашу горурлыгы, шул сугышта катнашкан өчен түшенә хөкүмәт таккан калайлар. Укучы моны белә торгандыр дип уйлыйм: Бөек географик ачышлар чорында европалылар мәҗүси халыкларга төрле ялтыравыклы тәтиләр биреп аларның байлыкларын талап алганнар, җирләренә басып кергәннәр. Бәлки без, татарлар, да шул мәҗүсиләр дәрәҗәсендә томанабыздыр, ә? Юк, алай булуы мөмкин түгел, чөнки татарның тулы тарихын карасак, мәҗүсилек белән исламга күчү арасында гасырларга сузылган тәңречелек ятуын күрербез. Тәңречелек дине исә, безнең ерак бабаларыбызны Күк, Җир, Елга-Таулар дәрәҗә-масштабында эш итәргә өйрәткән. Шушы фикерне дәлилләү өчен дикъкать белән «Идегәй»не укып карау житә. Идегәй чорында шәхеслек масштабы гаҗәеп зур булган. Ә инде бәяләү шкаласына, яшәеш өчен мөһим һәм пүчтәк нәрсәләр арасындагы аерманы тоемлауга килгәндә, Урта гасырларда яшәгән бабаларыбыз чынчыннан рухи аристократлар булганнар. Ә ни өчен соң без бүгенге көндә түшкә тага

торган ялтыравыклы бер калай бәрабәренә иманыбызны сатарга әзер торабыз? Бу фикеремне мин йөзләгән мисал белән дәлилли алам. Мәсәлән, зыялыларыбыз чит илләргә чыгып йөри башлагач түшләренә көмеш тәре тагып кайтырга тотындылар. Бу чирдән милләт өчен жан атып яшәгән бер генә шәхес тә читтә кала алмады. Ә Суверенитетны шартнамәгә алыштыргач, безнең иң баш түрәләребезнең түшләренә Ельцин ясаткан тәреләрне тагарга тотындылар. Шулар арасында бер генә дә баш тартучы табылмады. Орден-медаль гына түгел, төрле дәрәжә тирәсендә дә нәкъ шушындый психик ажиотаж туа. Мәсәлән, Лондонда берничә авантюрист 30 долларга «Елның иң күренекле шәхесе» аталган коры куык сатарга керешә. Татар зыялылары шундук бу кармакка да капты. Ә инде Рәсәй Фәннәр академиясенә генә түгел, гомумән, фәннең үзенә бернинди катнашы булмаган оешмалар ачып, 6 мең сумга академиклык таныклыгы сата башлагач, татар кешесе бу авантюра җимен дә кабып йотты.

Бу эпедимия бер татарда гына дисәм дөрес булмас иде. СССРның 50 еллык юбилеена багышланган бүләкләр өләшү чорында мин бер министрлыкта түрә булып утыра идем. Бүләкләү комиссиясенә мине дә теркәп куйганнар. Шул калай абруй алыр өчен тәкъдим иткән ришвәтләр, өреп кабартылган «батырлыкларын» раслый торган ясалма документлар комиссия карамагына елга булып агып керә башлады. Ә инде югарыда утыручы туган-тумачалары, әшнәләре аша басым ясап орден-медаль даулаучылар «армиясе» турында сөйләп тә торасым килми. Шул ук вакытта, бу өлкәдә, барыбер, урыс халкы татар дәрәҗәсенә житеп аңын югалтмагандыр дип уйлыйм мин. Әнә, Александр Солженицын белән Евгений Евтушенко Ельцин тәкъдим иткән орденнардан баш тарттылар. Шуннан соң инде татар зыялыларын күз алдымнан үткәрәм. Бездә тәре тагудан баш тартырлык шәхес бар дип әйтә алмыйм, куркам. Нишләргә?!

Нигә соң татар мескене шул түшкә тага торган ялтыравыклы жиз кисәге бәрабәренә җанын, иманын сатуга каршы тора алмый? Татар егетләренең түшендә Чечня үтерешендә күрсәткән геройлыклары өчен тагылган калайларны күргәндә чәчләрем үрә тора. Үләсем килә башлый... Ә бәлки минем аларга бәя бирергә хакым да юктыр? Чөнки үзем дә бит утыз елга якын жир шарының барлык төбәкләренә Рәсәйдә ясалган коралны ташып, кан коюга катнашкан гөнаһлы бәндә. Түшкә тага торган калайның күп очракта үтерештә катнашкан өчен бирелгәнлеген искә алганда, шуны да искә төшереп китәсем килә. Николаев портыннан өстәрәк, Буг елгасының бер аулак затонына урнашкан Балабановкада, каракларча, караңгылыкка яшеренеп, трюмнарыбызга корал, твиндекларга гаскәр төйибез... Босфорны да нәкъ террористларча—төннең иң караңгы вакытында узабыз да, кан коеласы һәм толлар, ятимнәр барлыкка киләсе «кайнар ноктага» курс сызып, юлга чыгабыз. Гибралтарны үткәч, твиндекларда нәкъ Африкадан плантаторларга сатарга төяп илтелгән кара коллар хәлендәге тынчулыкта барган солдатларның командирына яшерен конверт тапшырыла. Командир конвертны ачкач кына мескен солдатларның кайсы континентка, кемнәр канын коярга барулары ачыклана. Капитанның сейфында икенче, тышына «Корабны кулга алу куркынычы туганда ачарга» дип язылган «Совершенно секретный» конверт ята. Конверт эчендәге кәгазьдә: «Корабны кулга алу куркынычы туганда иң ышанычлы рядовой коммунистны машина бүлегенә кингстонны ачарга төшерергә, аның боерык үтәвен күзәтер өчен командир коммунистны билгеләргә. Боерыкның үтәлүен үзегез тикшерәсез. Бу приказ беспрекословно, без обсуждения үтәлергә тиеш», дип язылган була иде. Ә бүген, әнә, террористлыкка өйрәтүдә мөселманнарга яла ягалар. Ә бит массакүләм террористлыкка өйрәтү, өйрәтү генә түгел—шуңа күндерү гамәле, совет чорында СССРда, бүгенге көндә Рәсәйдә алып барыла икән ләбаса... Юк, без корал илтеп сугыш уты кабызган илләрнең халыкларына карата гына түгел, үз-үзебезгә, шул коралны ташучыларга карата да террористлык эшләнеп килгән икән ул озак еллар дәвамында. Һәм әнә шул эш уңышлы башкарылганнан соң түшкә тагарга калай өләшәләр иде. Әгәр без адәми заттан, һомо сапиенс затыннан икәнбез, түшкә тагылган калай безнең җинаятьче булуыбызны фаш итәргә тиеш иде, югыйсә. Ә без шул җинаятькә катнашуыбыз билгесен горурланып тагып йөрдек. Шушы парадокс озак еллар мине аптырата иде. «Татар вакыты»н укыгач, шушы мәсьәлә шактый ук ачыклана башлады. Бу каныбызга сеңгән икән. Без уйланудан, бәхетсезлегебезне аңларга тырышудан туктаганбыз...

Рәсәй халкы беркайчан да тулы хокуклы граждан булып яши алмады. Аяусыз көчле дәүләтчелек белән искиткеч дәрәҗәдә кыерсытылган, милексез, хокуксыз, үзенең шушы хәлдә яшәвен төшенә алмаган халыкка бу турда аңлатып та булмый бит. Ул бит инде шуңа тәмам күнегеп беткән, яшәешен шул чынбарлыкка яраштырган, шунлыктан,

анлата башлау белән, беренчедән, син аны унайсыз хәлгә куясың һәм дошманлык тудырудан тыш берни майтара алмыйсың.

Тагын бала чагымдагы бер хатирә искә төшә. Минем җизнәм, авыл мәктәбенең иң абруйлы математигы, минем белемгә омтылуымның төп сәбәпчесе, бер көнне үзенең ГТО значогын югалтып кайтты. Ат югалтудан да фаҗигалерәк тоелды бу хәл безгә. Төнлә йокыдан уянып китәм дә: «Ничек үзенең зур, абруйлы кеше икәнлеген исбатлый алыр икән?»—дип ут йотып, кайгырып ятам. Чөнки ул чорда һәр авыл, район һәм Казан зыялысы түшендә ГТО, ГСО, МОПР, «Ворошиловский стрелок» һәм тагын әллә нинди тузга язмаган «абруй» тамгаларын ялтыратып йөртергә тиеш иде. Шулай булмаган очракта аның күнел төбендә бер төрле кимсенү барлыкка килә иде. Хәзер инде бу хәл миңа көлке дә тоела, әмма гади көлке түгел—еласыларны китерә торган газаплы көлке...

«Татар вакыты»н укыганчы мин ни сәбәпле татарның ялтыравыклы калайга чат ябышуын, шуны алу өчен хәтта шәрә күкрәге белән амбразура капларга әзер торуын анлап җиткерә алмый иза чигә идем. Ә менә Мотаһар мисалы моңа да ачыклык кертә: тоталитар урыс дәүләтенең дәгъвачысы, фаш итүче төп көче булганлыктан, татарны башка милләтләргә караганда ныграк кимсеткәннәр, кыерсыту чараларын да күбрәк кулланганнар икән. Каршы торучыларны даими юкка чыгарып килгәннәр. Ә бит татарның да башкалардан ким буласы килмәгән, абруйлы, ихтирамлы яшисе килгән. Шуңа күрәдер инде, үзен өлкән абзыкайлар дәрәҗәсенә күтәрә алырлык һәр дәлилгә татар кешесе теше-тырнагы белән ябышкан. Шул дәлилләр арасында иң кыйммәтлесе һәм ышанычлысы орден-медаль саналуын Айдар Хәлим үз әсәрендә искиткеч ышанычлы итеп күрсәтә алган.

Әсәр бик тә тыгыз язылган, баштан ахырынача бербөтен тукыма булып бара. Бәлки шуңа күрәдер дә аннан мисал итеп өзек бирү шактый катлаулы:

«... Ишектән иң тәүдә хәрбинең сәмруг кошлы кокардасы, аннан соң шинель поставы эчендәге йомырка гәүдәсе керде. Артында фотоаппарат аскан хатынкай да бар.

—Гафью итясез, мин татарча начар суляшам,—позвольте местами урысча говорить.»

Медаль тапшырырга килгән капитан Ярмухаметов шушы рәвештә пәйда була.

«—Сезгә короче, Рәсәй Президентыннан Жуков медале да плюс Ленинградский медаль тапшырырга килгән...

—Кхе-кхе... кхе-кхе...—Мотаһар гүя бу медальне күтәп илле дүрт ел көлмәгәнен көлә, чынаяктагы тун сөзмә кебек җепши, эреп таркала иде...»

«—Сез—защитник Отечества! Гафу итягез!..

—Әйе, әйе, мин шундый ул,—дип урынында сиртмәләнде Мотаһар.—Мин шатлыктан... Җылы сүздән... Тыела алмыйм!

... —Капитан дипломатыннан әүвәле ике кечкенә кап алып, аларны саксыз гына өстәлгә ташлады. Аннан, астарак бутанып, шешә чыгарды:

—Меня бу аракы Башкомандующий Ельциннан,—капитан шап итеп, шешәне өстәлгә утыртты.—Ә сез, Сәкинә Шакировна, стакан-фаляннар, короче! Калай кружка еще да яхшырак булгян.»

Менә шушындый бүләкләнүләр, медаль тагулар һәр очракта да аракы белән янәшә йөреп татарның моңа хәтле мең елларга сузылган айныклыгын челпәрәмә китереп ташлады. Туган авылымның бүгенге рәисе сыер савучыларны лаякыл итеп сыйлаганнан соң ул мескенкәйләрнең үрмәләп өйләренә кайтып барулары—иң куркыныч саташу сыман күз алдыма кат-кат килә дә баса, килә дә баса.

Татар әдәбиятында «Татар вакыты»на тиң әсәрләр еш тумый. Аңа чын бәяне бирерлек әдәбият белгечләре дә, зәвыклы укучы да табылыр әле. Ә мин тагын болай уйланам: Әйтик, чираттагы Тукай бүләгеен бирү кампаниясендә Айдар Хәлимнең түшенә лауреатлык билгесе тагып куйсалар, бу эш аның әдиплек абруен күтәрерме, әллә киресенчә булырмы? Аны Тукай бүләген үзләренең югары постта утыруларыннан файдаланып алучылар белән тигезләп, дәрәҗәсен генә төшерерме? Бу сорауны бүген, татар әдәбиятын җитәкләргә яна көчләр килгән хәлиткеч чорда, җавапсыз калдырмаска иде.

**Миргазиян ЮНЫС.**

*Səgit Rəmiefneņ tuuına 120 yıl*



## Səğit Rəmief

### Taņ waqıtı

*Məsəccəq nəser*

Taņ waqıtı... Tatar yoqlıy...
Min, yoqısız, uyanam,
Uyanam da, tile kebek,
Tik ber üzem uylanam.
Uylanam, uyıma batam,
Tormıymın üzem, yatam...
Yatmas idem də, cibərmi
Atadan qalğan xatam.
Xatam tirən, tamrı yıraq...
Botağı dənya qaplağan,
Qaplağan da tora-tora haman,
Yafrağın da qaqmağan.
Qaqmağan ber yafrağın da
Hiç tatar qurqu belən,
Tege, ləğnət, üsə, zuraya, əle haman da...
Qolaqtan qolaqqa tuqu belən.
Uqıylar qolaqqa, uqıylar tarixın,
Tikşerergə təben quşmıylar;
Atalar səyli babadan işetep,
Balalar şunı xuşlıylar.
Xuşlıylar çın küņel belən,
Işanmıylar hiç: «yuq, tügel» belən.
Başların watqan tatarlarnıņ
Tik şul ber Alla!
Betərlər mikən tatarlar, Alla, di-di?
Əllə belerlər mikən xataların ber alda?

Hay, yuq, xata bik zur,
Bəten dənyanı bar itkən,
Bardır, üze berder,
Əmma kənhenə[1] ireşməktən
Ğaqıllarnı tar itkən.
Əy sin, Ğabdulla!
Məselman bulsan, uylama yuqnı!
Yat, yoqla!
Yoqla rəxət, yoqla tınıç, saqlan,
Saqlan, utqa taba yəz totma!

Yuq, yuq!.. Min şaşam!
Yatalmıym urnımda, kükkə aşam!
Menə tan attı!.. Ənə qoyaş çıqtı!..
Ənə əllə kem mina qıçqıra:
— Əy sin, qayğırma, şat bul:
Ayağın bəydən ıçqına!
Menə sina yul, bu anağa uğıl bul, —
Di, mina ber yəş qız kürgəzə. —
Tuğ yanadan məğrifətle anadan!
Yuğisə sin, əy tatar,
Bel, betəsen!—di,—nadan.
Betmə nadan, tuğ yanadan
Məğrifətle anadan!
Bul keşe, üzen tınış, əmid itmə,
Xata ul əmid Alladan!

## «Sin»

Mine utqa atqan ul—sin,
Mine suğa salğan da—sin,
Utqa yansam, suğa batsam,
Tartıp alğan Allam da—sin!

## Sızla, künlem

Sızla, sızla, sızla, künlem!
Sızla ber tuqtamıyça,
Sızla aylar, sızla yıllar,
Sızla tən yoqlamıyça!

Sızla, sızlap, sin məxəbbət
Yalqının gəllər yasa,
Mənge xəsrət həm qyara tən
Yılların kənnər yasa!..

[1]kənhenə—xaqiqətenə, asılına.

Китап
КҮЗӘТҮ

# İGELEKLE XEZMƏT

Tatar ədəbiatı tarixın planlı rəweştə, yəğni tirənten ɵyrənə başlau, belgənebezçə, altmışınçı yıllardan ayıruça canlanıp kitte. Əlege awır, ifrat qatlaulı eşneꞑ üzəgendə tanılğan ğalim, professor Xatıyp ağa Ğosman buldı. Nəq menə anıꞑ citəkçelegendə həm anıꞑ «yul yarıp» yɵrüe nəticəsendə ruxi mədəniətebezdə tirən ez qaldırğan Qol Ğəli, Qotb, Xisam Kətib, Səyf Sarai, Məülə Qolıy, Utız İməni, Ğəbdelcabbar Qandalıy həm başqa küp qələm iələreneꞑ icatları ğilmi nigezdə tikşerelə başladı. Əytelgən şağirlərneꞑ icatların ɵyrənügə bağışlanğan məqələlər yazıldı, kandidatlıq həm doktorlıq dissertatsiələre yaqlandı. Alarnıꞑ əsərləre gəməldəge əlifbada nəşer itelep, uquçılarğa da ireşterelde.

Xəzer inde tatar ədəbiatınıꞑ urta ğasır çorındağı üseş-üzgəreş xərəkəten, tendensiələren bilgeli torğan, başqa ədiplərne də həm alarnıꞑ yadqərləren də ɵyrənep, xalıqqa qaytaru waqıtı citte. Dɵres, bu yünəleştə ğalimnərebez tarafınnan eşlər başqarıla. Ul xezmətlərne sanap tormastan, alarnıꞑ bersenə kiꞑrək tuqtalıp ütüne kirək sanıybız. Tatarstan Fənnər Akademiəse Ğ. İbrahimof isemendəge Tel, ədəbiat həm sənğət institutınıꞑ ɵlkən ğilmi xezmətkəre, filologiə fənnəre kandidatı Ramil İslamof qələme belən yazılğan «Altın Urda həm məmlüklər Misırı: yazma miras, mədəni bağlanışlar» (Qazan: Matbuğat yortı, 1998, 250 b.) digən monografiə ul.

Xezmət urta ğasır çorı dɵnya sivilizatsiəsendə bilgele ber urın alıp torğan Altın Urda həm məmlük-qıpçaq Misırı dəwlətendə barlıqqa kilgən tɵrle yazma istələklərne barlauğa, alarnıꞑ tyurkologiədə həm orientalistikada ɵyrənelü dərəcəsen açıqlauğa, şuşı ike məmləkət arasındağı mədəni bağlanışlarnı anıqlauğa bağışlanğan.

Monografiə tematik yaqtan ɵç bülekne təşkil itə. Şunısı əhəmiətle, Altın Urda həm məmlük-qıpçaq Misırınıꞑ yazma mədəni yadqərləre turındağı berençe həm ikençe büleklərdə əüwəl şul dəwlətlərneꞑ ictimağisəyəsi tormışlarına berniqədər analiz yasala. Ul təbəklərdəge çorına xas sənəğət, arxitektura üzençəleklərə, səüdə, meditsina, ğilmi dairə həm başqa məs'ələlər turında qızıqlı məğlümat kiterelə.

Altın Urda cirlegendə barlıqqa kilgən həm bezgə inde bilgele bulğan yazma əsərlər belən bergə əle az ɵyrənelgən həm fənni qullanışqa nıqlap kertelməgən «Məğıynel-mɵrid» («Mɵridkə yərdəmçe»), «Rəünəqel-İslam» («İslam çırağı») kebek əxlaq temasına bağışlanğan şiğri yadqərlər turında da şaqtıy beleşmə alabız.

Kitapnıꞑ ikençe bülege, tirən inanuıbızça, tatar uquçısı ɵçen ɵr-yaꞑa məğlümat bularaq qabul itelə. Çɵnki ul moꞑa qədər məmlük-qıpçaq Misırı turında üz telebezdə yazılğan xezmətlər arasında bay eçtəlekle həm küləmle bulu belən ayırılıp tora.

Əytelgən dəwləttə barlıqqa kilgən yazma istələklər bülektə ike tɵrkemgə, yəğni ğərəpçə həm tɵrki yadqərlərgə bülenep tikşerelə. Ğərəbi ruxani miras üz çiratında tağın ikegə— tarixi həm ədəbi əsərlərgə ayırıla.

Məmlük-qıpçaq Misırı cirlegendə barlıqqa kilgən ğərəp telendəge tarixi xezmətlərneꞑ küpçelege xəzerge tatar

uquçısına bətenləy diərlek tanış tügel. Alar bezne barınnan da elek üzlərenen kin masştablı həm ensiklopedik xarakterda buluları belən soqlandıra. Məsələn, ən-Nəwəyrinen utız tomlı «Nihayətel-arəb fi fənünel-adəb» («Adəb fənenə qarata teləknen çiklə-re»), əl-Diməşqinen yegerme tomnan ğıybarət «Tarixel-İslam» («İslam tarixı») yəki üz gemerendə altı yəzdən artıq kitap yazğan əs-Səyutıy, ğərəp tele grammatikasına citmeşləp, ə tərki tellərgə biş fənni xezmət bağışlağan Əbu Xəyən həm başqalar tirən ixtiram xislərе uyata.

Monografiədə tikşerenü ob'yek-tlarının berse bulğan əlege tarixi xezmətlər, avtor raslağança, Mısır tarixın ğına tügel, ə ğəmumtərki dənyanın ütkənen əyrənüdə də əhə-miətle çığanaq bulıp toralar.

Məmlük-qıpçaq çınbarlığının ğərəp ədəbiatında çağılışı turındağı ədəbi əsərlərgə iğtibar birelü—xezmət avtorının tağın ber unışlı yağı. Kitapta üzlərenen şiğri həm çəçmə əsərlərе, antologiələrе həm ensiklopedik xarakterdağı xezmətlərе belən tanılğan yegermeləp şağir, yazuçı turında məğ-lümat birelə. Alar arasında, məsələn, Məxəmmət pəyğəmbərnen kiemenə bağışlap yazılğan həm bəten məsel-man illərendə ataqlı bulğan «Qası-ydətel-bərdə» («Xəllə qasıydəse») avtorı əl-Busıyri (əlege qasıydə tatarlar arasında da məşhür bulğan, ul berniçə tapqır tərcemə itelgən, ana şərexlər yazılğan), küləgə təşerep uynatıla torğan qurçaq teatrı əçen əsərlər yazğan dramaturg həm şağir İbne Danial, məmlük-qıpçaq taifəsennən çıqqan ataqlı şəxeslər əz-Zahir Bəybars həm Zu Yəzan uğlı Səyf, Ğəli Zibəknen tormış yulları turındağı ğərəp xalıq romannarı, «1001 kiçə» əkiətlərenen məmlüklər cirlegendə barlıqqa kilgən əçençe redaksiəse həm başqalar bar.

İkençe büleknen zur ələşe tərki yazma istələklərgə bağışlanğan. Ul yazma istələklər üzlərenen eçtələklərе belən küptərle buluları, yəğni cəmğiət tormışının ayırım əlkələrenə qarağan-lıqları belən iğtibarğa layıq. Anda süzleklər həm grammatika kitapları, xərbi eşlərgə bağışlanğan traktatlar, atçılıqqa bağlı əsbaplar, yurispru-densiəgə, yəğni məselman xoquqına qağılışlı istələklər, ədəbi əsərlər bar.

Süzleklər, grammatika əsbapları, bilgele bulğança, cəmğiət tormışında tərle xalıqlarnın ber-berse belən aralaşu ixtıyacınnan barlıqqa kilələr. Əlege yadqərlərdən kitapta avtorı bilgele bulmağan «Kitabe məcmuğe tərcemani tərki wə ğacəmi wə maguli wə farsi» («Tərki-farsı həm mongol-farsı telləren anlatuçı cıyıntıq kitabı»), Əbu Xəyannın «Kitabel-idrək li-lisnel-ətrək» («Tərki tellərgə anlatmalar birü kitabı»), şulay uq avtorı əlegə açıqlanmağan «Ət-təxfətez-zəkiyə fil-ləğətet-tərkiyə» («Tərki telne əyrənüdə qimmətle bülək»), Cəmaleddin ət-Tərkinen «Kitabe bəlğatel-məştak fi ləğətet-tərk wəl-qıfcak», Əl-kava-ninel-kəlliyə li-zabtel-ləğatet-tərkiyə» («Tərki telne əyrənüdə tulı qullanma») (avtorı məğlüm tügel), «Əd-dərrətel-muzıya fil-ləğətet-tərkiyə»(«Tərki tel turında yaltırawıq encelər»), «Kitabe xilyətel-insan wə xəlbətel-lisan» («Keşelərnen bizəge, telnen şirbətlege») həm alarnın tyurkologiədə, orientalistikada əyrənelü məs'ələlərе tikşerelə. Bu unaydan xezmət avtorı tatar ğalimnərе, ayırım alğanda Ə. Nəcip, W. Xaqof, A. Nurie-va həm başqalarnın xezmətlərenə də citdi iğtibar birə.

Məmlüklər cirlegendə barlıqqa kilgən suğış hənərе buyınça qullanma əsbaplar «Kitab fi ğılmen-neşab» («Uqtan atu ğıleme turında kitap»), «Mənyətel-ğozat» («Din əçen kərə-şüçelərgə») dip atala. Alarnı əyrənü, avtor fikerençə, berençedən, ütkəndəge tarixnın qayber buşlıqların tulılandırırğa, ikençedən, tatar telenen terminnar əlkəsendəge citeşsezleklərеn betererge yərdəm itəçək.

Atçılıqqa bağlı xezmətlər dəwlət-təge xərbi kəçnen, nigezdə atlı ğəskərdən ğıybarət buluı belən anlatıla. Kitapta bez alarnın «Kitabe bəytaratel-wazıyx» («Xaywannar turında da açıq kitap») həm «Kitabe fi riyazatel-xəyl» dip atalğannarına küzətü yasala. Əlege yazma istələklər, kitapta belderelgənçə, at həm ana bəyle məs'ələlərgə, veterenariə buyınça qayber xəl iteləse problemalarğa açıqlıq kertergə, ə leksik

material tel tarixı, terminologiə əlkəsendə əstəmə məğlümat birəçək.

Xezməttən kürengənçə, məselman xoquqına qağılışlı istəleklərne «Kitab fil-fiqhe» («Xoquq turında kitab»), «Kitab fil-fiqhe bil-l lisant-tərki» («Tərki teldəge xoquq kitabı»), «Kitab moqaddimət Əbelləyes əs-Səmərqandi» («Əbelləyes əs-Səmərqandinen kitabına kereş») təşkil itə. Alarnın tekstları, kitapta yazılğança, tel tarixın tikşerüdə, dəwlətnen şul çordağı yurisprudensiəsenə qarağan qayber məs'ələlərne açıqlauda məhim çığanaqlardan sanala.

Məmlük-qıpçaq Misırı cirlegendə tərki teldə icat itelgən ədəbi əsərlər, əytergə kirək, mona qədər tatar filologiəsendə nıqlap əyrənelmədə. Monografiədə əlege məs'ələ şulay uq tieşle dərəcədə yaqtırtılğan. Anda «Siyare nəbəwi» («Pəyğəmbərlər tormışı»), «Fetuxateş-Şam» («Şamnı yaulap alu») digən zur küləmle kitaplar turında süz bara.

XVI yəz başında Firdəüsinen «Şahnamə» poeması tezmə ısul belən tərcemə itelə. Anı Şərif Amidi isemle şağir başqarğan. Əlege yadqər şul cirlektə barlıqqa kilgən ədəbiat qazanışlarının zurlarınnan berse sanala. Ul üz çorındağı tərki-farsı ədəbi bağlanışlar protsessı sıyfatında da, şiğriət üseşenen zakonçalıqlı küreneşe bularaq ta əhəmiatle.

Yənə şunısı iğtibarnı cəlep itə, qayber məmlük soltannarı üzlәre də ədəbi eşçənlek belən şөğelləngənnər. Xezməttə şundıylardan ike şəxes kürsətelə: Qaytbay həm Qansau əl-Ğauri. Alar üz çorında tanılğan şağırlər bulğannar. Sonğısı məwəşşah janrında da icat itərgə yaratqan. Anın şulay uq ğərəp telendə də əsərlərе bilgele.

Tərki ədiplərdən tağın Mostafa bine Yosıf isemle tərceməçe həm İbrahim Gəlşani digən şağır turında qızıqlı məğlümat kiterelə.

Kitapnın əçençe bülegendə Altın Urda belən məmlüklər Misırı arasında diplomatik mənəsəbətlər, alarnın ike dəwlətnen həm səyəsi, həm matdiruxani tormışlarına unay yoğıntı yasawı bilge-lənə. Ul, məsələn, arxitektura, ğөref-ğədət, kiem-salım, din, ğilem həm başqa əlkələrdə açıq çağılış tapqan, xətta, ike il arasında zur dərəcəle ğailə elemtələre urnaştıruğa kilep totaşqan, əytik, Bərkə xan üzenen qızın soltan Bəybarsqa kiəügə birə.

Quşımta itep tərki yazma istəleklərnen Parij, London, İstanbul, Leyden, Florensiə, Sankt-Peterburg, Düşənbe, Qazan kitapxanələre fondlarında saqlana torğan küçermələrennən ürnəklər urnaştırılğan. Alar uquçığa urta ğasırda tərki, tərki-tatar kalligrafiə sənğətenen dərəcəse turında fiker yərtergə yərdəm itə.

Monografiə bik küp çığanaqlarğa nigezlənep yazılğan. Bibliografiədən kürengənçə, faydalanılğan ədəbiat unike teldəge cide yəzdən artıq berəmlekne təşkil itə.

Xezmətnen tanılğan tyurkologlar A. A. Zayonçkovskiy həm Ə. N. Nəcipnen yaqtı istəleklərenə bağışlanuı avtornın üz eşenə bulğan mənəsəbəten açıq kürsətə.

Əytelgən unışlar belən bergə, avtorğa kiləçəktə başqarası eşlərendə iskə alu əçen ber telək tə belderəse kilə. Ayırım oçraqta qayber faktlarnı terkəü, bilgeləü belən genə çiklənep qalmasqa kirək ide, alarnı tağın da tirənəytü sorala.

Ğəmumən alğanda, bu xezmət belən tanışıp çıqqaç, min avtornın Altın Urda mədəniəte (məmlüklər Misırı turında əytep tə torası tügel!) həm anın bağlanışları kebek ütə çeterekle, «çualıp betkən» həm şul səbəple qayber ğalimnər «kerergə» şiklengən əlkəgə ışanıçlı rəweştə yul aluın, andağı monarçı əyrənelməgən cəühərlərne tabıp, alarnın qimməten başqalarğa da kürsətə-anlata aluın kürep, çın künel-dən şatlandım. Əlkən yəştəgelərgə almaşqa ənə şundıy eşçən, tyurkologiədə genə tügel, ə bөten orientalistika əlkəsendə də yuğalıp qalmıyça, üzenə dөres yünəleş tapqan əmetle yəş buınnın kilüe, çınnan da, quanıçlı küreneş.

**Ənwər ŞƏRİPOF,**
*filologiə fənnəre kandidatı.*

# МӨСЕЛМАН КАЛЕНДАРЕ

## (2000 милади елы, 1420—1421 һиҗри еллар)

| Көн | Ай | Һиҗри ел | Милади календарь | Дини көннәр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Рамазан | 1420 | 9 декабрь, 1999 ел | Рамазан аеның башы |
| 26—27 | Рамазан | 1420 | 3—4 гыйнвар, 2000 ел | Кадер кичәсе |
| 30 | Рамазан | 1420 | 7 гыйнвар, 2000 ел, җомга | Гарәфә |
| 1 | Шәүвәл | 1420 | 8 гыйнвар, 2000 ел | Рамазан гаете (1 көн) |
| 2 | Шәүвәл | 1420 | 9 гыйнвар, 2000 ел | Рамазан гаете (2 көн) |
| 3 | Шәүвәл | 1420 | 10 гыйнвар, 2000 ел | Рамазан гаете (3 көн) |
| 1 | Зөлкагъдә | 1420 | 7 февраль, 2000 ел | ай башы |
| 1 | Зөлхиҗҗә | 1420 | 7 март, 2000 ел | ай башы |
| 9 | Зөлхиҗҗә | 1420 | 15 март, 2000 ел | Гарәфә |
| 10 | Зөлхиҗҗә | 1420 | 16 март, 2000 ел | Корбан гаете (1 көн) |
| 11 | Зөлхиҗҗә | 1420 | 17 март, 2000 ел, җомга | Корбан гаете (2 көн) |
| 12 | Зөлхиҗҗә | 1420 | 18 март, 2000 ел | Корбан гаете (3 көн) |
| 1 | Мөхәррәм | 1421 | 6 апрель, 2000 ел | Һиҗри елының башы |
| 10 | Мөхәррәм | 1421 | 15 апрель, 2000 ел | Гашура көне |
| 1 | Сәфәр | 1421 | 5 май, 2000 ел, җомга | ай башы |
| 1 | Рабигыль—әүвәл | 1421 | 4 июнь, 2000 ел | ай башы |
| 11—12 | Рабигыль-әүвәл | 1421 | 14—15 июнь, 2000 ел | Мәүлид кичәсе |
| 1 | Рабиуль-ахыр | 1421 | 3 июль, 2000 ел | ай башы |
| 1 | Җөмәдел-әүвәл | 1421 | 1 август, 2000 ел | ай башы |
| 1 | Җөмәдел-ахыр | 1421 | 30 август, 2000 ел | ай башы |
| 30 | Җөмәдел- ахыр | 1 Рәҗәб | 28—29 август, 2000 ел, җомга | Рәгаиб кичәсе |
| 1 | Рәҗәб | 1421 | 29 сентябрь, 2000 ел, җомга | ай башы |
| 26—27 | Рәҗәб | 1421 | 24—25 октябрь, 2000 ел | Мигъраж кичәсе |
| 1 | Шәгъбан | 1421 | 28 октябрь, 2000 ел | ай башы |
| 14—15 | Шәгъбан | 1421 | 10—11 ноябрь, 2000 ел, җомга | Бәраәт кичәсе |
| 1 | Рамазан | 1421 | 27 ноябрь, 2000 ел | Рамазан аеның башы |
| 26—27 | Рамазан | 1421 | 22—23 декабрь, 2000 ел, җомга | Кадер кичәсе |
| 30 | Рамазан | 1421 | 26 декабрь, 2000 ел | Гарәфә |
| 1 | Шәүвәл | 1421 | 27 декабрь, 2000 ел | Рамазан гаете (1 көн) |
| 2 | Шәүвәл | 1421 | 28 декабрь, 2000 ел | Рамазан гаете (2 көн) |
| 3 | Шәүвәл | 1421 | 29 декабрь, 2000 ел, җомга | Рамазан гаете (3 көн) |

*Календарь Татарстан Диния нәзарәте тарафыннан төзелде*

## *«Казан утлары» архивыннан*

# «КЕМНӘР БАР ДА, КЕМНӘР ЮК!..»



*Язучылар җыелышыннан соң алынган фото. 1966 ел. Январь.*

*Беренче рәттә, сулдан уңга: Н. Дәүли (1910—89), Х. Хәйри (1910—94), Г. Кашшаф (1907—75), Ә. Ерикәй (1902—67), Г. Бәширов (1901—99), М. Әмир (1907—80), Н. Исәнбәт (1899—92), Х. Туфан (1900—81), Х. Госман (1908—92), А. Әхмәт (1905—76), С. Хәким (1911—86); икенче рәттә—В. Юдин (1911—95), А. Расих (1915—96), Г. Ахунов (1925), Х. Вахит (1918—78), Р. Төхфәтуллин (1924—94), Ш. Галиев (1928), З. Нури (1921—94), Г. Латыйп (1912—86), Г. Бакир (1986—82), Х. Ярми (1904—81), Ә. Исхак (1905—91), Ә. Юныс (1916—76), Б. Гыйззәт (1918—91); өченче рәттә—Г. Халит (1915—92), Р. Мостафин (1931), Н. Гайсин (1914—95), Ш. Шаһгали (1920—87), Ш. Зәйниморатов (1913—80), Г. Минский (1906—83), М. Фәйзуллина (1930), М. Ногман (1912—76), С. Сөләйманова (1926—80), Ә. Маликов (1921), И. Нуруллин (1923—95), Н. Юзиев (1931—96), Р. Бикмөхәммәтов (1929—95); дүртенче рәттә—Я. Халитов (1929), И. Салахов (1911—98), М. Хәмитов (1930—83), Э. Касыймов (1930—86), М. Шәрифуллин (1928—66), В. Ганиев (1934), З. Мәҗитов (1927), Н. Гыйззәтуллин (1928), М. Рафыйков (1925—86), И. Юзеев (1933), К. Фәсахов (1930), Г. Зәйнашева (1928), Н. Фәттах (1928).*

Бу фоторәсемнең төшерелүенә 34 ел. Юбилей түгел түгелен. Шулай да гыйбрәтле. 51 әдип бу рәсемдә. Һәркайсы әдәби хәрәкәттә актив катнашкан, рухи тарихыбызда эз калдырган кешеләр. Һәрберсе турында бит-бит мәгълүмат-мәкалә язарга мөмкин. Мәрхүмнәре турында да, исәннәре хакында да. Ә алар арасыннан бүген исән-саулары фәкать 11 генә кеше. Димәк, кырыгы гүр иясе. Шәхси архивымда сакланган бу рәсемгә карадым да, уйланып калдым. «Кемнәр бар да, кемнәр юк!..»

1966 елда алдырылган рәсем. Фотоның авторы—Таһир Ильясов. Заманында Бауман урамындагы Тукай клубында үткән әдәби кичә-җыелышлардан соң, күпмедер әдип язучыларны «карточкага» төшереп йөргән кеше. Үл үзе язучы да, әдәбиятчы да түгел, озак еллар Казан университетының эксперименталь-фонетика лабораториясенең

хезмәткәре булып эшләде. Хәтердә: өчаяклы фотоаппаратын зал уртасына урнаштырып, кирәк кешеләрне сәхнәгә тезеп, утыртып куя иде. Сәеррәк күренсә дә, хикмәтле кеше булган икән. Тарих өчен бу кичәнең, бу мизгелнең кирәк икәнен күпләргә караганда яхшырак аңлаган икән Таһир ага! 15 еллар элек ул да вафат булды. Авыр туфрагы җиңел булсын!

1965 еллар. Бу—безнең буынның—Р. Харис, Г. Рәхим, Р. Мингалимов, Р. Гаташ, Рәшит Әхмәтҗанов һәм тагын кайбер шагыйрьләрнең әдәбиятта буын ныгыткан чагы. Без Тукай клубындагы кичәләрнең даими катнашучылары булсак та, бу фоторәсемгә эләкмәгәнбез. Бәлки, «бу карт-коры» белән фоторәсемгә төшергә атлыгып та тормаганбыздыр, бәлки, яшьлекнең бүтән учакларына ашыкканбыздыр... Ә, бәлки әле (монысы дөресрәктер!) безнең бу төркемдә булуны теләмәгәннәрдер дә... Ул чакта, хәтта бик теләсәң дә, өлкәннәр төркеменә катнашып китеп булмый иде. Табигый тәртип бар иде, олыны—олы, кечене кече итү тәртибе бар иде... Хикмәт рәсемдә безнең буын вәкилләренең булу-булмавында түгел. Болай да, шул чор шәхесләренең тулы бер галереясы бирелә. Гомумән, бу фоторәсемгә тулаем комментарий бирү авыр. Шуңа күрә, рәсемдәге шәхесләрнең, Язучылар берлегенә, бигрәк тә, «Казан утлары» журналына катнашы булган кайберләре турында гына шәрехләп үтәсем килә. Әлбәттә, бу очракта Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, Х. Туфан, Ә. Еникәй, С. Хәким, М. Әмир, Г. Кашшаф, Х. Госман, А. Расих, Х. Вахит, Н. Дәүли, Г. Ахунов, З. Нури, Р. Мостафин, Ш. Галиев кебек мәгълүм шәхесләр турында тәфсилләп әйтү артык булыр. (Аларның күбесе ул заманда «Совет әдәбияты» дип чыккан журналыбызның мөхәррирләре, редколлегия әгъзалары!) Шуңа күрә, бу тарихи фотодагы, хәзерге әдәби даирәгә, бигрәк тә яшьрәк буынга аз билгеле булган кайбер әдипләр турында гына берничә сүз язып үтәсем килә.

Башлыйк өске рәттән. Сулдан уңда—беренче: Яхъя Халитов—Тәтеш районының Үтәмеш авылында туган. 50 еллардан башлап, төрле елларда, безнең журналда 20 еллап хезмәт иткән кеше. Нигездә, проза бүлегендә эшләде, телне яхшы белгән таләпчән редактор иде. Оста тәрҗемәче. Хәзер—пенсиядә. Шул ук рәттә, мәшһүр И. Салахов белән янәшә (рәсемдә өченче)—егет кыяфәтле Малик Хәмитов. Яшел Үзән районының Күгәй авылыннан. 25 ел буе «Казан утлары» («Совет әдәбияты» заманында да) журналында хезмәт иткән кеше. Очерклар һәм публицистика бүлегендә мөдир булды. 1983 елны вафат. Шул рәттән бишенче—Мәсгут Шәрифуллин. Башкортстанның Ярмәкәй районыннан. 1965—66 елларда СССР әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры иде. Аның белән рәттән (рәсемдә алтынчы)—Вил Ганиев. Норлат егете. 60 еллардан башлап гомере буе диярлек СССР Язучылар союзында тәрҗемә эшләре буенча җаваплы эштә булды. Әдәбият институтында да укытты. Г. Тукай, М. Гафури, Ә. Фәйзи, С. Хәким әсәрләрен русчага тәрҗемә итте. Хәзер М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтында өлкән сотрудник. 50 еллар ахырында ике елдан артык безнең журналда эшләгән. Фотода тугызынчы—Мәҗит Рафиков. Башкортстанның Күгәрчен районыннан. Үзенчә кабатланмас әдип. Рус һәм татар телләрендә иркен иҗат итте. Дөнья әдәбияты классикларыннан үз телләрендә сәгатьләр буе яттан шигырьләр укый ала иде. Фронтовик. Сугыштан инвалид булып кайта. 50 еллар ахырында журналыбызның тәнкыйть бүлегендә эшли. 61 яшендә, 1986 елны вафат. Шул ук рәттә—уңнан өченче—Касыйм Фәсәхов. Берничә шигырь китабы авторы. 70 елларда Татарстан китап нәшриятында баш редактор булып эшләде. Тарих фәннәре кандидаты. Казан финанс-экономика институты доценты. Өстән икенче рәткә күчик. Сулдан дүртенче—драматург Шамил Шаһгали. Фронтовик. Озак еллар Татарстанның Чирмешән районы үзәгендә тел һәм әдәбият укытты. 1987 елны вафат. Аның белән янәшә—драматург Зәйни Шаһиморат. Оренбург өлкәсенең Кондызлы Тамак авылыннан. Озак еллар халык иҗаты йорты директоры булып эшләде. Шул ук рәтнең иң ахырында—Н. Юзиев белән Б. Гыйззәт уртасында—Роберт Бикмөхәммәтов—әдәбият галиме, профессор, Мәскәү университетында СССР халыклары әдәбияты кафедрасы мөдире. Үз вакытында «Казан утлары»ында да хезмәтләрен бастырды. Ил күләмендә дәрәҗәле галим иде...

Аңлатманы дәвам итеп булыр иде дә, житеп торыр. Сүз озын—гомер кыска. Шулай да, алга таба да мондый характердагы хәтер-язмаларны журналыбыз рубрикасында урнаштырып барырбыз дип уйлыйм. Хәтер—киләчәк өчен кирәк.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

*январь, 2000*

## Укучы сүзе

* * *

Хөрмәтле иптәшләр!

Мин үзем Башкортостанда туып-үскән, заманында хәрби академия тәмамлаган, 32 ел армиядә хезмәт итеп, Санкт-Петербург шәһәрендә яшәп ятучы сугыш ветераны, пенсионермын. "Казан утлары" журналын 1952 елдан бирле өзлексез алдырам. Хатыным Тәнзилә Ленинградта туып-үскән, блокада газапларын кичергән кеше. Икебез дә журналның һәр санын көтеп алабыз, куана-куана укыйбыз.

2000 елда журналны тагын да яхшырту өчен үзебезнең берничә кинәш-теләгебезне дә язып җибәрәсе иттек әле менә.

Безнең татар халкы дөньяның бик күп илләрендә яши. Аларның һәммәсе өчен Казан—башкала, ә "Казан утлары"—милләт авазы. Без ул авазларда чит илләрдә яшәүче кардәшләребез тавышы да яңгыравын бик телир идек. Мәсәлән, С.-Петербургта гына да 350 меңләп татар яши. Татар иҗтимагый үзәге эшләп тора. Аның рәисе Мөхлисә Зарипова милләтпәрвәр җанлы, утә дә тырыш кеше. Бу үзәк һәм аның җитәкчесе хакында журнал битләрендә бөтен татарга мәгълүмат бирелсә бик яхшы үрнәк булыр иде бит.

Тагын... Без Державин, Карамзин, Тургенев, Аксаков, Кутузов, Тимирязев, Баскаков, Урусов, Юсупов, Тенишев, Куприн, Шереметьев кебек Русия дәүләте тарихында гаять мөһим роль уйнаган байтак шәхесләрнең татар тамырыннан икәнен яхшы беләбез. Алар хакында тәфсилләбрәк язып булмасмы икән!? Бүгенге көндә дә андый генераллар, артистлар, спортчылар җитәрлек ич. Әйтик, Ринат Дасаев, Вагиз Һидиятуллин, Галимә Шөгерова, Ирек Мөхәммәдов, Акчуриннар... Аларны санап бетерерлек түгел. Ул язмаларны горурланып укыр идек.

Редакция коллективына иң яхшы теләкләр! "Казан утлары" алдагы гасырда тагы да нурлырак балкысын, чәчәк атсын.

**Тәнзилә һәм Үзбәк ШӘРИПОВЛАР,**
*Санкт-Петербург.*

* * *

"Казан утлары"ның 1999 елгы 6 санында Мәгъсум Хуҗинның "Каңгый иләндә" һәм "Фидая" хикәяләрен укып зур ләззәт алдым. Әсәрләрнең һәр җөмләсе искиткеч тирән эчтәлекле, кешегә хөрмәт һәм җылылык белән сугарылган. Мондый әсәрләрне фәкать изге ниятле, саф күңелле, мәрхәмәтле һәм шәфкатьле кеше генә язарга мөмкин.

Ходай Тәгалә авторга исәнлек-саулык биреп, иҗат эшендә тагын да зуррак уңышлар яуларга насыйп әйләсен иде.

**Ибраһим МӨХЕТДИНОВ,**
*Казан дәүләт медицина университеты доценты.*

* * *

"Казан утлары"ның тышлыгын бизәгән сурәтләрдә инде ничәнче тапкыр тәрәзә... Тәрәзәгә караган татар хатыны, татар шагыйре... Психоанализда тәрәзә—көтү, киләчәккә ашкыну символы. Нечкә, сизгер рәссамнар халык күңелендәге халәтне, кәефне әнә шулай чагылдырганнар. Корылыктан хәлсезләнгән үләннәр яңгыр теләгән кебек, без СҮЗ көтәбез; зарлану-әрләү, үткәннәрне, гаепләләрне эзләүдән арып-җиләп, тамырларыбызга кан өстәрдәй, җаныбызга—азык, рухыбызга көч бирердәй СҮЗ—ИДЕЯ көтәбез. "Ачыгып", тәкатьсезләнеп газит-журналларны актарабыз. Яшәешебезгә мәгънә бирердәй, күтәрелеп, үсеп китәргә этәргеч бирердәй Мәгънәле Сүз килеп чыкмасмы?

Айдар Хәлимнең "Татар вакыты" (К.У. № 3-1999) үзенең пацифистик рухы, экспрессив хикәяләү манерасы, ассоциатив тирәнлеге һәм иң мөһиме—юл күрсәтүе белән күңелләргә уела, көткәннәребезне аклый. Гомум модага ияреп үткәнне тәнкыйтьләве яки "Дөньясы шулай иде, нишлисең..." дигәнрәк сыгымта ясап куюы

әлләни авыр түгел, ә минә ялгышмы ул—дөресме, нинди дә булса юл эзләргә тырышу, әлеге зарлану, төшенкелек халәтеннән чыгарга талпынып карарга тәкъдим итү—бу әле, ялгышмасам, татар прозасында беренче тапкыр. Шуның белән бергә, бу—көтелгән, көтеп алынган күренеш.

"Тарих безгә форсат бирә, бердәнбер хак юл—иман юлына басыйк, үз ВАКЫТЫБЫЗны табыйк: иманлы ВАКЫТЫБЫЗны, дәүләтле ВАКЫТЫБЫЗны, сәгать житте..." Шәхсән минем күңелдә менә шундый уйлар уятты бу әсәр. Тирән мәгънәле, символик эчтәлекле, көтелгән әсәр!

**Булат АХУНОВ,**
*Уфа.*

* * *

Факил Сафинның "Кече Укмаска сәяхәт" (К. У. № 11-1999) дигән мәкаләсен яратып, якын итеп укыдым, рәхмәт яусын үзегезгә. Кадыйр язмышы минем язмышка якын, уй-фикерләре уртак, ә аның аларны талантлы рәвештә шигырьгә салып бирү осталыгы—сокланырлык... Тик күңелгә "дегет тамчысы" булырдай бер сүзе борчу салды. Менә "Дога" исемле шигырь:

Үзебезгә хужа була алмадык—
без янадан синен ***колың*** булыйк.
Алла сүзе керсен адәмнәргә—
без янадан синен ***улың*** булыйк.

Соңгы юлдагы фикергә христианнар гына ышана. Алланың *колы* булган кеше аның *улы* була алмый. Мөселман Хак Тәгаләнең берлегенә, мәңгелегенә инана. Җанәбел Хакның гаиләсе дә, балалары да юк, булмаган икәнлеген шагыйрь үзе дә белгәндер дип уйлыйм. Димәк, ялгыш киткән. Бу ялгыш кадерле шагыйрьгә гөнаһылар өстәү була торгандыр. Әгәр мәкалә авторы, Кадыйрның якын туганнары белән уйлашып, киләсе басмаларда бу ялгышны төзәтә алса, шагыйрьнең җаны бик рәхмәтле булыр кебек.

**Мәхмүт САБИРОВ,**
*Уфа.*

* * *

Флүс Латыйфиның "Ишелеп төшкән бәхет" романы (К. У. №№ 5,6-1999) йә сәхнә, йә экран сорый торган әсәр. Авыл сәрхүшләре турында дилогия күрсәтеп сару кайнатканчы, бу роман инде әзер диярлек кино материалы! Автор аны күреп, уйнап карагандай итеп язган. Бәлки, үзеннән-үзе шулай килеп чыккандыр. Барысы да кинодагыча кызыклы башлана. Сириннең студентлар ашханәсендә Асия артыннан йөгерүе, биюче Хәдичә апа тарихы, аның сабаклары, студентлар тормышы, аннан соң контраст—армия хезмәте... Тасвирланган чор—безнең студентлык еллары, таныш, сагынулы, җилкенүле яшьлек еллары. Еш кына хәтта романда сурәтләнгән кешеләрне дә беләм кебек, алар күптәнге танышларым кебек тоела башлый. Кайчандыр бер сукмакта йөрелгән бит!

Әсәр тукымасына шигырьләрнең күбрәк русчадан алынуы гына бик аңлашылып җитмәде. Безнең үзебездә дә нечкә лириклар аз түгел. Сөйләм телендә артык әдәби сүзләр күбрәк: кыйтга һ. б. Алар гади телдә сирәк кулланыла ич.

Нәрсә белән һич килешә алмыйм, анысы—романның исеме. *"Ишелеп төшкән бәхет"* телебездә *фәкать уңай төсмергә* ия. Бу *бәхет* сүзенең көчле булуы белән аңлатыламы, белмим. Ләкин "ишелеп төшкән бәхет"—"күп итеп, ишелеп бәхет килә" мәгънәсендә яңгырый. Әллә мин генә шулай аңлыйммы, әллә безнең телне аңлавыбыз үзгәрдеме?!

Ф. Латыйфи үтә катлаулы, фаҗигале теманы күтәрә һәм чынбарлыкны агартмыйча, кызартмыйча язган. Бусы—үзе зур батырлык! Авторга теманы тагын дәвам иттерүен теләр идем. Кирәк, кирәк—бүгенге кеше турында порно-мафия күзлегеннән генә түгел, роман күзлегеннән язылган яңа әсәрләр! Уңышлар телим!

**Зәрия ХӘБИПОВА,**
*Әлмәт.*

*Безнең календарь*

# КҮҢЕЛЕ ЯКТЫ ИДЕ...

ХӘСӘН ХӘЙРИНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ



Күренекле әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Хәсән Хәйри 1910 елның февралендә хәзерге Казакъстанның Уральск өлкәсендәге Чапай поселогында туа. Сигез-тугыз яшьтә ул әти-әнисез кала, 1925 елның көзенә кадәр Уральскидагы балалар йортында тәрбияләнә, шунда башлангыч белем ала. Аннары рабфакта укый, бераздан Җаекта казакъча чыга торган «Кызыл ту» («Кызыл байрак») газетасында эшли. Яшь Хәсән Кузнецк металлургия комбинаты төзелешендә катнаша, бу хакта «Кузнецк төзелеше кешеләре» дигән күмәк китапта аның да язмалары урын ала. Ул чорда аның көндәлек матбугатта дистәләрчә очерклары, хикәяләре, шигырьләре басыла. Бу әсәрләр 1934 елда аерым китап булып дөнья күрә.

1934 елда Хәсән Хәйри Казанга килеп, икееллык укытучылар институтына укырга керә, аны тәмамлагач башта «Уку ударнигы» исемле газетада, аннары «Совет мәктәбе» журналы редакциясендә эшли. Булачак галим шулай ук Татарстан дәүләт нәшриятында, Татарстан Язучылар берлегендә дә хезмәт итә. Шул елларда аның әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге башлана. Ул урта мәктәпләр өчен әдәбият буенча дәреслекләр яза, 1941 елда үзенең «Эзләнүләр» исемле әдәби тәнкыйть мәкаләләре тупланган беренче җыентыгын чыгара.

1942—1943 елларда ул Тел, әдәбият һәм тарих институтында, ә 1944 елның гыйнвареннан 1948 елга кадәр партиянең өлкә комитетында инструктор булып эшли, аннары янадан «Совет мәктәбе» журналына редактор вазифасына кайта.

Сугыштан соң Хәсән Хәйри иҗади эшчәнлеген аеруча активлаштыра, Һади Такташның тормышын һәм иҗат юлын өйрәнә, шул хакта монография бастыра. Башка әдипләрнең иҗаты да бу галимнең игътибарын еш тарта. Хәсән Хәйри шулай ук татар әдәбиятына багышлап Казанда һәм Мәскәүдә басылган күпсанлы күмәк хезмәтләрдә дә катнаша, энциклопедик җыентыклар өчен аерым мәкаләләр яза. Аның «Иҗат чишмәләре» (1975), «Язучы һәм тормыш» (1979), «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә басылган «Һади Такташ» (1984) һ. б. китаплары бар.

Галим һәм тәнкыйтьче бик күп әдипләр хәтерендә якты күңелле, гаять кешелекле, ярдәмчел шәхес буларак саклана.

# ЯШЕЛ КИЛЕШ ЯФРАК КОЕЛДЫ...

Әгәр исән булса, аңа 60 яшь тулган булыр иде.
Безнең тәүге китапчыкларыбыз 1967 елда «Беренче карлыгачлар» сериясендә бергә дөнья күргән иде. Бер кассетада—ундүрт яшь автор. Бер оядагы карлыгач балалары кебек бер-берсенә күләме ягыннан бик тә охшаган, фәкать төсләре белән генә аерылып торган китапчыклар иде алар. Тәүфикъ Камалиевның шигъри җыентыгы «Ромашкалар эзлим» дип атала. Китапка кыска гына кереш сүзендә үзенең Буа районы Ташкичү авылында туган булуы, җиденче классны Казанда тәмамлау белән һөнәр училищесында укып, бик яшьли заводта, эшчеләр арасында кайнап яшәве, кичке мәктәптә укып, өлгергәнлек аттестаты алганнан соң, Казан университетында гыйлем эстәве турында яза. «Шигырьләрем кирәгеннән артык озын булсалар да, үтелгән юллар бик кыска әле... Билгеле, язылачак шигырьләрнең кыскарак, боларыннан мәгънәлерәк, ә үteläсе юлларның чиксез озын булуын телим»,—ди.

Әйе, озын булмаган гомер юлында Тәүфикъ, журналист буларак, шактый катлаулы вә катмарлы юлларны узарга өлгерде, төп эшеннән бушаган аз гына араларда һәм йокысыз төннәрендә үзенең дөнья көтүдән алган тәэсирләрен, яшьлек хисләрен, сагыну-сагышларын, ил-көн язмышы өчен борчылуларын шигъри юлларга салды. Аның бер-бер артлы нәшер ителгән «Сабыр канатлары сынмый» (1968) дигән беренче мөстәкыйль китабын, «Адымнар» җыентыгындагы «Озата бармагыз» дип аталган шигырьләр бәйләмен (1969), «Сезгә генә сөйлим» (1970), «Хәләл көчем белән» (1972) һәм «Яшьлеккә кайту» (1978) исемле китапларын әдәби җәмәгатьчелек җылы кабул итте, шигърияттәге остазы Хәсән Туфан да үзенең яшьлеген хәтерләтеп, эшче сыйныф хисләрен җырлаучы бу егеткә өмет баглавын яшерми иде.

Тәүфикъ Камалиев классик традицияләргә таянган җылы күңелле лирик шагыйрь иде.

... Тарта, диләр,
тарта туган җир,
Тарту көче аның нидә соң?
Килә минем сезгә бирәм-бирәм
Ромашкалар өзеп бирәсем...—

дип, яшьлек ашкынулары белән ихлас хисләр дулкынында Шигърият мәйданына килеп кергән яшь шагыйрь китаптан-китапка осталык һәм фәлсәфи фикерләү ягыннан үсә барып, соңгы—«Яшьлеккә кайту» җыентыгында «ромашкалар эзләү» белән бергә, милләт язмышы турында җитди уйланулар югарылыгына күтәрелде. Һәм:

Мең өметем, мең каргышым...
Ялгызым йөзсәм-йөзим,
Төпсез ялган дингезендә
Хаклык утравын эзлим,—

дип әйтә алды.

Әйе, җир куеныннан, тирәннән бәреп чыккан һәм үз юлындагы каршылыкларны җиңә-җиңә алга таба юл сапкан чишмә шикелле, чын талант иясе дә үз юлын тапмыйча калмый ул!

Әле аның шигъри хисләр чишмәсенең ачылып кына киткән чагы иде, ни аяныч, ул үзенең хыялы рәшәләренә кадәр барып җитә алмый калды.

Рәшәләрем алга дәшәләр дә,
Дәшәләр дә... Шушы хәлемдә
Ерагая барам рәшәләрдән,
Якыная барам кабергә...—

дип язып калдырды ул хастаханәдә, мәрхәмәтсез үлемнең салкын сулышын тойган минутларында.

Мин еш кына кулыма «Беренче карлыгачлар» җыентыкларын алып, 60 нчы елларда Шигърият мәйданына бергә-бергә килеп кергән каләмдәшләрем турында уйланам. Инде шушы сериалда китаплары чыккан ундүрт авторның бишесе дөньяда юклар икән ләбаса. Егор Уткин, Дифгат Сирай, Хәниф Хөснуллин, Фаил Шәфигуллин, Тәүфикъ Камалиев. Янә дә, бу сериалда шигырьләре булмаган, ләкин фани дөньядан иртәрәк киткән талантлы шагыйрьләребез вә язучыларыбыз исемлеген дәвам итсәк: Сажидә Сөләйманова, Рәшит Әхмәтҗанов, Кадыйр Сибгатуллин, Ринат Рәхимов, Зиннур Насыйбуллин, Фәннур Сафин, Газиз Кашапов, Ямаш Игәнәй, Роберт Рәкыйпов, Эдуард Мостафин... Үзләренә Ходай



*Рәсемдә: Абдулла Сәләхетдинов, Фәридә Кудашева, Тәүфикъ Камалиев, Бәхти Гайсин*

салган талант нурларын туган халкыбызга тулысынча бирә алмыйча якты дөньядан китеп барган бу шагыйрьләрнең язмышы бик тә уйландырырлык, бик тә гыйбрәт алырлык... Аларның фаҗигале үлемнәре узган сугышларда канатлары каерылган татар шагыйрьләре язмышының дәвамы шикелле тоела миңа... Хәтердә Кадыйр Сибгатуллинның «Яшел килеш яфрак коела...» дигән шигъри юллары янара һәм:

—Үзенә «ромашкалар бүләк итәсе», «төпсез ялган дингезендә хаклык утравын эзләргә» булышасы улларыңны, кызларыңны сакла, халкым!—диясе килә.

**Шамил МАННАПОВ**
*Ноябрь, 1999*

*Котлыйбыз!*

## Мәхмүт Газизовка 60 яшь



Мәхмүт Газизов 1940 елның 8 февралендә Татарстанның Шөгер (хәзерге Лениногорск) районы Туктар Урдаласы авылында колхозчы гаиләсендә туган. 1958 елда Иске Шөгер урта мәктәбен тәмамлагач, Казанга килеп, педагогия институтының тарих-филология факультетында укый. 1963-1969 елларда Лениногорск районы мәктәпләрендә тарих, җәмгыять белеме фәннәре укыта, мәктәптә укыту бүлеге мөдире, директор булып эшли. Мәхмүт Газизовның әдәби иҗат эшчәнлеге урта мәктәптә һәм институтта укыганда башлана, шул елларда район һәм өлкә газеталарында беренче шигырьләре басыла. 1969 елда яшь шагыйрьнең «Миләш сиртмә» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрә.

Татарстанда КамАЗ төзелеше башлангач, Мәхмүт Газизов, беренчеләрдән булып, Чаллыга—Бөтенсоюз удар комсомол төзелешенә күчеп килә (1970 ел) һәм хәзерге көнгә кадәр шунда яшәп иҗат итә. Ул Чаллыда иң «кайнар» урыннарда эшли: тулай торакта тәрбияче, төзелештә геодезист, мастер, тимерчелек заводында эшче—язучы әнә шулай тормышны өйрәнә, булачак әсәрләре өчен материал җыя, көндәлек матбугатта үзенең шигырьләрен, хикәя, очерк, репортажларын бастыра. Хезмәт, төзелеш темасы шагыйрьнең «Тәгәри китте йомгагым...» (1976) җыентыгында да үзәк урынны алып тора.

Мәхмүт Газизов балалар өчен дә яза («Бер, ике, өч» исемле шигырьләр җыентыгы, 1972 ел). Соңгы елларда шагыйрьнең «Мәйдан» (1990), балалар өчен «Гаҗәеп көн» (1995) исемле китаплары, «Аргамак» журналында «Журнал эчендә китап» сериясендә «Серле иҗек», «Көмеш кыңгырау», «Кыска буйлы» әкияти шигырьләре дөнья күрде. Шагыйрьнең аерым әсәрләре «Новый мир», «Волга» журналларында һәм коллектив җыентыкларда русчага тәрҗемәдә дә басылып чыкты.

Мәхмүт Газизов 1978 елдан Язучылар союзы әгъзасы.

*«Казан утлары» журналы редакциясе юбилярны кайнар котлый, иҗат эшендә уңышлар, бәхет һәм сәламәтлек тели.*

*Имеш-мимеш түгел*

## «Мин хәзер керермен—көтегез»

1937 ел. Шәхес культының чәчәк аткан мәле. Язучылар да бер бер артлы югала торалар. Кави Нәҗми 2 июньдә, Галимҗан Ибраһимов 29 августта. Галимҗан Мөхәммәтшин белән Ибраһим Сәлахов октябрь аенда кулга алыналар, декабрьдә Мирсәй Әмиргә «чират» җитә.

Кави Нәҗмидән соң, Татарстан язучылар берлегенен җитәкчесе итеп Ләбиб Гыйльмине билгелиләр. Ул искиткеч активлык күрсәтә, «халык дошманнарын» фаш итү җыелышлары үткәрә, ялкынлы нотыклар сөйли, язучыларны үз араларындагы «дошманнарны» күрмәүләре, гамьсез булулары өчен гаепли. Шундый җыелышларнын берсендә швейцар кереп Ләбибне чакыра. Ләбиб Гыйльми язучыларга:

—Иптәшләр, мин тиз генә чыгып керәм, сез фикер алыша торыгыз,—дип чыгып китә.

Язучылар сүзсез генә, шомлы уйларга чумып, Ләбибне көтәләр. Шактый озак утырганнан соң, иң өлкән язучы Шәриф Камал:

—Озаклады... Берәр хәл булмадымы икән? Берегез чыгып белешегез әле,—дигәч, кемдер швейцар янына барып килә. Хәрби киемле ике кеше Ләбиб Гыйльмине «кара машина»га утыртып алып киткәннәр икән.

Бу хәл 1937 елның 21 сентябрендә була.

## Батыйның икенче мәртәбә Мәскәүне алуы

1957 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрелде. Татарстан делегациясен Татарстан Югары Советы рәисе Батыев җитәкли.

Шул уңай белән рухланган башкаладагы татар җәмәгатьчелеге һәм зыялылары Мәскәүдә татар газеты чыгаруны тергезү (утызынчы елларда андый газет бар иде), әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал нәшер итү, сугышка кадәр татар мәдәнияте үзәге урнашкан Асадуллаев йортын кайтарып бирүне сорап Үзәк Комитететка мөрәҗәгать итәләр. Мондый үтенечләр Мәскәүдә яшәүче татарлардан да алына. Аларны укыгач Мәскәү түрәләреннән кемдер: «Батый ханның икенче мәртәбә Мәскәүне алуына юл куймаска кирәк»—дип әйткән, имеш.

## Америкалы Гөлнар белән очрашу

1972 елның җәендә Казанда АКШтан килеп халык хуҗалыгы күргәзмәсе оештырдылар. Бу вакытта мин дә Казанга килгән идем.

Күргәзмәгә кергәч, экспонатларны карый-карый, кеше күбрәк җыйналган урынга килеп җиттем. АКШтан килгән гидлар саф татар телендә сөйләшә.

Мин Гөлнар исемле кызны сокланып тынлыйм. Ерак Америкада яшәүләренә карамастан, ана телен, милли мәдәниятне, гореф-гадәтләрне онытмыйча яшәүләре шатландыра.

Казанлылардан берничә кеше Гөлнарны кунакка чакырды. «Ата-баба җиренә кайткач, милли ашларыбыз белән сыйланмыйча китү гөнаһ булыр,—диделәр. Гөлнар: «Без «Волга» кунакханәсендә торабыз. Якшәмбе көнне ял итәбез, шул көнне килсәгез, барырга мөмкин,—диде.

Бер шук казанлы җиңел машина сорап АКШ президентына хат язган һәм аны яшерен генә гидларга тапшырган. Шунысы кызык, Америка президенты: «Совет хөкүмәте рөхсәт итсә, машинаны җибәрербез»,—дип җавап биргән, имеш. Шуннан соң бу бәндәне тиешле органнарга чакырып, «акыл» өйрәткәннәр, дип сөйләделәр.

**Шамил ӘХМӘТОВ,**

*Башкортостан.*

*Үткен мәсьәлә*

# БЕР АДЫМ АЛГА... НИЧӘ АДЫМ АРТКА?

Моннан биш ел элек (1995 ел, 12 сан), ул вакыттагы редакция хезмәткәре, язучы Тәүфикъ Әйдинең «Инкыйраз көзгесе» исемле мәкаләсе басылган иде. Автор анда милли матбугатның Татарстанда һәм чит төбәкләрдә таралышына җентекле анализ ясап, нәтиҗәнең чаң сугарлык дәрәҗәдә хәвефле булуын искәрткән иде. Дөрестән дә, соңгы дәвердә, республикабызда татар дөньясы шактый җанлану кичергән чорда, без үзебезчә эйфорик сөенеп, шатланып йөргән вакытта милли басмаларга язылу коточкыч дәрәҗәдә түбән тәгәрәгән икән ләбаса! Моны безнең журнал мисалында да ачык күреп була: 1989 елда «Казан утлары»н Татарстанда 36582 кеше алдырса, алты елдан соң, 1995 тә нибары 6978 әбүнәчебез калган!

Социологик тикшерү-анализны дәвам итеп, соңгы биш елны да кертеп, 10-11 ел эчендәге үзгәрешләргә күзәтү ясап карарга булдык. Баксаң, нәтиҗә, сөенечләргә караганда көенечлерәк икән. Халкыбызның рухи көзгесе, әдәби энциклопедиясе саналган «Казан утлары» журналын бүген Татарстанда фәкать 6521 кеше алдыра. Дөрес, алдагы яртыеллык белән чагыштырганда 11% үсеш бар-барын. Әмма... нәтиҗәләр сискәндерерлек! Республикабыздагы мең татарга уртача нибары 3.6 «Казан утлары» туры килә. Ягъни, мең татарның өчесе яки дүртесе генә безнең журналны укый. Калганнары әдәбиятыбызга битараф булып чыга.

Ә хәзер кайбер районнарда мең татар кешесенә ничә журнал туры килүен карап үтик. Югарырак күрсәткечле дип саналган районнар түбәндәгеләр: Балык Бистәсе, Актаныш, Балтач, Мөслим, Теләче. Боларда уртача мең татарга 8-10 журнал туры килә. Әйтик, 300-400 хуҗалыклы зур гына авылда журналны 8-10 кеше укый дигән сүз бу. Ә башка районнарда? Кайбычта бу сан нибары 1.6 ны тәшкил итә, Югары Осланда—2.2. Татарлар саны гаять зур булган шәһәрләрдә исә хәлләр бөтенләй начар. Әйтик, Яшел Үзәндә (Зеленодол) мең татар кешесенә нибары 1 журнал туры килә. Белем йортлары белән республикага гына түгел, бөтен Рәсәйгә мәгълүм Алабугада—1.3, Чаллыда да 1.3...

Инде чит төбәкләргә күз салыйк. 1995 елда Рәсәйнең республика-өлкәләренә 4548 журнал чыгарылган булса, бүген ул сан 1787 не генә тәшкил итә. Татарстаннан кала татарлар иң күп яши торган Башкортстанда журналны 1191 кеше алдыра. 160 меңгә якын татар яшәгән Мәскәү каласында «Казан утлары»н... 5 кеше укый. Мең татарга 0.03 журнал туры килә, димәк. 44 мең татар яшәгән Санкт-Петербургта—2, Астрахань өлкәсендә—5, Пензада—4...

Журналыбызның таралышына күзәтү ясау безне җитди уйланырга мәҗбүр итте. Якынлашып килә торган рухи һәлакәткә күз йому мөмкин түгел. Түбәндәге саннар безне генә түгел, республика, шәһәр һәм район җитәкчеләрен, мәгариф, мәдәният бүлеге башлыкларын, гомумән, үзен милләт баласы дип санаган һәр кешене дә борчылырга һәм шушы афәтне булдырмау юлында нәтиҗәле чаралар күрергә мәҗбүр итсен иде.

## «Казан утлары»ның Татарстанда таралышы

| Казанда һәм районнарда | татарлар саны * | 1989 | 1995 | 2000 | мең татарга 1989 | 1995 | 2000 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Авнакай | 22475 | 1706 | 266 | 205 | 34.4 | 5.3 | 3.8 |
| Аксубай | 12412 | 331 | 62 | 64 | 22.8 | 5.2 | 5.2 |
| Актаныш | 31440 | 1207 | 214 | 267 | 36.0 | 6.9 | 8.5 |
| Алабуга | 26056 | 224 | 50 | 35 | 13.8 | 2.2 | 1.3 |
| Алексеев | 6806 | 182 | 32 | 21 | 26.4 | 4.6 | 3.0 |
| Апас | 18037 | 1047 | 156 | 126 | 30.4 | 8.7 | 7.0 |
| Кайбыч | 12877 | | 43 | 20 | | 3.3 | 1.6 |
| Арча | 44277 | 2015 | 224 | 263 | 34.4 | 5.1 | 6.0 |
| Әтнә | 13630 | | 48 | 65 | | 3.7 | 4.7 |
| Әгерҗе | 23404 | 728 | 136 | 119 | 30.0 | 5.9 | 5.0 |
| Әлки | 14279 | 540 | 87 | 57 | 35.3 | 6.2 | 4.0 |
| Әлмәт | 92540 | 1552 | 270 | 299 | 18.5 | 3.0 | 3.2 |
| Балтач | 24363 | 1318 | 183 | 202 | 56.3 | 7.6 | 8.3 |
| Балык Бистәсе | 24231 | 651 | 124 | 231 | 25.8 | 5.2 | 9.5 |
| Баулы | 22619 | 693 | 69 | 44 | 18.0 | 3.0 | 1.9 |
| Биектау | 29389 | 622 | 85 | 72 | 23.6 | 2.9 | 2.5 |
| Буа | 28931 | 868 | 127 | 94 | 27.0 | 4.4 | 3.2 |
| Вәгелмә | 33314 | 410 | 85 | 46 | 12.3 | 2.4 | 1.4 |
| Зеленодол | 55873 | 670 | 105 | 56 | 13.0 | 1.9 | 1.0 |
| Зәй | 32383 | 622 | 137 | 107 | 20.7 | 4.6 | 3.3 |
| Кама Тамагы | 9128 | 380 | 114 | 68 | 38.8 | 12.7 | 7.4 |
| Кукмара | 38110 | 1331 | 217 | 257 | 35.0 | 5.7 | 6.7 |
| Лаеш | 13107 | 281 | 33 | 51 | 23.4 | 2.5 | 3.9 |
| Лениногорск | 43546 | 716 | 110 | 91 | 18.1 | 2.7 | 2.1 |
| Мамадыш | 36493 | 1168 | 210 | 272 | 31.7 | 5.7 | 7.5 |
| Менделеев | 14714 | 188 | 18 | 17 | 15.9 | 1.3 | 1.2 |
| Минзәлә | 18310 | 554 | 107 | 102 | 24.7 | 5.6 | 5.6 |
| Мөслим | 20630 | 1147 | 151 | 173 | 54.4 | 7.2 | 8.4 |
| Норлат | 23921 | 928 | 125 | 59 | 37.7 | 5.2 | 2.5 |
| Питрәч | 15373 | 517 | 65 | 62 | 35.2 | 4.3 | 4.1 |
| Саба | 27180 | 1516 | 198 | 161 | 38.1 | 7.1 | 6.0 |
| Теләче | 11890 | | 71 | 98 | | 5.9 | 8.2 |
| Спасс | 7003 | 226 | 48 | 29 | 28.6 | 6.8 | 4.1 |
| Сарман | 29032 | 1198 | 179 | 147 | 39.1 | 6.0 | 5.1 |
| Тәтеш | 8621 | 216 | 31 | 24 | 23.7 | 3.4 | 2.8 |
| Чаллы | 214652 | 2411 | 254 | 295 | 16.9 | 1.2 | 1.3 |
| Түбән Кама | 113133 | 991 | 156 | 126 | 10.0 | 1.5 | 1.1 |
| Чирмешән | 11336 | 382 | 63 | 62 | 31.8 | 5.7 | 5.6 |
| Чистай | 32307 | 716 | 133 | 85 | 24.2 | 4.2 | 2.6 |
| Чүпрәле | 17507 | 326 | 54 | 59 | 16.5 | 3.0 | 3.3 |
| Югары Ослан | 4078 | 64 | 19 | 9 | 17.3 | 3.2 | 2.2 |
| Ютазы | 13910 | | | 82 | | | 5.9 |
| Яңа Чишмә | 6305 | 347 | 61 | 43 | 51.0 | 10.2 | 6.8 |
| Казан | 440235 | 4860 | 474 | 1756 | 11.7 | 1.1 | 1.6 |
| Барысы | ~ 1 900 000 | 36582 | 6978 | 6521 | 22.1 | 3.9 | 3.6 |

*1997елгы мәгълүматлар буенча

## *Иҗтимагый—мәдәни тормышыбыздан*

### БӨЕК ӘДИП ЮБИЛЕЕ

Татар җәмәгатьчелеге драматург, шагыйрь, галим Нәкый Исәнбәтнең тууына 100 ел тулуын киң билгеләп үтте. Халыкка титаник хезмәт күрсәткән әдип турында матбугатта бихисап мәкалә-хезмәтләр басылды, радио-телевидениедә күп санлы чыгышлар булды, театрларда аның әсәрләре буенча спектакльләр куелды, музей залларында махсус күргәзмәләр оештырылды. Журналыбызның өч санында аның татар халык мәкальләренә багышланган зур гыйльми хезмәте кабатлап басылды. Олуг юбилейның йомгаклау ноктасы булып, яна ел алдыннан Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында тантаналы кичә үтте.

### МАТБУГАТ ДУСТЫ

Президент Минтимер Шәймиевкә Россия Журналистлар берлеге һәм Халыкара матбугат клубы тарафыннан «Матбугат дусты» дигән мактаулы исем бирелде, Мәскәүдә диплом тапшырылды.

Бу бүләк Татарстанның демократиягә һәм сүз ирегенә ышанычлы юл тотуын һәм эштә ирекләребезнең төп гаранты республика Президенты булуын тагын бер кат раслый.

### КОМПОЗИТОРЛАР БӘЙРӘМЕ

23 декабрьдә киң җәмәгатьчелек катнашында Казан дәүләт консерваториясенең Зур концерт залында Татарстан Композиторлар берлеге оешуга 60 ел тулуга багышланган бәйрәм кичәсе үткәрелде. Әлеге мәртәбәле тантана Татарстан дәүләт симфоник оркестры башкаруында композитор Нәҗип Җиһановның «Сабантуй» исемле симфониясе белән ачылды.

Зур концерт программасы республикабызның танылган җырчылары, сәнгать осталары—Зилә Сөнгатуллина, Эмиль Җәлалетдинов, Клара Хәйретдинова, Разия Үзбәкова, Гөлнара Юзеева, Лариса Маслова, Шамил Монасыйпов, Рубин Абдуллин һ. б. чыгыш ясады.

Татарстан композиторларын вице-премьер Илгиз Хәйруллин, башкала мэры Камил Исхаков, Россия Композиторлар берлеге рәисе Владислав Казинин, «Музыкальная академия» журналының баш мөхәррире Юрий Корев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Галимҗан Гыйльманов, Рәссамнәр берлеге рәисе Абрек Абзгильдин, шәһәр һәм авыл районнарының хакимият башлыклары котлады һәм яңа иҗади уңышлар теләде.

Әйе, узган 60 ел эчендә Татарстан Композиторлар берлеге мәдәниятебез горурлыгына әверелгән Салих Сәйдәшев, Фәрит Яруллин, Нәҗип Җиһанов, Җәүдәт Фәйзи, Рөстәм Яхин, Александр Ключарев, Альберт Леман, Фасил Әхмәтов, Мирсәет Яруллин, Бату Мөлеков, Әнвәр Бакиров, Хөснул Вәлиуллин, Ринат Еникеев, Шамил Шәрифуллин, Рәшит Кәлимуллин һ. б. бик күп талантлы иҗатчыларны үстерде.

### ОЛПАТ РӘССАМНЫҢ ОЛЫ ГОМЕРЕ

СССРның халык рәссамы, СССРның Дәүләт, Россия Федерациясенең И. Репин исемендәге, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге премияләре лауреаты, рәсем сәнгате аксакалы Харис Габдрахман улы Якуповка 80 яшь тулды.

Юбилей уңаеннан оештырылачак рәсми тантаналар яз айларында узачак. Мартта Татарстан дәүләт сәнгать музеенда Харис Якуповның зур шәхси күргәзмәсен ачу планлаштырыла. Юбилярны тәбрикләү М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында үткәреләчәк.

### ОЛУГ ГАЛИМНЕ ХӨРМӘТЛӘҮ

17, 18 декабрьдә Татарстанның Сәүдә-сәнгать палатасында XX гасырда киң танылган татар дин әһеле, реформатор, сәяхәтче, мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Муса Бигиев үлеменең 50 елына багышланган Халыкара симпозиум узды.

Симпозиумда катнашучы Татарстан һәм Төркия галимнәре, дин һәм җәмәгать эшлеклеләре, аерым алганда, симпозиумның Башкарма комитеты рәисе Хамди Мерт, Татарстан Фәннәр Академиясе президенты М. Хәсәнов, Татарстан Диния нәзарәте мөфтие Госман хәзрәт Исхаков, Төркиянең Татарстан Республикасындагы консулы Әхмәт Рыза Демерәр, Муса Бигиевнең кызы Фатыйма Таһирҗанова, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы

дин эшләре Советы рәисе Р. Нәбиев һ. б. тәбрикләү сүзләрендә олы галимнең татар иҗтимагый фикеренә һәм Ислам диненең халык тормышындагы ролен үстерүгә керткән хезмәтләренә югары бәя бирделәр.

## МӘШҺҮР РӘССАМ КҮРГӘЗМӘСЕ

Башкалабызның сынлы сәнгать музеенда Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан халык рәссамы, Г.Тукай премиясе лауреаты Илдар Зариповның 60 еллык юбилеена багышланган ретроспектив күргәзмәсе ачылды. Илдар Зарипов—дөньякүләм билгеле рәссам. Аның байтак эшләре Европа илләре, бигрәк тә Германия музейлары экспозициясендә урын алган. Чираттагы бу күргәзмәдә тамашачылар игътибарына төрле вакытта—70-90 еллар дәверендә иҗат ителгән илле рәсем тәкъдим ителгән. Рәссамның даими эшли торган үз күргәзмә-галереясы булдыру турында Татарстан хөкүмәтенең махсус карары кабул ителде.

## МУЗЕЙЛАРЫБЫЗ—ИНТЕРНЕТТА

Казандагы А. М. Горький музеенда «Татарстан Республикасы Берләштерелгән дәүләт музее—Интернет челтәрендә» исемле проектны тәкъдим итү тантанасы булып узды.

Интернетка Дәүләт музее һәм аның җиде филиалы—А. М. Горький, Г. Тукай (Казан), Е. Баратынский, С. Сәйдәшев, Ш. Камал, М. Җәлил, К. Васильев (Васильево бистәсе) музейлары турындагы мәгълүматлар тупланган сайтлар кергән. Алар рус, татар телләрендә бирелеп, инглиз телендә дә кыскача аннотацияләре бар.

Бу Татарстан күләмендәге зур вакыйга. Моннан соң анда кергән музейларыбыз турындагы мәгълүматларны дөньяның теләсә кайсы почмагында ала алалар дигән сүз. Кыскасы, бу безнең башка ил-җирләрдә танылуыбыз юлында бик зур һәм бик әһәмиятле адым.

Бу проектның спонсорлары—«Хәтер» нәшрияты һәм Министрлар Кабинеты каршындагы «Хәтер китабы» редакциясе.

## ПОЭМАЛАР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Язучылар йортында соңгы елларда басылып чыккан поэмалар нигезендә зур сөйләшү үткәрелде. Анда шагыйрьләр, тәнкыйтьчеләр, шигърият сөючеләр катнашты. Сөйләшү барышында татар шигъриятендә поэма жанрының гаять зур тарихы күздән кичерелде, аны баетуга саллы өлеш керткән шагыйрьләр искә алынды, бүгенге поэмаларның уңай һәм кимчелекле яклары күрсәтеп үтелде. Фикер алышуда катнашучылар зур күләмле шигъри әсәрләрнең татар әдәбиятына зурлык-олпатлык китерүенә, аның киләчәген билгеләвенә ассызыклап әйттеләр, шулай ук поэмалар тарихын булдыру, гомумән, шигърият тәнкыйтен җанландыру җәһәтеннән үзләренең уй-фикерләрен белдерделәр.

Шигърият һәм Тәнкыйть остаханәләренең берләштерелгән утырышын аларның җитәкчеләре Зиннур Мансуров һәм Мансур Вәлиев алып барды.

## МИЛЛИ МОҢНАР

10 гыйнварда Мәскәүдә Мәскәү, Казан, Уфа шәһәрләренең сәнгать әһелләре һәм үзешчәннәре катнашында изге Рамазан ае тәмамлануга багышланган концерт зур уңыш белән үтте.

Концертта катнашучыларны һәм тамашачыларны Россиянең Мөфтиләр шурасы башлыгы мөфти шәех Равил Гайнетдин котлады. Бәйрәм кичәсендә тамашачылар танылган артистлар—Газинур Фарукшин, Лидия Әхмәтова, Наилә Фатыйхова, «Айкай» яшьләр коллективын алкышлар белән каршылады.

Танылган татар җырчысы, Россия һәм Халыкара конкурслар лауреаты Роза Хәбибуллина бәйрәм кичәсен оештыручыларның берсе булды.

Концертта Татарстан Республикасының Россиядәге Вәкаләтле вәкиле Нәзыйф Мириханов та катнашты.

## ЯҢА ЕЛНЫ ЯҢА ӘЛИФБА БЕЛӘН

Аксакаллар һәм Халык Мәжлесе карары белән, 2000 елның 1 гыйнварыннан Төркмәнстанда латин язуы һәм төркмән теле рәсми тәстә игълан ителде. Латин алфавитына кисәк кенә күчү унаеннан авырлыклар килеп чыгу ихтималын истә тотып, хөкүмәт күпмедер вакыт дәвамында газеталарның латин һәм кириллица алфавиты белән басылуына рөхсәт бирәчәк.

Төркмәнстанда латин алфавитына күчү 1997 елда башланган иде. Шул вакыттан бирле урта мәктәпләрдә уку-укыту латин язуы нигезендә алып барылды. Берничә ел дәвамында алфавитның төрле варианты сыналды. Иң соңгы вариантта 34 хәреф бар.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Казан дәүләт университеты доценты **Марсель Хәернас улы Бакиров** «Гомумтөрки поэзиянең генезисы һәм иң борынгы формалары» дигән темага филология фәннәре докторы дәрәҗәсен алу өчен диссертация яклады.

*Тышлыктагы сурәтләр*

# ШАГЫЙРЬ ҖАНЛЫ СӘНГАТЬКӘР

Олуг талант ияләренең һөнәре күптөрле булучан. Артык борынгыларга кагылмыйча, үзебезнең замандашлардан Р. Кент, К. Коровин, Н. Рерих, Б. Урманчеларның исемнәрен телгә алу да җитәдер: әлеге шәхесләр төп һөнәрләре итеп рәсем сәнгатен сайласалар да, ара-тирә кулларына каләм дә алганнар.

Гомерен сынлы сәнгатькә багышлаган Виктор Федоровның да таланты бер генә яклы түгел. Һәркемгә мәгълүм булганча, ул рәссам, иң әүвәл—рәссам. Аннары ул балалар язучысы: әкиятләр һәм хикәяләр иҗат итә.

Рәссамның шигырь язуы бер дә гаҗәп түгел, чөнки сынлы сәнгать ул шул ук поэзия, күңел түрендәге серләренне ачып салу, йөрәгендәге хәзинәне бүтәннәр белән уртаклашу.

Мөгаен, Федоровның шагыйрь булып китүенә язу сәләте генә түгел, бәлки әле үз эшенә артык таләпчән шәхеснең сәнгать әсәрләрендә әйтеп бетермәгән серләрен чишәргә омтылу да этәргәндер.

Виктор Федоровны халык сынлы сәнгать остасы, монументаль әсәрләр авторы буларак таный, һәм нәкъ әнә шул хезмәте өчен олылый, хөрмәт итә. Чөнки аның китапларына очраклы рәвештә генә юлыккан кешеләр дә, аның шигырьләрен яратучылар да, аның сабыйларга атап язган хикәя вә әкиятләрендәге самимилеккә соклanучылар да ул китапларны көн дә укымый. Хәтта әле рәссамның картиналарын да көн саен карамый. Ә менә зур күләмле, ягъни монументаль сәнгать өлкәсендәге әсәрләрен берәү дә читләтеп үтә алмый, чөнки алар Казан каласының һәр төбәгендә безне сәламли: «Татарстан» кунакханәсендә чәй белән сыйлый; аннан уңга борылсан—университетның яңа бинасындагы «Фән» дигән зур күләмле гамәли сәнгать композициясе белем йортына чакырып-дәшеп тора; юлыңны трамвай-троллейбус белән дәвам итсән—Кызыл Позиция урамы башындагы биш катлы йорт диварына ясалган тупчы Бөек Октябрь көннәрен хәтереңә төшерә. Тагын да арырак—Төзүчеләр мәдәният сарае фасадындагы гүзәллек синең игътибарыңны, һичшиксез, үзенә җәлеп итә; үзәктәге «Сәламәтлек комбинаты»нда гүя җәен-кышын яңгыр ява; «Яшьләр үзәге»нә сугылсаң—яшьлекнең чагылышына тап булырсың; тагын да арырак китеп, Химиклар мәдәният сараена, йөзү бассейнына барып җитсәң—су өстендәге һәм су астындагы мажараларны күреп, таң калырсың; әгәр берәр якка сәфәр чыгарга ниятләп, Казан вокзалына барсаң—анда сине Сөембикә ханбикә ачык күңел күрсәтеп каршылар һәм хәерле сәфәр теләп, озатып калыр; ә инде Петербургка ук барып җитсәң, метроның Маяковский тукталышын бизәү нияте белән шагыйрьгә багышлап ясалган эскиз-тасвирламага тап булырсың.

Нәкышь өлкәсендә Виктор шулай ук тырышлык күрсәтә, һич тә кимен куймый. Ул язган табигать күренешләре һәм чәчәкләр күпләрнең өйләрен бизи. Сәнгатькәр шулай ук портрет остасы буларак та дан тота. Ә инде аның тарихи темаларга язган сюжетлы картиналары аеруча популярлык казана. Аларда автор җөмһүриятебез тормышын гаять зур осталык белән гәүдәләндерә. «Емельян Пугачев һәм Бәхтияр Канкаев», «Комиссар Камил Якуб», «Габдулла Тукай «Сәйяр» труппасында» һ. б. әсәрләрендә авторның татар халкына хөрмәте-мәхәббәте аеруча нык чагыла. Тышлыкның беренче битендәге Г. Камал портреты моның ачык мисалы.


Талантының киң колачлы булуы белән дә, кешеләргә мәрхәмәтле-шәфкатьле мөгамәлә кылуы белән дә, хәтта әле туган көне белән дә сәер, бик тә сәер шәхес Виктор Федоров: гәрчә 60 яше тулса да, үзенең туган көнен... унбишенче мәртәбә генә бәйрәм итә, чөнки 1940 елның 29 февралендә Казан каласында дөньяга килгән ул. Саулык-сәламәтлек, иҗади озын гомер телик үзенә!

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ**

**Тышлыкның дүртенче битендә:** язучы Галимҗан Гыйльманов.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. **Гомер тәлгәшләре.**
Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 1999.-202 бит.
Тиражы—2000 данә.




Күренекле әдәбият галиме һәм язучы Тәлгат Галиуллинның иң әүвәл безнең журналда басылган «Тәүбә», «Элмәк» дип исемләнгән детектив романнары киң катлам укучыларда зур кызыксыну уяткан иде. Ә «Гомер тәлгәшләре» исә бөтенләй бүтән характердагы әсәрләрдән тора. Истәлекләр, хатирәләр... «Мин үзем яхшы белгән, башымнан узган хәлләр, дусларым, танышларым, үз дөньям турында сөйлим» ди язучы. Җыентык авторның 60 яше тулу уңае белән чыгарылган.

Китапта фотоиллюстрацияләр дә урын алган. Редакторы—Нияз Акмалов.

Зиннур МАНСУРОВ. **Күңел сәфәре.**—Казан: «Мәгариф» нәшрияты, 1999.—224 бит. Тиражы—1500 данә.

Танылган шагыйрь Зиннур Мансуровның бу китабына әдәби җәмәгатьчелектә уңай бәя алган сайланма шигырьләре һәм соңгы елларда иҗат ителгән яңа әсәрләре тупланган. Шигырьләр тематик яктан дүрт өлешкә бүленеп символик рәвештә «Беренче кәрван», «Икенче кәрван», «Өченче кәрван», «Дүртенче кәрван» дип исемләнгән. Китап заманча полиграфик ысулда басылып, рәссам Надир Әлмиев офорт-рәсемнәре белән бизәлгән.
Редакторы—Мансур Вәлиев.



Индекс 73210



Галимҗан Гыйльманов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)